ISSN 0206–

# КАЗАН УТЛАРЫ

6.1983



# КАЗАН УТЛАРЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС
ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-
ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР
СОЮЗЫ ОРГАНЫ

6

1983

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

## *Бу санда*


1 ИЮНЬ — БАЛАЛАРНЫ ХАЛЫКАРА ЯКЛАУ КӨНЕ

**Р. ИШМОРАТ.** Балалар хакына . . . . . . . 3

**М. ЮНЫС.** Юлда уйланулар . . . . . . . . 7
**Р. ФӘЙЗУЛЛИН.** Яңа шигырьләр . . . . . . 98
**М. ГАЛИЕВ.** Җирдәшләрем. Шигырьләр . . . . 104
**Р. НИЗАМИЕВ.** Галиянең бер көне. Хикәя . . . 109

БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

**Ә. ЕНИКИ** (113 бит), **С. ШАКИР** (146 бит), **М. МӘҺДИЕВ** (158)
**К. ЛАТЫЙПОВ.** Язлар килер. Шигырьләр . . . 114

ТАТАРСТАН АЭСе — ЖУРНАЛНЫҢ ӘДӘБИ ПОСТЫ

**Г. КАШАПОВ.** ...һәм башланды яңа көрәш . . 116

«АВЫЛ ОФЫКЛАРЫ» КОНКУРСЫ

**Җ. ДӘРЗАМАНОВ.** Шигер — гомер сукмагы. Очерк . . . . . . . . . . . 126

БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР

**Л. ИХСАНОВА.** Олы максатларны онытмыйк . . 131
**Ә. СӘХӘПОВ.** Күләгәләр яктыда югала . . . . 137

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Ф. ХАТИПОВ.** Күңел хәзинәләрен ачканда . . . 140

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

**Я. АБДУЛЛИН.** Борылыш . . . . . . . . . 147
**Е. КАЗАКОВ.** Йөзек кашына ни язылган! . . . 159
**Ф. ХӘКИМҖАНОВ.** «Йөзек кашына ни язылган!» дигән мәкаләгә карата . . . . . . . . . 162

БИБЛИОГРАФИЯ

**Г. ВУЛЬФСОН, С. МИХАЙЛОВА.** Революцион көрәш серләре . . . . . . . . . . . 163
**Р. ХАРИС.** Бакый Урманче альбомы . . . . . 164
**Н. ЮЗИЕВ.** Шигърияттә үз йөзе бар . . . . 167
**Ф. САФИН.** Тормыштан һәм тормышчан . . . . 169
**Ф. ГАЛИМУЛЛИН.** Изге ният . . . . . . . 171

ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

**М. ВӘЛИЕВ.** Искергән акчалар тарихы . . . . 173

НӘҖИП ДУМАВИНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

**Р. ГАНИЕВА.** Каршылыклы еллар авазы . . . . 174

СӘНГАТЬ

**Н. ХӘЙРУЛЛИНА.** Җирне җыр бизи . . . . . 184

Каләмдәшләребез — СССР Язучылар союзының яңа әгъзалары . . . . . . . . . . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор* **РЕНАТ ХАРИС**

**Редколлегия: ШАМИЛ БИКЧУРИН, МАНСУР ВӘЛИЕВ, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, РӘИС ДАУТОВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ,** *җаваплы секретарь* **РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН,** *баш редактор урынбасары* **РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ, ЗӘКИ НУРИ, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ**

Техник редактор *Р. Сөләйманова*
Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Г. Салихҗанова*

Адрес редакции: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары — 53-07-09, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза бүлеге — 53-07-61, поэзия бүлеге — 53-07-61, тәнкыйть бүлеге — 53-07-63, сәнгать бүлеге — 53-07-63, очерклар бүлеге — 53-07-61, хатлар бүлеге — 53-07-63, корректорлар — 53-07-65, техник редактор — 53-07-65, машинисткалар — 53-07-60.

Производствога бирелде 24.03.1983 ел. Басарга кул куелды 17.05.1983 ел. ПФ 07047. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65049. Заказ Я-129. Бәясе 90 тиен.

Типография издательства Татарского обкома КПСС.
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

© «Казан утлары», 1983 ел.

## Риза Ишморат

# БАЛАЛАР ХАКЫНА

Алар — изге җан, гөнаһсыз, эчкерсез... Бәхетебез, шатлыгыбыз — балалар, якты киләчәгебез дә, ышанычлы дәвамыбыз да — алар.

Халкыбыз, дәүләтебез, балалар сау-сәламәт, белемле, хезмәт сөючән, намуслы, гадел, кешелекле булып үссен өчен, бөтен чараларны күрә. Аларга барлык ишекләр ачык, юллар киң. Туган көненнән үк аларны тудыручы, тәрбияләүче аналарга да уңай шартлар булдырыла. Балаларга — ясле, бакча, мәктәп, шифаханә. Нинди һөнәр алырга теләсәләр, шуңа хәзерли торган урта һәм югары уку йортлары. Һич түләүсез.

Социалистик Ватаныбыз 65 елдан артык яшәү дәверендә бик авыр хәлләр кичерде. Гражданнар сугышы, дәһшәтле ачлык, төзү чоры белән бәйләнгән авырлыклар, аннан Бөек Ватан сугышы...

Рәхим, шәфкать белмәгән гитлерчы фашистларга каршы сугыш аяусыз булды. Әмма иң авыр шартларда да партия һәм дәүләтебез балаларыбызның тормышын, аларның сәламәтлеген саклау өчен мөмкин кадәр чаралар күрде.

Фронтта сугыш алып барган солдатны, бер яктан, дошман уты сагалап торса, икенче яктан, аның йөрәген тылда калган хатыннар, аналар, нәни балалар язмышы кисә иде.

— Балалар! — дип аһ орды совет солдаты.

Гитлерчы илбасарлар исә, үзләре басып алган җирдә: «Сез партизаннарга ярдәм итәсез»,— дип, картларны, хатын-кызларны, яшүсмер балаларны да аэаплап үтерделәр. Сугышның беренче елларыннан ук фронтка китеп, Берлинга кадәр барып җиткән сугышчы буларак, миңа дошманның меңтөрле мәкер, ерткычлыкларын ишетергә туры килде.

Менә җимерелеп беткән Тернополь шәһәре читендәге каберлек. Буе — егерме, аркылысы өч метрлар чамасы. Монда — болар барысы да яһүдләр, дип, куып китерелеп, шул каберлекләр янына бастырып, атып үтерелгән меңәрләгән кеше, Тернополь кешеләре. Бу каберләрне тикшергәндә, без, фронт газетасы журналистлары да катнашабыз һәм тетрәнеп күзәтәбез... Күбесе — әниләре белән бергә атып үтерелгән балалар. Унлап алар, йөзләп! Боларны күрү коточкыч иде. Сугышта кичергән дәһшәтле хәлләрнең күбесе онытылды. Онытыла бара. Ләкин бу аналар һәм балалар кабере онытылмый, юк, онытылмый. Гөнаһсыз нәни балалар!..

Фронт юлында аңын яртылаш югалткан бер ана очрады миңа. Гитлерчы фашистлар аның өендә тукталып, эчү мәҗлесе ясаганнар. Кәеф-сафа корганнар. Шау-шуга, тәмәке төтененә түзә алмыйча, яшь ярымлык нәни бала елый да елый икән.

— Акыртма балаңны, туктат! — дип кычкырган исерек фашист офицеры. Ана баланы никадәр юатса да, бала тынычланмаган. Ул арада офицер алпан-толпан атлап килә дә, ана кулыннан тартып алып, баланы стенага бәрә... Фашистлар кылган мондый вәхшилекләр күп очрады миңа сугыш юлында.

Сугыш аяуны белми! Шулай да совет солдаты, юлында нәни бала яки балалы ана очраса, үзе нинди генә авыр хәлдә булмасын, ярдәм күрсәтми узмады. Дош-

ман тырнагыннан азат ителгән совет балаларының хәлләрен җиңеләйтүне үзенең изге бурычы итеп санады. Балалар гөнаһсыз. Хәтта аларның аталары безгә каршы сугыш алып бара торган булсалар да, кешелеклелек рухында тәрбияләнгән совет сугышчысы балага ярдәм күрсәтергә ашыкты.

Минә Берлин шәһәрен алу өчен барган урам сугышларында, үземнең катнашымда булган бер эпизод. 1945 ел. 26 апрель. Берлин совет гаскәрләре тарафыннан камалган. Безнең командованиенең ультиматумына карамыйча, гитлерчы фашистлар әле һаман каршылык күрсәтә. Һәр урам, һәр өй, өйнең аерым катын яулап алу өчен каты сугышлар бара. Газетага хәбәрләр җыйнар өчен без, рус һәм татар редакциясеннән тугыз кеше, Берлинга килдек. Төрле частьләрдә йөрибез. Безнең төркемдә өч язучы-журналист: шагыйрь Илья Френкель, прозаик-очеркист Александр Шаров һәм мин. Автомашинабызны арттарак калдырдык та үзебез әкренләп алга, сугыш барган урамнарга якынрак килергә тырышабыз. Хәвеф-хәтәр зур. Атышлар, шартлаулар бер минутка да тынып тормый. Без сагаеп кына атлап һаман алга барабыз. Безне барысы да кызыксындыра. Тәрәзәләренә ак флаглар эленгән җимерек өйләр. Машиналар. Машиналарга төялеп узучы совет сугышчылары. Хәрби әсирләр...

Сугышлар бара торган урамга әле өч-дүрт квартал чамасы җир бар. Шулай да без сак. Билебездә — пистолет, кулыбызда — автоматлар. Бара торгач, без, алдагы юлга план кору өчен, беразга тукталып калдык. Игътибарыбыз урамның икенче ягыннан бала арбасы тартып баручы ике кызга юнәлде. Берсе алсу йөзле, сапсары чәчле, икенчесе кара чәчле. Алга, сугыш бара торган кварталларга таба атлыйлар. Кемнәр алар? Шундый мәхшәрдә ут бураны уйнаган сәгатьләрдә кая баралар? Без, җавап эзләгәндәй, бер-беребезгә карашабыз. Безнең кызыксынуны аңлаган һәм безгә җавап бирергә теләгәндәй, кызлар, коляскаларын калдырып, кызу-кызу атлап каршыбызга килеп бастылар. Кара чәчлесе кыю гына сөйли дә башлады:

— Гафу итегез, иптәш офицерлар!.. Минем, дөресрәге безнең, сезгә бик зур үтенечебез бар.

— Сез кем буласыз соң? — диде аңа бик җитди караш ташлап майор Френкель.

— Мин — рус кызы, дөресрәге, Украинадан куып китерелгән кыз, украинка. Исемем — Люба. Ә бу иптәш кызым, немец кызы — Һерма... Биредән бер квартал ярым гына алда балалар шифаханәсе бар. Анда минә бу иптәш кызымның бер яшьлек баласы калган. Бер атна инде бара алганы юк. Сугыш чөнки. Ул йортка бомба төшкән дип тә сөйләделәр...

— Без ничек ярдәм итә алабыз соң сезгә? — дидем мин.

— Сез, барысы тик сез генә ярдәм итә аласыз... Үтенеп сорыйм, иптәш майорлар! — диде Люба өзгәләнеп.

— Бомба төшеп, йорт җимерелгән икән...

— Бу әле кеше сүзе генә, бәлки, балалар исәндер...

Без бер-беребезгә карашып куйдык.

— Барыйк! — диде Шаров.

Мин дә инде шул фикергә килгән идем. Каты сугыш барган чагында, бала язмышы белән бәйләнгән фаҗигале вакыйга, безнең газета өчен дә гыйбрәтле иде. Шуңа күрә артык уйланып тормастан:

— Әйдәгез, киттек,— дидем.

Ун-унбиш минут вакыт үттеме-юкмы, без инде Люба күрсәткән урам почмагына якынлашып килә идек. Берничә метр җир кала, Люба, коляска тартып килә торган иптәш кызын да, безне дә артта калдырып, алга ыргылды һәм почмакка җитү белән, башын уңга-сулга сузгалап алды да:

— Исән! Йорт исән! — дип кычкырып ук җибәрде.

Шуны ишетүгә, Һерма йөгереп барып, Любаны кочаклап, аркасыннан сөеп куйды. Берничә минуттан соң ук без бакча эченә салынган бер катлы гаҗәеп матур йортка, балалар шифаханәсенә якынлаштык. Алда, безнең килгәнне күреп, ишегалдына чыккан ап-ак чәчле, сөйкемле генә карт доктор, өсләренә шулай ук ак халатлар кигән утыз-утыз биш яшьләр тирәсендәге ике сестра басып тора иде.

Агарган йөзләреннән сизәргә мөмкин: алар, безне күреп, гаҗәпләнеп, куркып калганнар. Курыкмыйча. Коточкыч сугыш бара, бөтен шәһәр тетрәнә. Кичә, яки бүген иртән сугыш шушы өйләр тирәсеннән узган булырга тиеш. Һәм менә без... Люба да, Һерма да аларга таныш, баланы алып китү нияте белән килгәннәрен дә беләләрдер, мөгаен... Люба, килеп җитәр-җитмәс үк, безнең кемнәр икәнебезне әйтеп, курыкмагыз, дисә дә, алар бик ышанып бетмәделәр кебек.

Без йортка керергә рөхсәт белән бергә үк, анда кораллы фашист солдатлары юктыр бит, дигән сорау да куйдык. Әгәр була калсалар, хәл күңелсез төс алачак дигән кисәтү ясауны да кирәк таптык. Сестраларның берсе йөгерә-атлый барып, ишекне ачты.

— Юк, юк! Рәхим итегез! — диде.

Без өй эченә юнәлдек. Шулай да автоматларыбызның һәр очракка әзер булуын тикшерергә дә онытмадык. Карт доктор бездән шикләнгән сыман кызу-кызу атлап өйгә, балалар янына узды. Ул өлкәнрәк яшьтәге балаларга мөрәҗәгать итеп:

— Балалар, борчылмагыз, безгә кунаклар килде, алар сезгә тимәячәкләр! — диде. Үз сүзләренә ышаныр-ышанмас безгә карады. Аның күзләре яна, иреннәре калтырыйлар иде. Сәбәбе ачык: карт доктор гитлерчы фашист солдатларының аналар һәм балаларга да нинди рәхимсезлекләр кылганын яхшы белә. Докторның куркуы урынсыз икәнен аңлатырга теләгәндәй, Илья Френкель балаларга ачык йөз белән немецчә мөрәҗәгать итте:

— Хәерле көн, балалар!

Балалар башларын күтәреп Френкельгә, Шаров белән миңа карадылар. Мин дә, тәрәзәдән төшкән кояш нурларына ишарәләп, елмаеп, йомшак кына итеп:

— Кояшлы көн белән котлыйм, балалар! — дип өстәдем.

— Рәхмәт сезгә, офицер әфәнделәр! — дип җавап кайтарды сестраларның берсе.

Һерма да, койкадан койкага йөреп, нидер сөйли, балаларны юата, тынычландыра иде. Ә Люба?! Үрелеп, түр бүлмәгә карадым. Бер яшьлек баланы күтәргән дә кысып-кысып сөя, үбә, елый, көлә. Без инде күптән үк сизенгән идек: бала Һерманыкы түгел, Любаның үз баласы. Тик ни өчен яшерә ул аны?!

Баланы алуга ярты сәгать чамасы вакыт үттеме-юкмы — без инде бакчада, доктор һәм сестралар, аларга иярен чыккан сигез-ун яшьтәге балалар белән күптәнге танышларча сөйләшеп тора идек. Доктор да, сестралар да балаларга карата безнең яхшы мөнәсәбәтебез өчен кат-кат рәхмәт белдерәләр, безгә бәхетле тормыш телиләр. Сестраларның берсе:

— Хөрмәтле офицерлар, балалар шифаханәсенә сезнең солдатлар кереп борчымасын, балаларны шикләндермәсеннәр өчен, бу йорт тикшерелде инде, дигән язу бирә алмассызмы? — дип сорады.

Без бер-беребез белән сөйләшеп алдык.

Бу урам һәм якын-тирә урамнар — безнең гаскәрләр кулында. Андагы балаларның тынычлыгын саклау да — безнең бурычыбыз, намусыбыз түгелмени? Шулай уйлашып килештек тә: «Биредә балалар шифаханәсе, йортны без тикшереп чыктык, безнең адресыбыз — Полевая почта — 48828 — А», дигән язу калдырдык.

Саубуллашып, киң юлдан урамга чыгып барабыз. Люба белән Һерма коляскада яткан мөлаем йөзле яшь баланы тартып, шат күңел белән алдан атлыйлар. Безне ике сестра озата бара. Сүзебез, Гитлер Германиясенең яшәү көннәре бетеп, яңа тормыш башланачагы, Гете, Гейне Германиясенең яңадан кайтачагы турында. Сестраларның берсе, башкаларга сиздермәскә тырышып, минем арткарак калуымны үтенде һәм әкрен генә:

— Әйтегез әле, сезнең иптәшләрегез яһүдиләрме? — дип сорады.

— Әйе,— мин әйтәм,— икесе дә яһүдиләр. Ләкин алар руслар, украинлылар, казах һәм башка милләтләр кебек үк чын совет кешеләре. Бездә барлык халыклар да үзара тату яшиләр. Фашистлар гына, немецлар — югары раса, дип, совет халкын, аеруча яһүдиләрне кырып бетерү сәясәте алып бара.

— Гитлер — әшәке расачы, немец халкы үзе дә яратмый Гитлерны.— Сестра

миңа ялт итеп карап алды да, бераз елмая төшеп: — Сез, мөгаен, рус кешесе-дер? — диде.

— Мин — совет кешесе,— дидем.— Ә милләтем — татар, татар кешесе мин.

Күрәм, сестрам бөтенләй өнсез калды. Монда «татар» сүзе дә хәтәр яңгырый икән.

Бераз вакыттан сестрам нормаль хәлгә килеп:

— Шулай шул, совет кешеләре — гаҗәеп кешеләр. Руслар, татарлар, яһүдиләр... үзара тату, дус яшиләр. Бик яхшы бу. Я, дас ис гут, зер гут!.. Балаларга да рәхәт! — диде.

Без җылы исәнләшеп, аерылыштык.

Люба турында, кыска гына әйткәндә, белгәнебез шул булды: балалар шифаханәсеннән без алышып биргән нәни бала чыннан да аныкы икән. Әтисе дә Мишель (Михайло) — украин егете икән. Алар Берлинга Советлар Союзыннан куып китерелеп, аерым хуҗаларга бирелгәннәр. Ярым кол хәлендә яшәгәндә, егет белән кызда кайнар мәхәббәт башлана. Мең газаплар эчендә дөньяга килгән баланы исә кыю һәм кешелекле немец дуслары үлемнән коткарып калган. Шушы хәлләргә төшкән нарасый...

Берлин өчен барган алдагы бәрелешләрнең берсендә мин каты яраландым. Госпиталь. Нечкә һәм катлаулы операция кичереп ятам. Үткәндә кичергәннәр арасыннан күңелне яктыртырдай, җанны тынычландырырдай хатирәләр эзлим. Табам. Ул да булса — балалар. Туган илдә безне, әтиләрен, абыйларын, Бөек Җиңүне зарыгып көтүче балаларыбыз һәм Совет Армиясе коткарып калган башка илләрнең мең-миллионнарча балалары...

Ул хис мине хәзер дә, шатландырып, канатландырып тора. Балалар — дөньяның киләчәге. Шунлыктан прогрессив кешелек барыннан да бигрәк балалар мәнфәгате, алда яшәячәк буын язмышы турында кайгырта. Дөнья шуңа күрә Тынычлык өчен өзлексез көрәш алып бара. Бу изге көрәшнең иң алгы сафында, әйдәүче булып, безнең ил атлый. Балалар хакына, киләчәк хакына... Җәйнең беренче аендагы иң беренче көн дә Халыкара балаларны яклау көне итеп аерып билгеләнә.

# Миргазиян Юныс

# ЮЛДА УЙЛАНУЛАР

## Вавилон елгалары. Шәрык.



Мин диңгездән бер тапкыр аерылган идем инде. «Ярты гомеремне ашадың, ташлап китәм, котылам!» — дип, ләгънәт укып киткән идем мин аннан.

Үзәк матбугатта чыга торган яшьләр журналы 1977 елда мине диңгезчеләр турында мәкалә язар өчен командировкага җибәрде. Эшемне Жданов шәһәреннән башладым. Ждановтан соң Одессага, Новороссийскига һәм Батумига барырга тиеш идем.

Әле дә хәтеремдә: кояш баткан чакта диңгез ярына килдем. Зур океан корабы порттан чыгып бара. Палубага диңгезчеләр җыелган. Ярда калган кешеләр аларга кул болгыйлар. Кораб һаман ерагая, минем йөрәгем һаман кысыла бара. Ниһаять, теплоход торбасыннан ак төтен ургылып чыкты — саубуллашу гудогы колагыма килеп бәрелде. Икенче көнне иртән, йокысыз үткәргән төннән соң, мин кулыма гаризамны тотып, кадрлар бүлегенә диңгезчелеккә ялланырга килдем.

Диңгез минем ләгънәт укып ярга чыгып китүемне кичерде. Ул вакчыл түгел. Күңеле киң аның. Диңгез чын ир-егетләргә охшаган. Ул мине атасының йортына кире кайткан «блудный сын» кебек кабул итте һәм тагын өч елымны суырып алды...

Шул елларда күргәннәремне язарга ниятләп утырам. Алдымда — ак кәгазь. Саф, пакь, гөнаһсыз аклык. Әле аңа бер хәреф тә куелмаган. Нидән башларга? Нәрсә язарга? Сәяхәттә күргәннәр, каютада ялгыз утырганда күңелгә килгән уйлар, тыныч яшәргә ирек бирмичә, эчне тырнап газаплыйлар. Шулардан котыласым килә, язмыйча алардан котылып булмастыр кебек.

Бу әсәрдә диңгезчеләр язмышы һәм минем сәяхәттә туган сораулар урын алыр.

Бүлмәсендә телевизор карап утырган егерменче гасыр кешесе сәяхәтчедән күбрәк күрә, әмма ул күргән нәрсәләрен кулы белән тотып-капшап карый алмый. Сәяхәтче чит илләрнең туфрагына басып йөри, андагы һаваны сулый, чит ил чишмәләреннән ятып су эчә. Телевизор исә ерак илләрнең шәүләләрен генә күрсәтә.

Сәяхәткә йөрү — мавыктыргыч, тылсымлы эш. Юлда йөргәндә, һәр таңда кояш яңа офыктан калка. Йокыдан уянган саен, яңа атаулар, ят диңгезләр, чит ярлар күрәсең. Яңалыклар сине баета, тәҗрибәле итә.

Ләкин сәяхәтнең икенче ягы да бар. Ул сине туган илеңнән, якыннарыңнан, дусларыңнан аера. Сәяхәткә йөрү белән артык мавыгырга ярамый. Бирешмәскә кирәк аның татлы вәсвәсәсенә. Ул синең көннәреңне, айларыңны, елларыңны, юл тузаны итеп, йөргән җирләреңә чәчеп бетерә. Юл — озын, гомер — кыска...

Бу әсәр минем җир шарының ерак диңгезләренә, океан киңлекләренә чәчелеп калган гомерем турында.

### Беренче бүлек

*Увозят милых корабли,*
*Уводит их дорога белая.*
*И стон стоит вдоль всей земли:*
*«Мой милый, что тебе я сделала?»*

Марина Цветаева

## Хыял

Бер сүз турында уйлап утырам. Чамасыз еш куллана башласаң, сүз таушала, тоныклана, хәтта әкренләп үзенең асыл мәгънәсен югалта башлый диләр. Иң башта нинди сүз таушала икән? Беренче чиратта, мөгаен, модага кергән сүз таушаладыр. Без андый сүзне кирәге бармы-юкмы, һәр очракта тизрәк сөйләмебезгә кыстырырга ашыгабыз. Сүз карыша. Аның алай ашыгасы килми, ул киреләнә, чыгымлый. Без исә аны көчләп, рәнҗетеп булса да һаман йөгәнләргә тырышабыз.

Шундый еш кулланудан таушалып, мәгънәсен югалта башлаган сүзләрнең берсе, минемчә, «романтика» сүзе. Яшьләр газетасын яисә үсмерләр өчен чыккан китапларга күз салып карагыз әле. Укыганда, абзац саен диярлек шушы тәти сүзгә килеп төртеләсең.

Минем ике китабым «Кайда син, романтика?» рубрикасында чыкты. «Кайда син?» Бу сорау — җир йөзендә романтика белән тулы ниндидер махсус төбәкләр була икән дигән мәгънәдә яңгырый. Димәк, романтиканы эзләргә кирәк булып чыга. Аны табарга була, тапкач, шунда яшәргә була дип аңлыйсың. Матбугат романтиканы яңа төзелешләрдә, геологик экспедицияләрдә, сәяхәттә табып була дип аңлата.

Элек мин моңа чынлап торып ышана идем. Җилкәнле корабка утырып, «үкереп торган кырыгынчы параллельләр» аша үтүче, Чайльд-Гарольд шикелле тормыш ыгы-зыгысыннан качып, горур ялгызлыкта сәяхәт кылучы сукбай чын романтик булып тоела иде миңа. Ә хәзер, утыз елга якын сузылган, төрле мохитта, төрле эштә узган тормыш тәҗрибәсеннән соң, бу турыда башкачарак фикер йөртә башладым.

Диңгездә беренче йөзә башлаган елларда Николай Гребенкин дигән бер карт матрос белән дуслашкан идем мин. Ул — тәненә «бер карыш тоз сеңгән» чын «диңгез бүресе» токымыннан иде. Аңа табынуым, соклануым шулкадәр иде ки, мин шушы бәндәдән сораштырып, җир йөзенең кай урыннарында нинди могҗизалар, нинди романтик гүзәлләкләр барлыгын ачыкларрмын дип өметләнә идем. Бер-ике сөйләшүдән соң минем өмет-соклануларым юкка чыкты. Ул кеше үзе дә тоныкланып калды, табыну тәмам бетте. Безнең әңгәмә гадәттә менә шушы рәвештәрәк бара иде:

— Николай Семенович, сезнең Австралиядә булганыгыз бармы?

— Биш мәртәбә. Ике мәртәбә Яңа Зеландиянең Веллингтон портында булдым.

— Изге Елена атавында да булдыгызмы?

— Өч тапкыр.

— Наполеонның каберен күрдегезме соң?

Гребенкин кычкырып көлә һәм, мыегын сыпырып, өсти:

— Кабер карап йөрергә мин мәет күмүчемени?

Бер мәртәбә пароход Венеция портында торганда, Дожлар сараена экскурсия оештырдык. Гребенкин шәһәргә чыгудан катгый баш тартты.

— Трамвайда бару өчен — утыз, утырып кайту өчен — тагын утыз лир, сарайга керү өчен билетка йөз илле лир түләргә кирәк. Ике йөз лирга мин ике пар нейлон оекбаш алам да калган ун лирга ярты кружка пиво эчәм. Нәрсә ул экскурсия? Экскурсия ул юкка акча туздырып йөрү,— дип җавап бирде мине сокландырып килгән «диңгез бүресе».

Матрос Гребенкинның гаҗәп үзенчәлекле бер таланты бар иде. Үз күзе белән күргән йөзгә якын илнең дүрт йөздән артык портында тозшырпыдан алып затлы яхтага кадәр булган һәр нәрсәнең хакын төгәл белә иде ул. Шул турыда сөйләгәндә, эсәрләнүдән Гребенкинның күзеннән яшь бөртекләре тәгәри иде.

Шулай, Англиянең Плимут портында торабыз. Кич белән шәһәр карарга чыктык. Гребенкин безгә иярде. «Оча торган фәрештә» исемле диңгезчеләр клубына барышлый бер магазинга сугылдык. Пароходка кайтканда, Николай Семенович миңа кырык төрле әйберләрнең хәзерге бәяләрен һәм моннан җиде ел элек ни хак булуларын сөйләп бирде.

Матрос Гребенкин егерме сигез ел сәяхәттә йөргән. Җир шарын ничәмә ничә тапкыр әйләнеп чыккан. Ләкин, әйтик, шул кешедән тропик диңгезләрдә кояш калкуы, могҗизалы котып балкышы, альбатросның давыл белән көрәшүе яки Неаполитан култыгындагы фирүзә зәңгәрлек турында сорасаң, ул, авызын ачып, аптырап калыр иде. Боларның берсен дә күрмәгән иде Николай Семенович һәм күрергә дә теләми иде. Һәр нәрсә, фәкать хакы куелганнан соң гына, чынбарлыкка әйләнеп, Гребенкинның игътибарына лаек була иде. Гребенкинның романтикасы — әйберләр хакы, бәя, файда иде.

Хәзер Николай Семенович пенсиядә. Дюк Ришелье һәйкәле янындагы эскәмиядә аркасын җылы кояш нурларына терәбрәк утырган җиреннән ул сәяхәткә китүче корабларны, төтеннәре офык эченә кереп эрегәнче, карап-озатып кала. Бер көнне шунда утыруын күреп, мин аның ни сәбәптән гомерен бәя белән кызыксынуга багышлавын аңладым шикелле. Диңгезчеләргә бер-ике мәртәбә тавернага кереп сыра эчеп чыгарга җитәрлек чит ил акчасы — валюта бирәләр. Гребенкин әнә шул печтек акчага йөкләп товар алып кайтырлык берәр әкияти ил очрамасмы дип гомер буе ымсынып йөргән, күрәсең. Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер дигәндәй, мескен матрос егерме сигез ел эзләп тә, андый җирне таба алмаган, әлбәттә.

Романтиканың әнә шундые да була. Кызганычка каршы, андый кеше белән матурлык моңы, көрәш ләззәте турында сөйләшеп, фикер алышып булмый. Ул аларны аңламый һәм аңларга да теләми.

Чыннан да, кайда һәм нәрсәдә соң ул романтика? Нилектән КамАЗ төзүдә романтика күп тә, авылда мал карап йөрүдә юк икән ул? Минемчә, мал көтүдә дә бар ул романтика. Журналист чакта без романтика эзләп яңа төзелешләрдә йөрүчеләрне үтереп мактый, аны таба алмыйча кайтып китүчеләрне тетеп хурлый торган идек. «Нилектән шул ук төзелештә берәүләр романтика таба, икенчеләр таба алмый кайтып китә икән?» — дигән сорау ул чакта безнең башка да кереп карамаган.

Инде хәзер төшенә башладым — романтика кешенең йөрәк тибеше белән бәйле хис булса кирәк. Көндәлек тормыш шатлыгын кем тоя белә, шуңардан кемнең йөрәге ярсып тибә башлый? Романтиканы да, минемчә, әнә шундый кешеләр арасыннан эзләргә кирәктер... Яшәү ул үзе — көчле, матур романтика. Романтик табигатьле шәхес яшәүне — көрәш, белемне — зур байлык итеп тоя белә, шуңа ихлас күңелдән, балаларча эчкерсезлек белән куана ала. Шундый куанычка ирешә алма-

ган кешегә, романтика эзләп, Мадагаскар атавына барып та йөрисе юк. Ул аны анда барыбер таба алмаячак. Кайткач: «Каһәрле урын ул Мадагаскар атавы — черки талап теңкәмә тиде»,— дип шыңшып йөриячәк...

Каен урманының чәчәкле аланына чалкан ятып, төпсез зәңгәр күккә караганыгыз бармы сезнең? Өстә чиксез биеклек. Ул, син яткан җирдән башланып, йолдызлар янына, аларны да үтеп, ерак галактикаларга китеп югала. Иксез-чиксез, тоташ, илаһи зәңгәрлек. «Ак күмәч белән ашарлык саф һава». Кошлар сайрый. Урман моңы — яфраклар шаулавы ишетелә. Тоташ зәңгәрлек тә, саф һавасы да, кошлар сайравы да — барысы да синеке. Алар синең йөрәгеңдә һәм каныңда. Алай гына да түгел: син үзең — зәңгәр күк, урман, кошлар сайравы. Күктән яуган кояш нурлары да — үзең. Син алардан аерым түгел — тоташ. Йөрәгең ярсып тибә, бәхетең шундый мул, шундый ачык — төгәл, күңелдә әллә нинди кайнар тылсымнар кабына. Карап ята торгач, шушы биеклекнең үзеннең үткән гомереңдә һәм киләчәгеңдә дә булуын тоясың, хәтта шушы мизгелдә биеклекнең сине үзенә чакыруын да ишетә башлыйсың сыман.

Романтика эзләп, урмандагы аулак аланга да барып йөрисе юк. Ул безнең үзебездә, йөрәк тибеше ритмында.

Койма буендагы чирәмлеккә тезләнеп, җиргә җентекләп карагыз әле. Аяк астында аунап яткан үлән сабакларын күзәтә башлау белән, исең китеп, хәйран каласың. Үлән тамырлары тармакланып, чуарланып, барысы да җир астына, тирәнгә сузылганнар. Аска төшкән саен, тамыр тармаклана, нечкәрә, кыл юанлыгы гына кала һәм, үрмәкүч җепләредәй меңләгән нечкә капиллярларга әверелеп, җиргә сеңә. Ничек шул нечкә, нәзберек җепләр каты җирне тишеп керә алганнар? Тамырны бер мәртәбә тартып чыгарсаң, мәңге кире урынына утырта алмыйсың. Хәйран калырлык бөек могҗиза бит бу! Үләннең тагын бер гаҗәеп сәләте сокландыра мине. Ул үз юлында очраган һәр нәрсәне урап уза белә. Аны моңа кем өйрәткән?

Әйтик, менә койма тактасы урыныннан кубып чыккан. Ул үләннәр өстендә асылынып тора. Бер генә үлән дә сабагы белән койма тактасына килеп төртелмәгән. Алар коймага җитәргә бер сантиметр кала читкә борылганнар. Үлән тактаны ничек, кай җире белән күрә?

Үләннәр күләгәдән кояш нурларына таба сузылганнар. Үлән кояш нурын, аның яктылыгын сизә һәм һәрвакыт шуңа омтыла. Ул аны ни рәвешле белә?

Үсемлекләрне җансыз дип без бик тә ялгышабыз. Җансыз нәрсәнең акылы булмаска тиеш, ә үлән — акыллы. Үлән генә түгел, җир йөзендәге һәр матдә, һәр атом бөртеге акыллы. Мин шуңа гаҗәпләндем: тоташ акылдан торган галәмдә каян туа икән сугыш, җәбер, сәясәт тәкәбберлеге шикелле акылсызлыклар?

Сезнең һавадагы болытларга игътибар белән караганыгыз бармы? Һавада агылган болытлар сезгә нәрсә булып күренә?

Романтик кеше шул болытны давыл белән көрәшкән җилкәнле кораб сурәтендә, прагматик — базарга барырга комачаулаучы яңгыр итеп күрә. Романтик йөрәгендәге канатлы дәрт шулай күрсәтә болытны.

Дөрес, романтика — эчке бер тынгысызлык, ләкин тынычлыктан качып давыл эзләп йөрүче романтик бәндәгә шикләнеп карыйм мин. Адәм баласы тынычлык өчен яралган, чын тормышны туган-үскән җирдә, тынычлыкта гына корып була. Ахыр чиктә, тыныч яшәү генә канәгатьләндерә ала адәм баласын.

1969 елны мине Диңгез флоты министрлыгына бүлек начальнигы итеп билгеләгәннәр иде. Озак сәяхәттә йөреп алҗыганнан соң бу эш миңа бик тә рәхәттер кебек тоелды. Үз кабинетың. Алгы бүлмәдә һәр әмереңне үтәргә әзер торган секретарь кыз утыра. Эшкә җиңел ма-

шинага гына утырып йөрисең. Сәгать тугызда гына эш көне башлана. Алты тулу белән, ачкычны секретарьга тапшырасың да кайтып китәсең. Тешең-тырнагың белән ябыш инде шушы урынга. Кадерен белеп, тырышып эшлисе югыйсә. Юк, өч елдан мин шул кабинеттан ычкыну җаен эзли башладым. Давыл сагынудан, романтика эзләп түгел, эш минеке булмаганга күрә. Түрә булып, боерык биреп утыру минем өчен чит, йөрәккә ятмый торган эш булып чыкты. Кабинет тәрәзәсеннән Кремльнең Спас манарасы күренеп тора. Урамда машиналар ташкыны. Гөжлиләр, гудок биреп, кысынкылыкка зарланалар. Авылда яшәгән чак, атка утырып йөргән заманнар искә төшә. Машиналарга ияреп, ат килеп чыгуын көтәм... Кыскасы, кабинетта ат сагынып, җирсеп утырам. «Бахбаем, эшкә мин сиңа атланып килер идем... Урам аша гына күренеп торган аулак урынга бәйләп, алдыңа солы салып куяр идем... Өйлә җиткәч, Мәскәү елгасына төшереп, су эчереп кайтыр идем. Алтыда сиңа атланып өемә кайтып китәр идем...» — Менә шушындый сафсата һәм дуамал уйлар артык бимазалый башлагач, тилерүдән куркып, эшемнән китәргә мәҗбүр булдым.

Тыныч эшне ташлап, диңгезгә китү читтән караганда давыл эзләп качу булып күренә. Инде хәзер аңлый башладым. Диңгезчелекнең бер күркәм ягы тарткан икән мине. Корабта эш авыр, ләкин анда мөнәсәбәт гади һәм куаныч та гади — ифрат мөлаем, балаларныкына охшаш эшчеләр куанычы. Министрлыкта исә андый гадилек юк иде. Буйсыну һәм буйсындыру. Рәсми мөнәсәбәтләр. Кәгазьгә табынуга көйләнгән җитди ыгы-зыгы. Һәм мин аңа күнегә алмадым. Җан азыгы — куаныч эзләү мине кабат диңгез сәяхәтенә куды.

Татарның «Кая барсаң да, кара сакалың үз артыңнан калмас» дигән әйтеме бар. Кем генә булып эшләмә, җир шарының кай җирендә генә йөрмә, йокыдан уяну белән, син иң әүвәл үз уйларың, үз теләк-омтылышларың белән очрашасың. Без хәйран катлаулы машиналарны эшләтә, исикткеч четерекле мәсьәләләрне чишә яки кагыйдәләрне исбат итә, дәлилли алабыз. Ә көнелдәге уйларның, йөрәктәге теләк-омтылышларның каян туганын, нигә болай яки тегеләй булуларын аңлый да, аңлатып та бетерә алмыйбыз. Мәктәптә дә, университетта да безне аңа өйрәтмәгәннәр. Хәер, өйрәтә дә алмаслар иде. Чөнки аларны бары тик яшәү тәҗрибәсе, бары тик тормыш мәктәбе генә аңлата ала. Укып белем алу, һөнәргә өйрәнү генә канәгатьләндерми кешене. Үзеңне өйрәнү, үз теләк-омтылышларыңны аңлый, ачыклый белү кирәк безгә. Тик үкенечлесе шул: без моны бик соң аңлый башлыйбыз шул.

## Кораб

Дөнья экономикасында ягулык кризисының кара шәүләсе куера башлагач, җилкәнле корабларны тагын искә төшерделәр. Бу хакта сүз хәзер көннән-көн ишәя-куера бара. Кичә без дә каютъ-компаниядә шул хакта ләчтит сатып утырдык. Имеш, Николаев шәһәрендә бер конструктор җилкәнле кораб проектын төзеп хөкүмәт комиссиясенә тапшырган икән.

Күп илләрдә хәзер җилкәнле кораб — бриг, бригантина, барк, шхуна төзү турында баш ваталар. Философиядә «инкярне инкяр итү» дигән бер бөек канун бар. Кораб төзү дә шуңа буйсына, күрәсең. Корабларны пар белән йөрүче пароходлар юкка чыгарды. Пароходларга алмаш теплоходлар килде. Хәзер теплоходларның үзләренә үлем чираты җитеп килә. Ягулык көннән-көн кыйммәтләнә. Көн тәртибендә — җилкәнле кораблар. Аларга ягулык кирәкми, ләкин җил корабының бер кимчелеге бар: җилкән белән идарә итү өчен, кимендә җитмеш биш — сик-

сән кешедән торган экипаж кирәк. Хәзерге көндә һәр теплоходның экипажы кайбер илләрдә — унике — унбиш, бездә — утыз — утыз биш кешедән артмый. Җилкәнле корабны утыз — кырык кеше идарә итәрлек итеп камилләштерүгә, ул кабат диңгезгә чыгачак.

Океан корабларының күләмен зурайту белән мавыгу шаукымы да хәзер сүрелеп килә. Биш йөз мең тонна нефть сыешлы танкердан соң миллион тонналы супергигант төзү турында хыяллана башлаганнар иде. Ләкин әлегә ул хыял булудан узганы юк. Хәзер аягыңны юрганыңа карап сузу таләп ителә.

Фәнни-техник революция кешегә иксез-чиксез мөмкинлекләр тудырды. Шушы мөмкинлекләрдән файдаланып, без туйганчы җир асты байлыкларында актарындык. Планетаның тирән карынында яткан рудаларны, нефть-газны туктаусыз чыгара, файдалана тордык. Планета юмартлыгының да чиге була икән. Җир шары кысырая башлады. Капиталистик илләрнең галимнәре инде океан төбендәге рудаларны чыгару, айдагы минералларны җиргә ташу мөмкинлекләре турында баш ваталар.

Моннан фәкать унбиш — егерме ел гына элек океандагы балыкларның чиге-чамасы юк иде кебек. Алар мәңгегә җитәр дип өметләнә идек. Хәзер инде диңгездә балык азайды дип зарланабыз.

Нефть ташучы супертанкерлар суда яшәүче тереклекне агулау белән генә чикләнеп калмый. 1977 елны «Торри Каньон» исемле Америка танкеры, Британия ярлары буенда су асты кыясына бәрелеп, урталай сына. Аның фарсы култыгында төягән ике йөз житмеш мең тонна нефте диңгезгә түгелә. Норд-Ост җиле нефтьне Европа ярларына куып китерә дә ярга сирпеп ыргыта. Яр буенда яшәүче кош-корт — акчарлаклар, каз-үрдәкләр барысы кырылып бетәләр. Балык, устрица плантацияләре агуланып юкка чыга. Җәйге ял вакытында (Европа илләрендә ялны җәй бирәләр) иллешәр миллион су коенучы җыела торган Франция пляжлары дегет әлпәсе белән каплана. Капиталистик илләрдә һәр нәрсәне акчага күчереп исәпләү гадәте бар. Газеталарның хәбәр итүенә караганда, менә шул «Торри Каньон»ның һәлакәте яр буе халкына ике миллиард ярым доллар күләмендә зыян китергән имеш.

Мине, бөтен рәсми раслану баскычларын берәм-берәм узганнан соң, «Матвей Муранов» дигән теплоходка эшкә билгеләделәр. Мин шул турыдагы приказны тотып, портка юнәлдем.

«Матвей Муранов» причалда тора иде. Тугыз ел эчендә Жданов порты бик нык үскән, үзгәргән. Яңа причаллар өстәлгән, күмер төяргә көйләнгән эстакада ясаганнар, зур бетон мәйдан — контейнер терминалы барлыкка килгән.

Причалларга сырышып торган кораблар да яңалар, зурлар. Аларның архитектура рәвешләре миңа ничектер сәер тоелды. Минем ундүрт ел эшләгән «Чолым» пароходын Испаниягә сатканнар. Әле кичә генә пароходны Кадис портына илтеп тапшыручы капитанны күреп сөйләшкән идем. «Без аны металлоломга дип саткан идек, пароходны испаннардан греклар сатып алган икән. Исемен үзгәртеп, аңарда Итея портыннан Европага боксит ташыйлар ди»,— диде «Чолым»ның соңгы капитаны.

Чемоданымны күтәреп, «Матвей Муранов» теплоходы янына килеп туктадым. Йөрәгем дөп-дөп тибә. Беләсем килә: нинди сөенечләр, нинди мәшәкать-авырлыклар көтә икән мине бу корабта? Йөк төялеп беткән. Палубада тып-тын, беркем күренми. Трюмнар ябылган. Бары тик саклаучы матрос кына, фальшбортка таянып, причалга карап тора.

Бу корабта мин ят кеше әле. Ят кешедән, бигрәк тә беренче ярдәмчедән, экипаж яхшылык көтми. Башта аның үзеннән фәкать кимчелек кенә эзлиләр. Куркуданмы ул, әллә яңа кеше күнегелгән гадәтләрне бозар, катлаулык, кыенлыклар тудырыр дипме? Хәер, эше дә шундый-

рак бит. Беренче көннәрдә яңа корабка ияләшү ифрат авыр була.

Трап саклаучы матрос миңа капитанның беренче ярдәмчесе яши торган каютаны күрсәтте. Ишек шакыдым. Мине яше кырыктан узган шактый юан, шактый түгәрәк битле бер кеше каршы алды. Аның чыраенда ниндидер шөбһә-курку галәмәте бар иде. Башымнан: «Бу кеше миннән бераз курка шикелле»,— дигән уй йөгереп узды.

Таныштык. Аннары озакка сузмыйча конкрет эшкә күчтек. Коллега эш кәгазьләрен тапшыра, мин кабул итә башладым. Катыргы папкаларга тутырылган төрле кәгазьләр. Утыздан артык папка. Приказлар, күрсәтмәләр, документлар, экипаж әгъзаларының чит ил паспортлары, таможня декларацияләре, эшләнеп бетмәгән эшләр, гамәлгә ашырасы фәрманнар, әллә нәрсәләр...

Кабул итү кәгазенә куллар куйганнан соң, утыз өч кешелек экипажның язмышы, эш-гамәле тулысы белән минем мораль җаваплылыкка күчте дияргә була. «Әйбәт кешеләр генә булсагыз иде инде!» — дип, эчемнән генә ялварам үзем, алдымда яткан исемлеккә күз төшереп. Аннары, дулкынлануымны яшерергә тырышып, ялга китүче коллегамнан сорыйм:

— Исемлек буенча кемнең ниндирәк кеше икәнлеген кыскача гына сөйләп чыксагыз иде,— дим.

Коллегам бер тын уйланып тора да сөйләргә керешә. Аның сөйләве буенча «Матвей Муранов»та эшләүчеләр артык әйбәт тә, бик үк начар да түгелләр. Беләм мин аның нигә болай тыйнаклануын. Начар кешенең яман эшләрен фаш итәргә коллеганың батырлыгы җитми. Сүз чыгар, гайбәт таралыр дип курка ул. Мондый эштә тәҗрибәсе бар һәр кеше нәкъ шулай сөйләр иде. Ни сәбәптер, холыксыз, гауга куптаручан кешедән курку, аңа юл биреп, аны урап узу модага керә башлады хәзер. Алар яулап алган позицияләрен ныгытып, һаман һөҗүмнәрен үстерәләр. Без чигенәбез.

Айлар, еллар буе экипажның һәр әгъзасы белән якын аралашып яшәгән кеше, гадәттә, әкренләп аларның кайсы яхшы, кайсы начар икәнлеген дә аера алмый башлый. Таләпчәнлек йомшарса, тырышның — тырышлыгына, ялкауның — ялкаулыгына, күз буяучының күз буявына әкренләп күнегәсең дә, бераздан шулай тиештер дип үзең үк ышана башлыйсың. Тәрбия эше ифрат катлаулы.

— «Шешә» белән чиктән тыш кемнәр мавыга? — дип сорыйм.

Коллега җилкәсен кашый.

— Без болай сөйләшик,— ди ул, уңайсызлыктан күзләрен челт-челт йомып.— Бу сүз инде синдә генә калсын. Капитанның өченче ярдәмчесе Максютин бик әшәке эчә. Үзе әйбәт егет: белемле. Юаш, но «шешә» күрсә — бетте, тыела алмый. Акылын җуйганчы чөмерә.

— Кисәткәнегез, шелтә биргәнегез янсә җыелышка куйганыгыз булдымы соң? — дип сорыйм.

— Файдасы тимәячәк,— ди коллега һәм, тагын да авыррак елмаеп, җилкәсен кашый. Ул хәзер куркуын яшереп тә азапланмый иде.

— Берәр дәрәҗәле яклаучысы, «кулы» бармыни?

— Әтисе ХЭГС [1] начальнигы, безнең өстән идарә итә.

Аңлашылды.

— Тагын кемнәргә күз-колак булу кирәк?

— Икенче механикның кулы «озынрак», «обслуга» кызларының итәкләренә үрелгәли.

Бусы инде чиктән тыш гаугалы, кәеф кырылырлык яман хәбәр.

Гауганың башын шерше ля фам — хатын-кыздан эзлә, ди француз әйтеме. Сәяхәт вакытында ике егет арасында гауга купса, аның асы-

[1] ХЭГС — хозрасчетная экономическая государственная служба (хозрасчетлы экономик дәүләт служба).

лын аңлау өчен экипажга аш әзерләп, өләшеп торучы кызларны тикшерүдән башлау мәслихәт. Гауга бер кубып, җанланып китсә, таудан тәгәрәп төшкән җепшек кар шикелле, үсә, юлында очраучыларны зур тизлек белән үзенә ябыштыра бара. Җентекләп тикшергәндә, еш кына аның беренче очкыны шул кызлардан чыккан була. Диңгезчеләр кораб кызларын беркемнеке булмаган очракта гына ихтирам итәләр. Экипаждагы хан кызы морякның берсе белән ботка пешерә башласа, калганнарын үзенә дошман итә. Диңгезчелек эшенә нигә кыз-кыркынны яллыйлар икән?

Тапшыру-кабул итүне тәмамлап, рапорт яздык та капитанга кереп расластык. Капитанның имзасы гына җитеп бетмәс шикелле тоелды безгә. Каютага әйләнеп кергәч, бер-беребезгә уңышлар теләп, рюмка күтәрдек. Коллегамны порт капкасына кадәр озатып куйдым. Ул китте, мин калдым. Ул ял итәчәк. Ә мин?..

Вазифамны кабул итеп өстемә алу белән касыгымда кургашка тиң бер авырлык барлыкка килүен сиздем. Әйтерсең, бармакларымны шүрәленеке шикелле итеп бүрәнә ярыгына кыстырып куйдылар. Бармакларны суырып алып булмый. Без аны акт язып, кул куеп беркеттек.

Шүрәле дигәннән. Тукайның мескен Шүрәлесен шушы көнгә кадәр кызганып йөрим мин. Алдап Шүрәленең бармакларын бүрәнә ярыгына кыстырган мәкерле крестьян егетенә карата мәктәп елларыннан бирле нәфрәт саклыйм. Беренче мәртәбә шул шигырьне укып чыккач, Тукайга хәтерем калды: шагыйрь дә мескен Шүрәлене шундый авыр хәлдә ялгызын ташлап киткән шул мут егет ягын тота бит.

«Матвей Муранов» — җиде мең ярым тонна сыйдырышлы универсаль коры йөк корабы. Биш трюмы (кораб карынындагы базга охшашлы урын) бар. Шуларның берсе — тиз бозыла торган ашамлык төяр өчен ясалган суыткыч-рефрижератор. Чагыштырмыйча, җиде мең биш йөз тоннаның әзме, күпме икәнлеген күз алдына китереп булмый. Сугыш елларында мин ат белән элеваторга ашлык ташыдым. Арбага өч центнер бодай төяп була иде. «Матвей Муранов» алып кайткан йөкне сыйдыру өчен егерме дүрт мең җиде йөз илле олау кирәк булыр иде. Биш тонна сыешлы йөк машинасы белән ташыганда да бу корабның трюмнарын тутырыр өчен бер мең өч йөз мәртәбә юл ясарга кирәк.

Корабның тизлеге — сәгатенә унҗиде миль. Самолет белән чагыштырганда кораб әкрен йөри. Әкрен барса да, ул, бертуктаусыз, ялсыз, көне-төне, атналар, айлар буе барганлыктан, әллә кайларга барып җитә. Әкрен йөрешле кораб тәүлегенә алты йөз километр ара үтә. Бу яктан аның белән башка нинди транспорт ярыша ала?

Теплоход берьюлы уртача зурлыктагы заводның барлык җиһазларын сыйдыра ала. Заводны самолетка төяп ташып кара әле! Корабның тагын бер отышлы ягы бар: автомобильгә — асфальт, поездга рельс кирәк; корабка юл салып торасы юк — аңа юлларны табигать үзе салып куйган.

Фәнни-техник революция диңгез флотына автоматика кертте. Автоматизация физик көч түгел, көчәнеп эшли торган эшләрне киметте һәм диңгезчеләргә тагын бер вазифа — автоматларны карап, көйләп тору хезмәтен өстәде. Йорт эшендә дә шул ук хәл: кер юа, идән себерә, камыр изә торган машиналар барлыкка килүдән, ни сәбәптер, хатынкызның эше кимемәде. Алла белсен: әллә тормыш мәшәкате арта тора, әллә машина үзе бер мәшәкать?

Мин ярда эшләгән арада корабларга нинди үзгәрешләр кергән? Шуны ачыкларга тырышам. Җилкәнле кораблар калдырган мирас мачталар, аларны як-яктан тарттырып торучы вант, штангалар юкка чыккан. Йөк угын беркетү өчен, трюм араларында тимер баганалар гына тырпаеп тора. Фәнни-техник революция гадәти кораб архитектурасын челпәрәмә китереп ташлаган: корабның койрыгы — җәлпәк; ко-

рылманы түгәрәкләп, җыйнаклап азапланмаганнар, дүрт кырлы тимер куб утыртканнар да куйганнар.

Тойгыларым кабул итмәде бу яңалыкны. Минем зәвыгым иске кануннарга көйләнгән иде. «Картаю торгынлыгы, яңалыкны аңларга көч җитмәү менә шушыдыр инде»,— дип уйлап алгач, корабның каюталарын, экипажның тормыш шартларын тикшерергә керештем.



## Диңгезчеләр тормышы

«Матвей Муранов»ның һәр катына күтәрелеп, бик озак такта җәйгән палуба эзләп йөрдем. Палубалар һәммәсе дә тимердән иде. Соңгы елларда кораб палубаларына такта җәйми башлаганнар. Бу — минем өчен зур югалту иде. Такта палубаның аслыгы тиз тутыга. Аны чистартып, буяп торырга кирәк. Аның каравы, җәй көннәрендә комлап юылган җылы тактага ялан аяк басып йөрүе, чиста палубага сузылып ятып кояшта кызынуы шундый рәхәт була иде.

Каюталарның стеналарын, түшәмнәрен элеккеге шикелле фанер белән тышлау беткән. Стеналарга фанер урынына пластик ябыштырганнар. Мин аны башта чикләвек агачы белән тышлаганнармы әллә дип уйлаган идем. Карап торышка бик матур үзе. Пычранса, сабынлап юасың да, шундук чистарып, ялтырап китә. Ләкин уңайсызлыгы шунда: икенче көнне үк тән, стеналарның агач түгел икәнлеген сизеп, тынгысызлана башлады. Пластикада табигыйлек юк. Тропикның кайнар, тозлы һавасында аннан сасы ис чыга башлый.

Корабның күп механизмын электр көче эшләтә. Стеналар фанер белән тышланган чакта электр алай куркыныч түгел иде. Яңа корабларның пластик стеналарына электр кыры туплана икән. Яныннан узганда чытырдап стенага күлмәк итәге ябыша, башыңны терәсәң, чәчләреңнән чаткы чәчри. Яңа корабларда мәче асрап булмый дип зарланалар. Мәче электр кырын кешедән ныграк сизә икән. Корабка керү белән, ул түзә алмыйча чыелдый башлый, бераздан аның йоны коела һәм акренләп вафат була, ди. Ә кеше түзә. Безгә табигать зур көч — түземлек биргән.

Кузгалып, диңгезгә чыккач, тагын бер яңалыкка — вибрациягә юлыктык. Двигатель эшли башлау белән, теплоход дерелдәргә керешә. Тешләр бер-берсенә шак-шок бәрелә. Кул калтырый, каләм тотып булмый.

Бер айдан вибрация тештәге пломбаларны бәреп чыгарды. Двигательнең әйләнеше бик көчле, вибрация — шуннан. Гаҗәп хәл: акренләп вибрациягә дә күнегәсең. Адәм баласы барысына күнегә, түзә, берәр төрле дәлил табып, яшәү шартларының әйбәт булуына ышана башлый.

Болары яңалыкның кимчелекләре. Уңай яклары шактый, хәтта аларны санап та бетерерлек түгел.

Миңа күп еллар күмер ягып йөри торган «Чолым» пароходында эшләргә туры килде. Андагы каютам иңе өч, буе өч ярым адым зурлыкта иде. Тар тимер карават, бәләкәй өстәл. Кием шкафы (рундук) һәм башың гына сыярлык сыңар иллюминатор. Кысан иде. «Чолым» каютасында. Яңа корабтагы каютамның тәрәзәләрен санийм: бер, ике, өч... Алты тәрәзә. Алгы бүлмә, иркен салон, йокы бүлмәсе, ванна, санблок. Каютада ясалма климат. Тропикларда һаваны — суытып, корытып, тузаннан чистартып, кышкы салкыннарда җылытып, дымландырып кертә.

Каютада ашамлык саклау өчен суыткыч тора. Шунда ук савыт-саба буфеты, китап шкафы, кием-салым гардеробы. Йомшак креслолар, кә-

нәфи, язу өстәле; табынныкы — аерым. Палубага кыйммәтле келәм җәелгән. Зур радиола һәм телевизор. Дөресен әйткәндә, бу җиһазларның күбесе кирәк тә түгел. Телевизор кызыл почмакта да, комсостав салонында да бар. Кают-компаниядә — зур суыткыч шкаф. Алган ашамлыкны анда да саклап була. Мин ярда яшәгән арада пароходчылык шактый баеган.

Без әле байлыкка өйрәнеп җитмәгәнбез. Кирәкме-юкмы, йорт җиһазы җыя, кием-салым... әллә нинди кирәксез нәрсәләр җыярга тотынабыз. Байлык әйбәт нәрсә, әгәр ул комсызлык, саранлык тудырмаса. Байлыктан баш әйләнү — вак буржуазлык мирасы түгелме икән?

Каюта — минем эш урыны. Монда йоклыйсың, ял итәсең. Слесарь — үзенең цехында, тракторист тракторы өстендә яшәми бит. Без яшибез. Каютаның эш урыны икәнлеген стенага кадаклаган язу раслый.

«Матвей Муранов»та һәр диңгезче аерым каютада яши. Матросларныкы салонсыз, санблоксыз. Шулай да — аерым каюта. «Чолым» пароходында бер каютада дүртәр диңгезче яши иде. Диңгездә йөзгәндә кысанлыкка түзеп була. Ә инде портка кайтып, хатыннар белән очрашкач, «Чолым» пароходында трагикомедия башлана иде. Бер каютада хатыннарын назларга сусап кайткан өч-дүрт ир — ходай язмасын...

«Матвей Муранов»ның спорт залы, мунчасы (сауна), суы җылытыла торган бассейны, кер юа һәм кер үтүкли торган машиналары да бар. «Чолым» пароходында без керне, бауга тагып, диңгезгә ыргыта идек тә, бер-ике сәгатьтән дулкын юган керне кире сөйрәп чыгара идек. Бер тапкыр Кызыл диңгездә барганда чалбарымның бер балагын акула өзеп йотып киткән иде.

Ерак диңгезләрдә йөзгәндә семьяң белән элемтә тоту өчен радиотелефон куелган. Хәтта көн саен яңа басылган газета уку мөмкинлеге дә бар. Чыккан газетаны алу өчен факсимиле дигән аппарат куйганнар. Телетайп та бар. Бер минут эчендә министрлык, портлар белән документлар алышып аласың. Томан, калын караңгылык аша алдагы юлны күзәтү өчен ике радар эшли. Навигация приборлары турында сөйләп тә торасы юк.

Ипи корабның үзендә пешерелә. Тәүлегенә өч мәртәбә кайнар аш. Көн аралаш каютаң җыештырыла. Башка ни кирәк адәм баласына? Чын җәннәт тормышы. Шундый тәрбияле, рәхәт яшәү булырга тиеш, ләкин... нигәдер...

Мин «Матвей Муранов» теплоходының затлы каютасында яшәү турында уйлап утырам. Үкенеп тә куям. Бер мәртәбә диңгезне ташлап киткәч, бәлки кире әйләнеп кайтасы калмагандыр? Аерылышкан хатын янына кире әйләнеп кайтырга ярамый дип сөйлиләр бит. Бәлки, диңгез эшенә дә кире кайтырга ярамый торгандыр? Кызганычка каршы, яшәүнең һәркемгә яраклы уртак, универсаль кагыйдәсе юк. Берәүләргә бәхет китергән кагыйдә икенчеләрне бәхетсезлеккә дучар итә. Бәхетле булу кануны һәркемнең үзендә, ул аны үзе таба.

Урынымнан торып, коридорга чыгам. Күперчеккә күтәреләм. Машина бүлегенә төшәм. Кире каютага кереп телевизор кабызам... Сәяхәт озакка сузылса, шушы комфорт, шушындый уңайлы шартлар җирсүне, өйгә кайтасы килүне тагын да көчәйтеп җибәрәчәк. Җилкәнле флот чорында бер кубрикта кырыгышар кеше яшәгәндә, диңгезчеләр тәүлегенә унсигезәр сәгать эшләгәннәр. Эш авыр булган. Шунлыктан аларның сагынуга көчләре дә, вакытлары да калмаган. Дөнья бу. Аны аңлап бетерерлек түгел.

Экипаж әгъзалары өйләренә таралышкан. Аларның күбесе шушы портта, Ждановта яши. Мин регистрация кенәгәсен күздән кичердем. Башка шәһәрләрдә яшәүчеләр дүртәү. Дневальный булып эшләүче кызның эти-әнисе Макеевкада тора. Электромеханикның семьясы — Херсонда. Токарь — Керчь шәһәреннән һәм мин — Мәскәүдән.

Сәгать икенче яртыда экипаж янә җыелачак. Сәгать төнге икегә чикне ябар өчен чик саклаучылар белән таможенниклар килә. Кесәдә калган акчалар, исемлеккә теркәлеп, кораб кассасына тапшырылырга тиеш. Һәр диңгезче «таможенная декларация» дип аталган документ тутырачак. Таможенниклар эшне бетергәч, чик саклаучылар килеп, каютанда чит кеше юкмы икәнлеген ачыклыйлар, синең йөз-чыраеңны паспорттагы фоторәсем белән чагыштырып карыйлар. Туган ил белән аерылышу ритуалы әнә шундый.

Нәкъ бер сәгать егерме минуттан соң минем күз алдымда нәкъ менә шушы эш башланачак. Мин шуны көтәм. Көткән арада экипаж әгъзаларының исем-фамилияләрен хәтердә калдырырга тырышам. Алдымда диңгезчеләр телендә «судовая роль» дип аталган экипаж исемлеге. Анда утыз җиде кеше — минем юлдашларым. Дүртенче, өченче, икенче һәм өлкән штурман; дүртенче, өченче, икенче һәм өлкән механик; электромеханик, рефрижератор механигы, радиостанция начальнигы, доктор. Боцман, плотник һәм биш матрос — болары штурманнар белән бергә палуба командасына керәләр. Токарь, ике электрик, электрогазосварщик, өлкән моторист һәм алты гади моторист — болары механиклар белән бергә машина бүлеге командасын тәшкил итә. Кок, ипи пешерүче, буфетчы, җыештыручы — боларын «обслуживающий персонал» — диңгезчеләр шивәсендә: «абслуга» (никадәр эзләнсәм дә, бу сүзнең татарчасын таба алмадым).

Утыз җиде кеше. Утыз җиде төрле фигыль-холык. Утыз җиде төрле өмет. Утыз җиде төрле теләк-омтылыш. Математикада сочетание дип аталган бер гамәл бар. Шул гамәлгә таянып фикер йөртсәң, вакыйгага, кәефкә, сәяхәтнең озынлыгына һәм тагын әллә нинди туктаусыз үзгәреп торган шартларга бәйләнешле катлаулы үзара мөнәсәбәтләр җыелмасы килеп чыга!

Башкарган эшнең сыйфаты, чит илдә йөргәндә таләп ителгән политик уяулык, тәртип саклау, әхлакый сафлык, өйрәнүләр, авариясез йөзү — экипажның тавык чүпләп бетерә алмаслык әнә шундый эшләре өчен без капитан белән икәү җавап бирәбез.

Болай булгач, капитанга аерым тукталып китмичә булмас ахры...

## Капитан

Бала чакның хыял диңгезләрендә минем дә капитан булып йөзгәнем бар иде. Хыял дәрьясында малайларның барысы да — я очучы, яисә капитан.

Җаваплы эш — ул океан корабы белән идарә итү. Кораб белән идарә итүнең башка җаваплы вазифадан аермасы шунда: башка эштә үзеңнән югарырак утыручы начальник белән киңәшеп эш итәргә була, ә монда андый мөмкинлек юк.

Капитанның җаваплылыгы чиксез зур, мәҗбүрият кырыс һәм катгый булгангамы, капитаннар арасында мәзәк кыланышлы кешеләр дә еш очрый.

Азов пароходчылыгында эшләүче бер капитанның: «Каютада ялгыз калган чакларымда үлеп китүдән куркам»,— дип миңа зарланганы бар. Диңгездә чакта ул, мескен, рубка диванына ятып йоклый, ә портта торганда янына хатыны кунарга килеп йөри иде. Бер мәртәбә ни сәбәптәндер хатыны килми калган.

Ул чакта кораб портта тора иде. Йөк бушату көйләнгән. Хәзер ул тәмамланганчы шулай дәвам итәчәк. Мин йокларга яттым. Төнге өчтә ишек шакыдылар. Ачтым. Каршымда дер калтырап, «дәүләт ышанычы, тапшырылган шәхес» — капитан басып тора:

— Гафу итегез, Миргазиян Закирович,— диде капитан, варенье урлаганда тотылган бала шикелле.— Тыным кысыла. Доктор кайдадыр купып йөри. Ярдәм итәр кешем юк. Инфаркт түгелме икән?

«Түгел!» — дип кенә ишекне ябасы иде дә җылы урыныма чумып йоклыйсы иде югыйсә. Юк, мин, аның йөрәк тибешен, сулыш алышын тикшермәк булып, каютасына кердем. Мин керү белән, өстәлгә «Митакса» коньягы, закускалар йөгерешеп килеп утырдылар. Бу минутта ул мине үз каютасында чыгармыйча тотар өчен җанын бирергә дә риза иде. Миңа «СССР гражданнарының абруен һәм интересларын саклаучы»ны ялгызлыктан саклап, яктырганчы, аның каютасында утырырга туры килде.

Минем беренче мәртәбә диңгезгә чыккан корабымның капитаны мәрхүм Василий Степанович Миронов исә ырымга бик ышанучан кеше иде. Палубадан диңгезгә төкерергә, кнехт[1] өстенә утырырга, дүшәмбе һәм айның уникенче көнендә диңгезгә чыгу яки корабтагы хәлләр турында аның белән сүз кузгатырга һич тә ярамый иде. Бервакыт Потидан Одессага кайтып килгәндә, боцман: «Кич белән Одесса портына керәбез. Бүген мин үз өемдә кунам»,— дип шатланып әйтте. Капитанның чырае сытылды:

— Вон куперчектән! — дип кычкырды ул боцманга.— «Өемдә кунам» имеш... Күрәзә!

Кич белән Одесса рейдына килеп җитеп, якорь ташладык. Портта буш причал юк иде. Керергә рөхсәт бирмәделәр. Рөхсәт итүләрен ике тәүлек көтәргә туры килде. Портка әләгә алмауны капитан боцманның алдан күрәзәлек итүенә ягып калдырды. Инану логикага бәйләнмәгән шул.

Яшь чагында Миронов, матрос булып, инглиз корабында йөзгән. Патша заманында теләсә кайсы илдә эшләргә рөхсәт ителгән булганга, штурман дипломын алганнан соң ул шактый озак вакыт Италия, Мисыр һәм Франция флаглары астында йөзүче корабларда ялланып эшләгән. Капитан биш телдә иркен сөйләшә иде.

Диңгез мәкерле ул. Кайчак ул синең өмет-хыялларың, корып куйган планнарың белән һич исәпләшми, аларны көтмәгәндә кинәт җимерә дә ташлый. Кырык ел диңгездә эшләгән иде Василий Степанович. Шул вакыт эчендә аның ничә тапкыр өмет, хыяллары җимерелеп юкка чыккандыр? Ул шулай, әкренләп, диңгездә кешеләрнең өметләрен җимереп, юкка чыгарып торучы ниндидер иләһи көч барлыгына инана башлаган, күрәсең. Шуннан инде ниндидер планнар корып, планнарның тормышка ашуын көтмәскә өйрәнгән. Чыннан да, диңгездә йөзгәндә, синең алдан корып куйган планнарың бик сирәк очракларда гына тормышка аша.

Диңгездәге тормыш гаҗәп кырыс. Шул кырыслыкны бераз төрле эш-гамәл белән йомшарта беләсең икән, син — бәхетле. Берәүләр китап укый, икенчеләр домино уйный, өченчеләр кораб моделе, рәсем ясап юана. Корабта чигү белән шөгыльләнүче, оекбаш, свитер бәйләүче, чыпта, кәрзин үрүче морякларны очратканым бар минем. Бернинди мавыгуы, өстәмә шөгыле булмаган диңгезче аш пешереп, балык тозлап, варенье кайнатып булса да юанырга тырыша. Капитан Миронов әнә шундый «шөгыльле» кешеләрдән берсе иде. Буш вакытын камбузда, плитә янында кайнашып уздыра иде ул. Җир йөзендә ничәмә-ничә мең төрле милләт-халык бар. Аларның барысының да үзләре генә белгән тәмле аш пешерү серләре бар. Шуларның күбесен Василий Степанович белә иде. Танышкан көнне үк ул миңа татар ашлары турында дулкынланып сөйләргә кереште. Чибәрәк, азу, бәлеш, өчпочмак, сумса,

---

[1] Кнехт — швартов бавын беркетә торган җайланма.

тутырган тавык, казылык... Шулай да казанлыларның ашлары кырым татарларыныкыннан аерымрак булуын ул белмәгән икән. Мин капитанга гөбәдия, кыстыбый, катлама, боламык, каклаган каз, карта бәлеше турында сөйләдем. Шуларны пешереп карамыйча тынычланмады Василий Степанович. Һәм шул ашларны татып караганнан соң капитанның татарларга карата ихтирамы тагы да артты:

— Яши белгән бу халык, ә! Мондый тәмле ашлар әзерли белгән халык культурасыз булмаска тиеш,— дип сабыйларча куанып йөрде.

Һәм бер мәртәбә, Поти портында торганда, ул мине шәһәргә алып чыкты. Тәвәккәл һәм хирес атлап китте ул:

— Лачын (яшь диңгезчеләргә ул шулай дәшә иде), мин сине бер җиргә алып барам.

Ярты сәгать чамасы бардык. Шәһәрдән чыгарак, бер кечкенә таш кибеткә кердек. Кибеттә, тузанга батып, авыл хуҗалыгы кораллары — сәнәк, чалгы, ураклар аунап ята. Сатучы, шәрык кешеләренә хас хисләнү белән дөрләп кабынды да, Василий Степановичны кочаклап алды. Учлары белән бер-берсенең аркаларына суккалап, бик озак аһ-ваһ килеп, тел шартлатып тордылар, шушындый бәхетле очрашуга хәйран калып, бот чабып, кычкырып сокланыштылар.

Кибетче безне базга алып төште. Капитан аның белән төрекчә сөйләшә иде. Базга төшкәч, кибетче, татарчага күчеп, утырырга кушты һәм елмаеп сорады:

— Үз телеңне әллә белмәстерсеңме, нәмә дәшмисеңдер?

Ул чакта татарча сөйләшергә ояла идем мин. Чит милләтләр арасында, бигрәк тә тупасрак кешеләр арасында яшәгәндә, үз телеңдә сөйләшергә тартынасың. Ишетсәләр, өнәмәсләр, әллә ни уйларлар дип шөллисең. Безнең канга ниндидер тирән курку сеңеп калган. Әллә ниндиастыртын, сәбәпсез курку. Шул тойгы үз гадәтләреңне тотарга, үз кыйблаңны сакларга комачаулый.

Һава тынчу. Күктә субтропик кояшы. Тышта — мунча һавасы, подвалда салкынча иде. Гаҗәп тыныч, рәхәт иде монда. Таш подвалның ярты өлешен йөз чиләк керешле зур имән мичкә, һәркайсы илле, егерме биш, унике, алты, өч чиләк керешле вак пар мичкәләр алып тора иде. Шәрабне мичкәдән агызганда, аның эченә һава керә, вино ачый. Шуңа күрә кулланыр алдыннан шәрабне икенә бүлеп бәләкәйрәк мичкәләргә агызалар.

Агач өстәл. Дүрт урындык. Өстәлдә кызарып пешкән озынча помидорлар, хуш ис таратып торган ләвеш, йөзем тәлгәшләре, сулугуни һәм балчыктан ясалган кружкалар. Өстән, түшәмгә тиеп торган бәләкәй түгәрәк тәрәзәдән кояш нуры кереп, ул подвалның сыек караңгылыгын кыйгачлап тишеп чыккан. Яктылык баганасында миллионлаган тузан бөртекләре биеп тора. Капитан белән кибетче һаман төрекчә сөйләшәләр. Ә мин газапланам.

— Син, лачын, чын шәраб эчеп караганың бармы? — дип сорады Василий Степанович, русчага күчеп.— Юк, сез хәзерге заман моряклары, тәм өчен, ләззәт өчен эчә белмисез. Сез исерер, исерек баштан шапырыныр өчен генә эчәсез. Градус кирәк сезгә, сугып аяктан ега торган алкоголь дәһшәте кирәк.

Подвал хуҗасы почмакта торган кечкенә мичкәдән озын муенлы чүлмәккә шәраб агызырга керешә. Карасу кызыл ахакка, анар ташына охшашлы йөзем суы, агып төшкәндә, тоныкь ниндидер тылсымлы тавыш чыгарып чупылдый иде.

— Вино кеше шикелле ул,— дип дәвам итте капитан Миронов.— Аның акыллысы-акылсызы, затлысы-арзанлысы, дусы-дошманы бар. Адәм баласының холкы нинди шартларга бәйле? Иң әүвәл, кешенең токымына. Безне токымсызлык харап итә. Токымсыз кешегә белем бир, аны зур чинга күтәр, күкрәген тутырып, орденнар так, шөһрәт-

данга төреп ташла. Әгәр ул барахло икән, барахло килеш калачак. Шәхесне токым ясый. Аннан соң — нәсел, тәрбия, әхлак атмосферасы, яшәгән урыны, эше, белеме. Вино да шундый. Лаеклы винога әверелсен өчен, виноградка — токым, нәсел, затлы урында, әйбәт кеше тәрбиясендә үсү кирәк. Җыйган җимешне винога талантлы кеше әверелдерергә тиеш. Асыл винонгы авызыңа капсаң, тәнеңә кояш нурлары тарала. Шәрабка даладан искән саф таң җиле, виноград җыючы кызларның елмаюлары, кошлар сайравы, дулкыннар тавышы сеңгән була. Син шуларның барысын да эчәсең. Аңладыңмы, лачын?

Хуҗа өстәлдәге чүлмәк кружкаларга шәраб агыза башлаган иде, Василий Степанович туктатты:

— Мостафа, син миңа стаканга салып бир. Эчкәндә мин аның төсен күрергә тиеш. Хванчхара чын /ахактан да матуррак була — мин беләм.

Капитан эсәрләнгән иде. Аның мондый чагын күргәнем юк иде әле.

Мостафа, өстәл тартмасыннан борынгы пыяла стакан чыгарып, шәрабне шуңа салып бирде.

— Елмаюларыбыз табигый, шатлык мул булсын өчен,— диде капитан, стаканын күзенә якынайтып. Һәм стакан читен иренәнә тидереп тә өлгермәде, келт итеп пыяласы чатнады. Капитанның түшенә, чалбар балагына, подвал идәненә канга охшашлы шәраб түгелде. Уелып төшкән стакан төбе җир идәндә җәйрап ята иде.

Капитан елмаерга тырышып карады һәм кинәт агарды, ияге асылынып төште, күзләре шарланды. Чыраенда кан бөртеге калмады. Хәлсез куллары дерелдәп, асылынып тора иде.

— Нәрсә бу? Нилектән бу, ә? Ризыгым бетте микәнни?

Подвал хуҗасы яңа стакан алды, яңадан вино агызып бирде. Ескен капитанның шәраб тәмен сизәр хәле калмаган иде.

Без, ашык-пошык саубуллашып, корабка кайтып киттек.

Капитан йокысыз төн үткәрде. Икенче көнне, диңгезгә чыгар өчен күперчеккә күтәрелгәндә, ул тәмам картайган, йончулы кыяфәттә күренә иде. Кораб белән идарә итәрлек хәле калмаган иде аның. Без көчкә порттан чыга алдык.

Ул чакта миңа капитанның надан карчыклар шикелле кылануы көлке тоелган иде. Хәзер уйлыйм — авызыма китергән стаканның төбе төшсә, мин үзем дә куркып-шөбһәләнеп калган булыр идем. Гомер кыскарган саен, шик, хорафатларга ышану көчәя бара икән ул. Без барыбыз да адәм балалары бит...

Капитан Иван Андреевич Белов белән мин унбер ел бергә эшләдем. Аның белән күпме шатлык, күпме авырлык уртаклашылгандыр? Актык сынык икмәкне дигәндәй урталай бүлеп, соңгы йотым суны да уртаклап эчәргә туры килде безгә. Безнең семьялар да бер гаилә булып, бер табыннан ашап яшәделәр. Очраттыммы икән мин тагын андый гадел, намуслы, кешелекле адәмне?

Капитан Беловның да бер сәер ягы бар иде: ул пароходчылыкта һәм башка идарә итү учреждениеләрендә эшләүчеләрдән шөлли иде. Житәкчерәк кеше күрү белән югалып кала, тәмам таралып төшә. Урыны капитанныкыннан түбән булган, җитәкчеләр тирәсендә чуалучылардан курка иде Иван Андреевич. Шунлыктанмы, гаҗәп оста кораб йөртүчене рәсми рәвештә мактаучы да, күтәрүче, күрсәткән эшләрен телгә алучы да булмады.

Аның җитәкчерәк кешедән өркүенә карап, бу булдыксыз, җебегән капитандыр дип уйлыйлар иде.

Хәтеремдә бер вакыйга сакланып калган. Төн урталарында Гибралтар бугазыннан Атлантик океанга чыгып киләбез. Пароходка ток биреп торган динамомашина кинәт сафтан чыкты. Кораб — улеккә әйләнде. Гирокомпас әйләнми, руль эшләми башлады, навигация утлары

сүнде. Аккумуляторга көйләнгән аварийный ут юк иде пароходта. Штурманнар, керосин фонаре яндырырга шырпы таба алмыйча, әрлебирле чабышып йөриләр. Ниһаять, шырпы таптылар, әмма ут кабыза алмадылар. Фонарьның керосины беткән булып чыкты. Гигант танкер безгә туп-туры якынлаша. Өч минут — ул безне урталайга өзеп китәчәк иде. Вахтадагы штурман, башка чакта шактый тәвәккәл кеше — нишләргә белмичә югалып калды. Ул күперчектә әрле-бирле йөгереп йөри. Шул чакта Иван Андреевич, күперчеккә күтәрелеп, тыныч кына машина телеграфын «полный назад»ка күчереп куйды. Гигант танкер, безгә бәрелә язып, янәшәдән узып китте. Аның җиле биткә бәрелеп калды. Эшендә капитан Белов кыю, тәвәккәл кеше иде.

Хәзер Иван Андреевич пенсиядә. Ул гомер буе бакча үстерү турында хыялланып йөрде. Һәм пенсиягә чыгар вакыт җиткәнен зарыгып көтә иде. Пенсиягә чыкты, әмма юашлыгы аркасында бакча ала алмады. Ул хәзер йорт эшендә: базарга, магазиннарга йөри, семьясына аш әзерли, һаман әле бакча үстерү турында хыяллана.

Капитанлыкка гел Миронов, Белов шикелле кешеләр генә куелып торса, беренче ярдәмче булып эшләүнең авырлыгы да булмас иде.

Капитан вазифасының нинди катлаулы булуын тагын бер нәрсәдән күрергә була: алтмыш яшькә җитеп, пенсиягә чыкмаган капитаннар корабта чиктән тыш сирәк очрый.

## Насыйрбашев

«Матвей Муранов»ның капитаны Булат Җамалович Насыйрбашевны күптәннән күреп белсәм дә, моңа кадәр безнең бергә эшләгән юк иде. Аның исеме — газета битләреннән, рәсеме Мактау тактасыннан төшми, үзе дә ул дан-шөһрәтне ярата торган кешеләрдән иде. Аның юмартлыгы, горурлыгы турында бернинди фантазиягә сыймаслык анекдотлар сөйлиләр иде.

Кавказлылар арасында андый кешеләр еш очрый. Аларның тар кагыйдәгә сыймый торган киң колачлы гадәтләрендә теләсә нинди капма-каршылыклар бергә сыеша ала. Алар кыланса да, барысы да килешә аларга.

Кавказлылар, чыннан да, югары сыйфатлы җете буяуга буялган шикелле ерактан ялтырап күзгә ташланып торалар. Нилектән бу?

Шәрык халкы бала ярата. Аларда сабый баланы башта бик иркәлиләр, сөяләр, назлыйлар, аңа ни теләсә шуны рөхсәт итәләр. Бала яшеннән үсмер яшькә күчкәч, киресенчә, аны каты кулда тоталар. Әммә бала чактагы наз-иркәләүләр, кайнар яратулар аның табигатенә инде сеңеп өлгергән була. Шунлыктан, гомер буе аның йөзе балкып тора, табигате юмарт ярату хисе белән сугарылган була.

Булат Җамалович белән без кадрлар бүлегендә очраштык. Без берберебезне күптән яратышып йөргәнбез булса кирәк — кочаклашмыйча түзә алмадык.

Грузиннар югары урыннарда эшләгән дәрәҗәле кешеләр турында энәсеннән-җебенә кадәр белергә тырышалар. Капитан, күрәсең, мин Мәскәүдә эшләгән чакта ук минем белән якыннан кызыксынып, мине өйрәнеп йөргән. Ул минем биографияне шактый яхшы сукалый иде. Бәйрәм ашы кара-каршы: мин дә аның барлык орден-медальләрен әйтеп, күрсәткән геройлыкларын санап чыктым. Ошадык бер-беребезгә. Салпы якка салам кыстыру кемгә ошамый?

Элегрәк очрашкан вакытларда Насыйрбашев искиткеч чибәр кеше булып истә калган иде. Бу очрашуда ул бераз шиңгән, тоныклангандай күренде.

Каршымда уртачадан тәбәнәгрәк (элек ул шактый озын булып күренә иде) кеше басып тора. Юка гына маңгай. Зур борын. Төссез, кояшта уңган каш-күз. Өстәвенә, берөзлексез кулы дерелди. Кызганыч булып китте: абруй зур, түш тулы орден, тәҗрибә мул, квартир әйбәт, кием-салым затлы. Синең яшь чактагы теләкләреңнең барсы да үтәлгән. Ә нигәдер куанычы юк?! Картаю — тозсыз ашны хәтерләтә. Аш— каз шулпасы, сөләйман балыгы салып пешергән уха булуы мөмкин, ләкин тозы булмаганлыктан, аның тәме юк, тәмен картаю алган. Капитанга карап, мин шушы турыда уйлап куйдым.

Кадрлар бүлегендә эшне көч-хәл белән бетереп, без корабка юл тотабыз. Очраган бер кеше Насыйрбашев белән кул биреп күрешә. Без ашыгабыз. Вакыт тар. Ә капитанны адым саен диярлек туктатып, сөйләштереп торалар.

— Бусы кем? — дип сорыйм.

— Портта эшли. Йөк төяүче. Аның хатынының абыйсы башкарма комитетта бүлек начальнигы булып утыра.

Аңлашылды.

— Ә бусы?

— Прокурор кияве.

Капитанның прокурор кияве белән танышлыгы миңа сәер тоела. Сискәнеп китәм:

— Каян беләсез сез ул прокурор киявен?

— Шәһәрнең баш хирургы аркылы. Шуларда мәҗлестә утырганда таныштык.

— Ә баш хирург мәҗлесенә ничек эләктегез?

— Универмаг директоры алып барды.

Башка сорашмыйм. Татарның «...дус-иш кирәк дөнья күтәргә...»се биш йөз елдан соң да һаман актуаль яңгырый. Еш кына мәҗлесләр ачык бер максат белән оеша башладылар. Диссертация яклаудан алып бәрәңге кайтарыр өчен машина сорауга кадәр — барысын да мәҗлестә хәл итәргә омтылалар.

— Соңгысы кем булды? — дип сорыйм, капитанның бу танышы прокурорга да, пароходчылыкта эшләүчегә дә охшамаганын күреп.

— Кем белгән инде.

— Соң бит, танышлар шикелле сөйләштегез.

— Кызганычка каршы, мине таныйлар. Һәр адымымны белеп торалар.

Шул чак миңа күренекле кешеләр тормышының бер уңайсыз ягы ачыкланып киткәндәй булды. Капитан Насыйрбашевны бөтен Жданов белә. Ждановта гына түгел, аны Кара диңгез, Азов портларының һәркайсында да беләләр. Рәсеме шәһәрнең мактау тактасыннан төшми, аның турында елына берничә тапкыр газетага язалар, миф, легендалар чыгарып торалар. Без әкиятсез яши алмыйбыз бит. Мифсыз көндәлек тормыш майламаган арба шикелле шыгырдый башлый. Миф кешегә сокланырлык матур сыйфатлар тага. Ә чынбарлыкта ул үзе тормыш ыгы-зыгысында безнеңчә яши.

Корабтагы йөкне Сомали порты Берберага илтергә дип төйи башлаганнар иде. Йөк төялгән арада ике ил арасындагы мөнәсәбәтләр үзгәреп, безгә мәгълүм булмаган яңалыклар барлыкка килде. Йөк төялеп бетүгә, рейс үзгәргән иде инде. Хәзер безне Мисыр порты Александриягә җибәрергә булдылар. Димәк, юл кыскара. Александрия — «Матвей Муранов» шикелле корабка өч тәүлеклек юл. Әгәр теплоходны вакытында портка кертеп, вакытында бушатып өлгерсәләр, ике атнадан без яңадан туган илгә әйләнеп кайтырга тиешбез. Моңа куанырга кирәк иде. Ләкин диңгезчеләрне бу хәл шатландырмады. Хикмәт шунда: безнең моряклар Мисырга баруны яратмыйлар. Мисыр — Шәрык иле. Шәрык исә катлаулы, аңлашылмый торган дөнья ул без-

гә. Диңгезчеләр генә түгел, күп кеше аңлап бетерми Шәрыкны.
Төнге өчтә, йокының иң тәмле чагында, чикне яптылар. Кораб урыныннан кузгалды. Шәһәр утлары әкрен генә бездән ерагая, караңгылыкка кереп югала башлады. Йөрәкне аянычлы авыр тойгы — аерылышу, югалту тойгысы чорнап алды.
Язмыш мине тагын диңгез кулына китереп тапшырды. Мин — диңгез кочагында.

## Бугаз эче

Азов диңгезе давылдан соң ял итә иде. Аның көрән суы винт астыннан актарылып чыга да, күбекләнеп, кайнап кала. Кораб артыннан сызылып калган кильватер эзе диңгез сөрергә чыккан сабанчының беренче буразнасын хәтерләтә. Чәрелдәшеп, винт миңгерәүләткән балыкларны арттан чүпләп килүче комсыз акчарлаклар да сабанчыга ияргән каргаларны хәтерләтәләр.
Көзге диңгезнең тынычлыгы озакка бармый. Керчь бугазына житкәндә янәдән жил кузгалды. Кара диңгездә тугыз баллы норд-ост шашынып дулкын куа иде. Дулкыннар котырган эт өеренә охшап теплоходка ташланалар. Дулкын корабка бәрелеп ватыла да, авыр тамчыларга әйләнеп, югарыга томырыла. Ике бармак калынлыгы иллюминатор пыяласы шытырдап куя. Кораб ыңгыраша. Нәрсәдер гөрселдәп ава. Һавага очкан эре тамчылар бергә кушылып, кире кораб өстенә явалар. Иллюминатор пыяласыннан туктаусыз су ага. Пыяладан аккан су шәфкать сорап, ялварып елаган корабның күз яшен хәтерләтә.
«Матвей Муранов» юлын дәвам итә. Бу минутта ул миңа ничектер кызганыч тоелды. Жылы толыпка чумып чанада барганда, буран аша алга атлаучы атны шулай кызганасың.
Алда — Босфор, аннан соң ят диңгезләр, чит илләр. Артта — ярда калган тыныч тормыш, үткән гомер, искә төшкәндә йөрәкне ачыттырып алган аянычлы истәлекләр...
Аста, машина бүлегендә, тешләрен шакылдатып ач бүреләр үкерә сыман. Двигатель клапаннарының тавышы бу. Ә каютада тыныч. Каюта стенасын тышкы яктан жил талый, диңгез кыйный. Алар әчкә үтеп керә алмыйлар. Шушы ике дәһшәтнең синең яныңа керергә көчләре житмәве күңелдә ышаныч уята.
Диңгез өстендә үзара куышып, шашынып йөгерешкән ак яллы яшькелт дулкыннар ару-талуны белми шаулыйлар да шаулыйлар.
Күк йөзендә авыр, алама болытлар агыла. Алар да каядыр ашыгалар. Аларның офык читенә китеп күздән югалулары ямансу уйлар уята. Диңгездә күмәк, гаилә тормышы белән бердәм яшисең. Ләкин күмәк яшәү генә диңгездәге ялгызлыкны бетерә алмый. Үзеңне туган жирдән еракта тою күңелдә юксыну хисе тудыра. Бу тойгыдан берничек тә котылып булмый. Кают-компаниягә жыелып ләчтит сатасыңмы, кызыл почмакта, дөньяны онытып, домино сугасыңмы, кичләрен ашханәдә кино карап утырасыңмы — барыбер, корабның һәр почмагында сине әлеге күмәк ялгызлык хисе сагалап тора.
Диңгезчелекнең шушы михнәтеннән бары тик фатирыңа кайтып гаилә тормышына яшеренеп кенә котыла аласың. Ә анда икенче төрле тынычсызлык: кухнядагы кран су жибәрә, бәрәңге беткән, кызыңның итеге тишелгән, хатының эштә, ул кайтуга аш әзерлисе бар. Гомер буе нәрсәдер житми адәм баласына. Туган көннән алып үлгәнче, күңелдә даими бер мохтажлык яши. Шул мохтажлыкны жиңә белү генә бәхеткә ирештерә.
Диңгездә үткән көннәр корабка таба тәгәрәп килгән дулкыннарга

охшаганнар. Ерактан киләләр, шаулап ватылалар, эзсез юкка чыгалар. Аларның каян килгәне дә, кая киткәне дә билгесез. Аткан таңның, сүнгән шәфәкъның кирәкме-түгелме икәнен дә аңлап булмый. Көннәр эз калдырмыйча, синең тәкъдиреңь аша үтә, югала торалар. Хәтта гомернең кими барганын да сизмисең. Гомер кыскаруына ышанасың да килми — ышанмау отышлырак.

Сәяхәттә йөргәндә, син нәрсәдер табасың шикелле, карасаң йөргән арада зур бер кисәк гомерең үтеп тә киткән. Хәер, өйдә утырганда да гомер тиз үтә. Аерма тик шунда: өйдә утырганда көнләп уза, сәяхәттә — айлап, еллап. Ерак юлдан әйләнеп кайткан арада өч-дүрт аең төтен булып очкан була.

Алсу шәрык таңы нурларында әнә алда серле Босфор да күренде. Таң пәрдәсе артыннан әкияткә төренгән ярлар чыгып килә. Уңда — су эчендә басып торган көрән кыялар. Аларны ашыкмыйча гына дулкын кыйный. Таш кыялар артында, өстәрәк, көрәнсу йортлар, киптерергә элгән ятьмәләр, каплап куйган көймәләр. Таң нурларына төренгән сылу ак манара — Румели маягы.

Ярлар тоташ әле, шунлыктан бугазга керү юлы күренми. Сулдарак, Азия ягындагы яр читендә, томанга төренеп, Кара диңгездән килгән корабларга Анадолу маягы сәерсенеп карап тора. Маяк артыннан текә калкулык башлана. Калкулык сыртында соры томан аша, тылсымлы шәүлә булып, борынгы ныгытма — кальга төсмерләнә.

Төрекләр Босфорны «Бугаз эче» дип йөртәләр. Якынлашкан саен, Бугаз эче киңрәк ачыла бара. Аргонавтлар да шушы урынга якынлашканда, тауларның урыннарыннан кузгалып, әкрен генә киңәеп ачыла башлаганын күргәннәрдер, мөгаен. Таулар ачылып киткәч, балачак әкиятләрендәгегә охшаш каланың әкрен генә сиңа таба якынлашканын күрәсең. Ул да булмый, яр ягыннан корабны каршыларга давыл хәбәрчеләре һавага күтәрелә. Алар, очып килеп, теплоходны әйләнеп узалар да, алга чыгып, Бугаз эченә керергә юл күрсәтеп бара башлыйлар. Көрән кыялар янына җиткәч, кошлар, дәррәү борылып, кирегә — башка корабны каршыларга китәләр...

Бу изге эшкә аларны кем өйрәткән икән? Каян беләләр икән алар диңгезчеләрнең кош сагынганын? Давыл кошларының очуы гаҗәеп күренеш. Алар унбишәр, егермешәр булып бер сафка тезеләләр; аралары тигез, артка калучы да, алга чыгучы да юк — шундый бердәм, шулкадәр күмәк оча беләләр! Очканда, аларның канатлары диңгез өстен сызып бара. Тигез сафта җитез канатларын сызгыртып, тирәякка шатлык таратып очалар давыл хәбәрчеләре. Сокланудан пульс үзгәрә, йөрәк ярсыбрак тибә башлый.

Моннан тугыз ел элек соңгы сәяхәттән кайтканда да мине давыл кошлары озатып калган иде. Бу юлы алар әнә каршыларга чыкканнар. Менә бит нинди алардагы тугрылык хисе!

Мин югында Бугаз эче бер мыскал да үзгәрмәгән шикелле. Калкулык сыртындагы борынгы таш ныгытма-кальга әүвәлгечә үз урынында тора. Аңа хәзер ничә яшь икән?

Яр буенда кармак салып утыручы төрек картын беренче мәртәбә мин моннан егерме өч ел элек күргән идем. Ул да урыныннан кузгалмаган шикелле. Күңелдә — яңадан тетрәнү. Егерме өч ел буе гел бер урында балык тотып утырган микәнни? Юк, бу икенче кеше, әлбәттә. Минем беренче күргән балыкчым инде күптән кара җиргә кергәндер. Яшәү тукталмый. Картлар урынына яшьләр килә. Әкренләп алары да картая. Кеше китә, буын кала.

Кулыма бинокль алам, карыйм. Кармак салып утыручы минем беренче күргән картка бик охшаган.

Бала чакта ук мине бер хәл хәйран калдыра иде. Безнең Исергәп кешеләрендә бәхет эзләп читкә китү гадәте бар. Уналтынчы гасырдан

ук башланган котылгысыз гадәт. Берничә елдан сагыну хисе бу читкә китүчеләрне кире авылга куып кайтара. Ләкин алар шул берничә ел эчендә инде үзгәреп өлгерәләр: Донбасста эшләгәннәре — украинга, Урта Азиядәгеләр үзбәккә охшаган булалар. Кайтып күпмедер вакыт узганнан соң карыйсың: ул охшашлык янә юкка чыга, алар тагын безнең Исергәп кешеләренә әйләнәләр.

Босфор буендагы балыкчыларның яшәү шартлары, теләкләре, өметләре — уртак, бер төрле. Шунлыктан үзләре дә бер-берсенә охшаш булалар, күрәсең.

Бугаз ярлары әкрен генә артка таба шуыша. Европа ярында моңсу кипарислар күренде. Безнең Кавказ искә төште, анда да шундый кипарислар үсә... Кипарислар алар тол калган солдат хатыннарын хәтерләтәләр. Ирексездән: «Җир йөзендә гореф-гадәтләрен югалтудан тол калган халыклар да бар бит әле»,— дип уйлап куйдым. Кеше өчен иң каһәрле, каргышлы язмыш — ул милли горурлык хисенең үтерелүе. Милли горурлык хисен югалткан халык яши алмый, үлә, юкка чыга.

Әнә зират. Ак мәрмәрдән куелган кабер ташлары суга карап моңаеп утыралар.

Зиратны шул ук боек кипарислар — кайгы-хәсрәт символлары урап алган. Янә Кавказ искә төшә. Безнең Татарстанда үсәр идеме икән кипарис? Үссә, шуны алып кайтып, әниемнең кабере өстенә утыртыр идем.

Кипарислы зираттан соң чинар, каштан һәм хөрмә агачлары урманчыгы башлана. Бакча уртасында утырган төнге клуб. Кабаре. Чәлтәрле койма эчендә пөхтә коттедж. Кечкенә генә ике манаралы ак таш мәчет. Ат сыны. Мәрмәрдән ясалган. Ялгыз ат һәйкәлен беренче күрүем иде. Гадәттә ат сыртына патшалар, генераллар, башкисәр геройлар атланган була. Күп очракта ат сыны хөкемдар утырган урындык хезмәтен үти. Ә төрекләр, атның тугрылыгын, акылын һәм хезмәтен данлап, аның махсус үзенә һәйкәл куйганнар.

Шәһәр читендәге аулак бакчалар, мең төрле ханәләр, мең ысулда күңел ачу вәсвәсәсен тәкъдим итеп, кул сузып, ымсындырып артта калдылар. Алда — мәһабәт манаралар. Зифа буйлы, очлы мөгезләре белән болытларны сөзеп торган Истамбул манаралары. Аларның күбесен яңартканнар. Моннан тугыз ел элек Галата чардагының очы сынык иде — төзәткәннәр.

Кояш Азия ягыннан күтәрелеп килә. Алсу нурлары Европа ярындагы йөзләгән манараларның ярым ай сурәтләрендә чагылып балкый.

Истамбулның манараларын кисеп ташласаң, нәрсә булыр иде икән? Манарасыз яшәргә күнегерләр иде микән төрекләр? Кем чыгарды икән мәчетне манаралы итеп салуны? Мәшәкатьле авыр эш бит биек манара утырту, һәм тормыш-көнкүреш өчен аның кирәге дә шулкадәрле генә. Әнә, су басымы өчен куелган башнялар — алар файдалы. Ә манара — бер кирәксезгә тырпаеп утыра.

Әмма Истамбул манаралары — чын мәгънәсендә шәһәрнең күрке, йөзе, горурлыгы. Болытларга кадәр муеннарын сузып торган бу манаралар: «Күрегез, бу шәһәрдә безне төзи алырлык даһи осталар яшәде!» — дип горурланып, «Исламгол» данын җир шарының төрле почмакларына таратып торалар. Биек манара төзү — адәм баласының күккә менү хыялының бер чагылышыдыр. Манара салу — күзаллау офыкларын киңәйтергә тырышу юлындагы бер этап. Самолетны манара төзүчеләр токымыннан туган кеше уйлап чыгаргандыр дип уйлыйм мин.

Мин күрми торган арада төрек җире үзгәргән, бу илгә дә яңалыклар өстәлгән.

Истамбул һәм аның тирәсендәге дача поселоклары үскәннәр, киңәйгәннәр. Ун-унбиш ел элек бугаз эченә керү белән Европа ярындагы

Бөек Лиман, Яңа Мәхәллә, Бөекдере, Еникәй, Истинья, Арнауыткой ише кечкенә авыллар чинар агачлары, яшел чирәм каплаган калкулыклар арасында югалып утыралар иде. Ул чакта Бугаз эченең ярлары тулысынча диярлек урман, җимеш бакчалары, эшкәртелгән басу-җирләрдән тора иде. Истамбул шәһәре үзе Уртакой дигән урынга килеп туктаган иде. Ә хәзер авыллар үзара тоташып, калага кушылганнар. Яңа дачалар, биек йортлар, коттеджлар барлыкка килгән. Бакчалар кимегән, кырлар өстенә асфальт җәйгән урамнар сузылган. Шушы хәлне күргәч, шәһәрләшүнең нәрсә икәнлеген аңлый башлыйсың.

Тагын бер хәл уйланырга мәҗбүр итте. Яңа Мәхәллә дигән поселоктан бераз читтәрәк, тимер-бетон каркаслы ак плитәләр белән тышлап, яңа йорт салалар. Ике катлы йорт: аста гараж, өч яклап верандалар, як-ягында чәчәкләр утыртыр өчен ясалган түтәл-мәйданчыклар. Ярлы кеше мондый йорт сала алмый, билгеле. Мин моны беләм, ә шулай да гаҗәпләндерә — үз көчең белән менә шундый йортлар салу мөмкинлеге гаҗәпләндерә. Гомер буе үз кулым белән салган йортта яшәү турында хыялландым. Акчаны мул алып эшләдем, ләкин йорт салырга көчем җитмәде дисәм, дөрес булмас иде — мөмкинлекләр булмады. Акчам булганда — урын бирмәделәр, урын табылган чакларда — төзү материаллары юк иде. Минем йөрәгемдә йорт төзүчеләргә карата кайнар ихтирам яши. Торак төзү миңа иң изге эш кебек тоела.

Тагын бер яңалык күзгә ташланды — төрекләр Босфор аша күпер салып өлгергәннәр. Безнең кораб күпергә якынлашып килә. Искиткеч зур, матур күпер.

Шул гигант күпер ярның Азия һәм Европа якларындагы капкага охшашлы пар баганаларына тимер аркан белән асып куелган. Гомеремдә минем мондый да озын, мондый да биек күпер күргәнем юк иде. Ә үзе карап торышка кечкенә, уенчык шикелле генә булып күренә. Архитектурасы төгәл, җыйнак булганга шулай ул.

Диңгезче халкы төпченергә, һәр үзгәрешнең асылын аңларга тырыша. Күпер турында төрек ярларын карарга машина бүлегеннән күтәрелгән моторист Иван Кучма сөйләп аңлатты:

— Ике ел эчендә төрекләр бар чыккан расходларын каплап өлгергәннәр. Түләүле күпер ул. Акча түләмичә аңа кертмиләр,— диде.

Күпер караудан туктап, Кучма фамилияле диңгезчене күзәтәм. Экипаж исемлегендә Дәрвиш, Рәхмәтуллин, Әфәндиев кебек сәер фамилияле рус егетләре бар.

Кучма сөйләгәнгә бик ышанасым да килми. Ләкин төрекләрнең Босфор аша күпер салуларын исбат итеп торасы юк — без хәзер шуның астыннан үтеп барабыз. Минем каютамда белешмәләр өелеп ята. Теләсәм, хәтта кечкенә бер Баулы районының утызынчы еллардан башлап шушы көнгә кадәр дәүләткә күпме сөт тапшыруын, аның киләсе бишьеллыкта күпме, ничә квадрат метр торак йортлар салачагын да белә алам.

Босфор аша салынган күперне барлык белешмәләрдән эзләп карадым — табып булмады.

Инде бу язмаларны редакциягә тапшырыр алдыннан минем кулга «Правда» газетасының корреспонденты Алексей Васильевның төрекләр турында язылган «Босфор аша салынган күпер» исемле китабы килеп керде. Анда әйтелгән: «Босфор аша салынган күпер Европа белән Азияне тоташтыра. Аны 1973 елның 30 октябрендә Төрек республикасының илле еллыгы көнендә ачтылар. Аның биеклеге 64, озынлыгы 1074 метр. Күперне төзүдә төрекләр, инглизләр, немецлар һәм японнар катнаштылар. Проектның төп авторы инглиз фирмасы «Фримен Фокс һәм партнерлары» инженеры Уильям Браун. Күпер җиңел һәм искиткеч матур күренә. Аның баганалары Стамбулның манаралары белән гар-

мониядә. Төрекләрнең кайберләре күперне транспорт төзелешенең, икенчеләре — яңа Төркиянең символы итеп санаилар».

Фок мачта күпергә тияр дә, я сынып төшәр, янсә без туктап калырбыз дип курыккан идем. Тугыз катлы йорт биеклеге «Матвей Муранов» нәкъ күпер астында. Тоташ ташкын булып күпердән машиналар агыла. Клотик[1] өстенә тагын бер мачта утыртсаң да күпергә тимәс иде. Ул шундый биек булып чыкты.

Күперне узуга каршыда янә давыл кошлары пәйда булды. Алар бер күтәрелделәр һәм ук кебек атылып түбән төштеләр. Суга кадалдылар дигәндә, дулкыннарны канатлары белән сыйпап, кире югарыга — зәңгәр биеклеккә күтәрелделәр.

Эх, давыл кошлары шикелле яшисе иде бу дөньяда. Матурлык өчен, хакыйкать һәм ирек өчен генә яшисе иде! Чын бәхет шундый яшәүдәдер бәлки?

Мин дә сагынган идем давыл кошларын. Аларның давыл белән кычкырыша-кычкырыша безне каршы алырга килүләре искә төшә. Бәлки, мине давыл кошларын сагыну хисе диңгезгә кире кайтаргандыр?

Чит илгә чыгу белән, миңа еш кына үзебезнең туган тел бик кирәк булып куя. Бу юлы да Босфорга керер алдыннан мине күперчеккә чакырдылар. Төрек лоцманы инглизчә бераз сукалый иде. Штурманнар, «тел белгән» өчен, ун процент өстәмә акча алалар. Ә тулысынча аңлашып сөйләшә белүче юк. Алар тел өйрәнү урынына имтихан бирергә өйрәнгәннәр.

Без төрек лоцманы белән мәш килеп сөйләшәбез: ул төрекчә, мин — татарча. Аңлыйбыз бер-беребезне. Аңлашу һәрвакыт куаныч тудыра. Без ихлас куанабыз.

Сорауларым күп иде. Тик иркенләп сөйләшеп булмый. Каршы килүче пароходларга юл бирергә, аркылы чыгучы көймәләрне урап узарга кирәк. Сөйләшүгә мавыгып китеп, кораб тирәсеннән үтеп торган көймәләрне батырып ташлавың бар. Шулай да беркадәр серләшеп алырга өлгердек. Аңлаша торгач, уртак танышларыбыз барлыгы да ачыкланды.

Алтмышынчы елларда «Чолым» пароходында мин бер Вахид исемле лоцман белән танышкан идем. Ул безне берничә тапкыр бугаз аша үткәреп җибәргән иде. Бер мәртәбә Босфорда аның белән Назыйм Хикмәт шигырьләре турында да сүз чыккан иде. Лоцман шул Вахид исемле кешенең улы икән. Штурманлыкка Франциядә укып диплом алган. Берничә ел Америка корабында эшләгән. Өйләнгәч, хатынын озакка ташлап китә алмаганлыктан, лоцман булып эшли башлаган. Исеме — Азиз.

Лоцман Азиз көләч табигатьле, зирәк кеше булып чыкты. Мине кунакка чакыра. Әтисе йорт сатып алып, авыл җиренә күчеп киткән.

«Әти белән Назыйм Хикмәт турында гәпләшерсез. Ул татар шигырьләре белән дә кызыксына. Мин күбрәк Европа әдипләрен укыйм. Шулай да татарларның Дәрдмәнд, Тукай атлы шагыйрьләре барлыгын әтиемнән ишетеп беләм. Шулар турында иркенләп сөйләшерсез»,— ди. Рәхмәт әйтеп, баш тартам. Төркиядә кунакка йөрүнең бик катлаулы икәнлеген аңлатуы кыен. «Врачлар Кырымда ял итәргә киңәш бирәләр. Мин ел саен шунда барам»,— дим. Төрек лоцманы елмая: «Бугаз эче климаты нәкъ Кырымныкы шикелле,— ди.— Безнең һава һичшиксез килешәчәк». «Бәлки килеп тә чыгармын әле,— дигән булам.— Алдан план корып куярга яратмыйм».

Истамбул шәһәре шактый яңарган. Галата өлешендә егерме бишәр катлы йортлар калкып чыккан. Алар «мәңгелек» каланың панора-

[1] Мачта очы.

масын боза алмыйча, иске ысулга буйсынганнар. Шәрыкның сылу нәзберек архитектурасы беркайчан югалмаячак.

«Исламгол»ның тарихи өлеше — Бәйоглы һәм Кече Базар тирәләренең бер тамчы үзгәрмичә электәгечә калуына чын күңелдән куандым. Әнә солтан Әхмәт салдырган Зәңгәр мәчет. Урта гөмбәз тирәсенә сырышкан нефлар, бина әйләнәсендә ярым айларын зәңгәр күккә чөеп утыручы кызлар сыныдай зифа алты манара. Мәчет эченә өч йөз алтмыш витраж тәрәзәләрдән салават күперенә охшашлы нурлар коела. Мин шул нурларга чумып, Идел буеннан килеп шушы мәчеттә белем алучылар турында уйланып утырган идем бер тапкыр.

Шушындый мәһабәт, мәгърур манаралар кешенең рухи дөньясына да көчле тәэсир ясый торгандыр күрәсең.

Айя-Суфия дә үз урынында. Инде ничә гасырлар Айя-Суфия белән Зәңгәр мәчет үзара беренчелекне даулап, ярышып утыралар. Мөселманнар Зәңгәр мәчетне яраталар, христианнарга Айя-Суфия күркәмрәк күренә.

Византия греклары салган храмны мәчеткә көйләгән чакта аны пакьләндерү өчен төрекләр собор эчен роза чәчәге мае белән юганнар. Ничә тонна май тотылганы хәтеремдә калмаган. Хак-бәя белән эш итәргә яратучылар шул кыйммәтле май бәрабәренә Айя-Суфия зурлыгы тагын ике мәчет салып булыр иде дип офтаналар. Без, исергәпләләр, нәкъ шулай, мәчет эчен роза мае белән юучылар шикелле кыланырга яратабыз. Баламишкинлыкның бер төре бу.

Әнә Истамбул базары. Анда елан мөгезе, күгәрчен сөте һәм кешене мәңге унҗиде яшьтә саклый торган бәлзәмне дә табып була диләр. Нәрсә белән генә сәүдә итми мәшһүр базар! Аның турында нәрсә генә сөйләмиләр! Бер мәртәбә «дуслык» визиты белән килгән Америка авианосецының электрон-хисап аппараты ватылган, имеш. Бу дөньядагы бердәнбер уникаль аппарат булган. Авианосецның өлкән инженеры исерек баштан, эчен бушатыр өчен, базар картларына аппаратның ватылуы һәм шуның аркасында эшеннән куылачагы турында зарланып сөйләгән, имеш. «Карап карарбыз, өч көннән кил»,— дигәннәр картлар. Инженер ышанмаган, шулай да базар картлары янына сугылып чыгарга ниятләгән. Аның килүенә Истамбул базары әһелләре нәкъ шундый яңа электрон-хисаплау аппараты әзерләп куйганнар, имеш.

Кораб Мәскәүдәге Оружейная палатага охшашлы Төпкапы музее янына килеп җитте. Якында Истамбулның ике университеты һәм бер юлы биш үгез түшкәсен кыздырып пешерергә көйләнгән Сөләйман солтан Кануниның гигант ашханәсе.

Ата төрек күпере, данлыклы Таксим мәйданы, меңләгән тар урамнар, синең һәр теләгеңне үтәргә әзер торган тылсымлы, яшерен Шәрык ханәләре — боларның барысы да үз урынында иде.

Истамбул моннан биш мең ел элек тә зур кала булган. Атом сугышы кабызып, җир шарын тузанга әйләндермәсәләр, бездән соң тагын биш мең ел үткәч тә монда гасырлар серенә күмелеп зур, мәһабәт кала утырачак.

Бу каланы мин беренче тапкыр моннан егерме дүрт ел элек күрдем. Чирек гасыр эчендә мин күргән тауларның күбесе тәбәнәкләнде шикелле, хәтта күк йөзе дә, әзме-күпме зәңгәрлеген җуеп, бераз тоныкланды кебек, ә мәңгелек кала һаман шул килеш. Бу шәһәрдә, үзалдына тирән уйларга чумып, Галиәсгар Камал йөргән. Бәлки, Дәрдмәнднең кораб турындагы бөек шигыре дә бугаз аша үтүче ак җилкәннәргә карап, халык язмышы турында уйланганда барлыкка килгәндер?

Истамбул картаймый, яши. Картаю — аерым кешенең генә котылгысыз трагедиясе ул.

Азия ярындагы Чынык кала тугыз ел элек Бөгелмәнең уннан бер өлеше хәтле генә иде. Хәзер үскән. Ул чорда монда ике катлы йортлар да сирәк иде әле. Инде дүрт, биш, хәтта егерменче гасырның кеше тутырырга көйләнгән тугызар катлы универсал тартмалары барлыкка килгән. Панельләрдән корылган индустриаль кетәкләр төрек җиренә дә юл тапканнар. Әнә, шәпәр читенә кызыл кирпечтән фабрика салып азапланалар. Әле ул салынып та бетмәгән, ә аның клизмага охшашлы биек торбасы инде зәңгәр күкне ыслый башлаган. Дарданелл бугазы өстендә «Илиада»ның бөек җырчысы Гомер сурәтләгән саф, зәңгәр күк. Хәзер аны да сөремнәргә тотынганнар.

Чынык кала артындагы сөзәк тау кабыргаларын яшел чирәм каплаган. Шул чирәмлектә ялгыз ат утлап йөри. Чабылган печән урынына шытып чыккан яшел йомшак курпы өстендә атның сылу гәүдәсе ерактан ук күренеп тора.

Армиягә киткәнче мин өч елга якын колхозда сабан сөрдем. Минем сабанга җиккән күк алашама охшаган иде төрек аты. Атсыз яшәүнең кимсенүле тәмен мин даими тоеп йөрим. Бу турыда беркемгә, хәтта иң якын дуска да сөйләп аңлатып булмый — тилегә санарлар дип куркасың. Шәһәр тормышында атка урын юк. Дингездә ат — бөтенләй кирәксез хайван. Ә атка тиешле ярату йөрәктә исраф булып, коргаксып ята.

Уйсу җирләрдә бодай басулары. Көзгә кадәр саф яшеллеген саклаган арча куаклары, әрем баскан борынгы, бик борынгы хәрабәләр, шуларга бик озак сокланып карап тордым. Күздән югалганчы ялгыз атны, кан дустымны, рухи сердәшемне күзәттем. Сау бул, бахбаем!

Яр буена дачалар сала башлаганнар. Сөзәк аксыл ком ярлар, сыек фирүзәгә охшашлы тыныч зәңгәр култыклар. Су коенучылар керепкеше күзеннән яшеренсен өчен салынган җиңелчә таш корылмалар. Һәм мөселманнар яраткан агач — арча куаклары. Ялгыз мәчет. Авыл мәчете: гади, боек, әдәпле корылма. Бәлки аның эченә кереп, җомга намазы укучы да калмагандыр инде. Үткән гомер истәлеге, һәйкәле булып утыра бирә. Ата-баба салган йорт ул. Аның эчендә узган буыннардан калган эзләр, аларның догалары яши...

Ата-баба мирасыннан мәхрүм калган кеше — туып үскән күлен, камышлыгын югалткан ялгыз торнаны хәтерләтә. Үткәннән мирасы, тарихы, тамыры булмаганның — киләчәге дә юк. Киләчәккә сузылган юлны узган заманда яшәгән буыннар тәҗрибәсе генә күрсәтә ала. Ә киләчәксез бүгенге көн юк. Тау кабыргасындагы яшел чирәм җирләргә, басуларга, чикләвек агачыннан торган куе әрәмәлекләргә карап, шушы турыда уйлап бардым.

Чынык каладан өч-дүрт чакрым читтә, тау кабыргасында, бер ялгыз утар бар. Элекке сәяхәтләрдә мин аны үткән саен карап уза идем. Кулга бинокль алам, карыйм. Йорт түбәсендә ялгыз кара кош утыра. Тәрәзә капкачларын ябып, тышкы яктан аркылыга такта кадаклап куйганнар. Өй кырыендагы ике моңсу кипарис, ботакларын еракка җәеп, иркенләп үскән йөз еллык зур чинар, тау итәгенә сирпелгән җимеш агачлары. Аларның барысы да үз урыннарында. Ләкин һәр үлән бөртеге, һәр яфрак утарның ятим калуы турында зарланып утыра кебек...

1968 елның җәендә бу утарда күзгә күренеп тормыш кайный иде. Яннарында кеше яшәгән чакта агачлар да ничектер ышанычлырак үсәләр. Бер үтүдә, нечкә муенлы озынча чүлмәк күтәреп, чишмәдән утарга су алып кайтучы яшь кызны, бакчада эшләп йөрүче хатынны күргән идем. Ләкин йорт хуҗасы, нишләптер, бер дә күзгә чалынмаган

иде. Әллә ул хуҗасыз калган утар идеме икән? Юк, хуҗасыз булмагандыр. Ихаталар төзек, җир-бакчалары эшкәртелгән, җимеш агачлары пөхтә итеп кыркылганнар иде. Утарга ирләр кулы тигәнлеге ярылып ята иде ул чакта. Аннан соң, төрек хатыннары ялгыз яшәргә, үзләре хуҗалык карарга өйрәнмәгәннәр. Минем күзәтүем буенча, ялгыз яшәү югары белемле хатыннар арасында ешрак очрый.

Без үткән чакларда йорт хуҗасы бәлки эштә булгандыр?

Кырда, яисә Чынык кала шәһәрендә берәр вазифа башкаргандыр? Ә хәзер утарны ташлап китkәннәр. Ул ташландыкка әйләнгән. Йорт хуҗасы берәр Европа иленә, Көнбатыш Германиягә, яисә Швециягә киткәндер, бәлки. Эшкә урнашып, бераз акча җыйгач, гаиләсен дә чакыртып алгандыр. Читтә йөреп тамак туйдыру — авырлыклар, бәхетсезлекләр тудыручы йола — Төркиядә дә очрый икән. Патша заманында безнең халыктан да шулай читтә нужа күреп йөрүчеләр күп булган.

Бәхет эзләүчеләрнең тәкъдире һәрвакыт кызганыч. Туган җирдән еракта табылган бәхет беркайчан да куаныч китерә алмый. Читтәге бәхет бары тик туклык, мал табу белән чикләнеп кала. Читтә йөрүче үзенең туган җирен, ата-баба нигезен югалта.

Европа илләрендә, Кувәйттә, Ливиядә, Гыйракта, Сәгуд Гарәбстанында эшләп йөрүче төрекләрне еш очратам мин. Иң авыр, иң кара эш алар җилкәсендә. Акча җыйгач кайтырбыз дип туган туфракларыннан аерылып китүчеләрнең күбесе гадәттә чит җирдә бөтенләйгә кала. Балалары — туган җирдән, милли гореф-гадәтләрдән бизә, туган телен онытып, әкеренләп ят милләткә әйләнә. Андый кешеләрнең тамырлары корый, кешене бизәп, матурлап торган нәсел сурәте сүнә.

Бәхет эзләп китәргә җыенучылар баеп кайтучылар турында сөйләп юанырга ярата лар. Кара диңгез ярындагы Самсун шәһәреннән бер чемодан тәмәке күтәреп Америкага киткән Төркия грекы Аристотель Онассис җир шарының иң бай миллиардерына әверелә. Әмма туган җирне хәтта шундый зур байлык бәрабәренә дә алыштырып булмыйдыр.

Мин әле һаман хуҗасыз йорт турында уйлыйм. Ул инде артта калды, күздән югалды. Минем йортым да озак еллар күздән югалып торган иде. Хәзер ул һаман ешрак күз алдыма килә.

Пенсиягә чыккач, тәрәзәләре диңгезгә караган аулак авыл йортында яшисем килә минем. Төннәрен дулкыннар сөйләшкәнен тыңлап, томан төшкән чакларда пароход гудокларын ишетеп, дөнья гизәргә китүче кораблар артыннан калган яшькелт юлларны күреп яшәү турында хыялланам. Кайвакыт, киресенчә, диңгездән качып, урман эчендәге ялгыз йортта яшәү теләге туа. Кояшлы ялан. Кошлар сайрый. Өй артында чылтырап салкын чишмә ага. Төннәрен, йокы качкан чакларда, агач яфраклары шаулавын тыңлап ятасың... Хыялым шундый. Һәм беләм — ул хыял, тормышка ашмый, шул килеш калачак.

Диңгезгә мәхәббәт бер уянса, мәңге сүнми. Диңгез сине нык тота, җибәрми. Диңгез үз сүзле, иркә, кәнтәй хатынга охшаган. Ул чибәр, назлы. Диңгез синең кайнар мәхәббәтеңне уяткан, үзе яратуы белән уртаклашмый. Вәгъдә бирә — вәгъдәсендә тормый. Сине сихерләп үзенә караткан алсу мираж ул диңгез. Мәңгелеккә сине тырнагына эләктергән сәмруг-кош.

Аның фаҗигале икәнлеген картайгач кына аңлый башлыйсың. Кем белә, бәлки яшәүнең иң дөресе нәкъ шушыдыр? Тормышның кайсы дөрес, кайсы ялгыш икәнлеген безгә беркем аңлата алмый. Бәлки аңлауның кирәге дә юктыр?

Дарданелл ярлары тыныч кына артка таба шуыша. Чынык кала да күздән югалды. Ярлар тәбәнәкләнде. Ерактагы яшел калкулыклар тагын да ямьләнә, матурлана төште.

Шушы ярлар, үткән саен, мине бер сәбәпсез дулкынландыра баш-

лый. Ярга чыгып, туры көньяк-көнчыгышка таба егерме чакрым чамасы баргач, Гомернең «Илиада»сында җырланган бөек Троя шәһәрен очратасың. Трояның хәрабәләрен күрү өчен, мачтага мендем. Бинокльдән карыйм. Иркен басулар. Шул басулар арасында Хисарлык авылы һәм шуның янындагы сөрми калдырылган түгәрәк калкулык. Җилянгыр һәм кояш нурлары шомарткан соргылт ташлар җирне кочаклап, тыныч кына ята бирәләр. Бу ташлар, хәрабә тирәсендә үскән бу әремнәр — илле гасыр элек булып узган канлы сугышның моңсу шаһитләре. Илле гасыр эчендә йөздән артык буын алышынган...

Троя каласы, безнең Шәһри Болгар шикелле, каберлеккә әйләнгән. Хәрабәләр тирәсендә — сарык көтүе, күктә — ялгыз тилгән әйләнә.

Трояны Шәһри Болгар белән чагыштыргангамы, Татарстан искә төшә. Исергәп авылы турында уйлыйм. Гаҗәп хәл: гомер буе ындыр артына да чыкмыйча яшәгән авыл карчыклары Истамбулны бездән яхшырак беләләр иде. Аларның үзләре чыгарган үзгә география фәне дә бар иде: Югары Як-Шалты, Абдулла, Каргалы авыллары, «Урынбур», Сәмәрканд, Бохара, ниһаять, Исламгол. Югары якта ишаннар тарихы, авылыбыздан киткән кардәшләр, өрек, йөзем җимешләре, ишәкләр, бөркәнчек астына яшеренеп йөрүче үзбәк хатыннары, дин, кытлык килгәндә шунда китеп, исән калу мөмкинлеге. Түбән якта: Бөгелмә, Чаллы, Казан һәм Мәскәү. Бу яктан салым кәгазьләре, хәрби повесткалар, күмелгән ашлыкларны эзләп йөрүче «полнамучлар» килә. Корыч чыбык булып сузылган күзгә күренмәс идарә итү җепләре дә безнең авылга түбән як юнәлешеннән сузылган иде. Безнең төбәк элек, ни сәбәптер, Казан ягыннан игелек көтми иде. Сабый чакның бер сурәте күз алдымда: сазлык җиргә урнашкан Печән базары, уртада хөкүмәтнең кызгылт кирпеченнән салынган кәҗүннәй йорт, шуның түбәсеннән дагалы күн итек кигән юан аякларын асылындырып, «гөбернатор» утыра. Казанның бала чактагы сурәте шушындый иде. Мәктәпкә йөри башлагач, сурәт үзгәрде. «Камил Якуб» исемендәге китап фабрикасы, «Чаткы» һәм «Ватан» кинотеатрлары, еш кына авылга килеп, концерт биреп китүче җырчы Рәшит Ваһапов һәм авыл советы йортының кәрнизендәге кара репродуктордан урамга сирпелгән «Тыңлагыз, Казан сөйли». Истамбул янынннан үткәндә, нигәдер шушы сурәтләр яңарып китәләр. Бала чакның керсез, беркатлы ышанулары да яңара. Күзаллау чылбырының башында Исергәп авылы, очында — Истамбул каласы. Бу ассоциациянең каян барлыкка килүен аңлатуы кыен. Ни сәбәптер, безнең төбәк элек Уфа һәм дала ягына карап яшәгән.

Кояш Гелиболу таулары артына кереп батты. Алда Эгей диңгезе. Ун сәгать Мәрмәр диңгезеннән йөздек. Бу юлы да аны игътибарсыз узып киткәнбез. Мәрмәр диңгезен искә алган, аның турында сөйләгән диңгезчене очратканым юк минем. Сабыр табигатьле, тыныч диңгез. Күпме үтеп йөреп, Мәрмәр диңгезенең дулавын күргәнем булмады минем. Кара диңгез штормнарыннан, Урта диңгез давылларыннан соң Мәрмәрдә ярты тәүлек ял итәсең. Бу диңгез юаш, тыныч холыклы татар хатыннарын хәтерләтә. Тормыш безне юаш кешенең кадерен белергә, аны санга сугарга өйрәтмәгән. Бу сыйфатны ни сәбәптер өнәп бетермиләр бездә. Юашлык дөнья көтү өчен кулай булмаган, күрәсең.

Инде без Эгей диңгезе буйлап барабыз. Тирә-якны санап бетергесез вак атаулар урап алган. Төньяк Спорада, Киклада һәм Көньяк Спорада архипелагларына кергән кечкенә утраулар. Аларның каян барлыкка килүен аңлаткан борынгы грек мифы искә төшә. Алла Элладаны салыр өчен материал эзләгәндә, диңгезнең матурлыгына сокланып, кулындагы ташларын диңгезгә коеп төшергән, имеш. Шул ташлардан утраулар барлыкка килгән, янәсе.

Эгей — Арголида патшасының исеме. Арголидадан ел саен унике

яшь егетне сайлап, Крит атавындагы адәм ите белән тукланып яшәүче куркыныч минотаврга җибәрә торган булганнар. Бу елны Эгей патшаның улы Тесей шул җәнлекне үтерергә ниятләгән. Крит атавына киткәндә, ул әтисенә әйткән: «Минотаврны җиңсәм, кайтканда, ак җилкән күтәрермен, җиңелсәм — матрослар караны күтәрерләр»,— дигән. Крит патшасының кызы гүзәл Ариадна ярдәме белән Тесей минотаврны үтергән. Кайтканда җиңү хөрмәтенә ярыйсы гына бәйрәм иткәннәр һәм ярыйсы гына «салганнар». Матрослар Арголидага җитәрәк, исерек баштан ялгышып, ак урынына кара җилкән күтәргәннәр. Кыя өстендә улы кайтканны көтеп торучы Эгей патша, офыкта кара җилкән күренү белән, кайгысыннан диңгезгә ташланган.

Бу миф шәраб эчүнең безгә кадәр дүрт-биш мең ел элек тә кешеләргә зур казалар китерүе турында сөйли. Шул чорларда ук алкогольнең зыянын белгәннәр, аның белән көрәшеп килгәннәр.

Төн диңгездә үтте. Таң атканда, без Карпатос һәм Крит атаулары арасыннан Урта диңгезнең көньяк-көнчыгыш өлешенә чыгып килә идек.

Диңгез тыныч. Йөзү рәхәт. Дөнья тигез. Рәхәтлекнең иң татлысы — җан тынычлыгындадыр, бәлки? Еракта — Крит атавының таулары күренә. Анда минем ике мәртәбә булганым бар. Беренче баруда мифик патша Миносның сараен казып азапланалар иде. Ул чакта әкияти минотавр яшәгән лабиринтны да күреп кайттык без.

Борынгы грек дәүләте җимерелгәннән соң инде егерме дүрт гасыр вакыт үткән. Ә мифлары һаман яши. Яши һәм безне сокландыра. Аларда чиста самимилек, акыл, табигыйлек, яшәү серен аңлау һәм яшәү дәрте гаҗәп матур булып сурәтләнеп калган. Миф тудыру өчен халыкның рухи иҗат көче, яшәү тәҗрибәсенең югары дәрәҗәдә булуы һәм шул тәҗрибәне сәнгать кануннарына әйләндерә белү осталыгы кирәк булган күрәсең...

Үз халкымның миф тудырырга көче җитүе горурландыра мине. Чулпан, Тимер Казык, Зөһрә йолдызлары, үги ана золымыннан котылу өчен айга менгән көянтәле космонавт кыз. Алып, Алтынчәч турындагы мифларны тыңлап туймаслык.

Дүртенче тәүлектә Африка ярлары күренде. Соргылт томанга охшашлы тоныклык, куера-тыгызлана торгач, яр сызыгына әйләнде. Яр буендагы саргылт комлыктан бөдрә пальмалар калкып чыкты, Африка материгын ак дулкыннар кыйный иде. Материк ыңгыраша шикелле. Монда күпме аһ-зар, күпме җәбер-михнәтләр тупланган!

Александриянең тышкы рейдына кораблар җыелган. Шулар янына килеп, без дә якорь салдык.

## Искәндәрия

Гарәпләрнең Искәндәриясен өч яктан диңгез урап алган. Шунлыктанмы, бу шәһәрне Африка җиренә урнашкан итеп күз алдына китерәсе килми. Һава шартлары чүлдәгечә кырыс түгел монда. Кыш көне җылылык унбиш градустан түбән төшми, җәен аның утыздан артканы сирәк була. Җил көндез — материк ягыннан, төннәрен диңгездән исә. Шәһәр салучыларны шушы җиләслек кызыктырган булса кирәк. Моннан ике мең биш йөз ел элек шушы урында зур шәһәр булган.

Без портка кереп киләбез. Алда — мавритан ысулындагы патша сарае. Сарай каршында шәмдәй төз, очларына яшел җилпәзә беркетелгән сылу пальмалар. Җир йөзендә шундый агачлар булуына ышанасы килми. Пальма пластмасстан ясаган уенчыкны хәтерләтә. Сарайның урта гөмбәзе өстендә әләм җилферди. Баскычның як-ягында

мылтык тоткан ике солдат. Сарай каршына җиңел машиналар килеп туктыйлар. Ишек ачыла. Хәрбиләр, машинадан чыгып, атылып сарайга кереп китәләр.

Күп илләрдә шулай: иң зур, иң гүзәл сарайларны хәрбиләр яулап алган була. Сарайлар гына түгел, иң затлы яшәү шартлары да алар кулында. Израиль сугышы туктагач, бу илдә яңгырдан соң шытып чыккан гөмбә шикелле булып генераллар үрчи башлаган. Кая карама анда — симез тәнле, тәкәббер, ясалма дәрәҗәләрен көчкә күтәреп йөрүче җиз маңгайлы генераллар. Алар саранча көтүедәй хезмәт халкының җилкәсенә ябырылып кунганнар, шулар әзерләгән ризыкны ашап, эшче һәм игенче балаларын үлемгә хәзерлиләр. Мисыр илләрнең язмышы хәрбиләр кулында. Власть хәрбиләр кулында булганда, кешелек дөньясы беркайчан тынычлыкка ирешә алмаячак.

Сарайның уң ягында биек ныгытма. Аны борынгыларның «Җиде могҗиза»сының берсе Фарос маягы урынына салганнар. Ныгытмага янәшә — мәчет, бакча, урам, тагын йортлар, сарайлар, манаралар, завод бинасына охшаш корылмалар, коттеджлар, кетәкләр, эчү һәм азыну урыннары.

Шәрык бу. Европага аңлашылмый торган җир. Безнең халык башка төрле күзаллау мохитында тәрбияләнгән, шунлыктан шәрыкны без дә аңлый алмыйбыз. Аңларга тырышып карыйм: акылым көчсез, фикерләремә таш аскан шикелле. Без шәрыкка читтән, ят мохиттан карыйбыз. Мондагы тормышны безнеке белән чагыштырып булмый. Яхшылык та, начарлык та икенче төрле монда. Сыйфатлар кискенрәк. Изгелек һәм азгынлык, юмартлык һәм комсызлык, көч һәм көчсезлек — барысы да икенче төстә. Икенче төрле, мул һәм башка буяуларга буялган. Без уртачылыкка күнеккәнбез, шунлыктан, шәрыкка караганда, күз чагыла.

Урам почмакларына посып утырган йортларның баскычлары өстендә төннәрен кызыл утлар кабына. Ачык тәрәзәләрдән, ишек ярыкларыннан Европа кешесенә төче һәм озын тоелган тылсымлы музыка агыла. Мелодия синең тойгыларыңа сырыша, чорный, кинәт теләкләрең сулкылдый башлый. Моңа кадәр мөһим тоелган мәҗбүрилекләр кинәт юкка чыга. Шушы көйләрне тыңлаганда, яшәүнең әле син татымаган яңа мәгънәсе ачылып китә шикелле.

Искәндәриянең күләгәле урамнарында йөргәндә, аяк астында каткат түшәлгән тарих ятканын тоеп аласың. «Бәлки шушы шома ташларда Клеопатра янсә Юлий Цезарьның эзләре калгандыр?» — дип уйлап куясың. Шушы ташларга басып йөргәндә алар нәрсә уйлаганнар? Тарихчылар сүзенә яртылаш кына ышанам мин, ә Клеопатра белән Юлий турында язылган калын китаплардан: «Әйтегез, сездә хакыйкать бармы?» — дип сорап булмый. Миңа шунысы ачык: үзләре исән чакта Клеопатра һәм Цезарь болай язарга рөхсәт итмәсләр иде.

Шәһәрдә ике миллион ярым адәм баласы яши. Синеке шикелле үк шатлыклары, кайгы-хәсрәтләре, куанычлары, аянычлары белән яшиләр. Ә син үз кайгың, үз шатлыгың эченә бикләнгәнсең. Шунлыктан, син аларны юньләп аңлый да алмыйсың.

Тукталдым. Каршымдагы йортның икенче кат тәрәзәләренә карап торам. Юка пәрдә аша бүлмә эчендә кыймылдап йөргән хатын-кыз сыны шәүләләнә. Кем икән ул? Нинди икән? Нәрсә эшли, ниләр тели икән? Ара — биш адым һәм йөз гасыр. Үлсәң дә якыная алмыйсың. Безне тарих аерган.

Ә гомер кыска. Аның кыска икәнлеген шушы шәһәрнең бер мәйданы аша узганда тоеп алдым. Мәйдан уртасында кызгылт көрән лабрадордан ясалган дүрт кырлы биек монумент тора. Монументның һәр кырына борынгы мисыр иероглифлары белән ниндидер сүзләр язылган. Һәйкәлне моннан дүрт мең ярым ел элек яшәгән фир-

гавен хөрмәтенә куйган булганнар. Монументка карап торганда мидә кабынып киткән фикернең берсе: «Нилектән һәйкәлне гел фиргавеннәргә генә куялар икән? Бит, шушы фиргавен чорында да искиткеч акыллы, сәләтле даһи шәхесләр булган. Оста көмешчеләр, бөек шагыйрьләр, матур кызлар, гадел һәм изге ирләр. Аларның берсенә дә һәйкәл куймаганнар. Игенче үстергән икмәкне ашап, коллар тапкан малны туздырып тәхеттә кәеф-сафа корып гомерен уздырган әрәмтамак фиргавен үзенә һәйкәл куйдырткан. Аның фиргавен токымыннан булып, тәхеттә утырганлыгы өчен калдырганнар бу истәлекне. Фиргавен үлгәннән соң кырык биш гасыр вакыт үткән, ә без әле һаман һәйкәлгә кем лаеклы икәнен белмибез».

Шушы фикер белән кайту юлына чыктым. Портка керер алдыннан кораллы төнге патруль туктатты. Пропуск суздым. Төрлечә әйләндереп карады. Язу танымаганы күренеп тора.

— Американо?

— Но, руси,— дим инглизчә.

Тагын бер көн туды.

Эшемне тәмамлагач, янә шәһәргә юнәлдем. Бу юлы капкадан чыгу белән төньяк-көнбатышка борылдым. Ярлылар яши торган урам. Пычрак. Урам тулы бала. Пешкән карта, эчәге, кер, канализация исе аңкып тора. Төтенгә ысланган таш диварлар. Ишекләрнең күбесе ачык. Ишек яныннан үткәндә, борынга бала чүпрәгеннән чыккан әчкелт ис килеп бәрелә. Бу исләрне күмер һәм кайнар тимер исе алыштырды. Күрек белән өрдертелгән һава күмерне дөрләтеп яндыра. Корымга баткан ике таза негр зур чүкеч белән кайнар тимерне кыйныйлар. Алачык эчендә берничә шәрә бала кайнашып йөри.

Нәрсә генә ясамыйлар Мисыр осталары? Күз явын алырлык җиздән тукыган бизәкләр, бакыр комганнар, койма челтәрләре, хәйран калырлык матур шәмдәлләр, чаң белән ачыла торган бизәкле сандыклар, булат хәнҗәрләр — әллә нәрсәләр. Алачык яныннан узып киткәч тә, бик озак авызда тимер тәме тора.

Бездә дә оста тимерчеләр булгандыр дип уйлыйм мин. Грозный заманында безнең кешегә тимерче булып эшләргә рөхсәт ителмәгән. Шул сәбәпле, борынгыдан килгән милли осталыкка ифрат зур зыян китерелгән.

1965 елда энем Александриядә эшләгәндә мин аларга кунакка барган идем. Шул йортны эзләп киттем. Яр буе. Бакча эчендә утырган җыйнак коттеджлар. Бу урамда интеллигенция: адвокатлар, врачлар, укытучылар, журналистлар яши. Йортны таптым. Челтәрле койма аша ишек алдына карыйм. Диңгез ягындагы ачык верандада ак джинси чалбар, зәңгәрсу кисея блузка кигән күзлекле хатын китап укып утыра. Чәчләре аксыл. Кояшта уңганга охшашлы зәңгәрсу күзләр. Гайрәтле юу порошогы салган күбекле суда бик озак чайкалганнар диярсең — тоташ төссезлек. Әфлисун агачлары шәүләсендә ике кыз бала бер-берсенә оча торган тәлинкә җибәреп уйныйлар. Төссез хатын аларга нәрсәдер әйтте. Кызлар, уеннарын ташлап, веранда янына килеп туктадылар:

— Лэнч вакыты, кулларыгызны юыгыз.

Хатын Америка диалектында сөйләшә иде. Шәһәрдә адым саен Америка солдатлары очрый. Әнвәр Садат идарә итү штурвалын Америка фарватерына таба борды. Әлеге машиналар бездән киләләр. Пароходчылыкның утыз биш мең тонна керешле ике балкеры [1] без салып биргән металлургия комбинатына шихта [2] ташый. Ә дәүләт тәртәсе АКШ ягына борылган.

[1] Руда ташый торган кораб.
[2] Корыч койганда кулланыла торган чимал.

Бусы байлар яши торган урам. Көзнең соңгы ае. Кыш якынлашып килүгә карамастан, бакчалар чәчәккә күмелеп утыра. Орхидея, бугенвелия, роза, әллә нинди мин белми торган купшы чәчәкләр челтәрле койма өстеннән тротуарга бүселеп төшәргә торалар. Яллап эшләткән бакчачыга буйсынып, байлар тормышын бизәү өчен үскән куштан чәчәкләр. Матур алар, ләкин аларны мин кыр чәчәкләрен яраткан шикелле ихлас ярата алмыйм.

Җәй айларында шушы кыйммәтле виллаларга Сөгуд Гарәбстаны, Кувәйт илләренең байлары ялга киләләр. Акча түгүгә, кәеф-сафага көйләнгән астыртын төнге яшәү хәрәкәткә килә. Көндез урамнар буш. Тыныч. Беркем юк. Кыйммәтле коттеджлар, чәчәкләргә күмелеп, төнге «эшләреннән» соң ял итәләр.

Караңгы төшә. Урам уяна, квартал мыштым гына хәрәкәткә килә. Кыйммәтле спектакль — гомер яндыру уены башлана. Байлар урамының чәчәк исенә баткан һавасы ясалма тоелды миңа. Үзәккә таба юл тоттым.

Әле ун гына минут элек мин җәннәтне күзәтеп йөри идем. Бусы мәхшәр. Машиналар каядыр ашыгалар. Катафалкка охшашлы кыйммәтле кара «Роллс ройс», бүксәсен киереп, алга шуыша. Америка бизнесменына охшашлы нахал «фордмустанг». Ул үзенең көчле булуын, кыйммәткә төшүен яшерми, башка машиналарны тәкәббер генә як-якка этәреп, юл әрчеп бара. Космик ракетага охшашлы спортив «Ягуар», кәләш эзләп йөрүче спай этәчкә охшашлы «Пэжо», интеллигент кыяфәтле «Альфа-ромео» һәм күргәзмәләр чемпионы — чыдам «Мерседес».

Бер тын машиналарның күплегенә, аларның мең төрле кыяфәтенә хәйран калып, тораташтай катып торасың. Ярты сәгать агымны күзәткәннән соң җир йөзендә ничә төрле машина булуын махсус өйрәнүнең кирәге калмый. Генри Фордның беренче «Фордзон»ыннан башлап, иң соңгы модификацияле япон «Датсун»ына кадәр булган барлык машиналар синең күз алдыннан үтә.

Машиналар арасыннан ике көпчәкле зур арбага җигелгән соры ишәк кына юыртып бара. Ишәк ябык, баш зур, гәүдә кечкенә, аяклар нечкә. Дилбегә сигез-тугыз яшьлек малай кулында. Ишәкне зәңгәр «Шевроле» урап узмакчы була. Горур ишәк, юл бирмичә, юыртуын дәвам итә. «Шевроле» сигнал бирә, ашыга, ләкин ишәкне урап уза алмый. Ишәк хуҗасының өстендәге киндер күлмәкнең уч төбе зурлыгы гына да исән урыны юк. Ямау өстендә ямау. Ә малай үзе шундый шат, шундый канәгать. Ул бәхетле. Аның йөзендә саф, ләззәтле, самими елмаю. Морадына ирешкән бала кулында арбага җиккән ишәк дилбегәсе. Әтисе рөхсәт итеп, ишәккә утыртып җибәргәнгә куанамы, әллә аның сигез яшьлек саф балачак гомере шулай балкыймы? Күздән югалганчы, малайның йөзеннән күземне ала алмыйча, соклanып карап тордым.

Ишәк борылма артына кереп югалды. Мин машиналар арасыннан баручы җиңел кабриолетка җиккән гарәп атына күз салдым. Мондый атның рәсемен генә күрсәң дә, дөньяңны онытып, озак, бик озак карап торасың. Дугаланып торган аккош муен. Сылу гәүдә. Кырып эшләгән орчыкка охшаш озын матур аяклар. Киң горур күкрәк һәм ут янып торган акыллы күзләр. Сулыш алганда, атның танау тишекләре киңәеп китә, тояк астыннан чаткы чәчри. Көмеш тәңкә тезгән кара каеш йөгән, чуклы пастромка, көмеш бизәкле ыңгырчак ак юргага шул кадәр килешә. Атның маңгаена бер бәйләм тавис каурыеннан ясаган чук беркеткәннәр. Аргамакны күрү белән, минем өчен машиналар юкка чыкты. Бу минем балачак хыялымдагы тылсымлы дөлдөл иде. Әгәр шушы бахбайны сатсалар, минем ат сатып алырлык

акчам, аны тотар урыным булса, соңгы күлмәгемне, фатирымдагы соңгы өстәлемне биреп, алыр идем. Ачлы-туклы яшәргә риза булыр идем...

Машиналар шашынып гудок бирәләр. Мәхшәр көне, яэҗүҗ-мәэҗүҗ купкан чактагы авазлар. Атлар, өркеп, аягүрә басалар. Машиналар юл эзләп як-якка ташланалар. Ишәк халкы гына шушы мәхшәргә төкереп, тыныч кына атлый бирә. Ишәкләрнең сабыр уйчан күзләрендә дөнья тарихы: «Без күп гасырлар кешеләрнең йөкләрен ташыдык. Авыр йөк өстенә алар үзләре атланып йөрде. Яшәү авыр булды, бик авыр. Күп вакыт безне ач тоттылар. Без зарланмадык. Кешеләр безгә ялган яла ягып, «аңгыра, юләр, тинтәк» дип нахакка көлделәр. Йөкне машинага төяп йөртә башлагач, хәлебез бераз җиңеләйгәндәй булган иде. Без сизенәбез, машинага салырга бензин беткәч, кешеләр тагын безгә атланып йөри башлаячаклар».

Урамдагы атны, ишәкне, машинаны адәм баласы белән бер тормыш агымы, тәкъдир берләштерә. Шәһәрдә егерменче белән янәшә урта гасыр, шул чордагы ышанулар, дин, шәригать яши. Алар үзара буталышып беткәннәр, һәм яңалыкны искелектән аерып булмый.

Ишекләре тротуарга ачылган һәр бинаның беренче катында кибетләр. Анда шәрыкка хас кайнар алыш-биреш, сәүдә. Сәүдә, кибетләргә сыя алмыйча, урам чатларына, базарларга агып чыккан, тартмачылар муенындагы әрҗәләргә сирпелгән.

Әнә бер яшь чибәр егет, товарны ике тәгәрмәчле арбага төяп, урам буйлап алучы эзләп йөри. Җиде яшьлек сабый муенындагы тартмада, төймә, тарак, сәдәфләр. Дүрт мең ел элек кәрван юлларында яралган шәрык сәүдәсе һаман яши. Сәүдә — кәсеп, сәүдә — юаныч, сәүдә — көрәш һәм сәүдә — өмет. Баета торган сәүдә, бөлдерә торган сәүдә, уләргә ирек бирмичә, ачлыктан саклый торган сәүдә. Күземне йомып, тыңланып торам: төрле яктан сәүдәгәрләр тавышы чорнап алган.

Тәкәббер байлык белән ачы ярлылыкның бергә яшәвен тик шәрык тормышы аша гына аңлый аласың.

Шәрык әле һаман йокыдан уянып җитмәгән. Шәрык хатыннары белән аның сәясәте, мәдәнияте әлегә бөркәнчек астында. Шәрыктәге хисләрнең кайнарлыгын, андагы утлы мәхәббәтне без тышкы яктан гына беләбез. Хафиз, Гомәр Хәйям, Сәгъди, Әл-Фәраби, Әл-Кинди, Ибне-Рөшд, Җәләлетдин Руми һәм Шиһабетдин Мәрҗәниләр турында башка телдә сөйләп аңлатып булмый. Аларның фикерләрен тапшыру өчен сүзләр җитми.

Без Александрия портында өч атна тордык. Мин, һәр кичне шәһәргә чыгып, гарәпләр тормышын күзәтеп йөрдем. Бәлки күзәтү белән артык мавыгырга да кирәк түгелдер? Соңгы чиктә барыбер күзаллау сәләте, акыл көче җиткән нәрсәне генә аңлый аласың. Ә яшәү акылга гына көйләнмәгән.

## Порт

Сәяхәт порттан башлана, портта тәмамлана. Корабларны аерым бер портка даими беркетүдә тирән бер мәгънә бар. Кораб туган җирнең бер кыйпылчыгы. Ул, читтә йөргәндә, башка илләрнең җиренә кушыла алмыйча, туган җиреннән аерылган кеше шикелле, җәфа чигә. Чит ил портларында торганда безнең корабка күтәрелгән һәрбер чит ил кешесе безнең законга буйсынырга тиеш. Кайларда гына йөрсәк тә, кораб эчендә ватанның үз законнары идарә итә.

Азов диңгезе кораблары Жданов портына беркетелгән. Шуңа күрә

ул безнең туган порт санала. Ул чыннан да туган порт, анда экипаж әгъзаларының гаиләләре яши.

Әле без чит ил портына кереп азапланабыз. Чит булса да, порт безгә таныш. Озак еллар диңгез эше белән шөгыльләнгән кеше җир шарының күп портлары белән танышып өлгерә.

Александриядә безгә килгән көнне үк урын таптылар. Торасы урын порт капкасыннан ерак, ярым җимерек, пычрак причалда булып чыкты. Шәрыкка хас әчкелтем-төчкелтем исләр: борыч, канәфер, ванил, гөлбадран, чери башлаган җимеш һәм ашка сала торган үлән исе. Кораб тирәсендә хуҗасыз этләр чуалып йөри. Алар безгә ниндидер кискен, ач өмет белән карап торалар да капылт кына юкка чыгалар. Төннәрен биек багана башына аскан прожекторлар причалга яктылык сибә.

Тирә-якта тартма өемнәре, мичкәләр, металл конструкцияләр. Ватык әрҗә эченнән ак суыткыч күренеп тора. Сытылган мичкә. Эченнән вареньега охшаш саргылт сыеклык агып чыккан. Мичкә тирәсендә бал кортлары гөжли, товар өемнәре өстенә брезент каплаганнар. Тирә-юньгә җир чикләвеге, кофе, какао, сарымсак тырнаклары коелып калган. Тагын өем, коелып калган ашамлык бөртекләре, кокос чикләвеге, хна, индиго, өем-өем сүс, мамык, такталар. Хуҗаларына тапшыруны көтеп алҗып беткән җиңел машиналар, өеп куйган сарык тиреләре. Шуларның барысын да соргылт тузан каплаган — вак, йомшак шәрык тузаны.

Товарлар арасында ниндидер яшерен хәрәкәт барлыгы сизелә. Берни селкенми, тавыш юк, ә өемнәр арасында ниндидер астыртын хәрәкәт барлыгын тәнең белән тоясың. Мыштым, күңелгә шом сала торган сизгер кыймылдау. Мин аны һәр әгъзам белән сизеп торам: «Әллә җен-албастылар бармы икән монда?» — дип, шикләнеп куям. Булуы да мөмкин.

Шәһәр йоклый. Ә порт туктаусыз эшли. Еракта пароход пошкырып ала. Кораблар янында чуалып йөрүче ялгыз буксир адашкан болан тавышы белән гудок бирә. Вагон буферлары шакылдап ала. Теплоход янында су чапылдап куя. Причал астындагы юеш, лайлалы свайларга ябышкан хәшәрәтләр күз алдына килә. Трап саклаучы матрос, йоклап китүдән куркынып, дөп-дөп басып йөри. Аның дагалы ботинкасы тимер палубага бәрелгәндә, тәннәрне чымырдата торган ямьсез тавыш чыга.

Мисыр күгендә самовар җизеннән ясалган ярым ай эленеп тора. Ул нигәдер чалкан яткан. Айның мөгезләре өскә, күккә карап тырпаеп торалар. Мондагы мәчет манараларына беркетелгән айларның да мөгезләре нәкъ шушы рәвештә күккә төбәлгән. «Диңгә дә чынбарлыктан читкә тайпылырга ирек бирмиләр»,— дип уйлап куйдым мин, һәм шулчак брашниль артыннан бер шәүлә чыкканын күрдем. Тимер палубага яланаяк баскан тавыш ишетелеп китте. Шәүлә фальшборт өстендә күренде дә эреп юкка чыкты. Йөгереп, бакка килеп җиткәндә, ике кеше утырган җиңел көймә, безнең пароходтан аерылып, экваториягә таба шуышып бара иде. Көймәдәге шәүләләргә няреп, корабның җитмеш метрлы нейлон арканы да ычкынып өлгергән иде.

Вахтада торучы матроска боцманны уятырга куштым. Вакытсыз уянудан һәм аркансыз калудан боцманның кәефе кырылды. Боцман теленә эләгүдән алла сакласын. Корылманың тимер стеналары дер селкенә иде. Кем ярыша ала икән рус боцманнары белән? Иң башта гарәпләрнең дине — исламга эләкте. Аннан соң аллаһе тәгаләнең үзенә, мәчетләргә, Әнвәр Садатка, Александриядә порт салган борынгы грекларга, Мисырның байларына, ярлыларына, аркан урлаучы балалар тудырган хатыннарга, аларның кретин ирләренә. Борыч һәм дегет тәме килә иде боцманның авызыннан чыккан сүзләрдән.

Сүгенүнең гайрәте таң атуны туктатырга, якты көнне караңгылатырга җитәрлек иде. Шулай да аның моннан тизрәк китеп, татлы йокысын дәвам иттерәсе килде булса кирәк:

— Эчәгеләрең атылып чыгарлык итеп түбәнә берне кундырыр идем дә инде, ярый, бәхетең, беренче ярдәмче тора,— дип, боцман сүзен йомгаклады һәм ботын кашып куйды.

Боцманның сүзләреннән соң, каютама кереп, авызымны чайкадым һәм йокларга яттым. Башка бер телдә дә андый «гайрәтле» сүзләр юк шикелле. Безнең боцманның сүзе килеп тигән җирдә тимер палуба яньчелеп чыга иде.

Дөрес, сүгенү гарәп көймәчеләре урлаган арканны кире кайтара алмады, әмма боцманның беркадәр эче бушады шикелле.

Гарәпләр йөкне ике атна буе бушаттылар. Ике атна буе боцман аркан урлаучыларны көн саен искә алды.

План-наряд буенча без Италия порты Тарантада зур диаметрлы газ үткәрү торбалары төяргә тиеш идек. Йөк бушату озаккарак сузылганга күрә, график бозылды, безнең урынга Тарантага бүтән пароходны җибәрделәр.

Йөк бушатылып беткән көнне пароходчылыктан радиограмма килде: «Александрия портыннан җиде мең тонна эфлисун төягез». Эфлисун төяргә кораб әзер түгел иде.

Юлга чыгар алдыннан без торба төягәндә кирәк булачак агач чөйләрне, чылбыр һәм тимер арканнарны алдан әзерләп куйган идек. Юкка вакыт уздырганбыз икән. Алар хәзер кирәксезгә калдылар.

Күргәнегез бардыр: эфлисун тартмасы юка дранчадан гына эшләнгән була. Тартмаларны берсе өстенә икенчесен утыртып төягәндә, астагылары сытыла башлый. Сытылмасын өчен аларның араларына такта куеп калдырырга кирәк. Диңгезчеләр телендә бу такталарны «сепарация» дип атыйлар.

Корабта сепарациягә яраклык такта юк иде. Аны, билгеле, сатып алырга да була. Әмма Мисыр илендә такта эфлисуннан кыйммәтрәк тора. Чит ил белән сәүдә итү дәүләткә табыш бирергә тиеш. Мисырда эфлисун арзан, такта кыйммәт. Кыйммәт хак белән сепарациягә такта алсак, дәүләткә керәчәк табыш бермә-бер кимиячәк иде. Без тактаны, сатып алмыйча, башка юл белән табарга булдык. Башта тышкы рейдта торучы үзебезнең ил корабларына мөрәҗәгать иттек. Сепарациягә яраклы такта аларда да юк иде. Бәлки булгандыр да, кем белә. Корабта тактаның һәрвакыт кирәге чыга.

Пароходчылыкка ашыгыч радиограмма җибәрергә туры килде. Җавап көтә башладык. Җавап юк иде. Радиотелефонга күчтек. Сөйләштек. Безгә: «Полтава» теплоходында сепарациягә җитәрлек такта бар, шуннан алыгыз»,— диделәр. «Полтава»га мөрәҗәгать иттек. Капитан Меленчук: «Сепарация бар, бәлки сезгә җитәр дә, әмма такта минем үземнеке түгел. Кисәтеп куям, пароходчылыктан фәрман килмичә, бирә алмыйм. Гафу итегез»,— дип җавап бирде.

Ждановка тагын бер радиограмма очты. Радиограмма эш көне тәмамлангач кына барып җиткән күрәсең — җавап килмәде. Пароходчылыкның йөз егерме корабы туктаусыз радиограмма җибәреп тора. Аларга вакытында җавап бирергә кирәк. Эш көне сигез генә сәгать. Радиограмма җомга көн китте. Җомгадан соң — шимбә, аннан якшәмбе. Пароходчылык идарәсендә эшләүчеләр атнасына ике көн ял итәләр. Җимеш хуҗалары безне ашыктыралар. Эфлисун — нәзберек җимеш. Ул озак көтәргә яратмый, бозыла башлый.

Ниһаять, дүшәмбе җитте. Көтәбез. Төш вакытында җавап килде: «Шушы радиограмманы алу белән, «Полтава» сезгә ашыгыч рәвештә такталарны тапшырырга тиеш».

Җавап килгәндә, диңгездә тугыз баллы шторм башланганга,

«Полтава», якорь чылбыры өзелүдән куркып, дрейфка ятып өлгергән иде. Безнең капитан УКВ[1] аша «Полтава» капитанына никадәр генә ялынмасын, капитан Меленчук гел бер сүзне кабатлады: «Сине такталы итәм дип, унбиш миллион сумлык корабны челпәрәмә китерәсем юк».

Шторм вакытында портка керү шактый куркыныч эш. Аның өчен зур тәвәккәллек кирәк. Меленчук үз корабының иминлеген кайгыртты. «Ул Булат Җамаловичтан көнләшә. Аның өчен өстенә җаваплылык алмаячак»,— диделәр элек Меленчук белән бергә эшләгән диңгезчеләр. Аларның сүзе дөрес булып чыкты.

«Полтава»ның портка кермәячәген аңлагач, Булат Җамалович кавказлылар кайнарлыгы белән эче бушаганчы чәпчеде:

— Трус! Капитанмыни ул Меленчук! Ул...— Эчкерсез, изге кабыну, нәфрәт Насыйрбашевның фикер йөртү сәләтен җуйган иде.— Әгәр штормга сылтап, башка корабка ярдәм итүдән баш тартканымны күрсәгез, килеп битемә төкерегез. Төкерегез битемә берәр нәрсәдән курыкканымны күрү белән!

Ә штормның туктарга исәбе юк иде. Чүл ягыннан искән коры җил диңгезгә тузан ташый. Офык тонык. Басым һаман төшә. Дулкыннар һаман үкереп тәгәриләр.

Булат Җамалович бер тын уйланып торды да, фуражкасын башына чәпәп, портка чыгып китте.

Төш вакыты җиткәндә, без күреп алдык. Капитаныбызны ике яктан ике кораллы полицейский саклап каядыр алып бара иде.

— Комиссар!— дип кычкырды ул миңа.— Төрмәгә япсалар, балаларымны ач калдырма. Ярдәм итәргә тырыш!

Йөгереп причалга төштем. Капитанга ярдәм. Полицейскийлар миңа таба борылдылар.

— Ычкын тизрәк,— диде капитан.— Сине дә алсалар, кем кайгыртыр экипажны, кем кайгыртыр корабтагы эшләрне? Йөкне төйи башларга кирәк. Вакыт бушка уза.

Мин агентлыкка, аннан соң Александриядә эшләүче Министрлык вәкиленә шалтыратып карадым. Аларның катнашасылары килми иде. Консулга хәбәр итәргә ашыкмадым. Аларга барып житсә, гауга куптарып, тизрәк, Мәскәүгә хәбәр итәчәкләр. Анда тикшеренеп торырга яратмыйлар, турыдан-туры эшеннән алалар.

Ике сәгатьтән такта төягән машинага утырып, Насыйрбашев үзе кайтып килде. Машинадн төшү белән кычкырды:

— Сепарация әзер. Йөкне төйи башларга кирәк:

Чыгырлар хәрәкәткә килде. Докерлар эшкә кереште. Корабны әфлисун исе чорнап алды.

Кичке чәй вакытында кают-компаниядә утырганда, Булат Җамалович такта мажараларын безгә сөйли иде.

Ул портта торучы корабларның капитаннарыннан такта турында сорашып бара торгач, Польша пароходына барып җиткән. Польша капитаны сепарация бирергә булган. Килешкәннәр. Тактаны нәрсәгәдер төяп, «Матвей Муранов»ка китерергә кирәк. Насыйрбашев үз акчасына йөк машинасы яллаган. Сепарацияне төягәннәр. Кузгалып китү белән такта төягән машинаны эләктереп алганнар.

Һәр йөккә төяләсе һәм бушатыласы әйбер таможня аша үтәргә тиеш. Таможняның рәсми рөхсәтенән соң гына әйбер урыннан кучерелә. Безнең капитан, такта табу сөенеченнән, гарәп таможнясы белән сөйләшеп, рөхсәт алырга оныткан. Булат Җамаловичны контрабандистка санап, полиция кулга алган. Аны участокка алып киткәннәр.

[1] Ультракыска дулкынлы радиостанция.

Бәхетенә каршы, участокта Насыйрбашевның таныш начальнигы, аның дусты туры килгән.

Традициядә корабка кергән кешене ашатып-эчертеп чыгару гадәте бар. Капитан Насыйрбашев шушы гадәтне гаҗәп искиткеч гадел үти иде. Александриядә торганда капитанның туган көне килеп җитте. Ул шушы бәйрәмгә алдан әзерләнә башлаган икән. Сәгать дүртләр тирәсендә капитан каютасына кунаклар җыела башлады. Консуллык һәм сәүдә вәкиллегендә эшләүчеләр, диңгез флоты министрлыгының Александриядәге вәкилләре — боларның барысы да чакырылган иде. Чит илләрдә эшләүче совет кешеләре, гомумән, корабка килергә яраталар. Берәүләр борщ сагынып, икенчеләре туйганчы русча сөйләшәсе килеп, өченчеләре... Кунакны нинди көч куып китергәнне әйтеп буламыни?

Тормыш шартлары үзгәргән саен, кунак җыюның сәбәбе һәм максаты үзгәреп тора. Элек туган-тумача кадерле кунак саналган, хәзер— кирәклерәк кешеләр...

Портта торган совет корабларының капитаннары килде. Экипаж әгъзалары да бу бәйрәмгә «актив» катнашкан иде. Сәгать биштә мәҗлес башланды. Аш-су әйбәт, шәраб дигәнең елга булып ага.

Кунаклар киткәч, Насыйрбашев командирларны сыйлады. Алардан соң рядовой составны. Иртәнге җидедә физзарядкага чыкканда, капитан каютасында идәнне дер селкетеп аш пешерүче, табак-савыт юучы кызлар бии иде.

Бәйрәм әнә шулай күңелле, матур узды. Эш хакы түләргә пароходчылыктан ведомость килгәч, Булат Җамалович әҗәткә алган акчаларына кул куйды. «Алган әҗәтләремнең яртысы түләнде, киләсе айга бәлки бөтенләй түләп бетерермен?»— дип, ул тагын бер кат шатланып йөрде. Юмарт кешеләрнең хәләл җефетләренә алла ярдәм бирсен! Юк, барыбер Насыйрбашев шикелле әйбәт кеше белән яшәве рәхәт! Акча барыбер кешегә бәхет бирә алмый. Булат Җамаловичның бәхетле чаклары шактый еш була иде.

## Яшьлек белән очрашу

Алтмыш өченче ел. Без «Чолым» пароходы белән Александрия портына бодай алып килдек. Гарәп докерлары трюм эчендә, яныппешеп, капчыкларга бодай тутыралар. Капчыкларны йөк төйи торган ук белән өскә күтәрәләр дә машиналарга төйиләр. Ач-ялангач булсалар да, гарәпләр тырышып эшлиләр. Башкача булмый — әкрен кыймылдаучыларны икенче көнне ялламыйлар. Эш эзләүче күп. Ялкау эшсез кала.

Докерлар белән җитәкчелек итүче стивидор — үзе рәис, үзе профком, үзе халык контроле. Алай гына да түгел, докерлар өчен ул — конституция. Надан докерлар илдә конституция барлыгын, төп законның стивидордан, хәтта президентның үзеннән дә өстен икәнлеген аңламыйлар. Аңласалар да инде... Җир йөзендә законны кулланып, гамәлгә ашырып булмый торган илләр бар.

Шул чакта докерлар арасында тугыз-ун яшьлек бер малай эшли иде. Малай капчык авызын тегеп тора иде. Барлык илләрнең дә сабыйлары бер төрле. Аларны бер-берсеннән аерып булмый. Адәм балаларын үзара аера торган милли, сәяси, социаль сыйфатлар өлкәнәю чорында гына барлыкка килә. Гарәп малае минем бала чакта уйнап үскән дусларыма охшаган иде. Докерлар ялга туктагач, трюмда шул малай белән таныштым. Атнага якын аның белән очрашып, аралашып яшәдем. Диңгезгә чыккач та нигәдер шул малайны сагына

идем. Сагыну гарәп малае турында «Тимер фил» исемле хикәя язарга мәҗбүр итте — үз гомеремдә язган беренче хикәям. Белмим, нинди дуамаллык беләндер, хикәяне Одесса шәһәрендә чыга торган «Моряк» газетасына (ул газетада вакытында Константин Паустовский, Валентин Катаев эшләгән) конкурска җибәргәнмен. Конкурска катнашып, җиңү, бүләк алу турындагы уй башыма да килеп караганы юк иде. Һәм, ни сәбәптер, миңа беренче урынны биргәннәр. Мине шул беренче урын харап итте, мине тыныч, рәхәт яшәүдән яздырды... Язучылыкның газапларын алдан белгән булсам, язу эшенә тотынып идем-мени?

Шушы юлларны язганда, порт краны белән трюмга әфлисун төшергәннәрен күзәтеп торам. Әрҗәләр юка. Төшергәндә үк күбесе сытыла. Аларны төзәтеп торырга аерым бер кеше куйганнар. Урта яшьләрдәге сыңар аяклы бер гарәп. Үзе җәһәт эшли. Бер хәрәкәт — әрҗәнең сынган тактасы каерылып ташлана, икенчесендә — яңа такта беркетелә, өченче хәрәкәт — төзәтелгән әрҗә йөккә кереп урнаша.

Гарәпнең шундый өлгер, шундый әсәрләнеп эшләвенә мин озаграк сокланып торганмын булса кирәк, ул миңа таба борылып елмайды. Елмаю хәтернең ерак почмагында вакыт тузанына әверелгән бер вакыйганы актарып чыгарды.

— Исемегез ничек сезнең?— дип сорадым әрҗә төзәтүчедән.

— Багра.

Теге малайның да исеме Багра иде.

— Моннан ундүрт ел элек совет пароходыннан бодай бушатканыгыз булмадымы сезнең?— дип сорыйм.

— Бәлки булгандыр? Кем белгән. Тәпи йөри башлаганнан бирле тамагымны порт туйдыра.

— Минем тугыз йөз алтмыш өченче елны портта торганда мин бер Багра исемле малай белән дуслашкан идем. Истәлек итеп бер күлмәк белән бер бөтен икмәк тә биреп калдырган идем.

— Күлмәк хәтеремдә,— диде ул шатланып.— Мамык тукымадан тегелгән зәңгәр күлмәк иде. Әни аны кечерәйтеп, апама кигергән иде,— әрҗә төзәтүче миңа текәлеп карады.— Ул чакта син күзлексез идең бит. Яшьрәк тә идең. Картайгансың.

Уңайсызлык туды. Ни әйтергә белмичә бер тын югалып тордым. Җир шары зур. Планетада ничә миллиард кеше яши. Ә мин башка континент кешесен гомеремдә икенче тапкыр очратам. Ә күзем һаман гарәпнең өзелгән аягында.

— Күптәнме?

Әрҗә төзәтүченең күзләрендә нәфрәт очкыннары күренде.

— Яһүдләрне Сүәеш каналыннан куганда.

— Пенсия түлиләрме?

— Унбиш фунт. Көненә илле пиастр. Биш бала. Хатыным авыру. Габдел Насыр чорында ашамлык арзан иде. Хәзер күтәрелде. Ачка үлмәс өчен көненә уникешәр сәгать тир түгәргә туры килә. Башкача яшәп булмый.

«Мәңгелек көрәш, —дип уйладым мин.— Ачлыкка, ялангачлыкка, изүгә, гаделсезлеккә каршы. Гасырлар буе тукталмыйча, буыннан буынга тапшырылып килгән көрәш».

Инде күптән ачлык күргәнебез, аны татып караганыбыз юк. Белмибез, аңламыйбыз без ачлыкның каһәрле якларын. Көне буе диярлек мин шушы турыда борчылып йөрдем. Янында ач кеше барында яшәүнең рәхәте, мәгънәсе югала. Бернинди шатлыгың, куанычың калмый.

Эш көне тәмамлангач, телевизор карарга утырабыз. Мисыр президенты Әнвәр Садат Израильнең премьер-министры Бегин белән капма-каршы утырган, көнбатыштан килгән журналистларга интервью

бирә. Садат янында — сул күзен кара чүпрәк белән бәйләгән Израильнең чит ил эшләре министры Моше Даян. Ике юлбашчы сугыш кырында түгелгән халык каны, яшь буынның язмышы белән сәүдә итә. Сыңар аяклы Багра шушы вакыйганы күрдеме икән? Ул ничек түзде икән шушы хыянәткә?

### Икенче бүлек

*Сатлык җан да, палач та, шымчы да*
*тыныч кына йолдызлар астында яши бирә.*
*Килмешәкләр таптаган ватаның өзелеп*
*сөйгән көрәшчегә генә монда урын юк...*

Сальваторе Квазимодо

## Күңел сызлаганда

Тәрәзәдән төнге шәһәр күренә. Тау кабыргасына ябырылган тынгысыз утлар. Аста, тау итәгендә, алар куерып, бер-берсенә сырышып җемелдиләр. Өскә күтәрелгән саен, утлар сирәгәя, сыеклана бара. Алар түземсез дерелдиләр. Бәлки, бу сәер хәрәкәт аларның үзара киңәшүе, нәрсәнедер аңларга теләп серләшүедер?

Утлар, яр белән генә канәгатьләнмичә, Цемес култыгының суына ук кереп урнашканнар. Су астында балкып торган тагын бер зур шәһәр күренә. Көндез ул каядыр поса, яшеренеп, караңгы төшкәнен көтә. Тау кабыргасында утлар кабыну белән, су асты шәһәре тагын уянып, әкияттәгечә балкый башлый.

Мин «Бригантина» исемле кунак йортына тукталдым. Диңгезчеләр өчен салынган унике катлы гостиница. Монда кораблары сәяхәттән кайтканын көтүче моряклар яши. Илнең бер төбәгеннән икенче төбәгенә, шәһәрдән шәһәргә командировкага йөрүче тынгысыз, шома халык та җитәрлек монда.

Мин дә «Академик Арцимович» исемле корабның ерак сәяхәттән кайтуын көтәм. Шул кораб турында уйларга, аның туган илгә ашыгуын күз алдыма китерергә тырышам. Мин аны күрмәгән әле, аңа утырганым да юк, андагы кешеләрне дә белмим. Шунлыктанмы, кораб турында уйлыйсы урынга авылымны искә төшереп утырам. Ярда[1] вакытта диңгездәге давыллар, штормнар, тәнеңне көйдергән аяусыз тропик кояшы, тропикның тынчу юеш һавасы онытыла. Җирдә яшәгәндә, диңгезнең көләч елмаюы, рәхәте, китергән бәхете генә кала.

Сәер халык ул диңгезчеләр: өйдә дә, сәяхәттә дә һич тынгы белмиләр. Сәяхәттә йөргәндә, туган җирне, кардәш-туганнарын, сөйгән ярларын сагыналар, өйләренә кайткач, диңгезне уйлап җирсенә башлыйлар. Тынгысызлык яши диңгезче йөрәгендә, тормыш, көнкүреш өчен уңайсыз тынгысызлык.

Бүлмә буш. Почмакта агач карават. Карават өстендә еш юудан төссезләнеп калган зәңгәр җәймә. Вакытлы кешеләрнең башлары таптап таушалдырган сыек мендәр. Тәрәзә янында аяклары какшап беткән бәләкәй өстәл. Өстәл читен эт кимергән диярсең — буеннан-буена теш эзләренә охшаш җәрәхәт сузылып киткән. Сыра бөкесен ачудан барлыкка килгән җәрәхәтләр бу. Мин өстәл кырына карамаска тырышам. Бүлмәдә сыңар урындык һәм мин. Һәрнәрсә ялгыз монда: карават та, өстәл дә, урындык та, мин үзем дә. Күңелсез уйлар кила буш гостиница бүлмәсендә ялгыз утырганда. Адәм баласына сердәш кирәк.

[1] Диңгезчеләр җирдә яшәүне шулай атыйлар.

Ике кешелек бүлмәгә урнашсам, туктаусыз тәмәке көйрәтүчегә, аракы эчеп, былагайланып йөрүчегә юлыгырмын дип курыктым. Элек алай түгел идем. Олыгая башлагач, төннәрен гырылдап йоклаучы ешрак очрый башлады. Ирләрдәге ике сыйфат пычаксыз суя мине: исерек баштан сырышу һәм гырылдап йоклау. Шуңа күрә гостиницадан көч-хәл белән бер кешелек аерым номер алдым, һәм хәзер менә шуңа үкенеп, ялгызым күңелсез уйларга батып утырам.

Япония һәм Куба, Урта Азия һәм Кавказ, Чукотка һәм Сахалин, Днепр яры, Одесса һәм башкала. Җирдә, күктә, океан дулкыннары арасындагы озын юллар. Артта калганнары һаман озая, алдагысы, киресенчә — кыскара. Юлларга чәчелеп калган гомер. Шуларның барысын да күз алдыма китерергә тырышам. Кайда ул минем узган гомерем? Бала чак, яшьлегем кайда? Фән матдә һәм энергия югалмый, тик рәвешен генә үзгәртә дип аңлата. Хәзер нинди рәвештә ул минем үткән гомер?

Гел бер урында, гел бер генә авылда яшәгән булсам, узган гомерне күреп булыр идеме икән? Белмим. Беркем җавап бирә алмый бу сорауга.

Яңа корабка билгеләнер алдыннан мин авылыма кайтып килдем. Кайткач, ничектер Урындык тавына менәргә оныткакмын. Бишенче класста укыганда, шул тауга менеп, игәү белән кыяга ике исем язып куйган идем. Берсе үз исемем... Балачакның көләч ваемсызлыгы шул кыядагы хәрефләргә йогып калмадымы икән? Шуны нигә карамадым?..

Авылга кайткач, мин мәктәп балалары белән очраштым.

«Сез тауга менәсезме? Тау түбәсеннән офыкларга, зәңгәр күктәге агылма болытларга карыйсызмы?» — дип сорарга оныткакмын. Тау түбәләре, офык артына ашеренгән ерак урманнар, зәңгәр бушлыкта йөзгән ак болытлар белән мавыкмаган яшьлек нинди була икән? Шуны беләсем килә.

Сәяхәт турында сөйләгәндә, балалар күңел биреп тыңлыйлар. Хикмәт тыңлауда гына да түгел. Яшь кеше үз гомерендә бер генә тапкыр булса да биек тауга менәргә, урман эчендәге аулак ялан чирәменә чалкан авып, биеклектә йөзгән болытларга карап, уйланып ятарга тиеш.

Ләкин тауларга менеп, елгалар кичеп, болытларны күзәтеп йөрүнең уңайсыз ягы шул: ул гадәт сине гомер буе төзәлмәс сәяхлек хастасына сабыштыра.

Күз алдымда — бала чакта җир шарының иң зур, иң матур елгасы тоелган Ык, иң биек тоелган Урындык тау һәм кайчандыр иң матур күренгән Исергәп авылы. Бала чакта башка авыл кешесе миңа башка планета бәндәсе булып тоела иде. Исергәптән башка җирдә җан иясе булуга, аларның Исергәп тормышыннан үзгә шартларда яши алуларына ихлас гаҗәпләнә идем. Тәҗрибә миңа киресен исбатлады. Адәм баласы теләсә нинди шартларда да яши ала. Аңардагы күнегү, җайлашу сәләте иксез-чиксез. Әмма ул фәкать бер урында — туган жирендә генә бәхетле. Мин шул хакыйкатьне ничә еллар буе җир шарының төрле почмакларыннан эзләп йөрдем.

«Академик Арцимович» моннан ике тәүлек элек Новороссийск портына кайтып житәргә тиеш иде. Инде ике тәүлек көтәм. Ә кораб һаман юк. Һава торышы турында прогноз бирүчеләр Һинд океаныннан тайфун үткәнен әйткәннәр иде. Кораб ул тирәдән исән-имин килеш үз вакытында узган. Мин юлга чыкканда, ул Дарданеллга житеп килергә тиеш иде. Сигез сәгатьтә Мәрмәр диңгезен, унжиде сәгатьтә Кара диңгезне үтсә, хәзер инде Новороссийскида булырга тиеш диган сүз. Ә ул менә юк та юк.

Ахырда ачыкланды: «Академик Арцимович»ны йөк төяр өчен Истамбулда тоткарлаганнар булып чыкты.

## Сукбайлыктан качу

Бер атна элек мин торган кунак йорты тәрәзәсеннән Казанның Бауман урамы күренә иде. Тәрәзә каршына ыңгырашып троллейбус килеп туктый. Ишекләре ачылып китә дә, троллейбусның тыгыз карыныннан тротуарга халык коела.

Кая карама анда тыз-быз җәяүлеләр атлый. Туктаусыз. Берәүләр— уңга, Кремль ягына, икенчеләр — Кольцога таба. Халык көне-төне туктаусыз хәрәкәттә. Кешеләрнең кулларына карыйм. Әйберсез, буш йөрүче юк диярлек. Ирләр портфель тоткан. Ун ирнең сигезендә портфель. Хатын-кыз кулында — хуҗалык сумкасы, редикюль, целлофан капчык, азык-төлек җәтмәсе. Берьюлы өчәр сумка күтәргәннәре бар. Мин бәләкәй чакта шәһәр хатыннары күзге һәм пудра сыя торган редикюль генә тотып йөриләр иде. Сугыштан соң — җәтмә, соңрак хуҗалык сумкасы өстәлде. Хәзер, шуңа өстәп, портфель кушылды.

Казанга киткәндә, минем ике атна ялым бар иде. Шул вакыт эчендә туган республикамның башкаласын туйганчы карап йөрермен, дусларым белән туйганчы сөйләшермен дип өметләнеп барган идем. Корылган планым буенча Кремль коймасыннан таң атканны күзәтергә, Кабан күлен җәяү әйләнеп чыгарга, Тукай һәйкәленә чәчәк куярга, Такташ, Җәлил, Галимҗан Ибраһимов яшәгән йортларны күрергә, Камал театрын карарга, Шиһабетдин Мәрҗәнинең каберенә зыярәт кылырга тиеш идем. Төн кунуга, эшемнән ашыгыч телеграмма килеп төште. Мин эшлисе кораб сәяхәттән кайта, шуңа өлгерергә кушылган иде. Ашыгып аэропортка киттем. Дусларым белән саубуллаша да алмадым хәтта.

Казаннан Ждановка очышлый өйгә сугылганда, мин булган бөтен вакытымны диярлек сәяхәткә алып китәсе әйберләрне сайлауга сарыф иттем. Чемодан, капкачын киереп ачып, бүлмә уртасында ята. Инде күлмәк-чалбар, костюм, кулъяулыклар, оекбашлар күптән салынган. Аяк киеменең кайсыларын алырга? Иң авыры — аяк киеме сайлау. Тышкы кием сайлавы да җиңел түгел: диңгезче юлга чыкканда, берсе өстенә икенчесен кияргә яраклык юкарак кием алырга тырыша. Тышта сентябрь. Агач яфраклары саргайган. Көз. Озакламый яфраклар коела башлаячак. Көзге шәфкатьсез җил салкын яңгыр ташый. Кошлар көньякка очарга җыеналар. Мин дә җыенам, безнең язмышлар бер. Диңгезче тәкъдире очар кошларныкы кебек... Аерма тик шунда — кошлар сәфәргә иң мөһим, иң кирәк нәрсәләрне генә алалар: чыдам мускул, җылы мамык, каты, нык каурый һәм алдагы юлның имин булуына ихлас ышану. Кошларның бар йөкләре шул.

Ә мин чемоданыма кирәксез әйберләр тулса, аларның кайсын кайда ташлап китәрмен икән дип баш ватам. Акыл көзге кием алырга куша. Әмма, Босфорны үтү белән, җәй. Урта диңгездә көзге кием кирәксез йөккә, өстәмә бәлагә әйләнә. Өйдән алган әйберне ташлап калдыруы кызганыч. Аны сатып алыр өчен син шактый бил бөккәнсең.

Сүәеш каналын узгач, кайнар мунча эсселеге башлана. Кызыл диңгездә җәйге киемнең дә кирәге калмый. Тропикларда йөзгәндә, иң кулае — кыска чалбар, җитен яисә мамык җепле күлмәк (синтетика ярамый), ачык башлы сандали. Кояш кыздырганда кию өчен юка йон күлмәк тә әйбәт. Йон эсселекне үткәрми. Тропикларда шулар җиткән. Ә инде экватор аша узып, Кәҗә мөгезе тропигына чыккач, аны да артта калдырып, «үкереп торган кырыгынчы» параллельгә җиткәч, кышкы кием кирәк була.

Сәяхәткә кием сайлауның тагын бер катлаулы ягы бар: өйдән җәен китсәң, кышын урап кайтасың. Кыш киткәндә, киресенчә, җәй кайтыла. Һәрвакыт шулай. Берьюлы өч сезон киемен күтәреп йөрүе ифрат авыр. Берьюлы ике чемодан кием-салым күтәреп йөрмәс өчен, мин әйберләремне Керчь, Херсон, Туапсе портларында бүлеп калдырган идем. Инде менә өченче ел китте: мин йөзгән кораблар ул портларга кермиләр. Әйберләрем исәнме-юкмы—анысын да белгән юк. Узган елны алты ай Һиндстанда, гарәп илләрендә йөреп пароходтан Одессага төшкәч, Мәскәүгә кайтырга туры килде. Өйдән июньдә чыгып киткән идек, январьда кайтылды. Өстә — дүрт кат күлмәк, свитер, аякта — өч кат оекбаш. Бүрек юк иде. Башыма да оекбаш киеп кайттым. Көлүен көлделәр. Әзмени ахмак кешеләр. Иң кыйммәте — өшемәдем, салкын тиюдән сакланып калдым, хәтта томау да төшмәде. Сәяхәткә йөрү үзе берни түгел, аның менә шушындый вак мәшәкатьләре, уңайсызлыклары бимазалый.

Киенүнең өченче катлаулы ягы бар. Бусы — хатынның күңелен күрү. Рәисәнең миңа затлы костюм кигертеп, тәти галстук тактырып йөртәсе килә. Аның бу теләге тиктомалдан гына түгел: хатын чамалап йөри — өстенә соңгы модада тегелгән кыйммәтле костюм, кулына атташе-кейс тотып йөрүчеләр тормыш киртәләрен җиңел атлап үтәләр. Мин үзем дә сизәм — андыйлар күп вакыт теләкләренә ирешәләр. Ә диңгез кануннары икенче төрле. Диңгездә очраган авырлыкларны, аның каршылыкларын тәти галстук, атташе-кейс белән генә җиңеп булмый. Диңгез чыдамлык һәм түземлек таләп итә. Авырлыклар очраганда тайпылмыйча юлыңны дәвам итүне, ихтыяр көчен, тугрылыкны таләп итә.

Кызымның да миңа булышасы килә: «Әти,— ди ул,— чит илдә күпме йөреп, үзеңә джинси чалбар алып кияргә дә кулыңнан килмәде. Хәзер вельвет модага кереп бара. «Ли», «Рой-Роджерс», «Леви Страусс», «Вранглер» — шушы фирмаларныкын алырга тырыш». Сүз көрәштереп торырга вакыт юк, мин аларның икесенең дә киңәшләре белән килешкән булам. Ә эшләвен — үземчә эшлим. Шәрык ысулы бу.

Күлмәкләр өстенә Габдулла Тукайның «Сайланма әсәрләр»ен салам. Бу китап минем белән ничә тапкыр экватор аша үтте. Без аның белән бергә Антарктикада кораб күкрәгенә дөбердәп бозлар бәрелгәнен тыңладык. Китап дүрт материкны, барлык океаннарны гизеп чыкты. Ул хәзер сердәш кенә дә түгел, үзенә бер талисманга, нәзер китабына әйләнде.

«Татар халык җырлары»н да алмыйча булмый. Аның кирәк чаклары еш була. Сагыну газабы йөрәкне сыкрандыра башлагач, тәмле аш та, затлы эчемлек тә хозурын югалта. Хәтта якын дусларны да күрәсе килми башлый. Шушындый чакларда борынгы җырлар, халык моңы — алҗыган йөрәккә бердәнбер шифа, туйдырмый торган дәвалы юаныч.

Корабларда русча китапны табып була. Алар җитәрлек. Дөрес, күбрәк Бабаевскийлар очрый. Андыйлар корабта ифрат күп булучан. Шуңа күрә чемоданыма татар китапларын тутырырга тырышам. «Җырлар» янына татар әдипләре кереп утыра. Чемодан тулды. Аны ябып биклим. Мин әзер. Чемоданны күтәреп карыйм,— әйтерсең тимер-томыр тутырганнар, кузгалмый да.

Үгет башлана. Хатыным: «Врачларның кисәтүен онытмыйсыңмыни? Дүрт-биш килодан артык күтәрсәң, ревматизм атакасы башланачак дип колагыңа киртеп куйдылар бит»,— ди. Үзе юкса әле генә варенье ал дип каныма тоз салган иде. Кызым исә миңа юлга бал әзерләп куйган. Врачлар тәкъдим иткән шифалы ашамлык. Алар чын күңелдән

яратуларын исбатлау өчен, әнә шулай янып-пешеп, миңа вареньe һәм бал тагарга тырышалар. Калган вакытны бәхәс ашап бетерә. Нәтиҗәдә — хатыным әзерләгән тәмле токмач ашы да өстәлдә утырып кала. Кайчан гаилә белән бергәләп ашыкмыйча гына ризык җыеп булыр икән? Кайчан?

Ишегалдына чыккач тагын бер бәхәс: хатыным белән кызымның мине таксига утыртып озатасылары килә. Мин метрога юнәләм. Мәскәүдә хәзер метро поезды таксидан тизрәк йөри. «Электрозавод» станциясеннән «Юго-Западная»га кадәр төгәл илле минут. Шунысы начар — вагонда кысынкы, һава җитми, аягүрә басып барырга туры килә. Шуңа карамастан, мин метрода барырга телим. Хәтта кыенлыкларга да риза. Метрода мин Мәскәү халкын һәм башкалага килгән барлык республика вәкилләрен күреп китәм. Суга чумар алдыннан, үпкәңне тутырып, сулыш аласың бит. Бу шуңа охшаш халәт. Озакламый өч дистә экипаж әгъзасыннан башка бүтән беркем белән дә күреп сөйләшеп булмый торган ялгызак тормыш башланачак. Шуңа күрә минем вагон эченә шыгрым тулган халыкны туйганчы, күңелем булганчы карап каласым килә.

Күп тә үтми, ТУ-134 безне һавага алып менеп китте. Гаиләм, җылы почмагым, тыныч тормышым, яшәү дәверендә барлыкка килгән элемтәләрем — барысы да түбәндә калды. Нинди төп максат өчен яши бу дөньяда адәм баласы? Кем җавап бирә ала шушы сорауга? Бүгенге көндә минем өчен иң кыйммәт нәрсә — тынычлык, гаилә иминлеге, туган ил иминлеге. Ә мин шуларны ташлап сәяхәткә чыгып китәм.

Сәгать икедә мин пароходчылыкның кадрлар бүлегендә идем инде. Кадрлар бүлегендә минем вакытында килеп җитә алуыма шатландылар.

— Өлгерә алмассың дип курыккан идек, молодец!— диделәр.— Сез мең километрдан килеп өлгергәнне, моннан биш йөз метрда яшәүче өлкән механикны әле дә таба алмадык. Квартиры бикле, кайдадыр йөри.

Кулга приказ тоттырдылар. Минем «Академик Арцимович» теплоходына билгеләнүемне раслап, кадрлар бүлеге начальнигы, партком секретаре, профсоюз председателе, чит илгә йөзүче моряклар белән эш итү бүлеге һәм бүлек начальниклары, инглиз теле өйрәнү кабинетының директоры һәм пароходчылык начальнигы кул куярга тиеш. Мин шуларның имзаларын җыярга керештем. Автографларны җыеп бетергәч, порт капитанының конторына кереп, моряк паспортына яңа корабның исемен яздырып, мөһер суктырдым.

Кабинетлар арасында юыртып йөрүнең бер уңайсыз ягы бар: җиде кешенең берсе каядыр чыгып киткән була. Командировкага киткән начальник урынына гадәттә ярдәмче кала, һәм приказга да ул кул куя. Әгәр начальник эш белән бер генә минутка чыгып киткән булса (бер минутка киткән начальникның бишәр сәгать йөреп кергән чаклары еш очрый), ярдәмче приказыңа егылып үлсәң дә кул куймый.

Бу юлы, бәхеткә каршы, бер генә бүлектә дә тоткарлык булмады. Эш артык шома эшләнгән чакларда мин нигәдер шомлана, курка башлыйм. Уңышлыкның һәр граммына бер грамм комачаулык әзерләп утыручы фәрештә юкмы икән җиденче кат күктә? Башкача ничек аңлатыр идең приказ нөсхәсен кадрлар бүлегенә тапшырганнан соң булган вакыйганы?

— Әллә әйләнеп тә чыктыгыз инде? Ут икәнсез, Миргазиян Закирович,— дип мактады мине кадрлар бүлеге начальнигы.— Медицина кенәгәсен өегездә онытып калдырмадыгызмы?

— Юк, алып килдем,— дидем мин, пиджак кесәсен капшап.

— Медкомиссияне кайсы айда үттегез?

Чигә тамырларым тибә башлады. Каушавымны яшерер өчен елмайган булдым. Агач маска, таш сын елмаюы иде бу. Кул калтыравын яшерер өчен, кесәмә тыгылдым. Кульяулык чыгарып, борынга кагылган булдым.

— Әйе...— Комиссия... комиссиягә... комиссияне... Үтеп була аны... Ул... ни... ул...

Авиациядә хезмәт иткән чакта ук врачлар минем йөрәккә бәйләнә башлаганнар иде инде. Унбер ел очып йөреп, авариягә эләккәннән соң мине эшкә яраксыз итеп пенсиягә чыгардылар. Врачларны иң куркыта торган авыру — йөрәк. Пенсиядән соң уналты ел диңгездә йөздем. Бу юлы медкомиссияне үтә алсам, тагын бер ел йөзеп булачак. Медкомиссия! Әбием миңа кечкенә чагымда сират күпере куркынычларын сөйли торган иде. Ул күпердән мин хәзер һич курыкмыйм. Бихисап медицина комиссияләре үтә-үтә мин сират күпере аша хәтәрсез чыгарга җитәрлек тәҗрибә туплаган идем инде.

Таң калырлык чыдам икән ул адәм йөраге.


Моннан дүрт ел элек йөрәк авыруы белән больницада ятканда врачлар йөрәккә ясалма клапан куярга тәкъдим ясадылар. Йокысыз озын төннәрдә мин йөрәгем белән серләшеп яттым. Мин аны болай үгетләдем: «Йөрәк, бирешмик яме? Тырышыйк. Тагын бер тапкыр тырышып карыйк. Зинһар өчен! Тагын бер мәртәбә Босфор таңын, Анатолия ярлары өстеннән кояш калыкканын күрик! Неапольның Санта Лючия ярында кояшлы көләч көндә яшь җырчылар ярышканын тыңлыйк. Бискай култыгында тәгәрәгән дәһшәтле дулкыннарны, аларның үкереп корабка ташланганнарын күрә алмыйбыз микәнни? Син бит гаҗәп әйбәт, чыдам, йөрәк! Мин юлләргә хезмәт итеп, күпме интектең, күпме авырлыклар кичердең! Сахалиннан Котыпка очканда, боз өстенә утыргач, иң таза малайлар арыдык дип зарланганда, бер сүзсез эшләвеңне дәвам иттең. Җиргә бәрелеп сытылган самолет эчендә канга батып ятканда да, хыянәт итмичә, һаман эшли бирдең. Син илле ел барлык әгъзаларыма, тәнемнең һәр күзәнәгенә җан биреп тордың. Тагын сафка басыйк! Сынатмыйк. Сер бирмик, яме! Тын бетү, хәлсезлек вакытлы гына ул. Без тереләчәкбез. Мин ышанам — син сынатмассың, соңгы мәртәбә! Мин сине авырлыклардан сакларга тырышырмын, көчәндермәм! Соңгы мәртәбә, яме? Шуннан соң ял итәрбез...»

Әгәр аның кешенеке шикелле хәтере калу гадәте булса, йөрәк миңа: «Синең дуамаллыгың аркасында һаман нужа күрәсем юк. Син мине кызганмыйсың. Тагын җикмәкче, тагын кумакчы буласыңмы? Җитте! Шабаш! Миңа ял кирәк. Ял бирмәсәң, туктыйм»,— дип әйтер иде. Кеше йөрәге — даһи. Ул аңлады. Аңлады һәм тагын тырышты.

Мин тагын йөзәм. Босфорда таң атканын, Везувий кратерыннан сыек төтен күтәрелгәнен күрәм. Диңгезгә куе томан төшкән чакларда пароходларның кызганыч тавыш белән гудок бирүләрен тыңлап йөрим. Боларның барысы да йөрәкнең күндәмлеге, аның тырышлыгы, миһырбанлыгы аркасында.

Еллар үткән саен, тазалык кими. Тәҗрибә исә һаман арта бара. Нигә ул карт кешегә тәҗрибә? Теләкләрне эшкә ашырырга барыбер вакыт юк, барыбер егәрлек калмаган. Тәҗрибәне эшкә җигәрлек көч калмый картлык көнендә. Шушы хакыйкатьне белеп, табигать бер даһи канун чыгарган: ул тәҗрибәле картларга кирәкле гайрәтне яшьләр кулына тоттырган. Яшьләргә кирәкле тәҗрибәне картларга биргән. Ике буынны шушы бөек җайланыш берләштереп, бер-берсенә беркетеп тора. Картларга — көч, егәрлек, яшьләргә тәҗрибә кирәк. Ә бит җәмгыятьтә тәҗрибә белән көч бергә кушылган очракта гына алга китеш, тәрәккыять барлыкка килә.

Бу — фәлсәфә. Ә миңа ничек кенә булса да комиссия үтәргә кирәк



иде. Йөзү эшенә яраклы дип раслап комиссия рәисе кенәгәмә кул куймыйча мине «Академик Арцимович» теплоходына җибәрмәячәкләр.

Сират күпере артта калды. Мин — җәннәт урнашкан яр ягында. Алда озын сәяхәтләр, ачы һәм татлы авырлыклар, саф һава, океаннар киңлеге.

Хирург минем тәндәге җөйләрнең тарихын сораштыра, иелергә куша, арт якка карый һәм ул да «таза» дип яза, кул куя! Ура! Калганнары җиңел генә уздырып җибәрәләр.

Менә мин — медкомиссия председателе каршында. Баш врач башка докторларның имзаларына таянып: «Капитанның беренче ярдәмчесе булып эшләргә рөхсәт ителә. Йөзү районнары чикләнми»,— дип яза һәм янә имзасын төшерә.

Кенәгәмне тизрәк кулыма алдым. Баш врачның секретаре мөһер сукты. Аве, цезарь, Моретури те салютант!

Кадрлар бүлегенә төшәм. Аванс сорап язган гаризама кул куйдыртам. Йөрәк ярсып тибә, ул да шатлана. Юләр йөрәк. Нигә шатланасың? Медкомиссияне үтә алмасам, сиңа җиңеллек килә иде ләбаса! Эчемнән генә аңа рәхмәт укыйм.

Алда — Новороссийск порты, кораб. Хәзер ничек кенә булса да шунда барып җитәргә кирәк.

«Академик Арцимович» — «ро-ро» тибындагы яңа теплоход. Ул портта әз тора. Иртәгә сәгать уникегә кадәр барып җитә алмасам, кораб китәчәк. Ә мин төп башына утырып калачакмын.

Аванс гаризасына имзалар җыеп бетердем, виза салдырып, хисапчы бухгалтерга кердем. Һәм — акча алу миражы юкка чыкты. Бүген тапшырган ведомостька акчаны иртәгә төштән соң гына түлиләр икән.

Сау бул, акча, сау бул, мираж! Элек, бухгалтер апалар шак-шок итеп счет төймәләре тартып утырганда, аванс акчасын сәгатендә ала идек. Электрон-хисап машиналары эшне бер тәүлеккә озайттылар. Гаҗәп кызык яклары бар фәнни-техник революциянең!

Әҗәткә акча эзләргә туры килде. Әҗәт — киләчәгеңне ашау. Әмма нишләмәк, аласың, ашыйсың. Чемодан — таш тутырган кебек. Авыр күтәрмәскә кушып, врачлар ничә мәртәбә кисәттеләр. Өйдән алган китапларыма өстәп, пароходчылыктан тагы бер кочак күрсәтмә кәгазьләре бирделәр.

«Нәрсә җиңел бу дөньяда?»— дип юанмакчы булам. Эшләмичә, ашап тик яту җиңел. Баш иеп, нәрсә кушсалар, шуны эшләп йөрү җиңел һәм теләкләреңнән ваз кичеп, берни теләмичә, максатсыз яшәү җиңел. Әмма бу җиңеллек ышанычсыз. Алай яшәү рухны ялкауландыра: өметләр сүрелә, ихтыяр сүлпәнләнә. Тере килеш мәеткә әйләнә башлыйсың. Кулдан килгән кадәр, җиңеллектән сакланырга кирәк.



## Түзәргә өйрәнү

Күзәткәнем бар: озак читтә йөреп, кире авылга кайткан кеше шактый озак авылдашларына кушыла алмый интегә. Беренче көннәрне ул бөтенләй чит кеше әле. Аның авылдашлыгы хәтердә генә сакланып калган. Кайткан кеше үзе моны аңламый. Ул шушы очрашуны түземсезлек белән көткән, авылын уйлап, йокысыз төннәр үткәргән һәм шул чакта кайту белән авылдашларыма кушылып, нәкъ шуларча яши башлармын дип өметләнгән. Дөрес, аны якты йөз белән каршы алалар, сораштыралар, кызыксынган булалар, ә үзләрендә — көндәлек эш кайгысы. Берсе түбә яба, икенчесе базга бәрәңге сала, өченчесе кызына пальто алырга йөри. Ә читтән кайткан кешегә — бәйрәм.

Әлегә аның эше дә, көнкүреш турында кайгыртасы да юк. Бәйрәмнең иң каты дошманы — көндәлек вак мәшәкать. Шунлыктан, читтән кайтучының бәйрәме авылдашларының көнкүреше белән кушыла-яраша алмый. Бу хакыйкатьне диңгезчеләр бик яхшы беләләр.

Диңгездә йөзгәндә, айлар буе кайту, очрашу турында уйлап йөрисең. Эш авыр — тырышасың, көнкүреш кырыс — башка чара юк — түзәсең. Ниһаять, очрашу. Синең кайтуыңа шатланалар. Гаиләң синең турыда уйлап йөргән, көткән, сагынган. Алар да шатлана. Шундый шатлыклы бәйрәм булырга тиеш. Куанычның иге-чиге юк, төне буе, таңнар атканчы сөйләшеп туя алмыйсың. Сигез тула, хатының эшкә ашыга. Кызың мәктәпкә җыена. Син тагын ялгыз. Тагын көтәсең. Һәм бу — сәяхәт вакытындагы моңаеп көтү түгел. Бу — үпкә, хәтер калу. Синең бәйрәм итүгә көйләнгән кәефең хатыныңның хезмәткә береккән күңеле белән ботка пешерә алмый. Диңгезчене шушы интектерә, аның канына шушы нәрсә уҷлап тоз сала.

«Академик Арцимович» портка кергәндә, мин трансфлот бүлмәсендә утыра идем. Трансфлот — кораб белән элемтә тоту, экипажның йомышларын үтәү өчен төзелгән оешма. Бүген мин оешманың эшен күзәтәм. Трансфлот диспетчеры ирләрен каршыларга килгән диңгезче хатыннарын залга урнаштырды, корабны причалга кую турында порт белән сөйләште, погранпостка һәм таможняга шалтыратып, «Академик Арцимович»ны каршы алырга, аңа чик ачарга кирәклекне әйтеп, сөйләшеп куйды. Мин эшлисе корабны Либерия ролкеры[1] «Си мерчант» («Диңгез сәүдәгәре») киткәч, шуның урынына куярга тиешләр иде. «Си мерчант»ның кайчан төялеп бетәчәген миңа беркем әйтә алмады. «Бәлки төштән соң, бәлки кич белән, я булмаса иртәгә иртән»,— диделәр. Төгәл әйтеп тә булырлык түгел иде шул. Либерия корабына төяләсе машиналар тимер юл белән килә. Ә вагоннарның вакытында килеп җитәме-җитмиме икәнен тимер юлчылар үзләре дә белми иде.

Ниһаять, төш вакыты җитте. «Си мерчант» эшен бетерде. Аны юлга озаттылар. Причалда урын бушады. Урын бушады, әмма «Академик Арцимович»ны портка алып керәсе лоцман тышкы рейдта чират көтеп торган инглиз танкерен алырга киткән иде. Инглиз танкерының машинасы кабынмый икән, лоцман шуны көтеп утыра. Ниһаять, инглиз танкеры да портка керде. Лоцман бушады, ә «Академик Арцимович»ка швартовка вакытында ярдәм итәргә билгеләнгән буксирны ниндидер бер супертанкерга җибәргәннәр булып чыкты. Бу киртәне дә җиңделәр: капитан портка буксирсыз керергә риза булды, һәм, нәкъ шушы минутта таможенникларның башка корабны тикшерергә керешүләре ачыкланды. Алар ике-өч сәгать актарынырга тиешләр иде әле. Чит илләрдән йөреп кайткан корабны таможенниклар һәм пограничниклар тикшермичә, аңа чикне ачмыйлар. Законы шундый.

Мин ирләрен каршы алырга килгән хатыннарны күзәтәм. Аларның да инде түзәр хәлләре калмаган. Дулкынланалар. Диспетчерны бимазалыйлар. Кыбырсыну, киеренке, кырыс тынгысызлык. Шушы тынгысыз мохитта бары тик сабыйлар гына үзләрен тыныч тота. Әнә бишалты яшьлек бер кыз курчагын киендерә. Курчак — чит илдә ясалган булса кирәк: өстендә зәңгәр нейлон күлмәк, аягында укалы башмак. Ун яшь тирәсендәге ир бала уенчык автоматтан әниләренә атып йөри. Малай берүзе ун кешелек ыгы-зыгы тудыра. Диңгезче хатыннары тәмам алҗыганнар. Төнге йокы калудан гына да түгел бу. Аларның йөзләрендә ирсез яшәүнең рәхимсез авырлыгы, ялгызлык, таянычсыз тормыш газабы чагыла. Тыштан үзләре яшьләр, чибәрләр. Алар-

[1] Ролкер — дөресе — «ро-ро». Бу типтагы кораб йөкне горизонталь рәвештә төяү һәм бушатуга көйләнгән була.

ның өсләрендә кыйммәтле дефицит кием. Ирле була торып ялгыз яшәү михнәтен тәти кием куанычы белән генә алдап булмый шул.

Башка төрле кораб сәяхәттән кайткач, портта бишәр тәүлек тора. Ә кайберләре берничә атна, хәтта айга кадәр дә торалар. «Академик Арцимович» — «ро-ро», аңа йөк төяве җиңел. Миңа: «Кораб ић күбе бер тәүлек тора алыр. Без аны дүрт-биш сәгатьтә төяп бетерербез»,— диделәр. Ә безнең хатыннарыбыз, балаларыбыз? Шушы чиксез кадерле кавышу вакытын без күпме көттек. Ә корабка төрле тикшеренүчеләр ябырылып килә башлады... Килсеннәр иде алар барысы бергә. Юк, берсе китүгә, икенчесе килә.

«Академик Арцимович» әле һаман тышкы рейдта. Ул лоцман көтә. Лоцманның нигә килмәвен экипаж белми. Хатыннар да ни сәбәпле корабны портка кертми торуларын аңламыйлар. Беркем бернәрсә белми. Күзәтүне дәвам итәм.

Түрдә утыручы ханым башкалардан кайсы ягы беләндер аерылып тора. Аның белән киңәшәләр, аңа юл бирәләр. «Капитан хатыны булса кирәк»,— дип куйдым мин. Урта яшьләрдә, күзе кысынкырак. Биттә җәлпәклек тә сизелә. Һәм иң күзгә ташланып торганы — мул, канәгать чырай. Вакыйгалар гел аның тирәсендә әйләнә. Башкалар аның күңелен күрергә, ошарга тырышалар.

Ханым үзенең юлбашчы икәнлеген тыштан сиздермәскә тырыша, эченнән — канәгать. Һәм акыллы, хәйләкәр булырга тиеш.

Диңгезчегә акыллы хатын кирәк. Юк, акыллыдан да бигрәк хатынның иманлысы кирәк. Хәер, нинди иргә кирәкми ул андый хатын?

Күзәтүемне һаман дәвам итәм. Семья дилбегәсе моның кулында булырга тиеш. «Син булмасаң, мин ни эшләр идем?» — дип назланса да, үзе астыртын гына, сиздермичә генә ирен биетеп тота торгандыр...

Тукта, нигә күзәтәм әле мин бу хатынны? Әйе, капитан җефете булганга кызыксынам. Шуннан? Хатында эшем юк. Минем аның иренең кем икәнен беләсем килә. Чөнки минем эшемнең нәтиҗәсе, сыйфаты башлыкның да нинди кеше булуына бәйле. Аянычлы нәтиҗә ясыйм: мондый хатынның ире кыю, җаваплылыкны берсүзсез үз өстенә алырга яратучы түгел кебек тоела. Шушы юрау кәефемне бозып җибәрде. «Ярый, күз күрер,— дип юанырга тырышам.— Мин бит күрәзәче түгел алдан белергә».

Тагын бер хатын башкалардан шактый аерылып тора — бусы автоматтан атып йөрүче малайның әнисе. Гаҗәп чибәр үзе. Өстендә джинси күлмәк, аягында кыйммәтле туфли. Чәче һәр хәрәкәтенә дулкынланып тора. Ләкин аның елмайганда күренеп киткән тешләре миңа ошамый. Әрләнгән кыяфәте бар бу ханымда. Хатынның биле нечкә, күкрәге килешле, гәүдәсе кырып ясаган орчык кебек төз-зифа. Тешләре! Шайтан алгыры — шул теш табигать иҗат иткән матурлыкка бер мичкә балга салган бер кашык дегет булып кушыла. Бу ханым җан-фәрман башкалардан өстен булырга тырыша. Димәк, аның ире өлкән командир булмаска тиеш. Хатыннар минем дикъкать белән күзәтеп торуымны сизеп алдылар. Әрләнгән хатын янымa килде:

— Сез дә «Арцимович»ны көтәсезме?

— Шулайрак иде.

— Кем урынына?

— Капитанның беренче ярдәмчесе.

Бераздан инде хатыннарның өлгер күзләре миңа текәлгән иде. Кайнар кызыксыну, минем кем икәнлегемне капшау, чамалау, тикшерү башланды. Мин моны тәнемнең бөтен күзәнәкләре белән диярлек сизеп тордым. Түзәр хәл калмады. Мин, хәйлә табып, тизрәк чыгып сызу ягын карадым.

Мин портка юнәлдем. Ике сәгатьтән чикне ачтылар.

Каютамда рапорт язып утырам. Шушы көннән мин «Академик Арцимович» теплоходында яшәргә тиешмен. Эшләргә, ял итәргә һәм тагын эшләргә. Мин алыштырган беренче ярдәмче, ялын тәмамлап эшкә чыккач, мине башка корабка күчерәчәкләр.

Эшкә урнашканда, даими бер корабка билгеләнү, гел шунда эшләү мөмкинлеге бар иде. Үзем теләп, ялга китүчеләрне алыштырып торырга риза булдым. Һәр яңа кораб, андагы экипаж — үзе бер галәм. Һәр пароходның үз юлы, үз юнәлеше бар, үз гадәтләре, холыклары һәм үзгәлекләре бар. Яңа кешеләр арасында яшисем, күбрәк яңа илләр, яңа диңгезләр күрәсем килде. Комсызлык түгелме бу? Үзеңне аңлау ифрат кыен.

Диңгезгә кире кайтканнан соң инде дүртенче корабта йөзәм. Һәр корабта утыздан артык кеше. Инде йөз утыз кеше белән якыннан таныш, димәк. Кирәк нәрсә ул тәҗрибә. Ләкин артык комсыз булырга ярамый... Вазифа — бер, таләп тә шул ук, ә эш ысулы дүрт корабта дүрт төрле. Ысул гына да түгел, вазифаны аңлау, аны эшкә ашыру, аның нәтиҗәсе дә дүрт урында дүрт төрле.

«Матвей Муранов» теплоходындагы минем коллегам кораб эчен наглядная агитация белән тутырган иде. Кызыл почмакта, кают-компаниядә, салоннарда, коридорларда бармак очы кадәр дә буш урын юк; стеналар күренми, кораб эче кызыл чүпрәккә язылган лозунглар диаграммалар, стендлар, күрсәтмәләр белән капланган иде. «Академик Арцимович»та эшләүче беренче ярдәмче отчет төзергә оста булып чыкты. Ул корабтагы җәмәгать эшенең һәр бөртеген, һәр вакыйганы кәгазьгә теркәп барган. Эшнең һәр тармагы буенча аерым кенәгә, алдан төзеп куелган планнар, аларның үтәлүен тикшерергә көйләнгән графиклар. Экипаж тормышының һәр сулышы баштанаяк кәгазьгә беркетелгән, һәр эшләнгән эш турында пароходчылык белән алдан киңәшеп-белешеп куелган. Бу мин күтәрә алырлык ысул түгел иде. Эш турында отчет язу белән мавыгу еш кына файдадан тыш зыян да китерә. Отчет язучы һәр очракта үз эшен яхшырак сурәтләргә тырыша, шомарта, буйый һәм эшнең күләмен шактый гына зурайтып күрсәтә. Кәгазьгә бер күнегеп киткәч, башкарылмаган эшне дә матур гына итеп эшләнгән итеп сурәтләп куясың. Шушындый осталык белән зур уңышларга ирешкән, берни эшләмичә, гел отчет язу белән шөгыльләнеп, абруйга лаек булган кешеләрне мин еш кына очраткалыйм.

Мин каютамда «эшне нәрсәдән башлап җибәрим икән?» — дип, маңгаемны кашып утырам. Каютам зур, иркен. Мине «Матвей Муранов» теплоходындагы каюта хәйран калдырган иде. Бу каюта андагыдан да затлырак — француз мебеле белән җиһазланган иде. Барысыннан да бигрәк миңа стенага элгән рәсем ошады. Франция — рәссамнар иле бит.

«Матвей Муранов»та минем каютамда Айвазовскийның «Вал» исемле картинасы эленеп тора иде. Бер атнадан соң мин аны, әйләндереп, стена ягына каратып элдем. Тышта да диңгез, эчтә дә. Күз башка күренеш эзли. Ә французлар каютага бикләнеп яшәүче диңгезчегә нәрсә кирәклеген аңлаганнар. Яшел болыннан боргаланып көмеш елга ага. Елга ярында — тегермән, тегермәнченең унҗиде-унсигез яшьлек кызы елгада кер чайкый. Кайбер ахмаклар каюталарына ярым шәрә реклама-кызларын асып куялар. Тегермәнче кызының күлмәге үкчәсенә тиеп тора, бите һәм беләкләреннән тыш шәрә җире күренми. Вәсвәсә юк. Рәхмәт рәссамга!

Минем коллега Ждановка оча торган самолетка ашыга иде. Шуңа

күрә эшне тапшыру-кабул итү өстән-өстән генә булды. Ул киткәч, мин корабны кабат карап, тикшереп чыгарга ниятләдем. Навигация приборларын — радарны, гирокомпасны, радиопеленгаторны, эхолотны, «Лоран» системасын, якорь күтәрү механизмнарын, авторулевойны — һәммәсен клотиктан алып кильгә кадәр җентекләп карап чыктым. Бу эшкә ике сәгать вакыт китте. Механизмнар барысы да төзек иде. Хәзер иң мөһим эшкә — экипаж әгъзаларын, сәяхәткә бергә чыгасы юлдашларымны өйрәнә башларга кирәк. Бу — эшнең иң катлаулы өлеше.

Без космоска кораблар күтәрә беләбез. Йөз мең километр ераклыктан шул кораблар белән идарә итү — безнең өчен берни түгел. Атом төшен, кузәнәкләр төзелешен, нәсел саклану серен — барысын ачтык, ачыкладык. Ә менә янәшә утырган адәм баласының ни сәбәптән тегеләй я болай булуын аңлый да, аңлата да алмыйбыз. Тәмәкенең сәламәтлеккә зарары безгә билгеле, ә улыбызның нигә тәмәке тарта башлавын аңлатырга көчебез җитми. Начар гадәтләрнең каян барлыкка килүен, аларның ничек саклануын кем аңлата ала? Ә үзара мөнәсәбәтләр? Кеше турындагы гыйлемне без әлегә начар сукалыйбыз.

Кара диңгез пароходчылыгында эшләгәндә, беренче ярдәмчеләр арасында иң яше мин идем. Хәзер миннән өлкәнрәк коллега сирәк очрый. Матрослар, мотористлар турында сөйләп тә торасы юк. Флотка яшьләр килә. Без соңгы сәяхәткә чыгар алдыннан тормыш дилбегәсен яшьләр кулына тапшырып өлгерергә тиешбез. Безнең кулдан байракны нинди рәкләр алыр икән дип, яшьләргә игътибар белән карыйм. Аларны аңларга тырышам.

Сугыштан соң туып үскән тәрбияле буын бу. Тазалар, көр күңелләр. Бәхетле яшәүләре әллә каян күренеп тора. Затлы кием киеп, акча туздырып яшәргә омтылалар. Сугыш авырлыкларын җиңгәннән соң «комфорт» сүзе барлыкка килде. Яшьләр комфорт ярата.

Болар — телевизор һәм магнитофон тәрбияләп үстергән балалар. Аларның кесәләрендә вуз дипломы. Күпне, бик күпне беләләр. Хәтерләрендә шыгрым тулы информация. Матур киенә, теләсә нинди машинаны эшләтә беләләр. Каннарында фән-техника революциясе шаукымы.

Бу юлы да экипаж исемлеген өйрәнүдән башладым. Иң беренче — капитан Грязевский Константин Николаевич. 1938 елны туган, рус, югары белемле, партияле, хатыны бар, балалары юк. Ни сәбәп балалары булмаганны теге — трансфлот бүлмәсендә очраткан ак куллы, тулы күкрәкле хатынның эт ияртеп капитан каютасына кереп киткәнен күргәч аңладым. Эш хакы түләргә ведомость килгәч, тагы да ачыкланды: алимент түли икән.

Икенче урында — үз исемем. Бу бәндәнең дә кем икәнлеген белмим мин. «Мин» атлы кеше белән илле ел таныш. Кай чакта мин аны аңламыйм, ул миңа ничектер ят-чит тоела. «Мин»гә үзем читтән карый алмыйм. Аның начар якларын, кимчелекләрен күрмәскә тырышуымны сизәм. Бу бәндәнең һәр кимчелеге миңа газап китерә. «Мин»нең кире яклары белән көрәшеп тә карыйм — җиңеп булмый. Аларны күп вакыт, астыртын инстинкт җибәреп тора. Өч катлы ул «мин» атлы кеше. Аның акылы — бер якка, тәне — икенче, гадәт-холкы өченче якка тарта. Шушы бер-берсенә дошман өч көч арасында инде менә илле ел яшим. Каты көрәш бара алар арасында. Өчесе дә исән һәм һаман үзара килешә алмыйлар. Алар өчәүләп, «миңа» ияреп, гүргә керәчәкләр.

Күзем бер мәзәк фамилияне эләктерде: Перечепидорога Владимир Иванович, моторист-электрогазосварщик, 1938 елда Ждановта туган, белеме ун класс, партиясез, хатыны, ике баласы бар, флотта унике

ел эшли. Элек шоферлыкта йөргән. Адресына караганда, үз йортында яши (адресында йорт номеры гына, фатир номеры юк). Үзе коммунистик хезмәт ударнигы, судовой комитет әгъзасы. Рәттән карап, тикшереп барам: исемлектә ударник булмаган диңгезче очрамады. Димәк, бу исемне экипаж әгъзаларына рәттән тагып өлгергәннәр: башта иң яхшы эшләүчеләргә, аннан соң яхшыларга, бераздан урта кулга, һәм, ниһаять, калганнарына. Уравниловка аркасында, һичшиксез, начар эшләүчеләр откан, яхшылар — оттырган.

Һаман укыйм, һаман тырышам: һәр кеше турында бер үк шаблон сүзләр: фамилия, исем, атасының исеме, вазифасы, туган елы, партиялеме-түгелме икәнлеге, белеме, адресы һәм җәмгыять эшенә катнашуы. Шуның белән бетте. Һәм барысының диярлек сыйфатлары бер тигез — ударниклар. Аерма да бар икән — утыз дүрт кешенең уналтысы югары белемле, уникесе ун класс бетергән, алты кеше — училище. Бу кенәгәдә рәсми тышкы сыйфатлары гына язылган. Ә миңа тәрбия эше өчен экипаж әгъзаларының эчке сыйфатлары кирәк. Кешенең эчке сыйфатын таный, бәяли белү ифрат авыр, ә минем эштә ансыз булмый.

Моторист-электрогазосварщик Перечепидороганы тирәнрәк өйрәнү теләге белән сейфтан аның «Диңгезче паспорты»н алам. Беренче биттә фоторәсем. Урта яшьләрдәге бер кеше, боеграк чырай белән миңа карап утыра. Күз карашында бераз курку да бар шикелле. Хәер, документ өчен эшләнгән фоторәсемнәрдә бу табигый хәл. Башка паспортларны актарып карыйм. Барысының да күз карашлары бер төрлерәк. Тетрәнеп киттем: өсләрендә соры пиджак, һәммәсе кара галстук таккан. Исемә төште: бит мин үзем дә рәсемгә гел шул соры төстәге пиджак киеп төшәм. Документлар әзерләгәндә кадрлар бүлегендә: «Ак күлмәк, кара галстук, соры пиджак киеп төшәргә тиешсең»,— дип алдан кисәтеп куялар. Паспортка баскан мөһер рәсемдәге пиджак өстенә туры килә. Кара пиджакка басылса, ул күренми икән...

Башлап экипаж әгъзаларының бер мөһим сыйфатын өйрәнүдән башларга ниятләдем: һәркемнең вәгъдәсе белән гамәле арасындагы аерма бармы? Зурмы ул аерма? Аңа коллектив нинди бәя бирә, һәм ул үзен кемгә саный?

Шундый мәшәкатьле уйлар эчендә баш ватып утырган арада «Академик Арцимович»ны төяп тә бетергәннәр. Бераздан пограничниклар һәм таможенниклар килеп, чикне «ябып» куйдылар. Без чикнең «теге ягында» калдык. Туган ил белән турыдан-туры элемтә бетте. Әнә, ирләрен алты гына сәгать күреп калган диңгезче хатыннары безгә кул болгыйлар. Арада — бушлык. Шул бушлык аша бары тик радио дулкыннары гына үтеп чыга ала.

Без яңадан сәяхәттә. Бусында юл тагын да озынрак. Алда — Кара диңгез, Урта, Кызыл, Гарәп диңгезләре. Һинд океаны, Фарсы култыгы һәм Тигр белән Ефрат кушылудан барлыкка килгән Шатт-ел-Гарәб елгасы. Без шул елга ярындагы шәһәргә диңгезче Синдбад каласы Басрага йөк машиналары төяп барабыз.

Сау бул, туган ил! Көт безне!

## Ролкер

Җилкәнле флот заманында кораб төрләре аз булган. Мачта санына, җилкән рәвешенә карап, бриг, бригантина, барк, баркентина, шхуна, галеон, клипер һәм тагын берничә төрле кораб. Алар бер үк төрле эш башкарганнар. Корабларны хәрби һәм сәүдә флотына бүлеп

тору да булмаган. Ул чорда ерак диңгезләрдә йөрү куркыныч тоелган. Юлда пиратлар очрап торган. Шунлыктан, һәр кораб туплар һәм мылтыклар белән коралланган булган.

Мин хәзер «ро-ро» корабында эшлим. Пароходчылыктагы иң яңа, иң катлаулы автоматика куелган, иң кыйммәтле теплоход бу. «Академик Арцимович»ны моннан өч ел элек Марсель белән Монте-Карло арасындагы «Ля Сейне сю Мер» исемле кораб верфендә төзегәннәр. Корабның тизлеге — сәгатенә унтугыз миль. Юлда очраган күп пароходларны җиңел генә узып китәбез без. Адәм баласының канында ярышу дәрте яши булса кирәк. Ярышта җиңү шатлык китерә. Ләкин тизлекнең бер начар ягы бар: тиз йөрешле корабта юл да тиз үтелә. Бүген Кызыл диңгездә барасың, һава эссе. Икенче көнне кораб Урта диңгезгә чыга. Монда җылы. Өченче көнне «ро-ро» инде Кара диңгездә. Монда кыш. Тән шушындый капыл үзгәрешләргә өлгерә алмый,— салкын тия. Күзәтеп йөрим — диңгезчеләрнең күбесендә томау.

«Ро-ро»га күнегеп булмый әле. Минем элек эшләгән корабларымда йөкне трюмга төйиләр иде. Трюм — базга охшашлы палуба астындагы чокыр. Аның өсте капкач белән ябыла. Зур корабларда җидесигез, урта тоннажлыда — дүрт трюм була. «Ро-ро»ның эче — тоташ бер трюм, бер бина. Завод цехын, гигант гаражны хәтерләтә ул. Палубада мачта да, трюм капкачлары да, чыгырлар да юк. Палуба ачык, киң, иркен, авианосецныкына охшаган. Йөксез йөзгәндә палубада футбол уйныйбыз.

«Ро-ро»ның коерыгына (ахтерштивеньгә) рампа беркетелгән. Кораб причалга арты белән килеп туктый. Рампа ярга төшерелә, һәм яр белән кораб арасында күпер хасил була. Койрыкта зур тишек (аппарель) уелган. Рампа ярда, аппарель — ачык, хәзер кораб төяргә әзер. Ярдан судно эченә машина агымы ургыла. Трюм тулгач, машиналар агымы твиндекка, ниһаять, кардекка юл тота. Кардек тулгач, агым өске ачык палубага күтәрелә башлый. Матрослар кораб эченә кергән һәр машинаны палубага чылбыр белән беркетеп торалар. Беркетмәсәң, алар шторм вакытында үзара бәрелешеп, челпәрәмә килеп бетәр иде. Алай гына да түгел: көчле штормда урыныннан купкан машина корабның бер як бортына килеп бәрелә дә бортны тишеп чыга. Кораб бата. Диңгезгә чыкканда, кораб эчендәге һәр нәрсә үз урынына беркетелгән булырга тиеш. Кораб эчендә йөргәнегез булса, күргәнсездер: каютадагы урындыкларга кадәр идәнгә беркетелгән була. Коридор стеналарында чайкалу вакытында тотынып йөрү өчен махсус тотка — култыксалар сузылган. Андый тоткалар — култыксалар ванна бүлмәсенә, һәр трапка, хәтта гальюннарга да куелган.

Мондый кораблар бары тик җитмешенче елларда гына барлыкка килде. Һәм алар докерларның эшләрен җиңеләйтте. Гади пароходка йөк төягәндә көчәнеп эшләргә туры килә иде. «Ро-ро»га дүрт-биш сәгать эчендә бөтен йөк җиңел генә төялеп бетә.

«Академик Арцимович» зурлыгындагы гади пароходны төягән арада без Кубага барып кайта алабыз. Ләкин отыш оттырышсыз булмый. «Ро-ро» су үтми торган аерым отсекларга бүленмәгән, корпусы тишелү белән, ул бата. Шунлыктан мондый корабта йөзү күпкә җаваплырак.

Йөк ташыган өчен кораб хуҗасына акча (фрахт) түлиләр. Советлар Союзындагы һәр пароходның хуҗасы — дәүләт. Без дәүләткә зур табыш китереп торабыз. Мәсәлән, «Академик Арцимович» чит ил акчасы (валюта) белән хисаплаганда елына миллион ярым табыш бирә. Аны Франциядән җиде миллионга сатып алганнар. Димәк, кораб үз хакын дүрт-биш ел эчендә кайтара да калган гомерендә гел файдага эшли.

Дәүләт безгә җиде миллион сумлык кораб тоттырган — өстә зур җаваплылык.

## «Шангрела»

Траптан өскә күтәрелгәндә, «Академик Арцимович»ның палубасында тыз-быз машиналар йөри иде. Шул чак беренче тапкыр авианосец күрүем исемә төште.

Ул чакта без экспедициядән кайтып килә идек. Атлантик океан аша хәвеф-хәтәрсез үтсәк тә, Бискай култыгында каты штормга эләгеп, өч тәүлек буе үлем белән көрәшә-көрәшә тәмам хәлдән тайган идек. Азык-төлек тә бетеп килә. Азык сатып алыр өчен без Мальта атавындагы Ла Валетта портына тукталдык.

Ул чакта Мальта Британиягә буйсына, Ла Валетта — инглиз хәрби флоты торган база иде.

Тоташ таш каплаган таулы утрау. Биек кыялар чорнаган тыныч бухтада хәрби кораблар тезелгән.

Моннан өч мең ел чамасы элек Мальтага финикиялеләр килеп утырганнар. Алардан соң — борынгы греклар, римлеләр, гарәпләр, төрекләр, испаннар, Венеция республикасы кешеләре, ниһаять, инглизләр. Килмешәкләр атау халкы белән аралаша, аңа кушыла торганнар. Нәтиҗәдә, гаҗәп үзенчәлекле мальта халкы барлыкка килгән. Мальталыларның хәзер нинди этник группага керүен ачыклавы шактый катлаулы. Алар монда яшәгән һәр милләткә бераз охшаганнар, һәм, шул ук вакытта, үзләренә генә хас сыйфатлары да бар. Хатын-кызлары чегәнгә тартым. Аларда темперамент һәм ут чәчрәтеп торган җенси көч барлыгы сизелә. Яннарыннан узганда кайнар дулкын бәрелгәнен сизеп үтәсең. Галәмне хәйран калдырырлык батырлык күрсәтәсең килеп китә.

Атауда күп гасырлар дини оешма — Мальта ордены яшәгән. Аның тәэсире әле һаман сизелә: Ла Валеттаның урамнарында йөргәндә минут саен күрән йон чикмән киеп, билен кылдан ишкән бау белән бугган капуцин монахлары очрый. Квартал саен — собор, һәр юл чатында — Иисус Христос сыны. Ябык тәнле шәрә ир, шуның аяк-кулларына кадак кагып, зур тәрегә беркетеп куйганнар. Кадак кергән җирләрдән кан саркып тора. Шундый сыннарны күрү белән тәнем чымырдый, кәефем кырыла. Иисусның интегеп үлүе белән сәүдә итү түгелме соң бу? Канлы җәза күрсәтеп, кешеләрнең исләренә төшереп тормаска иде. Бу дөньяда кан кою, җәбер болай да җитәрлек бит.

Шәһәрдән чыгып, тауга күтәрелә башладым. Ташны чокып ясалган юл. Ул электропоезд өчен салынган монорельс юлын хәтерләтә. Күпчәкләр ташта тирән эз калдырганнар. Нигә кирәк булган бу юл? Нәрсә җигеп йөргәннәр борынгылар: атмы, ишәкме, үгезме? Мин, юл буена утырып, бик озак тояк эзләре табарга тырыштым. Юк иде тояк эзләре. Таш көпчәкле гигант арбаны бәлки коллар йөрткәндер? Я булмаса — җил, кояш, су көче? Борынгыларның яшәү серләрен гасырлар каплап киткән. Дөрес, эзләре калган аларның. Алар яккан учакларның көлләре, тузанга әйләнгән сөякләре калган.

Шулар турында уйланып кайтып киләм. Ла Валетта шәһәренең үзәк урамы. Киң асфальт юл. Юлны аркылыга үтеп чыга башладым. Урам аркылы чыкканда башта сулга, аннан уңга карыйсың. Мин дә шулай эшләдем һәм уңга карау белән очып килгән гигант автобусны күреп алдым. Алга омтылдым һәм аяк таюдан гөрселдәп юлга капландым. Очып килгән автобусның җиле битемә килеп бәрелде. «Менә кайда икән әҗәлем...» — дип, шелтә һәм үкенү аша уйлап өлгерүгә,

тормоз сызгырды, чәлпәрәмә килеп, пыяла ватылган тавыш ишетелде. Пассажирлар чыелдап алды. «Хәзер мине сытып китәчәк...» Автобус көпчәге минем кабыргама килеп терәлде һәм... туктады.

Күлмәгемне автобус тәгәрмәче астыннан суыра башладым. Тукыма ертылды, уч төбе зурлыгы ситса көпчәк астында калды.

Ул арада пассажирлар автобус ишегеннән юл читенә коела башладылар. Кемдер изүемнән эләктереп алды — шофер икән. Өстендә зәңгәрсу униформа, күзләрендә нәфрәт очкыны. Елмаеп, инглизчә рәхмәт әйткән булам. Каяндыр полисмен калкып чыкты, кесәсеннән блокнот чыгарып, язарга кереште. Ә мин һаман шоферга рәхмәт укыйм. Шофер сүгенә. Ниһаять, ул куллары канга буялган ике хатынны җитәкләп алып килде. Салон белән шофер кабинасы арасындагы пыяла ватылган, ике пассажирның куллары яраланган. Мине полиция участогына алып киттеләр. Иркен генә бүлмә, дерматин тышлы йомшак диван. Тәмәке исе һәм шушы йортка эләккән кешеләрдән чыгып калган бәхетсезлек сулышы.

Берничә минуттан полиция участогында судья һәм адвокат барлыкка килде. Автобус астыннан чыгуыма ярты сәгать үттеме икән, миңа суд ясап өлгергәннәр иде инде. Ике мең биш йөз фунт штраф. Бу суммага куллары яраланган ике пассажирның эшсез калу бәһасе дә кушылган иде. Кесәмдә ике 'ай эшләп алган төгәл унөч фунт валюта. Суд карарына кул куярга туры килде. Штрафны түләү өчен өч ел эшләргә тиеш идем мин. Экспедициядән кайткач, рөхсәтсез автобус астына кергән өчен ел буена утыз процент эш хакымны басып тордылар. Утыз проценттан күбрәк басарга ярамый икән. Закон гадел бит ул.

Юлга егылуымның сәбәбен соңыннан ачыкладым: беренчедән, шәһәргә чыкканда, аягыма яңа туфли кигән идем, икенчедән, инглиз машиналары, инглизләргә хас тискәрелек белән, юлның уң ягыннан йөриләр. Урам аркылы чыкканда башта уң, аннан соң гына сул якка карарга кирәк булган. Без киресенчә эшләргә күнеккәнбез. Ике мең биш йөз фунт штраф миңа аң кертте: инглизләр җирендә аларның законнарын сакларга кирәк.

Автобус астына кереп чыкканнан соң төне буе машиналар күреп саташтым. Уянуга, безнең корабка янәшә АКШ авианосецы «Шангрела»ны куйганнар иде. Урта гасырларда Тибет тауларында Шангере-Ла исемле әкияти бер ил бар икән дип ышанып йөргәннәр. Янкилар корабларына шул ил исемен кушканнар.

Корабның күккә төзәлгән ракеталары бездән унбиш-егерме метр ераклыкта гына тырпаешып торалар иде. Палубага тезелгән самолетлар арасында коралды солдатлар йөри.

Авианосец янында безнең кораб балалар уенчыгы хәтле генә булып калды. Бу йөзә торган металл аэродромның кораб булуына ышанасы да килми иде.

Көн кичкә авышты. Авианосецның корылмасында неон утлар кабынды. Янкилар атау халкын банкетка чакырдылар. Гадәттә, хәрби корабларны кеше күзеннән яшеребрәк тоталар, аның эченә теләсә кемне кертмиләр. Күп илләрдә шулай. Америкалылар, үзләренең көчле булулары белән масаепмы, үзләре үк чакырып алалар. Янәсе: «Күрегез әйдә, безнең әнә нинди дәһшәтле коралларыбыз бар! Без гайрәтле. Без бай. Җир йөзендә безгә каршы тора алырлык ил юк...» Масаю гына да түгел бу: Америка ысулында үзләренең кораллы көчләренә реклама ясау һәм без җиңелмәслек дип халыкларны ышандырырга тырышу иде. Тарих гадел. Җир шарын яулап алырга теләгән һәр милләт юкка чыга килгән. Коралланy, яулап алу белән мавыгуларын дәвам итсәләр, америкалыларны да шул ук язмыш көтә.

Караңгы төшкәндә авианосецның палубасында гөрләтеп оркестр уйный иде инде. Атау халкы «Шангрела» янына җыела башлады. Шуларга ияреп, без дә тамаша карарга киттек.

Палубага өстәлләр тезеп куйганнар. Өстәлләрдә төрле эчемлекләр, кока-кола, сэндвич, чәйни торган резинка. Оркестр Америка гимнын уйный. Мачталарда төрле төстәге утлар яна. Хәрби матрос авианосец карарга килгән кешеләрне каршы алып тора: биш кешене бергә җыеп, кулындагы бауга тотындыра да авианосец эченә алып кереп китә. Сукыр кеше шикелле, матрос кулындагы бауга тотынып ияреп барасың.

Без авианосец эчендә ярты сәгать чамасы йөреп чыктык. Корабның эче тулы самолет, корал һәм бомба иде. Очарга тиешле самолетны лифт белән өске палубага менгерәләр, ул шуннан һавага күтәрелә. Бомба ташлап кайткач, кире палубага куна. Пентагон шушындый кораблар белән үлемне җир шарының теләсә нинди почмагына ташый ала.

Аңламыйм мин. Үлем белән уйнау елдан-ел кыйммәтләнә. Шул кыйммәткә төшкән уенга кешелек дөньясының көче тотылып тора. Борынгы заманда кылыч, ук, сөңге белән сугышканнар. Хәзерге көн сугышчысы кулында ун миллион доллар торган дәһшәтле самолет-истребитель. Борынгы сугышчы бер атуда бер кеше үтерә алган булса, хәзерге америка хәрбие кнопкага гына басып, миллионлаган кешене юкка чыгара ала. Кешелек тарихында моннан да зур вәхшилек булганы юк иде әле.

«Аллага шөкер, сугыш юк, без тынычлыкта яшибез»,— дип юанабыз без. Җир йөзендә икенче бөтендөнья сугышы беткәннән соң гына илле миллионга якын кеше үтерелде. Кан коюның тукталып торганы юк. Сугыш һаман бара. Тынычлык өчен көрәштә без төрле оешмалар төзибез, конференцияләр җыябыз, тынычлыкны яклап, кайнар нотыклар сөйлибез. Ә сугыш һаман дәвам итә.

Чит ил портларында торганда, мин АКШта чыккан газеталарны укыйм. АКШ хөкүмәте дә үзенең «тынычлык өчен көрәшүе» турында шапырынырга ярата. Корал ясарга фәрман биреп, җир шарының төрле почмакларына кораллы гаскәрләр җибәрүче чиновниклар тынычлык турында ләчтит саталар. Әгәр гади кеше алдаса, аны ялганчы диләр. Хөкүмәт ялганлавы политика дип атала.

## Төрек балалары

Инде икенче тәүлек «Академик Арцимович» диңгездә бара. Октябрь азагы. Сәяхәттә йөргәндә, ел алышынуын сизми каласың. Узган китүдә яз якынлашып килә иде. Без диңгездә чакта кар эрегән, алмагачлар чәчәк аткан. Без диңгездә чакта җәй үткән, чәчәкләр коелган, көз килгән. Сәяхәттә йөреп, матур җәй көннәрен күрмәгәнбез, яшел үлән үскән җылы җирдә яланаяк йөри алмаганбыз, агач яфраклары без югында коелган. Бер яз, бер җәй бездән башка үткән.

Бу юлы без киткәндә төньяк җиле исә, карлы яңгыр ява иде. Җепшек кар бөртекләре иллюминаторга килеп бәрелә. Кар эри, суга әйләнә, күз яше булып, иллюминатор пыяласы буйлап тәгәрәп төшә. Кораб елый. Горизонт тонык. Тирә-якта шомлы караңгылык. Кораб дерелди, яңгырга чыланган ат шикелле, өстенә коелган суны селкеп ыргытырга тырыша. Мачталарда юеш җил улый.

Көчле давыл вакытында дулкын юклыгы шомландыра башлады. Карлы яңгыр җил кузгаткан дулкыннарны сүндереп тора иде. Кораб

һаман алга бара. Аның зур максаты бар. Кеше дә шулай: максаты булганда, ул туктамый, бара. Егылса — тора, тагын атлый. Безнең максатлар — шул ук маршрут, теләкләр — алга куучы шул ук мотор. Максатлар бар чакта, теләкләр көчле чакта без бәхетле.

Язмыш безнең үз кулыбызда дип ышанып яшәргә тырышабыз без. Чыннан да шулаймы икән? Ә сугыш? Туган җиреңне яулап алучыларның дагалы итекләре таптавы? Язмыш — катлаулы мәсьәлә. Сәяхәтнең карлы яңгырдан башлануы — менә нәрсә борчый мине.

Яктырганда Босфорга килеп җиттек. Бугаз эченә ничәнче мәртәбә керүем икән? Диңгезләрне тоташтырып торучы су юлы һәр килүдә яңа чырай белән каршы ала. Күренешләрнең моңа кадәр кабатланганнары юк әле.

Эчкә керә башлагач, чайкалу сүнде. Бугаз эчендә безне тынлык кочаклап алды. Сабыр, көзге канәгатьлек хөкем итә иде Босфорда. Кырымда һәм Анатолия ярларында гына очрый торган әбиләр чуагы.

Анатолия ягындагы яшел таулар өстеннән кояш күтәрелеп килә. Галәм сыек алсулыкка буялган. Тау сыртлары сыек алсу. Торакларны, су көзгесен, һавадагы кошларны без килүгә алсуга буяп куйганнар. «Алъяпкычың алсу-алсу...» искә төште. «Таңның алсуланып атуы — кодрәте яңару түгелме икән?» — дип уйлап куйдым.

Босфор аша мин кимендә йөз мәртәбә үткәнмендер. Аның шушындый булуын беренче күрүем иде. Мондагы таң — үзе бер могҗиза.

Офык артыннан йортлар йөгерешеп каршыбызга чыга башладылар. Зур һәм кечкенә, җыйнак һәм тупас, күркәм һәм ямьсез, көләч һәм җимерек кашлы йортлар. Нилектән һәр эштә кешенең эчке һәм тышкы кыяфәте сурәтләнеп кала икән? Йорт үзенең хуҗаларына охшаган була.

Тау кабыргасындагы яшел чирәмлектә балалар уйнап йөри. Төрек балалары. Тауга каршы йөгерешеп менәләр дә аска таба, мәтәлчек атып, тәгәрәшеп төшәләр. Аларның гөж килеп шатланып кычкыруыннан кораб артыннан ияреп очкан акчарлаклар, шикләнеп, читкәрәк тайпылалар.

Чирәмлектә уйнаучы балаларның ач-ялангач булулары ихтимал. Һәрхәлдә, бинокльдән караганда шулай тоела. Тез башлары, җиңнәре ямаулы, ярлылык таныклыгы ул ямаулы кием. Ә нигә алар шулай тәмле, шулкадәр шат уйный беләләр? Бай балаларының шулай ләззәтләнеп уйнаганнарын күргәнем юк минем. Әллә байлыкны балаларга тиешле шатлык бәрабәренә алыштырып алалармы икән?

Минем балачак утызынчы елларның уртасына туры килде. Кибеттә ситсы сатылганын озак еллар хәтерли идек. Әтигә яңа тун тектеләр. Аның иске туны абыема, абыйның туны миңа күчте. Шул, биш-алты ел киелгән кайры тун икенчедән алтынчы класска китереп җиткерде. Алтынчыда язгы сабан вакытына кадәр генә укырга туры килде. Дөресен әйткәндә, бишенчегә дә ел буе йөреп булмаган иде. Сүз тун турында бит. Әйбәт тун иде ул. Яңа каткан көзге юка боз өстендә чаңгы шуганда суга батсаң, өйгә кайту белән, әни күргәнче тунны мич башына ыргытасың. Икенче көнне мәктәпкә киеп барырга ул әзер. Тунны чана итеп таудан шуарга да була иде. Чаңгыда йөргәндә, бер мәртәбә тимер ыргак белән йөк машинасына ябыштым. Аяк карга батты. Үзем егылып калдым, тунымның җиңе, умырылып чыгып, ыргакка эләгеп, китеп барды.

Безнең балачак, балдак кашындагы асылташ шикелле, хәтер түрендә ялтырап күренеп тора. Шул күренешнең иң затлы бизәкләре — уеннар. Туплы, качышлы уйнау, шар сугу, авыл башындагы чирәмлектә кичләрен сыер саклау, урманга бару. Кышкы озын төннәрдә таң атканчы әкият тыңлау. Уенның иң куанычлысы инеш аръягындагы тауларның кары эреп, чирәмлек ачылгач, шунда казан асып, «карга бот-

касы» пешерү. Зур казанда ысланып, тирә-якка көйгән ис таратып, ботка пешә. Без кар астыннан яңа ачылган хәтфә чирәмлектә тәгәрәшеп уйнап йөрибез. Өлкәннәрдән шул уеннарны оештырып йөрүчеләр дә була иде.

Тәпи йөри башлаганнан алып, армиягә киткәнче дәвам иткән уенярыш, уен-чыныгу, уен-акыл җыю, уен-кеше булырга өйрәнү — безнең буынны менә кем тәрбияләде. Балык тоту, баллы көпшә, балтырган, какы, кузгалак, җиләк, колмак, чия, чикләвек, балан җыюлар да ярты-лаш уеннан тора иде. Бәләкәй арба белән утын, печән ташу да, кәрзин үрү, чабата ясаулар да уенның дәвамы иде. Һәм әлеге сирәк эләгә торган бәхетле көннәр шул ук балачак уеннарның дәвамы.

Мәскәүдә министрлар дәрәҗәсендәге җитәкчеләрнең курслары бар. Аларны җитәкчелек итүгә уен аша өйрәтәләр. Менә нинди җитди нәрсә ул уен!

Мәскәүдәге мин торган йортта фатир биләүчеләр арасында урта белемле кеше юк диярлек. Инженер-конструкторлар, галимнәр, журналистлар яши ул йортта. Аларның күбесе — фән кандидаты, докторлык диссертациясе яклаган кешеләр. Шул югары белемле кешеләрнең тәти киенгән, көр, тәрбияле балаларын күзәтергә яратам мин. Дәрес әзерләп бетергән балаларны әти-әниләре ишек алдына һава суларга куып чыгаралар. Шул тәрбияле балалар чыгу белән эскәмиягә җәелеп утыралар да, кирәргә рөхсәт көтеп, тилмереп, тәрәзәләренә текәлеп каталар. Аларның уенда — җиңеп чыгу, йөгергәндә — хәрәкәт, мускул ару ләззәтен тоймаулары миңа шулкадәр кызганыч тоела.

Босфор ярында шат күңелле, ут чәчеп торган ярлы балалары. Биноклемне рубка өстәленә куям. Ярга чыгып, шуларга катнашасым — туйганчы уйныйсым килә минем.

Балалардан өстәрәк, таш койманың әчке ягында, төрек хатыны кер-ләр элеп йөри. Таш коймага аркаларын терәп өч карт сөйләшеп утыра. Нәрсә турында сөйләшәләр икән төрек картлары? Салымнарның һаман үсә торуы, базарда ит кыйммәтләнүе, түбә ябарга калай табып булмавы, әллә картлыкның аяусыз ашыгып килүе, гомернең аяусыз тиз узуы турындамы? Белә алмыйбыз без картларның нәрсә турында сөйләшүләрен. Төркиянең премьер-министры соңгы чыгышында нәрсә әйтүен без икенче көнне үк газеталардан укып беләбез, ә картларның таш койма буенда ни турыда сөйләшүләрен, нинди катлаулы мәсьәләләрне хәл итеп утыруларын белә алмыйбыз.

Койма янындагы куаклыктан ак кәҗә килеп чыкты. Бер тын муенын сузып, картларга карап торды да үлән чемченергә кереште. Балачакның кәҗә эзләп йөргән чакларын сагыну бәгырьне ачыттырып узды.

## Өченче бүлек

*Если б нам служить на суше*
*Да только б ленточки носить...*

Булат Окуджава

# Икария

Кара диңгездәге карлы яңгырлардан соң Эгей диңгезенең җылы кояшы нур сибә башлауга, экипаж әгъзалары, ябырылып, палубага чыктылар.

Кок Бандура белән ипи пешерүче Нина бәрәңге әрчиләр. Боцман

Марчук Новороссийск портында торганда өзелгән швартов бавын ялгап азаплана. Моторист Перечепидорога, баббит белән ышкып, двигательнең клапанын шомарта. Саф һава, тыныч диңгез һәм жылы кояш аларның кәефләрен күтәреп җибәргән. Диңгезчеләрнең кояш жылысында шулай ләззәтләнеп, салмак кына эшләп утырулары авыл җирендә яшәүче игенчеләрнең көндәлек тормыш ыгы-зыгысын хәтерләтә иде.

— Нина, яучы, җибәрсәләр, әнә теге атау патшасының малаена кияүгә чыгар идеңме? — дип сорады боцман ипи пешерүче кыздан.

— Нишләп мин чит ил кешесенә кияүгә чыгыйм ди. Анда бит капиталистлар.

Кок Бандура кызның җавабыннан гаеп тапты булса кирәк, кеткелдәп көлде, тәмәке кабызды:

— Нина, сиңа ничек виза биргәннәрдер? Политграмотаны белмисең икән син. Каян ул атауда капиталистлар булсын? Анда монахлар гына яши.

— Шундый шыр атауда ничек яши ала торганнардыр, исем китә. Анда бит таштан башка бернәрсә юк,— диде өлкән моторист, сүзгә кушылып.

Перечепидорога тәмәке көйрәтергә керешә.

— Монахларга нәрсә кирәк дип беләсең? — диде Бандура.— Алар бит ач та яши алалар. Ашыйсы килдеме, дога укыйлар да вәссәлам. Дога белән тукланып яшиләр дию.

— Нина, әйдә без дә экипажны дога белән тукланып яшәргә өйрәтик әле,— диде кок Бандура.

— Кимерергә сөяк бирмәсәң, боцман шундый «дога» укый башлар, аның ул «дога»сын ишетмәс өчен, көненә өч мәртәбә пешереп ашатырга да риза булырсың.

Эгей диңгезеннән калкып чыккан көрәнсу соры таулар, торган саен зурая барып, корабка таба якынлашалар. Яныбыздан узгач, тагын офык артына кереп, күздән югалалар.

Әнә Икария утравы. Бер-берсенә сырышып утырган көрән таулар. Көзен шытып чыккан үләннәр тауның көрән киеменә салган яшел ямаулык булып күренә. Шул ямаулыклар өстендә соры таплар — таш кыялар, валуннар төсмерләнә. Тау кабыргасында кәҗә көтүе йөри. Әнә көтүчесе дә: яшь кенә бер малай, тезләрен кочаклап, таш өстендә утыра.

Борынгы греклар атауга Икар дигән бер малай хөрмәтенә Икария дип исем кушканнар. Мин борынгы грек мифын сөйләргә керештем.

«Икарның әтисе Дедал Крит патшасы Миноска лабиринт төзеп биргән. Эшен тәмамлагач, останы туган җире Пелопоннеска кайтарып җибәрергә тиеш булса да, Минос патша аны җибәрмәгән, үз янында тотып калган. Патшалар һәр заманны шулай акыл ияләрен — акыллары өчен, осталарны — осталыклары өчен, шагыйрьләрне шагыйрьлекләре өчен үзләре янында мәҗбүри рәвештә тота торган булганнар. Патшалар әнә шул осталар төзегән зур, матур сарайларда яшәгәннәр, исән чакта ук үзләренә гүзәл һәйкәлләр куйдыртып калдырганнар».

— Мин узган елны Ленинградта патша сараен карап йөрдем,— диде Нина.— Шул сарайны ваклап бүлсәң, пароходчылыкта эшләүче һәммә диңгезчегә фатир биреп булыр иде. Ә патша ул сарайда берүзе яшәгән.

— Берүзе түгел, семьясы белән,— дип төзәтте боцман.— Аның семьясында ким дигәндә илле-алтмыш сорыкорт булган.

«Туган җирен сагынып, түзәр хәле калмагач,— дип дәвам иттем мин,— Дедал бер көнне үзенең малае Икарга әйткән: «Минос көчле. Атау аның кулында, әмма күк йөзе аныкы түгел». Һәм шул көнне үк Дедал канат ясарга керешкән. Каурыйны балавызга катырып, ике пар

канат ясаган. Ата белән малай очарга әзерләнә башлаганнар. «Диңгез өстеннән очу бик хәтәр, улым,— дигән Дедал.— Зинһар, сүземне тыңла: миңа гына ияреп оч. Биеккә, кояшка таба оча күрмә».

Дедал белән Икар һавага күтәрелгәннәр. Ләкин Икар, әтисенең кисәтүен онытып, югарыга, туп-туры кояшка таба очып менә башлаган. Кояшка якынлашу белән, аның канатларындагы каурыйларны беркетеп торган балавыз эрегән дә канат таралып төшкән. Икар шулай егылып төшеп һәлак булган...»

— Бу әкияттә бер ялгыш нәрсә бар,— диде кок Бандура.— Пардон, малайның канаты эрергә тиеш түгел иде. Өскә күтәрелгән саен һава салкыная. Шуңа күрә, канатлар, киресенчә, туңып, ныгырга гына тиешләр иде.

— Әкият әкият инде ул, аңа ышанырга кирәк. Безне бит шулай өйрәтәләр,— дип төзәтте боцман аш пешерүчене.

Мин борынгы грекларның өскә күтәрелгән саен һаваның салкыная баруын белмәүләре турында аңлатып тормадым.

Бу миф адәм баласының кайчаннан бирле күккә менү турында хыялланып яшәвен сурәтли. Борынгы греклар бездән ике мең ярым ел элек яшәгәннәр. Миф аларга кадәр тагын меңгә якын ел элек туган булса, күккә күтәрелү хыялы утыз биш гасыр тирәсе кешеләрнең теләкләрендә яшәгән дигән сүз.

Дедал белән Икар турындагы мифның тагы бер ягы игътибарга лаек: читтә яшәүчеләр шул чорда ук туган җирне сагынып җирсенгәннәр. Сагыну көчле булмаса, алар шулай, канат ясап, һавага күтәрелү турында уйларлар идемени? Сагыну, ярату, көнләшү, дөреслеккә омтылу — бу сыйфатлар борынгы грек мифларында бик калку рәвештә сурәтләнә. Димәк, бездән ике мең ярым ел элек яшәгән кешеләрнең тойгылары, әчке кичерешләре нәкъ безнеке шикелле булган.

Борынгы грек мифларын укыгач, өлкән һәм яшь буын арасындагы үзара авыр аңлашу шул вакытлардан бирле яшәп килүен беләсең. Икар әтисенең гадел кисәтүенә колак салмаган. Унбиш-уналты яшьләрдә без дә бит нәкъ шундый булабыз. Көч күп, теләкләр ашкынулы, өлкәннәрнең киңәше, үгете безне берничек тә тыеп тора алмый. Үсмер чакта бер омтылуда бөтен дөньяны яулыйсы килә.

Дедал һәм Икар турындагы миф минем бала чакта ишеткән әкиятләремне тернәкләндереп җибәрде. Ул чакта бар авылда кич утырып әкият сөйләү гадәте бар иде. Кызганычка каршы хәзер әкият сөйләү онытылып бара. Әкият хыялдан, өметтән туа. Ерак бабаларыбызның хыяллары, аларның өметләре әкият белән безнең чорга ук килеп җиткән. Ә без шул кыйммәтле мираска тиешле игътибар белән карарга әле һаман өйрәнеп җитә алмыйбыз.

Кичке чәй вакытында Крит атавы күренде. Ул курстан уңда калырга тиеш иде. Сулда — Карпатос утравы. Без шул ике атау арасыннан Урта диңгезнең ачык өлешенә чыктык. Озакламый Африка ярлары күренәчәк. Тирә-якта иксез-чиксез су сахрасы.

## Шәрык

Чит илгә беренче тапкыр чыгучы яшь диңгезчеләр белән мин бер тәҗрибә үткәрергә яратам. Сәяхәт алдыннан мин аларның һәрберсен аерым-аерым чакырып, сөйләшеп алам. Шәрык ягына барганда: «Без барасы илдә нинди кешеләр яши?» — дип сорыйм. Сорауны мин бераз читләтеп, җавапка зыян китермәслек итеп бирәм. Алар миңа шәрык җирендә нинди бәндәләр яшәгәнен сөйләп бирәләр. Диңгезчеләрнең әйтүенә караганда, ул якта артта калган, ялкау, хатын-кызга хайван-

ча караучы халык яшь. «Бу турыда сез каян беләсез?» дип сорыйм мин. Күбесе шул якта яшәгән кешедән ишеттек дип, икенчеләре — үзебез күрдек дип җавап бирәләр.

Ниһаять, без шәрыкның бер портына кереп, якорь салабыз. Анда берничә көн торабыз, андагы тормышны үз күзебез белән күзәтәбез. Сәяхәттән кайткач, мин шул ук егетләрдән: «Сез анда нәрсәләр күрдегез?» — дип сорыйм. Диңгезчеләр сәяхәт алдыннан әйткән сүзләрен чәчми-түкми кабатлыйлар. Аермасы шул гына — бу юлы алар фикерләрен сәяхәттә очраткан күренешләр белән дәлилилиләр.

Әйбәтләр үзләре. Безнең совет чынбарлыгында интернациональ тәрбия алган егетләр. Күбесе югары белемле. Күзәтә, күзаллый, фикер йөртә беләләр. Шәркыйләргә карата бернинди ачулары, үчләре юк. Ни сәбәп алар шулай ялгышалар? Нигә инглиз колонизаторларының шәрыкка яккан яласын кабатлыйлар?

Бу хәлгә мин әкренләп төшенә башладым. Милли хорафәт гаҗәп озак саклана торган йогышлы нәрсә икән ул. Ул стереотип рәвештә әзер килеш килеп керә һәм, йогышлы авыру шикелле, кешене тиз генә агулап өлгерә. Югары культурага, аңга ирешә алучылар гына шушы хорафатка каршы тора алалар. Пиджак культурасы, диплом белеме бу йогышлы авыруны җиңә алмый.

Кораб Порт-Сәидкә килеп җитте. Без Сүәеш каналына керергә әзерләнәбез. Тышкы рейдка җыелган кораблардан кәрван төзи башладылар. Алга пассажир лайнерларын куйдылар, алар артына — «Ро-ро» корабларын, аннан — контейнеровозларны, танкерларны. Танкерлар артына рефрежираторлар, балкерлар һәм коры йөк йөртүче кораблар тезелде. Кәрван әзер.

Өлкән штурман дневальный кыз Иринаны өйрәтә:

— Каналны үткәнче, буфетың бикле торсын. Бикләмәсәң, бар нәрсәңне урлап бетерәчәкләр. Хәтта үзеңне дә йозаклап тот. Алар хатын кызны урлап китәләр. Бикләп тотмасаң, бер нәрсәң калмаячак. Гарәп чебенен күргәнең бармы?

— Бар. Сүриядә Тартус портында торганда, талап тәмам интектереп бетергәннәр иде.

— Гарәп көймәчеләре дә нәкъ шул чебеннәр шикелле. Куып торасың — күзеңә кереп торалар. Бернинди чара юк, берничек котылып булмый алардан.

Ирина мәш килеп, савыт-сабаны, ашханә әйберләрен шкафка тутырып, бикләп йөри. Өлкән штурман, китешли, янә кисәтеп куйды:

— Үзең дә сак бул. Кызларны момент урлап китәләр алар. Синең шикелле яшь кызны монда ун баш сарыкка, яисә бер дөягә алыштырып була.

Өлкән штурман шаярып сөйләде. Дневальный йөзендә ихлас ышану.

Беренче күрүдә Иринаны әтисен каршыларга килгән бер үсмер кыздыр дип уйлаган идем мин. Саф, эчкерсез, мөлаем күзләр. Утыз дүртенче размерлы тәпиләр. Бармак белән урап тотарлык нечкә бил һәм метр ярым озынлыгы гәүдә. Карап торырга шундый әдәпле, нәзберек безнең Иринушка. Әйе, читтән карап торганда...

Узган рейста бер-бер артлы гауга куба башлагач, егетләрнең үзара ызгышуын аңлый алмыйча, шактый баш ваттым мин. Ызгышуның сәбәбен, аның төп чыганагын эзләп карадым — тавыш кузгатырлык бер сәбәп, бернинди бәхәсле нәрсә дә юк иде шикелле.

Комсостав салонындагы телевизорны кемдер төнгә каршы сүндермичә чыгып киткән. Телевизор иртәнгә кадәр эшләп торган. Бәхеткә каршы, янгын чыкмый калды. Бары тик трансформатор гына янган иде. Телевизор хакында ике буйдак — өченче штурман белән дүртенче механик чәкешеп алдылар. «Салонда син телевизор карап калдың»,— дип аклана иде өченче штурман. «Мин синнән алданрак чыгып киттем.

Соңгы вакытта син төннәрен йоклый алмыйча интегеп йөрисең»,— дип дустының канына тоз сибә иде дүртенче механик. Аларны тыңлап утыручы радиостанция начальнигы кинәт кабынып китте:

— Юкка тырышасыз, егетләр,— диде ул.— Ирина берегезгә дә эләкми. Аның ярда өч йөргән егете бар. Шуларның өчесен берьюлы кызган табага бастыргандай, табаннарын кайнарлап тора.

Шушы вакыйгадан соң дневальный кызны дикъкать белән күзәтергә керештем. Ул чыннан да буйдакларның икесенә дә сырпаланыбрак йөри торган кыз булып чыкты. Өченче штурман янында: «Син, ачык авыз, мине үзеңнеке итәргә кыюлыгың җитми»,— дигән кыяфәттә озын керфекләрен тибрәтеп уза. Дүртенче механикны очратканда: «Әгәр кыюрак кылансаң, син теләгеңә ирешер идең»,— дигән мәгънәдә тирән итеп көрсенә, оялып кызарган була. Шул ук вакытта, шайтан токымы, ике балалы электромеханикның юрганы астына чумып чыгарга да өлгерә иде. Көн аралаш өч егеткә радиограмма җибәреп, эфир аша аларны кайнарлап торуны искә алмаганда да, унга якын диңгезчегә Ирина: «Сез миңа ошыйсыз, мин сезнеке булырга риза һәм әзер»,— дип әйтергә җыенгандай янбашларын уйнатып, киная ясап тора иде. Шушы чәнчә бармак зурлыгы кызның кай җирендә сыеп беткәндер шундый азгын, шундый тынгысыз мәхәббәт? Сәяхәт тәмамланганчы кыз егетләрне җир тетрәнү алдыннан була торган шомлы бер халәттә тотты.

Урламадылар гарәпләр безнең Иринушканы. Сәяхәт тәмамлангач, ярда аның кайтканын көтеп торучы өч егетнең берсенә кияүгә чыгып, мескенне бәхеткә ирештерде.

Боцман белән матрос Алейников гарәп чебене кермәсен өчен ишектәрәзәләргә челтәр беркетеп йөриләр. Аларга боцманның эте Жулька ияргән. Эт минут саен башын күтәреп, хуҗасының күзләренә карый. Мул, ихлас ярату балкый этнең күз карашында. Эт тик бер кешене — боцман Марчукны гына ярата. Ул аңа соңгы тамчы канын, газиз гомерен бирергә әзер.

Сәяхәтнең берсеннән кайткач, Марчук санаторийга китте. Путевка биргәндә санаторийга эт белән барырга ярамый дип аны кисәтеп куйганнар. Боцман Жульканы корабта калдырды. Мескен эт инде икенче атнада ук, сагынуга түзә алмыйча, чиргә сабышты. Жульканың кан басымы күтәрелде, күзләре тонykланды, ашамас булды. Янында узганда диңгезчеләр: «Жулька, боцман сине ташлап киттеменни?»—дип сорыйлар иде. Мескен эт, «боцман» сүзен ишетү белән, палубаны тырный-тырный улап елый башлый. Доктор аңа резерпин һәм валерианка эчереп кенә торды. Хәзер Жулька көне буе боцманнан бер карыш калмыйча, тагылып йөри. Хуҗасы белән янәшә булуга ул чиксез горурлана, куана, минут саен Марчукның аягына сырыша. Диңгезчеләр боцманга ачуланып кычкырган булалар. Жулька хуҗасының «дошманына» һөҗүмгә ташлана. Янында эте булганда боцманга кырын карарга да базмыйлар иде.

Марчук — диңгез флоты боцманы. Башка боцманнар шикелле, мөмкин булганда зур стакан белән аракы чөмерергә, эче бушаганчы ләззәтләнеп сүгенергә ярата. Һөнәр безнең холыкта, гадәтләребездә тирән эз калдыра. Минем төрле боцманнарны очратканым бар. Аракыдан баш тартучы, сүгенмәүче боцман күргәнем булмады. Марчук сүгенүне фәнни-техник революциясе казанышларына җайлап үзгәрткән, камилләштергән: «Мин сине космик орбитага чыгарып фәлән иттем!»— дип кычкырды ул, мәсәлән, кагыйдә бозып, юлны аркылыга кисүче бер корабка. «Алкоголик» урынына ул «алконавт», «кораб»ны инглизчәрәк итеп «шипайло» дип йөртә иде. Узган атнаны аның авызыннан аракы исе килгәнен сизгәч: «Бу юлы кемнең туган көнен юдыгыз?» дип сорадым. «Кичә русның калын стаканының ике йөз еллык юбилее иде»,— дип җавап бирде Марчук.

Кайчакта Жульканың чиктән тыш эчкерсез мәхәббәте хуҗасының «җинаятен» ачарга ярдәм итә. Эт эчтән бикләнгән ишеккә күзләрен мөлдерәтеп карап утырса, каютада «алконавтлар» бәйрәменең кызган чагы була.

Сүэеш каналын үтү — авыр һәм җаваплы эш турында диңгезчеләрнең пафос белән сөйләгәннәрен ишеткәнем юк минем. Алар эшнең авырлыгын юмор белән җиңеләйтергә тырышалар. Каналны үткәндә бер тәүлек күперчектән төшмичә, зур дикъкать белән карап барырга кирәк. Як-якка тайпылырга, алга китәргә һәм артка калырга ярамый. Шушы җаваплылыкны боцман «итәккә тагылып йөрү» дип атый. «Эшебез шундый җаваплы безнең, аны уңышлы башкару өчен, чыдам һәм батыр булырга кирәк»,— дип аңлатканны ишетсәләр, диңгезчеләр сине көлкегә күтәрерләр иде.

Каналга керер алдыннан кораб борынына прожектор астылар. Прожекторны карап бару өчен ике гарәп электригы утырды. Безнең экипажда ике электромеханик һәм ике электрик бар. Алар, билгеле, бер прожекторны гына көйләп бара алырлар иде. Гарәпләргә эш кирәк. Шунлыктан алар мәҗбүри рәвештә корабка үз электрикларын утырталар. Электриклардан тыш, каналны үткәндә, швартов бауларын ярдагы тумбаларга илтү өчен көймәчеләр кирәк була. Аларны да Мисыр кешеләре башкара.

Корабка күтәрелү белән, гарәп электриклары безгә таләпләрен белдерделәр: алар көймәчеләрдән аерым яшәргә, аерым өстәлдә ашарга тиешләр. Көймәчеләр — кара халыктан, электриклар исә югарырак катламнан. Феодаллык чорыннан калган ак һәм кара сөяккә бүлү гадәте белән без менә шулай очраштык.

Электрикларга аерым каюта табып бирдек. Алар көймәчеләргә кадәр ашарга риза булдылар. «Инженер катламыннан» булган электрикларга һәр ике сәгать саен кофе әзерләп бирергә вәгъдә иттек. Ниһаять, рубкага ике лоцман күтәрелде. Болары да зәңгәр канлы аксөякләр токымыннан иде. Аларның икесенә ике аерым каюта, үзләре теләгән ашамлык. Бу мәсьәлә дә хәл ителде. Ниһаять, якорь күтәрдек.

Порт-Сэид каласында эңгер-меңгер вакыты иде. Йортларның тәрәзәләре безгә карап калалар, түбәләрдә төрле төскә буялган неон утлар яна. «Марлборо», «Кэмл», «Мерседес-бенц», «Сони», «Колгейт», «Датсун», «Грюндиг», «Һилтон»— тагын әллә нинди гарәп теленә ят, сәер Европа, Америка сүзләре. Алар ничек Африка җирендәге гарәп каласына килеп кунаклаганнар? Неон хәрефләрдән теркәлгән җор, нахал сүзләр синең күзеңә керергә торалар. Акча эзләүче сүзләр. Акчалы кешене сагалап йөри торгач, алар кеше аягы тимәгән джунглиләргә үтеп керәләр. Неон сүзләр черки шикелле бызылдыйлар, күзеңә сукыр чебен булып керергә торалар. Алар ихтыярыңны буып тоталар да, сатып алырга кыстап, бер генә минут та тыныч яшәргә ирек бирмичә, котырталар, вәсвәсәлиләр, әйбер сатып алмыйча яшәп булмый дип ышандырырга теләп, көне-төне бимазалыйлар.

Ниһаять, реклама сүзенә буйсынып, син ул тәкъдим иткән әйберне сатып аласың. Хәзер бәхетлеме син? Түгел. Сиңа тагын нәрсәдер кирәк. Реклама тагын кыстый. Син тагын реклама кушкан әйберне алырга тиешсең.

Буржуаз чынбарлыкта реклама: «Менә бу әйберне сатып ала алмасаң, бәхет юк сиңа»,— дип акыра, сиңа шуны ышандырырга тырыша. Реклама ялгыз түгел, аның кулдашлары бар: әйбер кирәклегенә инанып өлгергән күршең, хатының, балаларың. Ул шулар аша да кыса. Башка чара калмагач, әйбер алырга, мал җыярга керешәсең. Реклама сүзен тыңлап алган ашамлыклар сине симертә — йөрәгең начар эшли башлый. Кием-салым күплеге сине колга әйләндерә. Йорт җиһазлары, фатирыңдагы урынны биләп, синең үзеңне кысрыклаганнан кысрык-

лый бара. Завод-фабрикалар көне-төне әйбер ясый. Магазин аны сата. Заводлар син сулыйсы һаваны йотып торалар. Сиңа күләгә бирергә тиешле агач бүлмәңдәге урындыкка, син укыган газетага әйләнә. Синең чишмәңнең суын завод эчеп бетергән. Урамны машиналар яулап алган. Анда сиңа урын юк. Табигать тапталган, сытылган. Син йоткан һава — завод торбасыннан күтәрелгән төтен, машиналар карыныннан чыккан газ ул. Химик ашлама белән ашланып үскән бодай бөртеге белән тәнеңә агу үтеп керә.

Шушы хакыйкатьне Европа илләрен, АКШны, Японияне күргәч кенә аңлый башлыйсың. Ләкин аңлау сиңа бернинди куаныч китерми. Син — көчсез. Тәракъкыятькә каршы торырга бернинди чараң юк. Фән, техника казанышлары тудырган индустриаль комсызлык бу.

## Исем кушу

Каналдан Урта диңгезгә чыгып, юлларын дәвам итүче корабларга карап торам. Янымнан егерме дүртенчесе уза. Кызыл диңгездән бу якка чыгучы кәрванда кырык өч кораб булырга тиеш. Аларның чыгып бетүләрен инде утыз минут көтәбез. Тагын бер кораб узды.

Янымнан узган һәр кораб эчендә әллә нинди серләр бар шикелле тоела. Корылмага тезелгән түгәрәк иллюминаторлардан тонык, басынкы утлар күренә. Эчтә ниндидер шәүләләр кыймылдый. Хатын-кыз, бала-чага йөргәне күренеп кала. Болары, һичшиксез, хатыннары, балалары белән бергәләп сәяхәткә чыккан диңгезчеләр булырга тиеш. Аларны күргәч: «Их, мин дә шулай гаиләмә дөнья күрсәтеп йөрсәм иде!» — дип уйлап куям. Ләкин безгә семьяны йөзүгә алырга рөхсәт ителми, ярамый... Иллюминаторларга карамаска тырышам. Кораб исемнәрен укырга керешәм: «Давыл көрәшчесе»— Нью-Йорк. «Океан сәүдәгәре»— Балтимор, «Техасның алтын йолдызы»— Сан-Диего — болары Америка кораблары. Исем кушучыларга әдәплелек җитеп бетми. Исемнәр кирәгеннән артык яңгыравык һәм бераз шапырынуга көйләнгән. «Зәңгәр йөгерек дулкын»— Тулон, «Рамана Рашель»— Гавр, «Сөйкемле дустым»— Сен-Назер: болары француз кораблары. Француз пароходларын иркәлисе, назлап аркаларыннан сыпырасы килеп китә. «Изге Пантелеймон» — Пирей, «Тәүратчы Матвей»— Салоники, «Спирус Паподмитриу»— Пирей: греклар изге пигамбәрләр, дин әһелләре исемен яраталар. «Дмитрий Жлоба»— Новороссийск, «Вытегралес»— Архангельск, «Украина компартиясенең XXIV съезды»— Одесса — болары безнең илнеке, тугандаш кораблар.

Босфорга керер алдыннан өлкән штурман Кара диңгез пароходчылыгы корабы «Зоя Космодемьянская» белән радиотелефоннан сөйләшеп алды.

— Зоечка Космодемьянская, мин — Леня Арцимович, ишетәсеңме?
— Ишетәм, Ленечка. Нәрсә кирәк сиңа?
— Чүпрәм бетте. Ипи пешерергә йөз грамм чүпрә кирәк иде.
— Шлюпка җибәр, бирербез.

Мәшһүр галим белән герой-партизан кызның диңгездә чүпрә турында сөйләшүе мәзәк тоела. Аларның исән кеше шикелле үзара сөйләшә алулары да гаҗәп.

Безнең ил корабларына, кагыйдә буларак, тарихта эз калдырган күренекле шәхесләр, революцион-тарихи вакыйгалар, шәһәр, елга, бөек төзелешләрнең исемнәрен куялар. Кайчакта әйтер өчен авыр исемнәр дә очраштыргалый. Генуя агенты бер мәртәбә «Вытегралес» сүзен әйтә алмыйча, ярты сәгать чамасы газапланды. Артык көчәнүдән мескеннең кан тамырлары бүртеп чыкты, күзеннән яшь бөртекләре тәгәрәде.

Безнең экипаж академик Лев Андреевич Арцимовичның гаиләсе һәм СССР фәннәр академиясе белән даими элемтә тота. 25 февральдә Арцимовичның туган көнендә аның кичәсен үткәрергә төрле илләрдән галимнәр җыела. Бер мәртәбә шундый очрашуга мине дә чакырдылар. Анда Лев Андреевичның шәкерте академик Роальд Зиннурович Сәгъдиев тә бар иде.

Корабка исем куюда аерым бер максат истә тотыла. Хосусый флот биләүчеләр корабларына хатыннарының, әти-әниләренең, балаларының исемнәрен кушалар. Зур пассажир лайнерларына ил, халык исемнәре кушыла. Җилкәнле көймә белән ялгызы җир шарын урап чыккан алтмыш өч яшьлек герой диңгезче Френсис Чечестер яхтасына «Картлык—комачауламый» дигән исем биргән. Әйбәт исем бит.

Порт-Сәид артта калды.

Инде өч сәгать каналда барабыз. Ниһаять Синай чүле ягыннан кояш калкып чыга башлады. Хәзер чүлдә яңа тормыш башланачак. Ком өстендә яшәүче җан иясе, эсседән качып, җир астына кереп посачак. Үсемлекләр, бөрешеп, кояштан яшерену юлын эзләячәкләр. Синай ягында — соргылт ком сахрасы. Берниндн торак йортлары күренми.

Офыктан офыкка җәелгән җансыз ком океаны. Соңгы тапкыр үткән сәмум җиле дулкыннар калдырып киткән. Күтәрелеп килгән кояшның көрәнсу-кызгылт нурлары чүл өстендәге бер җөйне яктыртты. Шул җөйгә бинокльне төбим — кеше эзе. Кайнар ком өстеннән җәяү үтәргә кемнеңдер батырлыгы җиткән икән? Әллә миражмы дип торам: бархан артыннан бер сабый килеп чыкты. Кыз бала. Бер ялгызы, алтыҗиде яшьләр тирәсе. Артыннан эт ияреп килә. Кояшка таба турылап бара. Кояш зур, сабый — кечкенә, чүл — мәкерле. Кояш югарырак күтәрелгәч, чүл өсте күмергә утырткан табадай кызачак һәм мескен баланы куыра башлаячак. Шомланып куйдым: «Кая бара бу мескен сабый? Ул монда ничек килеп эләккән? Әти-әнисе бармы икән?» Нинди генә хикмәтләр юк бу дөньяда.

Уңда, Африка ягында, ярга янәшә асфальт юл сузылган. Юлның теге ягында тар гына бер канал Нил суын мондагы авылларга өләшә. Чакрым саен пальма күләгәсенә сырышкан саман йортлар. Казыкка кыска бау белән бәйләп куйган тәбәнәк соры сыер җәймә зурлыгы чирәмлекне кыркып йөри. Йорт каршында бер ябык хатын киледә нәрсәдер төя. Төйгечнең дөпелдәп агач төпкә бәрелгәне корабка кадәр ишетелә. Сөяк белән сеңердән генә оешкан чандыр икенче бер кеше кояшка кибеп яргаланган җирне китмән белән кыйный. Җир мәйданы кечкенә: ком өеменә төртелеп туктаган. Элегрәк ул бәлки зуррак та булгандыр. Ләкин ком өеме аны басып алып, яртылаш киметкән. Өемне сугыш барлыкка китергән. Аның өстендә — окоп. Окоп эченнән танк башнясы һәм җитмеш өч миллиметрлы туп көпшәсе каналга таба муенын сузып карап тора.

Җирне танк белән эшкәртүе, билгеле, җиңелрәк булыр иде. Ләкин танкның вазифасы җир сөрү түгел. Ул — кеше үтерү өчен ясалган машина. Җирне эшкәртергә трактор кирәк. Ә трактор алырга акча юк. Акча танк һәм башка кораллар ясауга кереп беткән. Сугыш ком өеме генә түгел, башка җәрәхәтләр дә калдырып киткән. Фәллах җиренең нәкъ уртасында — снаряд чокыры. Йорт янында үскән хөрмә агачының ботагын снаряд умырып ташлаган. Сынган ботак утынлыкта аунап ята. Агач төбендә вакытлыча казылган траншеялар. Абзар артында ташландык БМП (пехотаның сугышчан машинасы) мәете тутыгып ята. Ызан буенда бер төргәк чәнечкеле тимер чыбык. Тимер чыбык та фәллахның чәчүлек җирен киметкән. Чәнечкегә эләгеп калган төссез чүпрәк кисәге, әрнүле хисләр уятып, җилдә җилферди.

Сугыштан калган эзләр бу. Израиль сугышыннан калган эзләр. Җимерек йортлар, җәрәхәтләнгән җир, каберлекләр.

Йөрәк ярасы никадәр сызласа да, ярчыгын алсалар, бер заман төзәлә. Кеше тәнендәге ярага ит үсә, аны кием каплый. Җир җәрәхәте озак еллар төзәлмичә, сыкранып җәйрәп ята икән. Ул сугыш эшләгән җинаятьләрне искә төшереп тора.

Мисыр белән Израиль арасындагы сугыш тукталганга инде унбер ел. Җиргә түгелгән кан инде сеңеп беткән. Сугыш вакытында түгелгән күз яшьләре кипкән, сугыш хатирәләре онытылган. Ә мескен җир һаман елый. Аның тәне һаман әрни булса кирәк.

Мисыр җирендә Сүәеш каналын төзегән чакта да кан һәм күз яше мул коелган — илле градус эсседә җир казу, сусаулар, йогышлы авырулар ике йөз меңнән артык канал казучыны дөньядан алып киткән. Канал казуда һәлак булган гарәпләрнең сөякләрен өеп куйсаң, тирәяктагы ком бархannарыннан биегрәк булыр иде.

Ябылып торган чакта Сүәеш каналын ком басып киткән иде. Ком бураны үткән саен, канал саегая бара. Аны туктаусыз чистартып, тирәнәйтеп торырга кирәк.

Канал идарәсе Сүәеш каналын яңартып азаплана. Элек аның киңлеге — алтмыш, тирәнлеге унбер метр булган. Яңартканнан соң каналның киңлеге йөз ун, тирәнлеге унсигез метрга җитәчәк. Мисырның үзенең кулыннан килмәгән эшне японнар башкара. Кайда гына эшләмиләр японнар! Африкада, гарәп илләрендә, Тын океан киңлегендә югалган аулак атауларда — кая карама японнар эшли. Нәрсәдер төзиләр, яңарталар, үзгәртеп коралар. Бу халыкның бер күркәм ягы бар: ул патриотлыгын эш белән күрсәтә.

Егерме биш ел күзәтеп, минем японнар арасында якасы пычранган, яисә күлмәгенә тап төшкән кеше очратканым булмады. Җыйнак һәм чиста яши, җиңел һәм пөхтә эшли беләләр японнар.

Каналның урта өлешендә зур күл бар. Без хәзер шуңа якынлашып киләбез. Шул күл ярына Исмәгыйлия шәһәре урнашкан. Кызыл диңгез ягыннан безгә каршы килүче кәрван шушы күлгә туктап якорь ташлый да безнең үткәнне көтеп тора.

Исмәгыйлия тирәсендә сугыш эзләре тагын да ешрак очрый, шәһәр читендә җимерек йортлар, ватык кирпеч өемнәре, имгәнгән агачлар тырпаеп утыра. Әнә, яр кырыендагы бер йортның түбәсе, сытылып, эчкә баткан, диварлары таралып төшкән. Бары тик кыса — бетон, матчалар, баганалар гына тырпаеп калган. Йорт — җирдә озак яткән мәет скелетын хәтерләтә.

Я алла! Бу дөньяда сугыштан да ләгънәтле нәрсә бармы икән? Юктыр! Аннан да яман, аннан да ләгънәтле хәл булмый торгандыр!

Хәрабәләре астыннан сабый балалар үксеп елаган тавыш ишетелгән шикелле тоела. Тыңлыйм. Җимерек биналарга бәрелеп, җил улый, шуның тавышы икән.

Исмәгыйлия — мисырлыларның курорт каласы. Сугышка кадәр монда күңел ачу йортлары, төнге барлар, пляжлар тупланган булган. Сугышка ияреп шәһәргә ком һөҗүм иткән. Кала читендәге яшел чирәмнәрне, чәчәк атып утырган бакчаларны ком баскан. Ачлык, йогышлы авырулар, комсызлык, әхлаксызлык шушы ком шикелле сугышка ияреп йөри.

Шулай да күл буенда Урта диңгез һәм Американың Атлантик океан ярларындагы бай курортларны хәтерләткән кыйммәтле коттеджларны әле хәзер дә еш очратасың. Вак кызыл кирпеч, алсу чәчәкле бугенвелия, саф яшел чирәм, зәңгәр су. Һәр төс җете ачык, затлы, килешле. Чиста ак ком өстендә буржуй балалары кояшта кызына. Шау-шу, йөгерешеп, куышып уйнау юк монда. Су чәчрәтеп чуму, кычкырып көлү дә ишетелми. Җиде-сигез яшьлек бала әкрен генә урыныннан торып, ашыкмыйча гына суга керә. Балаларның шулай кылanулары күңелдә

шөбһә уята. «Пенсиягә чыккан картлар түгелме икән?»— дип, су коенучыларга кабат карыйм. Юк, бала-чага. Ә нигә алар үзләрен шулай табигый тоталар икән?

Биек тимер койма белән уратып алынган бакча эчендә көрәнсу кирпечтән салынган ике зур вилла күренә. Виллалар тирәсендә җете яшел чирәмлек, тәрбия күреп үскән затлы, көр агачлар. Виллаларны кораллы солдатлар саклый. Аларның берсе — Әнвәр Садатныкы, икенчесе чит илдән килгән хөкүмәт кунаклары өчен салынган. Моннан өч ай элек Әнвәр Садат Израильнең премьер министры Бегин белән шушында очрашты. Ул чакта һәр агач төбендә кораллы сакчы тора иде. Безнең корабка да Порт-Сәидтән берничә сакчы солдат утырттылар.

Күлне үттек, тагын каналга кердек. Ун миль тизлек белән көньякка таба шуышабыз. Әл-Кантара исемле авылга килеп җиттек. Монда канал аша Берләшкән Милләтләрнең гаскәри частьләре чыгып бара. Барысы да соргылт-зәңгәр киемнән, башларында соры берет, кокарда урынына артыш ботагы — тынычлык эмблемасы. Скандинавия илләреннән ялланган сары чәчле таза егетләр. Берсе чегәнгә охшашлы сылу яшь кыз җитәкләгән.

Кыз чибәр, колагында ат дагасы зурлыгы алтын алкалар, калын кара чәченә кызыл чәчәк кадап куйган. Грим да ягып торасы юк, тот та Кармен ролен билгелә. Ә нигә солдатларга ияргән икән ахмак кыз? Тормыш корыр өчен иң ышанычсыз, яраксыз кеше бит ул чит ил солдаты. Берләшкән Милләтләр гаскәрендә хезмәт итүчеләргә күп түлиләр. Эш анда түгел, кызыгырга ярамый солдат акчасына.

Караңгы төште. Алда Сүәеш шәһәренең утлары җемелдәп күренде. Корабтагы гарәпләр төшәргә җыена башладылар. Көймәчеләр, базар өчен алып килгән күн дөя, тәсбих, талисман итеп эшләнгән коръән, җиз Нефертити һәм башка вак-төяк әйберләрен палубага тезеп куйган җирдән җыеп алып, сумкаларына тутырдылар. Юк, булмады алышбиреш. Тәҗрибәле көймәчеләр беләләр. Андыйлар совет пароходына товарсыз киләләр. Без гарәпләргә күнегеп өлгердек инде. Алар да күнектеләр. Шәфкать җылылыгы, туганлык хисе барлыкка килде.

Шәрык вәкилләре белән аерылышабыз. Гарәпләр безнең белән тәүлек буе ашны бер казаннан ашап яшәделәр. Кыска гына вакыт эчендә без бер-беребезгә тәмам күнегеп өлгердек. Нindирәкләр соң алар? Наданнармы? Әйе, лоцманнан тыш аларның берсе дә укый-яза белми иде. Культура ягы ничек? Артта калган кара кешеләрме? Дөрес, артта калганлык бар. Әмма аларны кара, культурасыз дип әйтергә ничектер тел әйләнми. Угрылармы? Юк. Ялкауларымы? Түгел. Ут чәчрәтеп, тырышып эшлиләр. Хатын-кызга хайванча мөгамәләдәге кешеләрме? Юк, безнең корабта эшләгән гарәпләр бик әдәплеләр иде. Алай булгач, шәрык кешеләре алар карак, ялкау, хатын-кызга хайванча карыйлар дигән уйдырма каян туган? Гарәпләрне якыннан күреп белмәгән озын телле наданнар сөйләвеннән туган ул караш. Шовинистлыктан, карагруһчылыктан. Без мондый хәлләрне искә алырга, бу турыда уйланырга яратмыйбыз. Бу феноменның ничек барлыкка килүен фәнни яктан тикшермибез дә. Ә бит милләтләр арасын пычратып торган андый нахак сүзләр, ялган ялалар карагруһлар теленнән еш кына әдәби әсәрләргә, хәтта тарих китапларына да саркып керә.

## Кайнар диңгез

Новороссийскидан чыкканга биш тәүлек. Көн шундый эссе — сулыш алганда, һава тын юлын көйдерә. Сәяхәт башында кояш салкын болытлар артына яшеренгән иде. Босфордан соң безне мәрхәмәтле, җылы

кояш озата барды. Хәзер түзеп булгысыз эссе, бөркү. Тропик кояшының нурлары энә очы шикелле авырттырып биткә кадала. Тәннең кояш нуры тигән җире шундук кызарып чыга һәм ачыта башлый.

Тропик кояшының батуы да бездәгечә түгел. Әле берничә минут кына элек ул биектә иде, ә хәзер, карыйсың, ул инде офык артына чумып бара. Туп-туры диңгезгә төшеп батканда да кояшның кайнарлыгы сүрелми, тик һавада бөркүлек кенә арта. Һәрнәрсә дымга манчыла. Эчке күлмәк, чалбар — һәммәсе юеш. Кораб өстеннән яңгыр явып узгандай, палубага су җыела. Сулыш алганда үпкәгә су парлары тула. Кайнар су парлары тамакка тыгыла. Бирешмәскә тырышам: «Мәскәүдә әйбәтрәк мунчага эләгү өчен иртәнге сигездән чират торырга кирәк иде»,— дип үземне юатам.

Күктә Әл-Таһир йолдызы калтырана, бии. Йолдызлар шул кадәр күп, алар күк түшәменә ябыштырган алтын таңкәгә охшап җемелдиләр. Бу калтырану — галәмнең хәрәкәте. Моннан бер секунд элек секстан ярдәмендә Әл-Таһир йолдызының биеклеген үлчәдем һәм үлчәгән мизгелне билгеләү өчен секундомерның төймәсенә бастым, ә секундомер, текелдәп, вакыт агымын санап бирә. Миңа секундның уннан бер өлешенә дә ялгышырга ярамый. Һәр секунд йолдызлар хәрәкәтендә йөзләгән, меңләгән миль араны күрсәтә. Шушы хакыйкатьне аңлау — галәмнең очсыз-кырыйсыз, андагы хәрәкәтнең чиксез һәм катлаулы икәнлеген искә төшерә.

Мәсьәләне чишеп, корабның барган урынын тапкач, координатларны картага күчердем. Тропикка җитәргә өч йөз кырык ике миль калган. Шушы санны кораб тизлегенә бүләм: унсигез сәгатьтән экипажга шәраб бирә башларга тиешбез. Күмәк договорда шулай язылган: «Диңгезчеләрнең сәламәтлекләрен саклау максаты белән тропик киңлекләрендә йөзгәндә тәүлегенә өч йөз грамм әчкелт шәраб бирергә». Капитан шәрабны су белән сыеклап өләшергә дип артельщикны алдан кисәтеп куйган иде. Сизеп торам, ризасызлык башланачак.

Рубкадан чыгып, бакка юнәләм. Фальшбортка ятып, кораб борынының су өстен ертып баруын карыйм. Форштевень астыннан оча торган балыклар күтәрелә. Алар, канат кагып, су өстеннән очып баралар. Балык канаты тигән җирдә яшькелт фосфорлы яктылык кабынып кала. Форштевень гигант сабанга охшап суны актарып ташлый. Судагы фосфор уты шундый көчле, диңгез яшькелт ут чыгарып пыскый, яна сыман. Диңгездәге балыклар һәм планктон чәчкән ут бу.

Кораб астында берничә километр калынлыгы су катламы — салкын, караңгы упкын. Анда әллә нинди балыклар, әллә нинди куркыныч су җәнлекләре яши. Мин пеленгатор палубасына күтәреләм. Палубага йолдызлар нуры — ялтыравыклы тере җепләр сузылган. Алар, караңгылыкны тишеп чыгып, палубаны алтынга буяганнар.

Бәрхеттәй йомшак, нәзберек кара төндә диңгезнең тирәнлеге, күк йөзенең чиксезлеге аеруча тәэсирле. Астагы тирәнлек, өстәге чиксезлек нигәдер куркыта. Галәм каршында син үзеңне кечкенә, катрә бер тере нокта гына итеп тоясың. Катрәлек тойгысыннан аң, акыл коткара. Галәм синең күкрәгеңә, баш миеңә сыйган. Син аңа турыдан-туры тоташкансың. Йолдызлар, океаннар, чүлләр синең белән бергә сулыш ала. Алар синдә. Шушы бөек, бетмәс-төкәнмәс байлык сиңа мәңгелеккә бирелгән. Иксез-чиксез байлыкның хуҗасы булу өчен син беркемгә баш имәдең, ялагайланып, тез чүкмәдең. Аны үзеңнеке итәр өчен ришвәт тә кирәк булмады. Шушы байлыкка ирешер өчен, сиңа галәмне аңлау, аның бөеклеген ихлас тою җитте. Хәзер син шушы иксез-чиксез байлыкның хуҗасы. Баеганга кадәр акчаң аз, фатирың тар, урының түбән иде. Галәмне акыл коча алу бәхетенә ирешкәч, син зурайдың, ихтыяҗларың кимеде. Галәмне ярата алу үзе бер бәхет. Синең яратуың, ма-

турлык тоюың сиңа чын бәхет китерде. Тартып ала, киметеп бирә алмаслык рухи бәхет.

Кораб, юлындагы караңгылыкны умырып, һаман алга бара. Мачта очлары йолдызларны аралап килә. Койрыктан артка таба кильватер агымы йөгерә. Судагы яшькелт утлар һаман куера. Хакыйкать мизгеле бу. Рухи яшәүнең көндәлек мәшәкатьне, дөньяви ваклыкларны җиңгән чагы.

Төнге вахта алышынган чак иде. Бишенче унбиш минут. Ашханәгә кердем. Икенче механик Шевердин белән моторист Коноваленко табын әзерләп йөриләр. Таң беленеп килә. Күктәге яктылык сизелер-сизелмәс кенә сыеклана. Төнге вахтадан алышынучыларның кашлары җимерек.

— Нәрсә булды, егетләр? Әллә берәр начар хәбәр алдыгызмы?— дип сорыйм.

— Иртәнге чәйгә тагын «братская могила»,— диде Шевердин.— Тагын ач корсактан йокларга ятарга туры килә.

Вак диңгез маймычларын каешланганчы кайнатып ясаган балык консервасын диңгезчеләр «туганнар кабере» дип атап йөртәләр. Бу консерва тәмсез һәм карап торырга да шөкәтсез. Кайнатканда маймычларның ите таралып бетеп, кылчыклы ябык скелетлары гына торып кала. Өстәвенә, консервага сыек сары соус салганнар. Ике төр ашамлыкны яратмыйлар диңгезчеләр: шушы консерваны һәм флотча пешерелгән макаронны. Соңгысын алар «макароны с мусором» дип йөртәләр.

— Юрко кайда йөри?— дип сорадым.

— Ул бәрәңге эзләргә китте,— диде Коноваленко.

«Братская могила»ны дүрткә бүлеп ашарга гына керешкәннәр иде, ашханәгә матрос Юрко килеп керде:

— Ашамагыз шул үләксәне, хәзер бәрәңге пешерәм,— диде ул.

— Җыелышта кисәткәннәрен оныттыңмыни? Илтеп урынына сал бәрәңгеңне,— диде икенче механик Шевердин.

Юрко сукрана башлады. Бәрәңге пешерү тыелмаган чакта, ул бу эштән һәрвакыт баш тарта иде. Кушканны эшләргә яратмый. Кирегә эшләп тик йөри. Бу юлы, сукранып кына булса да, бәрәңгене рефрежираторның яшелчә камерасына кире илтеп салгач, Юрко мыгырданып, чыгып ук китте.

Төнге вахтада торучылар юньләп ял итә алмыйлар. Сәгать иртәнге биштә алар йокларга яталар. Җидедә экипаж тора. Көндәлек эш башлана. Чүкеч белән бәргәләп, палубаны тутыктан әрчү. Кычкырып сөйләшүләр. Корабта кычкырып сөйләшү, сызгыру, тавышланып йөрү тыела, ләкин һәр коллективта берме-икеме шундый әдәп саклый белмәгән пырдымсыз кеше була.

Туйганчы ял итә алмыйлар төнге вахтада торучылар. Диңгездә чакта әле түзеп була. Портта торганда яшьрәк диңгезчеләр ярты төн йөреп, арып кайткач, вахтага басалар. Ифрат озын тоела төнге вахта. Диңгезчеләр телендә бу вахтаны «эт шатлыгы» дип атап йөриләр.

Таң алдыннан Ассаб портының тышкы рейдына якорь ташладык. Бу тирәнең тәбәнәк ярларын локатор тота алмый. Яр буенда су асты кыялары, мәрҗән рифләре күп, йөзү шактый хәтәр.

Хәбәш иленең ярларын күзәтәм. Кораб белән материк арасына шлемга охшаш кызгылт-көрән төстәге Сана-Бор атавы урнашкан. Әйтерсең шлем кигән сугышчының аягы су эчендәге тозакка эләккән дә, ул шунда туктап калган. Аның баш киеме генә өскә калкып тора. Революциягә кадәр караңгы төннәрдә контрабандистлар Җиддә һәм Җибутидән ташыган товарларын шунда яшерәләр иде. Хәзер анда хәрби пост куелган.

Ассаб порты вулкан кратерыннан агып чыккан каткан магма өстендә утыра. Ташка әйләнгән магманы җил, яңгыр, кояш нурлары гасыр-

лар буе ашый килгәннәр. Әкренләп вак кызгылт тузан хасил булган. Шәһәр тирәсендә шундый тузан ята. Тузан асты да шул ук базальт ташы. Диңгез ярыннан утыз-кырык чакрым чамасы ераклыкта түбәләрен кар каплаган таулар күренә. Көнбатышта печән кибәнен хәтерләткән Селла тавы. Көнчыгыштагы Атбаргули-Кәбир тавы йоклап яткан арслан киекне хәтерләтә.

Бу портта мин беренче мәртәбә 1958 елда булган идем. Ул чакта без Ассабка нефть куа торган завод төзү өчен җиһаз ташыдык. Зөлхиҗҗә аеның унынчы көне җитеп килә иде. Кайтышлый, хаҗ кылучыларга илтер өчен Ассаб портыннан сарыклар төяп Җиддә портына юнәлдек.

Нефть куу заводы төзелә башлагач, бу портка еш йөрелде. Заводта эшләргә тиешле хәбәш инженерлары Башкортстанда практикада булдылар. Шуларның берсе практика вакытында Сәлимә исемле татар кызына өйләнгән иде. Бер мәртәбә мин Сәлимәләрдә кунакта да булдым. Үз якташың белән чит илдә очрашу — онытылмас вакыйга. Исәнме икән әле Хәбәшстанда яшәүче ул татар кызы?

Тышкы рейдта ике тәүлек көттек. Ниһаять, портка керттеләр. Алып килгән машиналарны бушатырга керештек.

Супервайзердан [1] Сәлимәнең ире турында сораштырам.

— Ул бик озак завод директоры булып эшләде. Аны күптән түгел Әдис-Әбибәгә алдылар. Министрмы, әллә министр ярдәмчесеме. Сезнең танышыгыз хәзер зур кеше,— диде ул.

Кайларда, нинди генә урыннарда очрамый безнең як кешесе. Төркиядә, АКШта, Көнбатыш Германиядә, Финляндиядә, хәтта Согуд Гәрәбстанының Даһлак атавында очратканым бар мин якташларымны. Илендә чакта үзенең кем икәнлеген белмичә яшәгән кеше, чит илгә әләгү белән, туган җирен, телен, гореф-гадәтләрен сагына башлый.

1977 елның көзендә бу портта тагын булырга туры килде. Сомали гаскәрләре Огаден чүлен басып алган чак иде. Эретрия — сепаратистлар кулында. Төньяк-көнбатышта монархистлар баш күтәргән чак.

Диңгез портларында барлык илләргә хас бер интернациональ уртаклык бар. Шунлыктан бу тормышка карап илдәге гореф-гадәтләрне, халыкның яшәү ысулын аңлавы читен. Мин якын-тирәдәге авылларны, анда яшәүче кешеләрне карап йөрергә яратам. Корабны бушаткан арада супервайзер Менелик миңа хәбәш авылларын күрсәтмәкче булды.

Меneликның җиңел машинасына утырып Ассабтан чыктык та, көнбатышка борылып, тауларга таба юл тоттык. Җил асфальт юлга ком ташыган. Көпчәкләр астында пычак кайраганда чыккан тавыш. Тавыш тешкә тиеп теңкәне корыта. Ярты сәгатьтән тау итәгенә килеп җиттек. Юл, боргаланып, өскә, тау кабыргасына күтәрелә башлады. Машина көпчәкләре упкын читеннән генә баралар. Бездән берничә йөз метр биеклектә, ычкынып китеп, өстебезгә төшәргә әзерләнеп, кызгылт кыялар асылынып тора. Алар астыннан узганда, йөрәк кысылып куя. Җир кайнар, коры. Бу җирнең исе икенче төрле. Тимерче алачыгы исе килә мондагы ташлардан. Тауларның кыяфәте шундый ят, шундый сәер, әйтерсең алар әле яңа гына утлы лава хәленнән арынып, суына гына башлаганнар. Әйтерсең, син айдагы тауларда.

— Инде ун ай бер тамчы яңгыр төшкәне юк,— дип зарлана супервайзер.— Бездә яңгыр бик сирәк ява. Бары тик кыш урталарында океан ягыннан искән муссон җиле болыт алып килгәли. Яңгыр, җиргә төшеп өлгергәнче, парга әйләнеп бетә.

Без һаман өскә күтәреләбез. Ташлар арасыннан сарык көтүе килеп чыкты. Мескеннәрнең сарык затыннан икәнен аңлавы да кыен. Йоннары көрәнсу сары, әйтерсең учакта тотып ыслап җибәргәннәр. Үләнле

---

[1] Йөк бушату белән җитәкчелек итүче.

жир эзләп йөриләр. Үләннең әсәре дә юк монда. Белмим, нәрсә ашап, ничек җан саклап йөриләрдер ул мескен сарыклар?

— Берәр кирәксез кәгазегез юкмы?— дип сорады юлдашым, минем күңелдәге уйларны аңлап алгандай.

Мин аңа ярты газета суздым. Менелик шоферга сарыклар янына барып туктарга кушты. Без көтүгә таба борылдык. Сарыклар өркеп, читкә тайпылдылар да, өрелешеп, безгә карап тора башладылар. Супервайзер газетаны йомарлап көтү өстенә ыргытты. Сарыклар, бер-берсен таптап, кәгазьгә ташландылар. Мизгел эчендә газета юкка чыкты.

Күз алдымда 1944 ел, резерв батальонда хезмәт иткән чагым. Без летный норма ашаучы инструкторлар өстәлендә калган ашамлыкларга нәкъ менә шулай ташлана торган идек. Җиңел оныттык без ачлык елларын. Кораб камбузында пешерелгән ашның өчтән бер өлеше диңгезгә түгелә. Сугыштан соң туып, муллыкта үскән акселератлар телемнән бер кабымлык тешләп алалар да калганын шулпага батырып калдыралар. Дөге боткасына тәмәке төпчеге төртеп китәләр. Шушы җинаятьләрне күргәндә җан рәнҗи. Юк, ачлык теләмим мин аларга. Ачлык — җир йөзендәге иң зур, иң каһәрле афәт. Ашыйсы килүгә, эчнең борып-борып ачытуына күнегеп була. Ашыйсы килү — ачлыкның бер билгесе генә. Ачлыкның иң әшәке нәтиҗәсе — шәхестәге кешелек сыйфатлары югалу. Ачлык, вөҗданны тар-мар итеп, иманны, намусны зәгыйфьләндереп, кешене хайванга әйләндерә. Тамагы ач кешене бернәрсә белән дә куандырып булмый.

Азия, Африка илләре өстендә гасырлар буе кара канатын җәеп ачлык көн яктысын, яшәү куанычын каплап тора. Бай илләр, ачларга ярдәм итү урынына, корал ясап, аларның хөкүмәтләренә китереп саталар. Хәбәшләрдә дә шушы хәл. Гасырлар буе ачлы-туклы яшәү бу илнең халкын вагайтып бетергән. Хәбәшләр ябык, тәбәнәк буйлылар.

Үзләре алар чиктән тыш тыйнак, әдәпле, чыдам халык. Пышылдап кына сөйләшәләр. Русның милли горурлыгы булган Александр Пушкинны бүләк иткән токым бит бу. Африканың бары тик бер илен, бары тик Хәбәшстанны гына колонизаторлар яулый, буйсындыра алмаганнар. Империалистларга баш бирмәгәннәр хәбәшләр. Бу илнең җирен колонизаторларның дагалы итеге таптый алмады.

Тау кабыргасындагы кыяларга сырышып утырган авыл күренде. Йортлар үзләре дә шушы кыялардан ватып алынган кызгылт таштан салынган. Түбәләре дә шул ук таштан. Яссыракларын сайлап, тезеп куйганнар.

Авылга керер алдыннан, машина кинәт читкә тайпылды. Юл уртасына ике мәетне чалкан яткырып куйганнар иде. Икесе дә яланаяк, кара майкадан гына. Ябык, ит кунмаган нечкә ботлар агач ботагы шикелле безнең якка таба тырпаеп катканнар. Мәетләрнең битләрен чебен сарган. Аларны саклап утыручы өч козгын машинадан куркып, җирдән күтәрелде дә читкәрәк барып кунды.

Күз алларым караңгыланып китте. Курку түгел иде бу. Фаразлап, үлемнең кирәк нәрсә икәнлеген аңлыйм мин. Үлем — бөек хакыйкать. Аның каршында хәерче дә, миллиардер да тигез. Үлем булмаса, тәхеттә мәңге тиран утырыр, власть мәңге картлар кулында булыр иде. Мәетләрне күргәч, дөнья үзенең кызыгын югалтты: хәбәшләрнең торaклары, аларның яшәү рәвешләре кинәт кирәксезгә әйләнде, аларны күрәсе килү сүнде, юкка чыкты.

— Борылыйк, Менелик. Рәхмәт, авылга кереп торасым килми инде,— дидем мин.

— Әллә мәет күреп кәефегез киттеме? Алар контрреволюционерлар бит. Император властен кире кайтару турында коткы таратып йөрүчеләр.

Юлда аунап яткан мәетләрнең үлем җәзасына лаеклы булуларына

шигем юк иде. Ләкин ни сәбәптер, үлгән кешене гаепли алмыйм мин. Мәеткә әйләнгән бәндәне гаепләп булмый. Ул инде фани дөнья хәлләренә битараф. Ул хәзер уңай һәм кире сыйфатларын югалтып, гомуми категориягә әйләнгән.

Без әйләнеп кайтканда корабның Ассабта калдырасы йөген бушатып бетергәннәр иде. Йөк документларына кул куйгач, якорь күтәрдек.

Су эченнән башын чыгарып карап торган Сана-Бор атавы яныннан узганда Шарль Бодлерның русча тәрҗемәдәге бер шигыре исемә төште:

> Горька и бесплодна наука дальних странствий,
> Сегодня как вчера, до гробовой доски
> Все одно и то же лицо встречается в пространстве...

Безнең ерак бабаларыбыз сәяхәтне туйганчы татыганнар булса кирәк. Алар француз шагыйренең фикерен гаҗәп акыллы бер җөмләгә сыйдыра алганнар: «Кая барсаң да, кара сакалың артыннан калмас...»

Юлда аунап яткан ике мәет сурәте бик озак төшемә кереп, саташтырып интектерде.

## Җиңү шатлыгы

Кораб двигательләренең эшләвен күзәтә торгач, бер мәзәк фикергә килдек: двигатель никадәр затлы, автоматикасы никадәр югары сыйфатлы булса, аның белән эш итү шулкадәр авыр һәм катлаулырак икән. Кагыйдә буенча, автоматлаштыру кешенең эшен җиңеләйтергә тиеш бит. Чынлыкта исә автоматикалы корабларда эш арта, вазифа катлаулана: механиклар двигательнең үзеннән тыш, аның автоматларын туктаусыз тикшереп, көйләп, төзәтеп торырга тиешләр.

«Академик Арцимович»ка Франциядә ясалган «Пилстик» двигателен куйганнар. Гадәттә, кораб двигателе өч катлы йорт биеклеге була. Бу двигатель — кечкенә һәм җыйнак, кораб эченә кергән күп кеше: «Ә кайда аның двигателе?»— дип сорый. Унсигез мең ат көче тудыручы машинаны җиңел генә трюм астындагы аралыкка яшереп куйганнар.

«Пилстик»ның эш режимын автомат күзәтә. Цилиндрлар даими температура режимында эшләргә тиеш. Аларга чиктән тыш кызарга да, артык суынырга да ярамый. Бу двигательгә ягулыкның да иң яхшысы, майның да бары тик «Шелл» заводларында эшкәртелгәне генә ярый. Әгәр шул тиешле ягулык, тиешле май, тиешле температура, тиешле көчәнү режимы бозыла башласа, двигатель, сигнал биреп, янына механикны чакыра, һәм, ярдәм вакытында килеп өлгермәсә, эштән туктый.

Машина бүлегенә кереп китәр алдыннан механик пульттаге бер кнопкага басып куя. Әгәр ул вакытында килмәсә, автомат тревога уйный башлый. Механикларның, кулларын кесәләренә тыгып, тик йөрергә вакытлары юк: алар көне-төне, майга батып, машина тирәсендә кайнашалар. Озак йөреп, туган илгә кайткач та алар, машинаны калдырып, ял итәргә өйләренә кайтып китә алмыйлар. Айлар буе ирен сагынып яшәгән механик хатыны күз яшен йотып аны тагын көтә. Түзәр хәле калмаган хатыннар кайчакта тәвәккәлләп: «Я минем белән, я шушы дөмегеп киткере машинаң белән яшәргә тиеш син, кайсыбызны сайлыйсың?» — дип, мәсьәләне кабыргасы белән куялар. Мондый очракта механикка нишләргә? Диңгезчеләрнең күбесе эшен дә, хатынын да ярата. Тойгы-мәхәббәт аларның икесенә дә җитә. Әмма аларда эш тәртибе үзгәрәк. Бездә эш вакытында — ял, ял вакытында — эш. Күп эшли диңгезче-механик, һәм техника алга барган, яңарган, яхшырган саен аңа эш өстәлә генә тора.

Баб-ел-Мәндәб бугазының иң тар, пароходларның иң еш йөргән җи-

рендә двигатель ярдәм сорап үкерә башлады. Юньсез сыер вакытсыз чакта бозаулый диләрме әле? Бу урында туктарга ярамый иде. Тирәяктан берөзлексез кораблар узып тора. Су артык тирән — якорь да салып булмый.

Капитан Грязевский яңа буын вәкиле буларак: «Нишләп машинагыз иң хәтәр җирдә ватылды? Саботажниклар!» — дип кычкыруны кирәк тапмады. Машина бүлегенә шалтыратып, өлкән механикны күперчеккә чакыртты да, җаваплылыкны үз өстеннән төшерер өчен, рапорт яздыртты. Рәсми кәгазь кулына кергәч, ул тыныч кына:

— Машинаны төзәтергә сезгә күпме вакыт кирәк?— дип сорады.

— Ике сәгать,— диде өлкән механик боек кына.

Рапортны капитан кулына тапшырганнан соң туктап торуның һәр минуты өчен хәзер ул җавап бирә иде.

— Руль сулга,— дип боерды капитан.

Кораб сулга борылды. Зөбәер атавының көньяк-көнбатышына кереп, бер тыныч кына култыкка якорь салдык.

Механиклар жиң сызганып эшкә керештеләр. Вахтадан соң ял итүче матрослар, штурманнар, ябырылып, палубага чыктылар.

Атау судан калкып торган гигант мунча ташын хәтерләтә. Тау итәгенең фәкать бер генә урынында тар гына комлык күренә. Шунда дистәдән артык соргылт таш йортлар бер-берсенә терәлеп утырганнар да, диңгез ягына карап, нәрсәдер көтәләр. Йортлар арасында ялгыз магазин һәм берничә карсак пальма күренә. Якын-тирәдә җәймә зурлыгы да эшкәртелгән җир юк. Ирексездән, мондагы халык нәрсә ашап тора икән дигән уй килә башка.

Атауда яшәүчеләрнең нәрсә ашап торуларын боцман Марчук әйтеп бирде.

— Егетләр, карагыз әле, кораб янында нинди зур балыклар йөзә?— дип кычкырды ул.

Техник революция тәэсиреннән читтә калган балыклар, кешедән курыкмыйча, тыныч кына кораб тирәсендә йөзеп йөриләр иде. Аларны күрү белән диңгезчеләр каюталарына ташландылар. Минут эчендә экипаж коралланып өлгерде.

Зөбәер атавының тыныч култыгында яшәгән эре балыкларны диңгезчеләр палубага сөйрәп меңгерә башладылар. Балыклар шундый аңгыралар иде ки, кармак суга тию белән җимне эләктереп алалар да, икенче мизгелдә, кояшта ялтырап, палубага шапылдап төшәләр.

Кармакка өч төрле балык каба: эре скумбрия, шамбыдан юанрак таңкәсез балык һәм диңгез алабугасы.

Аучылык безнең канга сеңеп калган, күрәсең. Балык тоту егетләрне исертеп җибәрде. Алар тәмам кыздылар. Хәзергесе минутта балыкка мохтаҗлык бармы-юкмы, ул сиңа кирәкме-түгелме — бу турыда уйлап торырга вакыт та, теләк тә юк иде. Балык тоту — әсәрләнүгә, азартлы бер уенга әйләнде.

Диңгезчеләрнең кармакларын күзәтәм. Капитан кыйммәтле, матур әйбер ярата. Аның кармак таягы бамбуктан, мельхиор һәм җиз белән инкрустацияләп эшләнгән. Капитанның балык тоту рәвеше дә башкаларныкына охшамаган. Ул кармагын суга: «Балык, мин сиңа шушы кармакка килеп эләгергә боерык бирәм!»— дигән катгыйлык белән ыргыта. Менә ул, башын күтәреп, вахтада торучы штурманга кычкырды:

— Эхолот белән үлчә әле, тирәнлек ничә метр икән?

— Унҗиде метр,— диде штурман.

Капитан кармак җебен кыскартты һәм шөгылен дәвам итте. Аңа балыкның эресе, затлысы каба иде. Әллә җиденче кат күктә кешенең дәрәҗәсенә карап әйберне сайлап бирә торган фәрештә бармы икән?

Капитан янында матрос Корбут кайнаша. Аның да кармагы әйбәт.

Лэкин ул капитан шикелле ашыкмыйча, җайлап кына сала белми. Ашыга, кабалана, иптәшләренең кармагына балык капканга көнләшүдәнме, егетнең куллары калтырана. Һәм аңа балык та юньләп эләкми иде. Шушы гаделсезлекне Митрофан Степанович авыр кичерә.

— Кармагым гел капитанныкы шикелле. Җимем дә бер төсле. Аңа каба, миңа — юк. Гел шулай. Бәхетем юк минем. Кая соң гаделлек?

Һәм шундый кызганыч күренә матрос Корбут. Башкаларда булган әйбер аның үзендә булмаса, ул үлеп көнләшә, хасталана, төннәрен йоклый алмый газаплана. Корбут егерме биш ел диңгездә эшли. Унунбиш ел соң эшли башлаган яшьләр, сары томшыклар, инде әллә кайчан капитанлыкта. Ә ул — һаман матрос, һаман вахтада, һаман швартов бауларын сөйри, һаман кемгәдер буйсына. Корбут боцманлыкка да күтәрелә алмаган. Ә үзе эшне яхшы белә. Тырышлыгы да бар. Нигә аны күтәрмиләр, яратмыйлар соң? Сәбәбе шунда — аңа кешелеклелек, киң күңеллелек, юмартлык җитми. Бу турыда аның үзенә дә әйтә торалар — аңламый. Ул вахтада чакта башка диңгезчеләр шәһәргә чыгып китсә, көнләшүдән Корбутның бавыры сызларга тотына. Яшәү тәмен, аның рәхәтлеген тоя алмый яши, михнәт чигә ул.

Тагын бер кызык сыйфаты бар Митрофан Степановичның: мал исраф булуы аны үтереп газаплый. Бер тапкыр мин аның шырпы сызганын карап тордым. Сызды, ут кабызды. Шырпының бары тик күкерте генә янып өлгергән иде. Степанычның кулында сыңар шырпы — тиеннең илледән бер өлеше. Ул исән диярлек. Шуны ташларга кызганып, Корбут бик озак газапланып торды. Ташлады, һәм шундук аның кәефе кырылды. Ачуыннан төкерде. «Мал исраф була»,— дип уйлый иде ул шушы мизгелдә.

Корбут бер салган чәйне өч тапкыр кайнатып эчә. Җебе беткән кәтүкләрне дә ташламый җыя. Хуҗалыкта ул да кирәк була, янәсе. Мал бар. Акча җитәрлек. Ихтирам гына юк.

Моторист Николай Иванович Цуриков балык тотучылар тирәсендә таптанып йөри. Үзе туктаусыз сүгенә. Монысы кешедән шикләнүчән һәм кыйбласызрак бәндә. Көенә килгәндә үзе әйбәт кенә эшли дә, яши дә белә. Тик бер сәер ягы бар: тиктомалдан аның сәяси «уяулыгы» көчәеп китә. Шул чакта Николай Иванович «хакыйкать» өчен көрәшә башлый...

— Хосусый милек кортлары!— дип кычкырды ул, бераз таптанып йөргәч.— Кулаклар! Машина турында кайгырту юк. Балык тоталар, бирәннәр!..

— Шаулама, Николай Иванович, балыкларны куркытасың,— диде капитан Грязевский.— Я, кармак табып, безгә кушыл, яисә машина бүлегенә төшеп, иптәшләреңә ярдәм ит.

— Сез дә корсак коллары яклы икәнсез, Константин Николаевич,— диде моторист Цуриков үпкә белән.— Белми идем. Сез дә аларны яклыйсыз...

Цуриковның балык ашыйсы килә иде. Ул балык шулпасы ашарга чакырмаслар дип курка иде. Үзенең балык тоту әсбаплары булмаганлыктан, Николай Иванович шулай өркетеп берәрсеннән кармак алырга өметләнә иде.

Өркетү юлы белән Николай Ивановичның ничәмә-ничә мәртәбәләр үз теләгенә ирешкәне бар. Әмма бу юлы, ни сәбәптер, өркетүнең файдасы тимәде. Кармак бирмәделәр аңа. Тагын бер тын бәйләнеп йөргәч, Цуриков каядыр китеп югалды һәм бераздан, кулына кармак тотып, янә палубага чыкты. Ул кармагын ит элә торган ыргактан ясаган иде. Җеп урынына тимерчыбык куйган һәм аңа зур бер калҗа ит саплаган. Ниһаять, кармагын диңгезгә томырды. Көтә башлады.

— Николай Иванович, син кармагыңа җим итеп сыер боты куйган-

сың түгелме соң?— диде матрос Юрко.— Суда сөяк ашый торган балык юктыр бит?

— Бу тирәдә су бүреләре булуы мөмкин,— дип елмайды капитан.

Тимер чыбык кинәт тартылып куйды һәм балыкчыны сөйри башлады. Бәхетенә каршы, Николай Иванович кармак җебен релингка урап өлгергән иде.

— Нигә авызыгызны ачып, карап каттыгыз, ярдәм итегез! Балык мине диңгезгә сөйрәп төшерә ич!— дип разбой салып кычкырды моторист.

Диңгезчеләр ярдәмгә ташландылар. Тимерчыбыкны тиз генә чыгырга урадылар. Чыгыр хәрәкәткә килде. Койрыгын болгый-болгый судан зур бер акула килеп чыкты. Аны көч-хәл белән палубага тартып мендерделәр. Акула чәбәләнә, койрыгы белән палубага бәрә, кораб дер селкенеп тора иде.

Балыкчылар, эшләрен ташлап, акуланы әйләндереп алдылар. Балык тотуның кызыгы бетте. Дошман! «Сак булыгыз, дошман!»

Акула авызын киереп ачкан, һава йота. Күзләрендә — ачы нәфрәт. Ул сизә, шәфкать булмаячак. Инстинкт әйтеп тора: аның да каршында — дошман. Бирешмә!

Югалып калып, акуланың зәһәрләнеп чәбәләнүен күзәтеп торган диңгезчеләр кинәт, дәррәү урыннарыннан кубып, корылмага таба ташландылар. Икенче караганда алар акулага таба кире йөгереп киләләр иде инде. Кулларында пожар инвентаре: лом, балта, көрәк. Кораллар хәрәкәткә килде. Дөмбәсләү башланды...

— Бәр башына! Тондыр! — дип төкерекләрен чәчеп кычкырды Цуриков.— Үтер каһәр суккырыны! Сыт! Изеп ташла!

— Бәр!

— Үтер!

— Тапта!

Минут эчендә палуба канга батты. Акула башын палубага бәрә, чәбәләнә, тешләре белән брашпиль тимерен кимерә. Тешләре шытырдап сыналар. Мин чыдый алмадым:

— Туктагыз!— дип кычкырам, егетләрне як-якка этәреп ташлыйм. Колакларына да элмиләр. Баш юк хәзер аларда. Хисләр туңган. Шәфкать хисен үч агуы алыштырган. Күсәк, лом, үтмәс балта, лап-лоп, лап-лоп... Күз алдымда ерак тарих эчләрендә калган әллә нинди вәхшилекләр кабат гәүдәләнеп күренгәндәй булды. Түзмәдем, яннарыннан китеп, каютама кереп бикләндем, караватыма капландым да, тавышлары тынмасмы дип, башымны мендәр астына тыктым. Юк, кая ул!

— Туктагыз, тешен әрәм итәсез. Яңакларын кисеп алырга кирәк!— Монысы матрос Юрко тавышы.

— Давай кис! Умырып ал! Давай үзем кисәм.— Бусы моторист Цуриковның акыруы.

Үтмәс балтаның тонык, тупас тавышы акуланың тәненә аяусыз бәрелгәне ишетелә. Ниһаять, балтаның йөзе тимергә тиде. Кистеләр. Акуланың башы юк хәзер, ә үзе һаман тере: койрыгы лап-лоп палубаны кыйный. Диңгезчеләрнең кан баскан күзләре, күм-күмгәк булып каткан иреннәре күз алдыма килеп баса.

Машинаны төзәттеләр. Зыңгылдап якорь күтәрелгәне ишетелде. Винт әйләнә башлады. Кораб урыныннан кузгалды. Артыбыздан кильватер агымы калды. Җинаятьне винт астыннан кайнап чыккан су каплады. Палубага аккан канны юдылар.

Иллюминатор каршыннан бер төркем моряклар үтеп китте.

— Теше нинди үткен,— диде матрос Юрко.

— Ерткыч,— дип аңлатты Николай Иванович.— Моның тешенә эләксәң...

Хәзер алар үзләрен тыныч, әдәпле тоталар иде.
Бераздан мине балык шулпасы ашарга чакырдылар.
— Рәхмәт,— дидем мин.— Ашыйсым килми.
Күз алдымда башы киселгән акуланың чәбәләнүе кызыл шәүлә булып күренеп тора иде.

## Махаулылар

Диңгездә, сирәк кенә булса да, җилкәнле кораблар очрап куя. Башларын күккә таба сузган озын, төз мачталар. Аккош канатыдай ак, киеренке, барабан карындыгы тавышы чыгарып җуылдаган тыгыз җилкәннәр. Җил белән дәгъвалашып, зәңгәр дулкыннар өстеннән йөгереп баручан шундый кораб офык артыннан калкып чыгу белән, син үсмер чакның пакь татлы хыялларына әйләнеп кайтасың. Йөрәгең ашкынып тибә башлый. Күзләреңне зәңгәрсу томан пәрдәсе каплап китә.

Нигә кызыктыра икән ул җилкәнле кораб? Без бит югыйсә егерменче гасырның иң зур казанышы саналган яңа ролкерда йөзәбез. Кораб көчле, тиз йөрешле, аның эчендәге көнкүреш шартлары шундый әйбәт, шулкадәр уңайлы.

«Академик Арцимович» Баб-ел-Мәндәб бугазыннан чыгып килә. Алда — океан. «Баб-ел-Мәндәб» — гарәпчә «күз яше» дигән сүз. Сәер исем биргәннәр гарәпләр бу бугазга.

Күп гасырлар элек, әле Европада кораб йөртү гыйльмен белмәгән чакларда, бу төбәктә яшәүче гарәпләр җилкәнле кораб белән Мадагаскар атавына, Һиндстанга, хәтта Кытайга ук барып йөргәннәр. Һиндстан юлын ачучы португал диңгезчесе Васко да Гаманың корабында гарәп лоцманы булган. Кайбер галимнәр Колумб та үзенең мәшһүр сәяхәтенә чыкканга кадәр Америкага бару юлын гарәпләр картасы буенча чамалаган дигән фикердә торалар.

Шәрык культурасының кайчандыр көчле булуы, гарәпләрнең Урта гасыр казанышларына зур өлеш кертүләре турында Европа илләрендә искә алырга яратмыйлар. Кытайлылар уйлап чыгарган компасны, дарыны һәм кәгазьне Европага алып килүче һәм аларны кулланырга өйрәтүчеләр гарәп галимнәре булган. Антик чорның фәлсәфәсе һәм башка казанышлары белән Европаны иң башлап гарәпләр таныштырган.

Баб-ел-Мәндәб бугазыннан караңгы төшкәндә чыгып җиттек. Таңда офык читендә җилкәнле кораб күренде. Бинокльдән карыйм. Бу тирәдә еш очрый торган сыңар җилкәнле самбук. Моннан мең ел элек тә диңгез буенда яшәгән гарәпләр нәкъ шушындый көймәләргә утырып йөзгәннәр. Көймәнең буе — ун-унбиш, киңлеге дүрт-биш адым. Экипажы биш-алты кешедән тора. Чүлмәк белән су, сохари, кипкән хөрмә алып, меңәр чакрым океан юлына чыгып китәләр чалмалы матрослар. Безнең унбиш мең тонналы корабны йомычкадай очыртып йөрткән давыл аларны да кыйный, гигант дулкын, тау шикелле тәгәрәп килеп аларны да баш өсләреннән каплап китә. Мескеннәрнең язмышлары җил, давыл кулында. Нинди кодрәт бирә аларга шундый зур тәвәккәллекне? Шушындый кечкенә көймәгә утырып океанга чыккан батырларның күпмесе генә кире әйләнеп кайта икән? Гарәп диңгезчеләренең тол калган хатыннары, ятим балаларын ияртеп, шушы бугазның кыялы ярларына килә һәм күз яше түгә торган булганнар. Гасырлар буе күз яшенә сугарылган бугазны гарәпләр соңыннан әнә шулай «Күз яше» — Баб-ел-Мәндәб дип атаганнар да инде.

Без океанда — йөз миллион, миллиард еллар яшәгән булса да, бер тамчы да картаймаган илаһи киңлектә йөзеп барабыз. Маршрут — көньяк-көнчыгышка таба. Бер тәүлектән алда Сокотра атавы күренәчәк. Шунда җиткәч төньяк-көнчыгышка борылырга тиешбез. Борылган-

нан соң Минекәй исемле атауга якынлашасың. Анда проказа — махау авырулы кешеләрне сөрәләр. Мескеннәр, үлгәнче шунда яшиләр. Өйләнешәләр. Балалар үстерәләр. Билгеле, аларның да куанычлары юк түгелдер. Адәм баласы куанычсыз яши алмый. Кеше затының иң зур казанышы — нинди генә шартларда да куаныч таба белүдә. Махаулыларга Минекәйдән чыгарга рөхсәт ителми. Концлагерь шикелле атау бу. Җир йөзендә концлагерьга әйләнгән илләр дә бар. Андый илләрдән шулай ук читкә чыгарга рөхсәт ителми. Анда да махаулылар атавындагы шикелле бикле яшиләр.

Нигәдер ямансу бүген. Сәбәпсез ямансу. Күңелдә ниндидер рухи бушлык, эчке юксыну. «Нигә кирәк миңа бу затлы кораб? Диңгез гизү, туктаусыз бару-йөзү нигә кирәк?» — дип берәр авыл картына зарланасым килә. Умарталыкта эшләгән, көтү көткән, гомерен каравылда үткәргән татар картын очратып, шуның белән эчем бушаганчы сөйләшәсем килә.

Пассат алышынган вакыт. Су һәм бушлык. Океан тыныч. Ниндидер мәкерле, дәһшәтле тынлык. Су чүле нәрсәдер көтә шикелле. Күктә — галәмгә битараф, бары тик кайнарлык өчен генә янган тропик кояшы. Кояш бата. Тропикның юеш, караңгы төнен тишеп, салкын йолдызлар калкып чыга. Шушы йолдызлар, шушы кояш астында безнең гомеребез кими, кыскара. Гомер аяусыз кими — туктатырга бернинди чара юк. Без океаннар, диңгезләр аша туп-туры картлык көненә якынлашабыз.

Юлга чыкканга инде икенче атна китте. Семья да юк, рәхәтләнеп басып йөрергә каты җир дә юк. Ярый әле дуслар бар. Авыр эш башкаручылар арасында гына була торган чын дуслык бар. Илдә яңа вакыйгалар, үзгәрешләр туып тора, синең әйләнә-тирәңдә — фәкать су сахрасы. Бүген дә, иртәгә дә, киләсе айда да һаман бер үк су. Тәүлегенә өч мәртәбә ходовой рубкада штурман һәм рулевой матрос алышына. Тәүлегенә өч тапкыр машина бүлегендә механик һәм моторист алышына. Көненә өч тапкыр каютъ-компаниягә кереп ашап чыгасың. Кичке тугызынчы яртыда кызыл почмакта кинофильм башлана. Кинодан соң яшьрәк диңгезчеләр (моряклар телендә — «очистная команда»), камбузга кереп, калган ашамлыкларны «себереп» чыгалар. Сәгать төнге унбердә — отбой. Атналар, айлар, еллар буе, пенсиягә чыкканчы шулай.

Гарәпләрнең җилкәнле көймәләрендәге тормыш белән чагыштырганда без җәннәт шартларында яшибез. Радио туктаусыз хәбәрләр ташып тора. Көн саен кино. Телевизор эшли. Ярга якынрак йөзгәндә күп илләрнең телепрограммаларын карап барабыз. Теләгән чакта радиотелефон аша хатының, балаларыңның тавышын ишетә аласың. Ләкин нигәдер мондый әлемтә сине канәгатьләндерми. Радио китергән хәбәрләр — син югында, синең катнашыңнан тыш туганнар. Син читтә калгансың — гаиләң, дусларың, туганнарың синсез яшиләр... Менә шушы хакыйкать ачыттыра күңелне. Сагынудан, җирсенүдән дә көчлерәк ачыттыра.

Өч-дүрт ай сәяхәттә үткәч, шушы бертөрлелек, сак-соклык хисе сине гарык итә башлый. Гарык булу — сәбәпсез бер газап ул. Үзе кичермәгән, татымаган кеше аны аңлый да, аңлата да алмый. Сагыну газабын бәгыреңне туктаусыз черки талагандагы халәт белән чагыштырып булыр иде. Юк, алай да түгел. Бу турыда сөйләргә дә оят. Мәсәлән, сәяхәткә чыкканда синең яныңда утырган егет шундый сөйкемле, культуралы иде. Айлар буе аның белән бер ана баласыдай яшисең. Өч-дүрт айдан кинәт сизә башлыйсың: ул авызын чапылдатып ашый. Өстәвенә көн саен кичке чәй вакытында хатынының тәти күлмәге белән мактана. Хәләл җефетенең күлмәген ул шулкадәр югары куя ки, әйтерсең ул бөек кешеләргә бәхетле яшәү юлын күрсәткән. Мактануы бишенче айга

киткәч, башка чара калмый: муеныңа таш асып океанга чуму сиңа зур бәхет булыр кебек тоела башлый.

Каюткомпаниядә мин капитан белән радиостанция начальнигы арасында утырам. Радиостанция начальнигы да туктаусыз мактана. Хатынын мактый. Имеш ул матур, уңган, акыллы. Мин бу егетне яратыр, ихтирам итәр идем. Ул әйбәт кеше, югары квалификацияле радист. Туасы ихтирамымны аның мактануы үтереп тора.

Мактану йогышлы, ул грипп шикелле тиз тарала икән. Менә бүген дә каюткомпаниядә ашаучы командирлар пыр тузып хатыннарын мактарга керештеләр. Өлкән механикның хатыны гаҗәп тәмле итеп кыяр тозлый белә, янәсе. Икенче штурманның хатынының биле нечкә, Украинада анықыннан да нечкә бил юк, имеш. Дүртенче механикның хатыны Эдита Пьехага охшатып җырлый белә, докторның хәләл җефете искиткеч хәтерле икән. Иң даһи хатын капитанныкы булып чыкты: капитан хатыны җиңел машина йөртә, мәрмәр ташка охшаш токымлы дог тәрбияләп үстерә, җир йөзендәге барлык асыл ташларның исемнәрен белә икән.

Башкалардан калышмас өчен, мин дә хатынымның лаеклы сыйфатларын эзли башлаган идем, шул чак өлкән штурман минем сүземне бүлде:

— Минем хатын да төшеп калганнардан түгел, ләкин мин аны мактамыйм,— диде ул. — Хатыннар, мактамыйча да, муеныңа менеп атланырга торалар. Запорожьеда Әхмәт исемле бер нугай күршем яши иде. «Урта мактанчык атын мактар, чын мактанчык хатынын мактар. Атны үр менгәч, хатыныңны үлгәч макта»,— дип әйтә торган иде. Аның белән килешәм.

Без айныбрак киттек. Мактануга сабышу сагына башлау шаукымы иде. Безнең татарда да бар ул андый гадәт. Без үзебезне кешегә санауны, ихтирам итүне көткәнбез. Озак көтеп тә, ихтирамга ирешә алмагач, әкренләп мактанып, юаныргa өйрәнгәнбез.

Без мактану турында сөйләшеп утырган арада каюткомпания ишеге яныннан кемнәрдер йөгереп уздылар. Палубада кычкырган тавышлар ишетелде. Дәррәү кузгалып, палубага чыктык.

— Әнә, әнә, маңгае күренә,— дип, боцман океан киңлегенә төртеп күрсәтте.

Диңгезчеләр, муеннарын сузып, нәрсәдер күзәтәләр иде. Мин дә шул юнәлешкә карадым. Курстан уңдарак, бер көрән нәрсә диңгез өстен ертып, дулкын кузгатып бара. Кинәт һавага фонтан чөелде. Тыгыз су тасмасы утыз-кырык метрга күтәрелеп, кире диңгезгә коелып төште. Ниһаять, төшендек: кит балыгы йөзеп бара икән. Нindидер кодрәт белән аулаучылардан котылып, исән калган зәңгәр кит балыгы! Аларны ике гасыр аяусыз эзәрлекләделәр. Бәлки бу исән калган бердәнбер экземплярыдыр аларның? Зәңгәр кит — җир йөзендә иң зур, иң көчле хайван.

Кит һава йотканчы су өстендә йөзеп барды да тирәнгә чумды. Берәздән диңгез өстендә тагын бер фонтан күренде. Бусы ким дигәндә биш-алты миль ераклыкта иде инде. Өченче фонтанны күрергә насыйп булмады безгә: кит күздән югалды.

Каюткомпаниягә кире кереп, чәй эчә башлаганда, күршемнең лачлоч чәйнәве алай нервага тими иде инде. Рәхмәт сиңа, кит балыгы! Син безгә нindидер рухи юаныч калдырып киттең. Кит аулау флотилиясенең гарпунлы тупларыннан котыла алуңа горурланам мин. Яшәргә, нәселеңне сакларга тырыш! Син табигатьнең «Кызыл китабы»на кертелгәнсең. Закон буенча сиңа тимәскә тиешләр. Әмма син кешеләр чыгарган законнарга бик үк ышанып бетмә. Алар үзара сугышмау, атом, водород бомбасын кулланмау, корал санын арттырмау турында күпме закон чыгарып, ничә тонна кәгазь исраф иттеләр. Ә сугыш һаман ка-

бына тора. Сез генә бетмисез, җир йөзендә кырылып бетеп, токымнары юкка чыккан халыклар, милләтләр дә бар. Америка җирендә яшәгән индеецлар, австралия аборигеннары, Канар атауларында матур, күркәм табигатьле гуанчылар, тагын... Юк, санап тормыйк, кирәкми. Җир йөзендә башка халыкларны буйсындырып торучы империалистик дәүләтләр бар чагында, алар кулы астында буйсынып яшәүче халыкларның язмышлары кит балыкларыныкы шикелле.



## Пәйгамбәрләр җире

Климатор әйбәт эшли. Ходовой рубкада егерме дүрт градус. Рәхәт. Рубканың ишеген ачып, күперчеккә атлыйм. Кайнар һава битемә бәрелә, тын юлын көйдереп ала. Кояш баткан чак. Кояшның диңгезгә керә башлаганын көтеп торып, гирокомпасның күрсәтүен дөреслим дә тизрәк рубкага чумам. Һава торышы әйбәт. Каршы килүче кораблар сирәк очрый. Су тирән. Якын-тирәдә су асты кыялары, рифлар юк. Тыныч, рәхәт йөзүдән файдаланып калырга кирәк. «Кызыл диңгез һәм Аден култыгы лоция»сенең 417 битен ачып укырга керешәм:

«Гарәп диңгезенең төньяк-көнбатыш ярларында үсемлек аз очрый. Кайнар һава, чүлдән искән көчле коры җил үсемлекләрне көйдереп, юкка чыгарып тора. Хәтта монда вак куаклыклар, карсак хөрмә агачлары да сирәк үсә. Су буенда тамырлары җир өстендә яткан мангр агачлары очравы мөмкин. Мангр агачы астында җир кипсә, ул үзеннән-үзе хәрәкәткә килеп, су кырындагы дымлы җиргә күчеп утыра. Мангр шундый гаҗәп агач.

Шушындый шәрә, шыксыз җирдә Җәбел-әл-Самхан тавын каплаган мәһабәт наратлар һәм шул агачлар арасында үскән куе үләнлек — табигатьтә сирәк очрый торган бер могҗиза...»

Чыннан да табигатьнең могҗизалы урыннары була. Лоциягә язган сүзләр журналист булып эшләгәндә күргән бер төбәкне искә төшерде. «Наука и религия» журналына бер хат килгән иде ул чакта. «Әндиҗан өлкәсендә Балыклы исемле бер чишмә бар. Шунда диңгә ышанучылар гыйбадәт кылырга җыелалар. Чишмә янына сырхаулар килә. Райбашкарма комитеты бу җинаятькә бармак аша карый. Чара күрегез, Балыклы чишмәсе янындагы дини пропаганданы туктатыгыз», — дип язганнар иде шунда яшәүче дәһриләр. Хатны кесәмә салып, Урта Азиягә очтым.

Август ае иде. Азиягә хас континенталь коры кайнарлык. Машина көпчәге асфальтка ябыша, әйләнгәндә, көпчәк табада кызган сызык тавышы чыгарып чыжлый. Яланнар өстеннән, күзгә күренеп, күкшел рәшә дулкыны ага. Озак карап торганда, кайнар һава агымы барлыкка килүен һәм өскә күтәрелеп эрүен күреп аласың.

Шофер газны киметте дә, асфальттан чыгып, арба юлына керде. Алда шаулап үсеп утырган оазис күренде. Колакка кошлар сайраган тавыш килеп бәрелде. Оазисның салкынча, хуш ис аңкытып торган, шифалы һавасы тын юлларын ачып җибәрде. Меңәр яшьлек чинар агачлары, җылы як наратлары, карагачлар, артыш куаклары көр һәм иркен сулыш алып үсеп утыралар. Мин күзәтеп килдем: бу төбәктә яфраклары самолеттан сипкән агу белән көйдерелгән мамык сабакларыннан тыш агач заты күренми иде. Нинди кодрәтле көч үстергән бу агачларны?

Оазис уртасындагы чокыр төбеннән чылтырап чишмә чыгып ята. Мул, чиста сулы бай чыганак. Иелеп чишмә суына карагач, тагын хәйран калдым: су төбе эреле-ваклы балык көтүеннән мыж килә иде. Шофер чишмәгә учлап бодай сибә башлады. Балыклар судан атылып

чыгып, шоферның кулына сикерәләр. Алар кешедән курыкмыйлар иде. Теләсәң, кулыңны тык та, койрыкларыннан эләктереп ал.

Командировкамның максаты — бу урынга гыйбадәт кылуны туктатырга, Балыклы оазисның «изге» түгел икәнлеген, андагы балыкларның җәннәттән чыкмавын фаш итеп мәкалә язу иде. Муллалар һәм ишаннар, шушындагы агачны киссәң, кулың корый, чишмәдәге балыкны ашасаң агуланып үләсең дип, кара халыкны шушы көнгә кадәр ышандырып киләләр икән. Минем вазифам — шушы ышануны юкка чыгару иде.

Мин кире Әндиҗанга кайтып, Балыклы оазисына врачлар һәм химик анализ ясый белгән галимнәр алып килдем. Мондагы һавага химик анализ ясадылар, чишмә суын тикшерделәр. Балыклы оазисының һавасында үпкә авыруына, тын бетүгә (астма, сердечная недостаточность) каршы шифалы фетонцидлар күп, чишмә суы ашказанына файдалы минерал тозларга бай дигән нәтиҗә чыгардылар галимнәр.

Дин әһелләре табигатьнең гүзәл серләреннән оста файдалана белгәннәр. Бу турыда күп язылды. Мин дингә әллә ни әһәмият бирмичә яшәгән гади авыл картларының зирәклекләренә сокланам. Алар агачларның «изге» икәнлеген инкяр итәргә ашыкмаганнар. Оазистагы мәһабәт карагачларның гади агач икәнлеген фаш итү белән, аларны әллә кайчан кисеп бетергән булырлар иде. Балыклы чишмәсендә үрчегән балыклар да күптән кырылып беткән булыр иде. Балык андагы бөҗәкләрне ашап чишмә суын чистарта. Балык — чишмәне, чишмә — тирәякта үскән агачларны, агачлар исә — якын-тирәдәге кешеләрнең сәламәтлеген саклый. Авыл картлары, шуны аңлаганга күрә, Балыклы оазисын «изге» дип игълан иткәннәр.

Балыклы оазисында чылтырап чишмә акканын, кошлар сайраганын тыңлап утырганда күңелемне бер кызык сорау тырнап үтте: элекке заманда әллә ышану шулай көчле булдымы икән? Бәлки, ышанырга остарак өйрәтә белгәннәрдер?

Бу дөньяда ышанусыз яшәп булмый. Әхлак кануннарын саклап яшәү ышануны инануга әйләндерә. Яхшылык эшләргә омтылышы көндәлек рухи ихтыяҗга әйләнгән кешене без иманлы дип атыйбыз. Бернәрсәгә дә ышанмаган, бернәрсәгә дә ихтирамы булмаган кеше теләсә нинди изге кануннарны да таптап, җимереп йөрергә сәләтле. Андый кеше агачларны сындырып, чишмәләрне пычрату белән генә чикләнми, әхлак кануннарын да вата, җимерә. Без әхлак кануннарын үзләштерү юлында гына Кеше дигән бөек исемгә ирешә алабыз.

Лоция китабын укуны дәвам итәм:

«...Бу урында егерме метрлы изобата[1] яр кырыена ук килеп җитә. Дингезчеләр өчен иң куркыныч урыннар Куриа-Муриа һәм Масира атаулары тирәсе. Гарәп дингезенең төньяк-көнбатышында май аеннан алып сентябрьгә кадәр еш кына ком бураннары кузгалып китә. Кай чакта кискен көчле җил комлы яңгыр алып килә. Күктән коелган эре пычрак тамчылар, горизонтны томалап, диңгездә йөзүне куркыныч әфәткә әйләндерә. Ноябрь-декабрь айларында Гарәп дингезенең шушы өлешендә көчле дулкын кузгатучы төньяк-көнчыгыш җиле исә. Декабрьдан мартка кадәр яр ягыннан искән белаат җиленнән сак булырга кирәк. Белаат җиле гаҗәп мәкерле...»

Лоциянең матур йөгерек теленә Константин Паустовский сокланып туя алмаган. Бу китапны әз генә сүзгә зур, тирән эчтәлек сыйдыра белүчеләр язган. Лоция төзүчеләрнең культуралы, укымышлы кеше булулары күзгә бәрелеп тора. Бу китапны унтугызынчы гасыр азагында хезмәт иткән диңгезче офицерлар язган.

Җәбел-әл-Самхан траверсын узгач, рубкадан төштем дә политза-

[1] Бертигез сайлыктагы урыннар

нятиегә әзерләнә башладым. Ленинның «Дәүләт һәм революция» дигән әше буенча семинар булырга тиеш иде. Мин Владимир Ильичның шушы әсәр өстендә эшләгәндә язган хатларын укырга керештем һәм, туктала алмыйча, кичке ашка кадәр укыдым. Хатлардагы тел лоцияне-кеннән дә матур, тыгыз, камил иде. Бер генә дә артык, урынсыз кулланылган сүз юк. Тәгаллек, зур тирән мәгънә сыйдырган кыскалык. Бигрәк тә Ленинның әнисенә язган хатлары сокландырды. Хатлардагы һәр сүз ихтирамга сугарылган чын ярату, әдәп, кешелеклелек белән яктыртылган иде. Россия самодержавиесе чынбарлыгында, исправниклар, жандармнар идарә иткәндә, һәр кешедән солдат ясау максаты белән оештырылган чынбарлыкта менә шушындый кеше тәрбияләнгән.

Политзанятиедән соң кичке сигездә чәйне эчтек. Кызыл почмакта кинофильм әзерли башладылар. Диңгездә һәр кичне экипаж кино карый. Елына өч йөз алтмыш биш фильм карагач, экранга чыккан кинофильмнарның нинди икәнлекләрен аңлый башлыйсың. Шуннан соң кино карау бер газаплы тамашага әверелә. Мин һава суларга палубага чыктым.

Океанда муссон җиле алышынган чак. Кышкы көньяк-көнбатыш муссоны тукталган, төньяк-көнбатыштан исәргә тиешле җәйге муссон әле кузгалмаган. Һава хәрәкәтсез тора. Атмосфера электр зарядлары белән сугарылган. Һавадагы электр кырының чиктән тыш көчле булуын бөтен хәләтең белән сизәсең. Тәндә хәлсезлек. Баш авырта. Болытсыз, аяз төннең тыныч һавасында капыл гына яшен ялтырап куя. Күңелдә шом. Эч нәрсәдер сизә шикелле. Тынгысызлык күзәнәкләргә таралган.

Каютага кереп, йокларга ятам.

Төнге икеләр тирәсендә кинәт уянып киттем. Двигатель туктаган — шуңа уянганмын икән. Хәрәкәтсез калган теплоходның кабыргасына гөжләп дулкын бәрелә. Сикереп тордым, ашыгып күперчеккә күтәрелдем. Төнге вахтада икенче штурман тора иде. Икенче штурман Крумм белән матрос Юрко тыныч кына кофе чөмереп утыралар. Йөзләрендә гамьсезлек. Мине күрү белән, матрос Юрко буш чынаякка кофе агызырга кереште.

— Миргазиян Закирович, Басрада дөя йоны табып буламы икән? — дип сорады ул.

— Нигә туктаттылар двигательне? — дидем мин сүгенеп җибәрүдән көчкә генә тыелып.

— Гребной валның подшипниклары кызды, механиклар суыту системасын көйлиләр,— диде Крумм.

— Хатынымның дөя йоныннан бәйләгән кофта киеп йөрисе килә иде, Басрадан соң Күвәйт портына керербезме икән, Миргазиян Закирович? — дип кабат сорады Юрко.

Бу юлы мин әдәп саклап тормадым инде. Диңгез бүреләре чорлар дәвамында эшкәрткән «тозлы» сүзләр Юрко маңгаена барып бәрелде.

Двигательнең туктавы механикларны йокыдан уятты. Алар бишектә имчәк баласы булган ана йокысы белән йоклыйлар. Двигательнең әйләнүе үзгәрү белән алар сикереп торып, машина бүлегенә төшәләр.

Рубкага кереп, картага күз салдым: курстан уңдарак, төгәл дүрт миль читтә Куриа-Муриа атавы җәйрәп ята иде.

— Дрейфне хисаплап чыгардыңмы? — дидем Круммга.

— Сәгатенә дүрт миль ярым.

— Юнәлеше?

— Бераз атауга таба алып бара.

— Штурманнар телендә «бераз»сүзе юк. Ничә градус?

Агым һәм җил безне туп-туры төньяк-көнбатышка атауның таш кыяларына таба алып бара иде.

— Ничә минуттан двигательне җибәрәсез? — дип сорадым машина бүлегеннән.

— Ярты сәгать чамасы вакыт кирәк булачак,— диде өлкән механик.

— Ярты сәгатьтән безгә берни кирәк булмаячак. Ярты сәгатьтән без утрау ярындагы кыялар астында ыштырларыбызны киптерә башлаячакбыз,— дидем мин.

Уникe минуттан двигатель яңадан эшли башлады. Корабка җан керде. Шундый куанычлы мизгел ул корабның җанланып китүе. Бала-чага шикелле, кул чабып чырылдыйсы, шатланып көләсе килә мондый чакларда. Шушы куанычлар аша: «Безнең яшәү күбрәк кыл өстендә тора. Двигатель кабынмаса, нишләр идек икән?» — дигән шөбһәле уй килеп китә.

Диңгез эшендә бу турыда уйламаска әһәмият бирмәскә өйрәнәсең.

Безнең корабны унсигез мең ат көче алга сөйри. Утыз диңгезчегә шул унсигез мең атны ышанып тапшырганнар. Экипажның һәр әгъзасы алты йөз атка атланган. Безнең кулда искиткеч зур кодрәт. Ләкин шушы көч, кодрәт белән артык масаерга ярамый. Техниканың бер уңайсыз ягы шунда: ул синең ихтыяҗларыңны аңламый, иң вакытсыз чакта туктый да синең ялынуыңа, күз яше түгеп ялваруыңа колагын да салмый. Тимер җанлы, кансыз, аяусыз ул машина.

Каютама төшкәндә, кораб өстендә бер яшькелт ут кабынып сүнгәнен күреп алдым. Туктап, бер тын карап тордым. Мачта очларын, антенна чыбыгын, флаг күтәрү өчен куелган гафельны яшькелт чаткылар чорнап алган иде. Алар, кабына-сүнә, бер тын биеп тордылар. Аннан корабны тагын караңгылык чорнап алды. Әйтерсең, күктән аждаһа төшкән дә, авызыннан утлы ялкын өреп, мачталарда үрмәләп йөри. Нәрсә бу? Йөрәкне шом кысып тотты.

Кичә кич кинодан соң кызыл почмакта бик озак диңгездә очрый торган төрле гаҗәп хәлләр турында сөйләшеп утырган идек. Кайчакларда ачык океанда баручы корабның экипажы юкка чыга. Җил юк, дулкын кузгалмаган, тирә-якта тынычлык. Корабның бар җире төзек. Ягулык, азык-төлек, эчә торган су — барысы җитәрлек. Кораб сызылган маршруты буенча юлын дәвам иттерә. Тик эчендә генә беркем юк. Өстәлдәге аш-сулар суынып җитмәгән, судовой журналдагы язманың карасы да кибеп өлгермәгән, ә пароходта җан иясе калмаган. Кайда кешеләр?..

Диңгезчелек тарихында мондый сәер хәлләр шактый еш булган, күрәсең. Кайбер куркыныч легендалар шушы фикерне дәлиллиләр: «кораб-пәри», «очып йөрүче голландлы», «гигант диңгез еланы», «үч эзләүче диңгез өрәге». Шушындый куркыныч, шомлы ышанулар бүгенге көнгә кадәр яши диңгезчеләр арасында.

Бу хәлне фән бары тик соңгы елларда гына ачыклый, аңлата алды: тайфун кузгалыр алдыннан диңгез өстеннән инфратавыш дулкыннары үтә икән. Шул тавыш дулкыннары зонасына эләккән кешенең йөрәк тибүе дулкын белән резонанска кереп, чиксез көчәя, кан тамырларын чатнатырлык хәлгә җитә икән. Куркудан, шушы газапка түзә алмыйча, диңгезчеләр суга сикерә торган булганнардыр дип аңлата фән корабның экипажсыз калуын. Бәлки аның сәбәбе башкадыр? Шушындый афәттән исән калып, башкаларга үз авызы белән сөйләгән кеше юк бит әле.

Мачталар очында биегән яшел чаткыларны күргәч, мин шушы турыда уйлап куйдым. Безнең пароход өстендә «изге эльм» утлары уйный иде. Тропик һавасы электр кырына чиктән тыш мул сугарылган чакта барлыкка килә торган утлар.

«Юлны хәрәкәт буйсындыра» ди шәрык мәкале. Инде менә ярты ай көне-төне, җил-яңгырга карамыйча, ял, бәйрәм көннәре белән исәпләшмәстән, туктаусыз барабыз да барабыз. Көне-төне винт әйләнә. Үнсигез мең ат җиккән гигант тимер көймә һаман алга ашкына. Инде Мисыр, Судан, Согуд Гарәбстаны, Хәбәшстан, Сомали, Йәмән, Оман, Маскат, Катар, Кувәйт, Иран ярлары, йөгереп, яныбыздан үтеп китте. Алар офык артына кереп югалдылар. Без юлыбызны дәвам итәбез. Кыяларны, су асты рифләрен урап узабыз, ярлардан ераграк торырга тырышабыз. Әлегә юнәлешебез дөрес, юлны һавадагы йолдызларга карап беләбез. Ярлар ачылган чакта, андагы маякларга карап, маршрутны дөресләп алабыз. Радио дулкыннары бездән меңәр чакрым ераклыкта урнашкан радиомаякларның позывнойларын китерә, шушы дулкыннар ярдәме белән барасы юнәлешне ачыклыйбыз.

Без юлда. Күңелгә Экклезиаста язылган бер гыйбрәтле фикер килеп төшә:

«Ыруг китә һәм ыруг килә, ә Җир мәңге яшәвен дәвам итә. Кояш калка һәм кояш бата, һәм ул үзенең калыккан җиренә ашыга. Көньякка таба искән җил төньякка борыла, әйләнә-әйләнә дә үзенең хәрәкәтендә кире әүвәлге юлына кайта. Барча елгалар диңгезләргә коялар, ә диңгез, тулып, ярларыннан ташып чыкмый. Урыннарына, ага башлаган җирләренә кире әйләнеп кайтыр өчен, мәңгелек хәрәкәтләрен дәвам итәләр барча дәрьялар...»

Без сәяхәткә чыкканда, җирдә кар ята иде, хәзер безнең өстебезгә кайнар тамчылы яңгырлар ява. Күп диңгезләр аша, артыбыздан очып, безне акчарлаклар озатып калды. Берничә мәртәбә кит балыгын, океан өстендә адашып очкан мәһабәт альбатросны очраттык. Экваторның тегә ягында, кырыгынчы параллельләрдә гомер итүче бу гигант кош — горур альбатрос ничек безнең юлга килеп чыкты икән? Бәлки, ул адашкандыр? Я булмаса, туган иленнән куылгандыр?

Альбатрос гомерен туктаусыз хәрәкәттә, очышта уздыра. Даими искән көнбатыш пассат җилләре агымына ияреп, ул ел тәүлегендә җир шарын әйләнеп чыга. Атлантик океандагы Көньяк Каролина атавына җиткәч, алар, туктап, йомырка салалар һәм бала чыгаралар. Балалары очарга өйрәнгәч, альбатрос тагын һавага күтәрелә һәм, океан киңлеген кочып, юлын дәвам иттерә. Үлгәнче шулай.

Менә шундый гаҗәп кош ул диңгез альбатросы. Ул — ирек һәм биеклек каһарманы. Альбатрос очмыйча яши алмый. Аны читлеккә ябып бикләп куйсаң ничек кенә тәрбияләп тотма — ирекне сагынуга түзә алмыйча ул сулып үлә. Ирек һәм киңлек кирәк аңа. Давыл кошы альбатроска: «Сиңа ике мөмкинлекнең берсен сайларга рөхсәт итәбез: я буйсынып яшә, яисә үл»,— дисәләр, ул бер мизгел дә икеләнеп тормыйча, үлемне сайлар иде. Адәми зат өчен нинди гыйбрәтле үрнәк!

Сокотра атавы янында очраган альбатросны без көне буе күзәтеп бардык. Ул, ике метрдан арткан җәенке канатлары белән киңлекне кочаклап, бер генә каурыен да кыймылдатмыйча, сәгатьләр буе зәңгәр күктә асылынып торды. Караңгы төшәр вакыт җиткәч, альбатрос башын як-якка боргалап, нәрсәдер күзәтә, эзли башлады. Ара-тирә моңлы итеп кычкырып ала, кемнедер чакыра. Ул кинәт өскә күтәрелде, артка таба борылды һәм мизгел эчендә офык эченә кереп юкка чыкты.

Мең тугыз йөз алтмыш җиденче елны бер инглиз корабының өлкән штурманы Австралиядән Плимутка кайтканда һавада очып барган альбатросны атып үтергән. Портка кайту белән, экипаж корабны ташлап киткән. Капитан яңа команда яллап караган. Шушы кораб кешесенең альбатрос үтерүен ишетү белән, яңа ялланган диңгезчеләр дә бу паро-

ходта эшләүдән баш тартканнар. Өч ай экипаж яллый алмыйча портта эшсез торганнан соң, капитан корабның исемен алыштырып караган — файдасы тимәгән. Ахырда кораб хуҗасы пароходны арзан хакка сатып җибәрергә мәҗбүр булган.

Дөньяда шушы кош шикелле ирек һәм киңлек өчен генә яшисе иде! Һәм альбатрос шикелле гомер буе горурлык саклый беләсе иде!

Уналтынчы көндә, ниһаять, суның төсе үзгәрә башлады. Моңа кадәр безнең корабны саф зәңгәрлек чорнап алган иде. Бүген су тоныкланган, көрәнсу-соргылт төскә кергән. Кильватер агымы кар катнаш яшел ахакка охшап бөтерелеп кайнамый инде. Аңлап алдым: без Фарсы култыгының елга суы тупланган җиренә якынлашып киләбез. Иртәнге чәй вакытында чират көтеп торучы кораблар күренде. Шулар янына килеп, уңайрак урын сайладык та якорь салдык.

Чират көтүче пароходлар арасында сыек ягулык — нефть ташыр өчен көйләнгән танкерлар күп иде. Япониягә, Америка материгына, Европага нефть ташучы йөз илле — өчәр йөз мең тонна сыешлы супергигант танкерлар. Алар Сүәеш каналы ябылып торган чорда барлыкка килделәр.

Әнә тышкы рейдка танкерлар туктый торган җиргә, трубопровод үткәреп, швартов баулары беркетергә махсус мичкәләр куйганнар. Шунда берничә танкер Ирак җиренең, борынгы Месопотамиянең майлы канын суыралар. Ун-унбиш сәгать үтүгә, танкер — тагын юлда. Ул Европа материгына әйләнеп кайтуга, аның соңгы мәртәбә калдырып киткән йөз мең тонна ягулыгын миллионлаган җиңел машиналар эчеп, төтенгә әйләндереп бетергән булалар. Җирнең мае һаман суырыла, һаман яндырыла. Елдан-ел җир карынындагы нефть хәзинәсе кими, һәм нефтькә ихтыяҗ елдан-ел арта тора.

Фарсы култыгының Фау исемле тышкы рейдына Басрага, Умм-Каср, Иранның Абадан портына юл тотучы кораблар туктый. Алар портка керү өчен лоцман көтәләр. Безгә янәшә Ирак флагы астында йөзүче «Румәйлә» исемле танкер тора иде, шул корабтан суга шлюпка төшерә башладылар. «Ярга чыгарга исәпләделәр булса кирәк»,— дип күзәтеп тора идек, шлюпка безнең якка борылды. Ниһаять, ул безнең янга килеп туктады. Өч диңгезче палубага күтәрелде:

— Кайсы порттан килдегез? Диңгезгә чыкканыгызга күптәнме? — дип сорады диңгезчеләрнең берсе рус телендә.

— Одессадан. Моннан уналты тәүлек элек чыккан идек,— диде вахтада торучы матрос.

Диңгезченең берсе капитанның беренче ярдәмчесен сорады. Мин аны үз каютама алып кердем. Минем коллегам иде бу. Сөйләшеп киттек.

— Нишләп йөрисез сез чит ил корабында?

— Гарәпләрне диңгезчелек эшенә өйрәтәбез,— диде минем коллегам.

— Авырмы эше?

— Фарсы култыгыннан Европага нефть ташыйбыз. Туган илне күрмәгәнгә инде тугыз ай. — Беренче ярдәмче сагынуын басар өчен мин салган аракыны каплап куйды. — Корабта ике экипаж, тыгын. Һәр диңгезче үз һөнәренә гарәп диңгезчесен өйрәтә. Тагын берничә айдан, эшне аларга тапшырып, туган илгә кайтып китәргә җыенабыз.

Сөйләшә торгач, уртак танышларыбыз булуын да ачыкладык. Илленче елларда Кара диңгез пароходчылыгында, Одессада мин дә танкерларда эшләгән идем. 1965 елны Кара диңгез пароходчылыгын бүлгәләп, Азов диңгезе, Новороссийск һәм Грузия пароходчылыкларын оештырдылар.

Диңгез министрлыгында эшләгәндә «Румәйлә» дә эшләүче экипаж-

ны Гыйракка җибәрү турында ГКЭС[1] белән үзем сөйләшеп йөрдем ләбаса. Ул чакта язмыш «Румәйлә» экипажы белән фарсы култыгында очраштырыр дисәләр, ышанмас идем. Әңгәмәнең азагында ачыкланды: 1955 елда «Кремль» исемле танкерда бергә эшләгәнбез икән. Саубуллаша башлагач, тагын сорау бирәм:

— Чит ил корабында эшләүнең нинди үзенчәлекле яклары бар?

— Бездәге шикелле бергәләп, күмәк яшәү юк. Һәркем, йомран шикелле, үз каютасына бикләнеп яши. Җыелыш дигән нәрсә ярты елга бер генә була. Чит ил корабында эшләүнең уңай ягы да бар: анда бернинди отчет язу юк. Безнең корабларда йөзгәндә рейс азагында бер кочак отчет язып тапшырырга кирәк бит. Анда ул юк.

Коллегамны озаткач, мин чыннан да отчет язарга утырдым. Безнең корабта биш язу машинкасы. Сәяхәттән әйләнеп кайтып, портка керер алдыннан ашыгып отчет кәгазьләрен суктыртканда шрифтлар ут кебек кыза.

Төнне тышкы рейдта үткәрдек. Таң атып, яктыргач, «Академик Арцимович» янына лоцман көймәсе килеп туктады. Якорь күтәрдек. Кузгалып киттек. Алда иксез-чиксез ком сахрасы. Аны су сахрасыннан тәбәнәк ярлар гына аерып тора. Ярга якынлашкан саен, суның төсе үзгәрә, күренлек куера. Ниһаять, без ярлары офыкта югалган киң елга тамагына керә башладык.

Шатт-эл-Гарәб дәрьясы иде бу. Тигр белән Евфрат бергә кушылганнан соң барлыкка килгән елга тамагы. Шатт-эл-Гарәб елгасы Фарсы култыгына ләм ташый. Ярлар елдан-ел диңгезгә таба үсә торалар.

Бу елга Месопотамияне башка илләр белән тоташтырып торучы үзәк магистраль. Елга өстендә хисапсыз күп җилкәнле көймәләр, моторлы катерлар, баржалар, саллар кайнаша. Алар ашыгалар, үзара куышып бер-берсен узарга тырышалар, көймәләрнең кайберләре кораб астына ук керә язып кала. Монда яшәүче гарәпләрнең күбесе көймәдә туып үсә, елгада йөреп, гомер уздыра, ишкәген кулыннан ычкындырмыйча, картаеп үлә. Аларның тамакларын елга туйдыра. Балык тоталар, йөк ташыйлар, агым китергән такта кыйпылчыкларын, буш әрҗәләрне, шешәләрне җыеп, шуны сатып көн күрәләр.

Өскәрәк күтәрелгән саен, ярлар бер-берсенә таба кысыла төшә. Хәзер без ике як ярны да күреп барабыз. Уң якта — саманнан салынган тәбәнәк йортлар. Бинокльдән карыйм. Саман йортның нигезендә аунап яткан пальма агачы кәүсәсендә өч хатын-кыз кояшта кызынып утыра. Берсе карт, кибеп, мумиягә әйләнеп беткән. Куллары агач тамырын хәтерләтә. Бите, беркәнчеге, астына җәйгән җәймәсе — барысы да иске, тирә-юньдәге комнар, шушы елга, йорт нигезендәге пальма кәүсәсе шикелле үк борынгы. Елмаюына кадәр борынгы елмаю. Үлә алмыйча, әкрен генә пыскып, гомер кичерүче мондый карчыклар шәрык җирендә еш очрыйлар. Алар инде үзләренең күпме яшьтә икәнлекләрен дә онытканнар. Дөньяга бернинди дәгъвалары калмаган аларның. Тамак ягын кайгыртудан туктаганнар, эссегә-салкынга да әһәмият бирмиләр. Вакыт агымыннан төшеп калган әкияти пәриләрне хәтерләтәләр алар. Җеннәр, пәриләр, албастылар турындагы әкиятләрнең тууына бәлки менә шушындый карчыклар сәбәп булгандыр?

Янәшәдә утырган икенче хатын утызлар тирәсендә. Зифа буйлы, өстендә кара ефәк тукымадан теккән озын күлмәк. «Теккән» дип ялгыш әйтәм. Гарәп хатыннары тоташ бер тукыманы күлмәк итеп тә, бөркәнчек итеп тә — кыскасы, теләсә нинди формадагы кием итеп тәннәренә урый беләләр. Шул тоташ тукыма аларга эшләгәндә — хәрәкәтләнергә, урамда йөргәндә — ят күздән йөзләрен, сыннарын яшерергә, салкын-

[1] ГКЭС — Государственный комитет по внешним экономическим связям. (Тышкы экономик элемтәләр буенча дәүләт комитеты).

да — тәннең җылылыгын сакларга, эссе чакта җиләсләндерергә ярдәм итә.

Өченчесе — яшь, безнеңчә, үсмер кыз. Безнеңчә үсмер, ә мондагы гадәтләр үлчәве белән — кияүгә бирерлек җиткән кыз. Өченчесенең дә битләре бөркәнчек астында, тик күз турылары гына ачык. Елгага карап утыралар. Күз карашлары утыру рәвешләре шундый сабыр, түзем, аларның беркая ашыгасы, кетәсе, бернәрсәгә катнашасы юк шикелле. Хатын-кызларның шушы сабыр кыяфәтләре күңелдә мәңгелек хисе уята иде. Гүя, алар Наву-ходоносор, Һарун әр Рәшид, Бөек Моголлар чорыннан бирле шушылай йортка аркаларын терәп, шушы пальма кәүсәсе өстендә кымшанмыйча утыралар. Елга да бит шул чорлардан бирле туктамыйча тын гына ага бирә. Аерым шәхес язмышы, токым, ыруглар, халыклар язмышы мәңгелек күзлегеннән караганда нәкъ шушы елганың агымы шикелле түгелмени?

Мин саман йорт янында утыручы хатыннарның гамьсез халәтенә кызыгып куям. Алар ярым ач, ярым ялангач. Кытлыкта яшәү — бәхәсләшмим — зур михнәт. Мин моны аңлыйм һәм, шуңа карамастан, хатыннарның көннәр буе бернинди ваемсыз килеш елгага каршы утыруларына ихлас кызыгам. Җир йөзендә тук яшәр өчен вакытларын кырып-себереп уптым сатучылар бар. Акчаны күбрәк алу өчен иманнарын, хәтта ирекләрен өстәп бирүчеләр дә бар бу дөньяда...

Без тук, безнең өстебез бөтен, әмма без, шушы хатыннар шикелле, көннәр буе гамьсез, тигез сабырлык белән елга агымына карап утыра алмыйбыз. Кыбырсыну — безнең каныбызда.

Өскә күтәрелгән саен пальма агачлары күбәя бара. Сулда, елганың уң як ярында, тоташ пальма урманы башланды.

Пальма кәүсәсендә утыручы хатыннар күздән югалгач, тагын бер мәртәбә исәпләп куйдым: ярлы яшиләр, әмма алар бай — вакытка бай кешеләр. Ә вакыт — гомер, гомер — без үзебез. Әллә нинди зиһен җитмәслек парадокс бу.

## Хөрмә бакчалары

Шатт-әл-Гарәбнең ярлары тәбәнәк. Йортлар яр кырына ук сыенып утырганнар. «Ничек боларны ташу суы юып алып китми икән? — дип гаҗәпләнеп барам. — Яз көне, боз киткәндә, елга суы әллә кайларга тарала торгандыр?» Һәм исемә төшә: монда ташу булмый. Тигр һәм Евфрат елгалары Төркия тауларының бозлыкларыннан башланалар. Суның иң мул вакыты — җәй уртасы. Кышын, боз эремәгән чакта, елгалар саега.

Яр буенда — пальма плантацияләре. Алар шундый төз, биек, матурлар. Очларындагы гигант каурыйга охшаш яфраклары җилпәзә сыман як-якка җәелеп тора. Җир шарының башка бер җирендә дә мондагы шикелле пальмалар юк. Аларны Европа илләрендә зур агач мичкәләргә утыртып, бина эчендә үстереп карыйлар. Данлыкны кунакханәләрдә, патша сарайларында да матурлык өчен утыртылган шундый пальмалар очратырга мөмкин. Ләкин, туган җиреннән башка урында пальма әкрен үсә, зәгыйфь була.

Финик (хөрмә) пальмалары — Гыйракның горурлыгы. Монда биш йөз төрле хөрмә агачы үсә. Дөнья базарына чыккан хөрмәнең дүрттән өч өлеше шушы илнеке. Елга буенда үскән плантацияләрне, ашлык басуларын сугарып тору өчен табигать үзе кайгырткан. Кырларга, бакчаларга су җибәрергә насос та кирәк түгел. Тәүлегенә ике тапкыр күтәрелгән диңгез суы елга тамагын вакытлыча буып тора, тәүлегенә ике мәртәбә басуларга су тарала. Мондагы һәр хөрмә, суган кыягы, бодай

бөртеге, үлән Шатт-әл-Гарәбнең ашламага бай шифалы суын эчеп үсә. Иң борынгы чорлардан бирле халыклар шушы елга буена урнашырга тырышканнар. Шатт-әл-Гарәб елгасы көчле ил-дәүләтләрне, гүзәл калаларны, зур сарайларда яшәгән тираннарны хәтерли. Елга күпне белә. Белә, хәтерли һәм дәшми. Сабыр, түзем ул Шатт-әл-Гарәб елгасы.

Кичә төнлә Кувәйт радиостанциясе инглиз телендә Вавилон турында бер җыр тапшырды. Язып алырга өлгерә алмадым. Хәтеремдә калганы:

Вавилон елгалары — коллар моңы,
Кайтарыгыз азатлыкны, бирегез ирекне.
Вавилон елгалары — җир ыңгырашуы,
Измәгез халкымны, эчмәгез канымны.
Вавилон елгалары — аналар елавы,
Таптамагыз җиремне, пычратмагыз динемне.
Ләгънәтлим коллыкны, тәбриклим үлемне.

Без һаман агымга каршы күтәреләбез. Пальма агачлары арасында пөхтә коттеджлар, сарайлар, алачыклар, пальма яфракларыннан эмалләнгән кетәкләр күренеп кала.

Портта эшләрен бетереп, диңгезгә таба юл алган кораблар ешрак очрый башлады. Аларның күбесе бу илгә машина төяп килгән, моннан хөрмә җимеше, тары, күн, мамык төяп китә. Танкерлар нефть төягәннәр. Кайбер кораблар, елгага якорь ташлап, йөкләрен шунда, елга уртасында ук плашкаутларга [1] бушатып маташалар. Югары менгән саен, алар күбәя баралар иде. Ниһаять, алда Басра шәһәре күренде.

Көн кичкә авышып килә иде. Шәһәр өстеннән азан тавышы яңгырап узды: «Лә-ә-ә ила-аһа и-ил-л-ла-а-а-а...» Якындагы мәчет манарасыннан күгәрченнәр өерелеп һавага күтәрелде. Азан тавышына канат тавышы килеп кушылды. Яр буендагы корабларда эшләүче докерлар, тәһарәтләрен яңартып, палубага намазлык җәйделәр: «Илаһым, ният кылдым синең тарафларыңа...»

Докерлар, эшләрен тәмамлап, өйләренә таралдылар. Кала өстеннән йолдызлар калкып чыкты. Күк йөзе алтын гөмбәзгә әйләнде.

Җиргә тынычлык, кешеләргә юаныч китерә торган шәрык төне туды. Бу төн әчкелтем өметкә, татлы моңга сугарылган иде. Һәм мин, караңгылыкка карап, Вавилон, Шумер чорларында кылычка-кылыч бәрелеп корыч чыңлавын, яралылар ыңгырашуын, коллар зарын ишеткәндәй булдым.

Урамда кайнашып йөргән машиналар әкеренләп тындылар. Кәрваннар юлга чыкты. Якында кыңгырау тавышы ишетелә иде. Үсмер чакта төн кунып ат саклаган чаклар искә төшеп куйды.

Җир өстен «Мең дә бер кичә» төне каплаган. Көне буе авыр йөк ташып арыган карт ишәк әкрен генә печән чәйни. Җариядәрнең кайнар куеннарына ярлар чакырып, духанда сорнай елый. Елга ягыннан сирпелгән җиләслек чәчәк исе алып килде. Бер-бер артлы утлар сүнә башлады. Шәһәр өстеннән мәзиннең төнге азаны яңгырап узды. Синдбад каласы татлы йокыга талды.

## Әл-Гүрнә

Тимер койма эчендә сыек кына бакча. Асфальт мәйданчык. Сыңар манаралы ак мәчет. Автобус җыйнак бер катлы турист бюросы каршысына килеп туктады. Дәррәү кубып, җиргә сикердек. Моторист Цуриков, чалбар сәдәфләрен ычкындыра-ычкындыра, шул бина янына йөгереп барды да изге җирне сугарырга керешә. Бинадан ун гына адымда туалет та бар икән ләбаса.

[1] Пароходтан бушатылган йөкне ярга чыгарыр өчен ясалган көймә.

Без җир йөзендәге беренче кешеләр — атабыз Адәм белән анабыз Һава яшәгән урында, әл-Гүрнәдә басып торабыз. Дүрт сәгатьлек юл аякларны оеткан. Шофер турист бюросыннан ак чалмалы бер яшь егет алып чыкты. Егет безгә инглиз, француз, немец һәм испан телләрендә мөрәҗәгать итеп карады. Без күп телләр белән ваклашырга яратмый идек, бер тын сатулашып торганнан соң, аралашу коралы итеп инглизчәне сайладык.

Чалмалы гид безне зәңгәр челтәрле койма белән әйләндерелгән алмагач янына алып килде. Анабыз Һава, шушы алмагачның ботагын сындырып, җимешен өзеп алганга җәннәттән куылган икән. Шушы сүзне ишетү белән кайсыдыр: «Оҗмахтагы тәртип нәкъ диңгез флотындагы шикелле булган икән»,— дип искәрмә ясап куйды.

Гади генә алмагач. Биеклеге дүрт метр чамасы бардыр. Агач төбендә череп беткән әллә кайчангы кәүсә аунап ята. Гид бу кәүсәнең атабыз Адәм чорыннан саклануы турында сөйли. Диңгезчеләр көлемсерәп тыңлыйлар, ышанмыйлар. Телевизор тәрбияләп үстергән егерменче гасыр егетләре бит. Алар диннән көчлерәк нәрсәләргә дә ышанмыйлар. Гомумән, аларда ышанмау батырлык санала. Алар шуның белән мактанырга яраталар. Өлкән буынның өметен инкяр итү аларга ләззәт бирә. Ә үзләре әйбәт егетләр. Ил чакырса, кулларына корал тотып, берсүзсез үлемгә барачакларына мин чын күңелдән ышанам.

— Аллаһы тәгалә җәннәт төзү өчен юньлерәк урын таба алмаган микәнни? — дип сорый боцман.

— Алма-Ата шәһәре тирәсендә үскән алмагачны китереп утырткан булсалар, җәннәтнеке дип ышанып идең,— ди Казахстанда туып үскән электромеханик Богданов.

Койма эчендәге гранит ташка инглиз һәм гарәп телләрендә атабыз Адәм һәм анабыз Һаваның тарихын язганнар. Шушы язуны да укып карыйбыз — ышанасы килми. Көндәлек тормышта бу егетләр, кирәк чакта, шушы легендадан да пүчтәк нәрсәләргә ихлас ышаналар, әмма аларның Коръән һәм Библиядә язылган риваятькә ышанасылары килми.

Алмагачны карап туйгач, гид безне елга ярына алып китте. Алда җир карыныннан чыккан басынкы гына тавыш ишетелә. Без текә ярга килеп туктадык. Аста елга ага. Тантаналы, илаһи күренеш — Тигр белән Евфрат елгаларының бергә кушылган җире. Бөек Вавилон елгалары, ургылып, бер-берсенә ташланалар. Дулкыннар бәрелешкән җирдә көчле ыңгырашу барлыкка килә. «Вавилон дәрьялары — коллар моңы...» — дигән җыр тагын искә төшеп китә.

Ике бөек елга бер-берсенә баш бирергә теләмичә, бер тын янәшә агалар. Агым ике суны бөтерелдереп болгата, кушылырга, берләшергә өнди. Ике мең җиде йөз километр ара узган Евфрат, мең җиде йөз чакрым юл үткән Тигр үзара кушылырга теләмиләр, даулашалар, бер-берсенә баш бирмиләр. Аларның икесе дә горур, икесенең дә бөек тарихы, гореф-гадәтләре бар. Уртак ярларга эләккәч берни эшли алмыйлар. Агым аларның суларын үзара бутап бетерә. Яңа елга — Шатт-әл-Гарәб барлыкка килә.

Мин яр астына төштем. Эземнән балчык коелып калды. Битемә елга суының салкын дымы килеп бәрелде. Исергәп авылы аша аккан инештән дә нәкъ шушы ис килә иде: ләм, бака ефәге һәм юешлек исе. Колакка дулкыннарның, бер-берсенә баш бирергә теләмичә, астыртын гына ызгышулары ишетелде. Йөрәк леп-леп тибә. Елга түгел бу — мин мең еллык тарих каршында басып торам. Канымда нидер эшләп, истәлек калдырып китү теләге уянды. Бу очракта минем ерак бабаларым корбан чала торган булганнар. Без андый йолалардан баш тарттык. Корбанның бары бер төрен — ватан өчен үлүне генә саклап калдык без.

Иптәшләрем ашыктыралар. Елгаларның кушылуы йөрәккә тетрәнү

бүләк итте, күңелгә тарихның яшерен серен ачты. Мин хак түләргә тиешмен. Хисне бушлай алырга ярамый. Талау була ул бушлай алу. Күп тапкыр сынаганым бар: талап алганны язмыш һәрвакыт каза белән түләтә. Нәрсә бирергә? Кесәмне актарырга керештем. Янчыгым буш: акчамның соңгы тиененә кадәр таможенниклар, декларациягә теркәп, сейфка бикләп киттеләр. Кулъяулык. Тарак. Газета кисәге — «Яшь ленинчы» газетасының ярты бите. Баулыга кайткач сатып алган идем, саклап йөртәм. Пәке.

Минем бабаларым ат һәм корал ятkatkannar. Ир-егетлекнең соңгы тамчысын югалтудан куркып, без кесәбездә коралны хәтерләткән пәке йөртәбез. Пәкем Исергәп авылының сельмагыннан сатып алынган иде. Исергәп белән Әл-Гүрнә арасында бәләкәй генә булса да йола уртаклыгы булсын әле. Шушы төбәк кешесе Ибне-Фадлан Идел буена килеп, минем бабаларымны дин тотарга өйрәтеп киткән. Минем бабаларым да бу ярларга килеп йөргәннәрдер — без тарихны начар беләбез.

Пәкемне әйбәтләп кулъяулыкка төрдем. Төйнәдем. Кизәнеп ике бөек елга кушылган җиргә ыргыттым. Елга кабул итте корбанны. Минем пәкем бер тын агым белән көрәшеп, бөтерелеп барды да елга төбендәге ләмгә әйбәтләп ятты. Шумер колларының сынык ишкәкләре, Вавилон сугышчыларының калканнары, татар-монгол гаскәрләренең уклары арасында пәкем калды.

Автобуска кереп утырдык. Гид белән саубуллаштык. Моторист Цуриковның пышылдап кына күршесе Юркога әйткәнен ишетеп алдым:

— Яр астына төшеп азапланган булды. Алмагач төбенә чүгәләдең— эше бетте китте.

Автобус урыныннан кузгалды. Юл тасмасы төньякка, Багдадка таба ага башлады. Николай Иванович Цуриков Әл-Гүрнә ягына карап, кулындагы кечкенә агач ботагын селкеп куйды:

— Сау бул, маймылларның агачтан төшеп җирдә йөри башлаган җире.

— Каян алдың бу ботакны, Цуриков?

— Алмагачтан сындырып алдым. — Моторист куанып елмайды. Елмайганда, аның күзе кечерәеп, бөтенләй югала. Танау тишекләре киңәя, җәнлекнекенә охшаш сирәк, вак тешләре күренә. — Вакыт уздырып йөрисе дә калмаган икән. Алмагачмыни бу? Барахло. Минем бакчамдагы агачлар Перечепидороганың йодрыгы зурлыгы алма бирәләр. Кәбестәгә кушып, тозлап куйсаң, һи! Артыннан шуны кабып җибәрсәң, күкерт кислотасы эчәргә була.

Җир йөзенә балалар сулышыдай чиста, нәзберек төн төшеп килә иде. Йолдызлар кабына башлады. Дала утлары автобуска бер тын иярен киләләр дә, артта калып, күздән югалалар. Ямансу иде нигәдер. Дөнья матур, киң, иркен. Автобусның радиоалгычы соңгы хәбәрләр тапшыра. Израиль Ливанның көньяк шәһәрләрен тупка тоткан. АКШтан Иран студентларын куганнар. Без моннан төгәл ике ай элек, нәкъ шушылай автобуска утырып, Ливанның Триполи исемле каласыннан Бәйрутка экскурсиягә барган идек. Шул без йөргән җирләрдә бүген снарядлар шартлый. Җир шарында матур, киң елгалар, киң сахралар бар. Адәм балаларының хәтерләрендә җәннәт турындагы легендалар, гүзәл риваятьләр бар. Җирдә тынычлык кына юк. Сугышларны, кан коюларны ничек туктатырга?

Корабка кайткач, ике генә сәгать йоклап алдым. Төшемә ак чатыр, сарык көтүе, күмер өстендә пешкән тәмле көлчә керде. Җилкәсенә озын муенлы чүлмәк утыртып, «Сагыну» көен җырлап судан кайтучы шәрык кызы, имеш, минем ярым икән.

Иртәнге дүрттә кораб урыннан кузгалды. Артыбыздан янә кильватер агымы сузылып кала башлады. Су өстендә сузылып калган ул яшькелт-ак юл кильватер агымы түгел — ул безнең газиз гомеребез.

Җирдә яшәүчеләр гомерләрен бер таңнан икенче таңга сузылган тәүлек белән үлчиләр, ә без гомеребезне сәяхәт озынлыгы итеп кисеп ташлыйбыз. Инде туктыйсы, тын аласы, ял итәсе килә. Ниндидер каһәрле көч, туктарга ирек бирмичә, һаман алга куа. Туган илгә кайтып очрашу өмете булмаса, түзеп булыр идеме икән?

Әнә, Басра каласының мәһабәт манаралары да ерагая. Синдбад каласының шау-шулы базарлары, фәхешханәләре, үзәк мәйданындагы сузылып яткан шәрә хатын өстенә басып торган арслан-киек һәйкәле дә һаман ерагая. Нефть сатып баеган гарәп илләре берни сатмыйлар, алалар гына. Без туган илгә балласт [1] белән кайтабыз. Диңгездә якынтирәдәге портларга радиограмма биреп, төяргә йөз эзләргә кирәк. Буш кайту — бер файдасыз ягулык яндыру. «Академик Арцимович» тәүлегенә егерме дүрт тонна солярка яндыра. Хәбәштан һәм Гыйрак түләгән табышны илебез өчен саклап калырга кирәк.

...Иртән торуга, чүл белән диңгез очрашкан җирдә Күвәйт күренде. Башлап өч гигант конус-манара күзгә ташланды. Манараларның иң биеге, ике пыяла шарны уртасыннан үтәли тишеп чыгып, гәүдәсенә беркеткән. Икенче манараның уртасында бер генә шар, өченчесе — җирдән болытларга сузылган шома конус кына. Каланың берничә җирендә биек колонналар өстенә утырткан «оча торган космик тәлинкәләргә» охшаш ак гигант савытлар күренеп тора. Атом көче белән диңгез суын тоздан арындырып, шәһәр йортларына таратырга көйләнгән установканың резервуарлары иде бу — Күвәйт каласының горурлыгы.

Гадәттә, һәр шәрык каласында сине манаралар җәлеп итә. Манарадан биек, аннан матур, үзенчәлекле корылма булмый гарәп шәһәрләрендә. Күвәйт каласының мондый булуын көтмәгән идем, мин югалып калдым. Бу — егерме беренче гасыр шәһәре иде.

Монда мин беренче тапкыр 1960 елда булдым. Ул чакта Күвәйт җиреннән нефть суыру көйләнеп килә иде. Галәмнең һәр молекуласын алыш-бирешкә, файдага көйли белүче бизнесменнар, акча исе сизеп, бу төбәккә әле яңа ябырыла башлаганнар иде. Саман йортлар, ак чатырлар, пальма яфракларыннан әмәлләнгән кетәкләр исән иде әле. Дөяләр, ишәкләр, кыйммәтле «Роллс-ройс»лар белән бер хокукта, бергә йөриләр иде. Хәзер шәһәрне модерн ысулында салынган йортлар басып киткән. Мин беренче килгәндә бер-берсеннән унар чакрымда яткан Шуайба, Бен-әл-Әхмәди портлары Күвәйткә тоташканнар.

Шәһәргә шлюпкага утырып кына чыгарга була. Диңгездә отлив вакыты иде. Портны дага рәвешендә урап алган кара кыялар судан калкып чыгып, күренеп торалар. Иртәнге сигезләрдә прилив башланды. Уннар тирәсендә кыялар күмеләчәк. Шул чакта портка үтеп кереп була. Шлюпканы суга төшерергә хәзерләп куйдык та каланы күзәтергә кирәштек.

Моннан унсигез ел элек калада агач заты юк иде. Шәһәргә су җибәргәч, агачлар да калкып чыкканнар. Бакчага күмелеп утырган виллалар, матур коттеджлар барлыкка килгән. Йорт салдыручылар, арзанлыкка төшсен дип, акча кызганып тормаганнар. Шәһәрдә әллә нинди фантастик биналар бар. Әнә, ярга килеп терәлгән егерме биш катлы гигант аккордеонга охшаган бина. Хатын-кызлар редикюленә, каплап куйган рюмкага охшаганнары — тагын әллә нинди мәзәк кыяфәтле йортлар бар монда. Бу калага да шәрыктәге бер гадәт көчле тәэсир иткән: урамда бер төрле ике йорт булмаска тиеш. Һәм шәһәрдә бер төрле ике йорт таба алмыйсың.

Нефть чыгару файдасына үскән шәһәрләрне күрү белән мин үземнең туган җирем Баулы турында уйлыйм. Һәрвакыт Баулымны матуррак, отышлырак итеп күрәсем килә.

[1] Буш йөргәндә кораб винты су өстенә калкып чыкмасын өчен балласт танкларына су тутырыла.

Сәгать тугызда суга шлюпка төшерә башладык. Юлны бикләп торган кара кыяларга бер сәгать барыла. Яннарына җиткәнче, дингез суы иң югары ноктада булачак. Портта бикләнеп калмас өчен, кайту юлына да кыялар су астына күмелеп торган арада чыгарга кирәк булачак.



## Әл-Күвәйт

— Шлюпканы суга!

Шушы боерыкка күнегә алмам шикелле. «Чолым» пароходында эшләгән чакта без бер мәртәбә суга баттык. Шул вакыйганың шаукымы әле һаман күңелдә тора, һәм: «Шлюпканы суга!» — дигән боерыкны ишетү белән, касыгымны ачыттырып, ниндидер тынгысыз курку биләп ала.

Унбиш минут үтүгә, шлюпка кораб янында суда чайкалып тора иде инде. Без, штормтрапка асылынып, көймәгә төшәбез. Көймәгә кереп утыргач кына зур корабның сине дингездән еракта тотканлыгын аңлый башлыйсың. Кораб эчендә яшәгәндә, су синнән ун-унбиш метрга астарак. Син аңа өстән генә карап йөрисең. Шлюпкадан үрелеп, кулың белән дингезне тотып була. Су исе синең борыныңа бөркелеп керә. Янәшә йөгергән дулкыннар көймәнең эченә үк чәчрәп керәләр.

Авариягә очрап, кораб бата башласа, экипаж шлюпкага утырып котылырга тиеш. Авариягә юлыккан танкердан нефть агып чыга. Су өстен ялкын чорнап ала. Шлюпкага утырган дингезчеләр ялкын аша үтә алмыйча янып үләләр. Янгын аша үтеп булсын өчен, коткару шлюпкаларын соңгы елларда герметик рәвештә ябылмалы итеп ясый башладылар. Ябык шлюпка эчендә тынчу: бензин, машина мае, буяу исләре бергә кушылып, тын юлына килеп тыгыла. Өстәвенә, дингезчеләр тәмәке көйрәтәләр. Тәмәке тартырга рөхсәт итмәскә дә булыр иде, мин тыелам: моряклар тыюны ифрат яратмыйлар. «Тартырга рөхсәт итмим»,— дип кычкыру белән тартасы килү көче бермә-бер артыр иде.

Шәһәргә чыгучыларның күбесе — яшьләр. Әйбәт егетләр. Яшьләрнең миңа бер яклары ошый: аларда куштанлык, икейөзлелек сирәк очрый. Тез чүгүне яратмыйлар алар. Әлегә аларда ике зур кимчелек бар: авырлыкка түзмәү һәм материаль якка артык зур әһәмият бирү. Тәрбия эше дөрес куелган очракта бу ике кимчелек тә вакытында юкка чыгарга тиеш. Яшьләрне тәрбияләүгә мин җаваплы һәм изге эш дип карыйм.

Портка кердек. Причалга килеп туктадык. Көймә сакларга бер матрос белән бер мотористны калдырдык та проходнойга таба юнәлдек.

— Шәһәргә аракы алып чыкмыйсызмы? — дип сорады полицейский.

— Юк, чыкмыйбыз.

Монда — «коры закон». Аларны башка нәрсә кызыксындырмый да. Пропуск язып бирделәр. Без, проходной аша үтеп, шәһәргә чыктык.

Кояш рәхимсез кыздыра. Һавада кайнар асфальт сулышы. Урамда шыгрым тулы машиналар. Башка гарәп илләрендә аларның төрлесе очрый: искесе, яңасы, кечкенәсе, зурысы, төрле илләрдә ясалганнары. Монда күбрәк Америка машиналары. Зурлар. Көчлеләр. Тәкәбберләр.

Борылмада машина борыны күренә. Ул үсә, озыная башлый. «Моның койрыгы кайчан күренер икән? — дип, син һаман көтәсең. Ниһаять, машинаның койрыгы күренә: хәйран калырлык зур, озын машина. Мондагы машиналарны күргәч: капитанның горурлыгы булган «Лада»сы шактый шиңде. Аның өч горурлыгыннан икесе — эте белән хатыны гына калды.

Европа илләрендә акчалы кешеләр дә зур машинага утырып йөрергә яратмыйлар. Тантана вакытларында, янсә контракт төзегәндә генә

президентлар йөри торган («Роллс-ройс», «Бьюик») машиналары ходка җибәрелә. Башка чакта миллионерлар да уңайлы, бензинны аз яндыра торган машинага утырып йөриләр. Ә монда һәр байгыш кулында патшалар йөри торган машина. Кувәйт гражданнарында акча бар — анысы аңлашыла. Аларга нефть сатудан кергән өстәмә табыш хисабыннан, Кувәйт гражданы булган өчен, акча түлиләр. Төрек, Пакистан, Һиндстан илләреннән монда эшкә килгән ач-ялангачлар да, эшли башлагач, машина сатып алалар. Билгеле, яңаны алырга аларның акчалары җитми. Кара эштә бил бөгүче чит ил эшчеләре дә машинаның зуррагын алырга тырышалар. Аларга нигә зур машина кирәк икәнлеген мин соңыннанрак аңладым. Монда фатир хакы кыйммәт. Квартирга түләргә мескеннәрнең акчалары җитми. Алар машина эчендә йоклыйлар, бар җиһазларын шунда тоталар.

Без тротуардан үзәккә таба атлыйбыз. Кибет витриналары, каршы төшеп, туктарга, эчкә керергә, янчыгыңны ачарга өндиләр. Вәсвәсәгә бирелмичә, бик озак бардык. Түзәр хәл калмады — кердек.

Башка гарәп илләрендә кибет хуҗасы сине сөйрәп кертә, көчли, сатулаша, товарын куеныңа тыга. Монда алай түгел. Кувәйт кибетләрендә ясалма климат. Салкынча. Хуҗа, сиңа күз кыры белән генә карап, кофе эчеп утыра. Сатулашырга яратмый. Сатулаша башлаган кешене ярлыга санап, елмаеп кына читкә борыла. Шәрыкның төп гадәте — тәмләп, әллә нинди тапкыр, көлке, татлы сүзләр әйтеп сатулашу монда әкеренләп юкка чыгып бара.

Товарлар күп. Кирәгеннән артык күп. Магазиннарны АКШ, Көнбатыш Германия, Япония товарлары басып киткән. Монда пошлина түбән, шунлыктан бөтен дөнья маллары Кувәйткә ташкындай агыла. Бигрәк тә Япония, бигрәк тә аның радиотоварлары күп. Төрле зурлыктагы транзисторлар, әллә нинди катлаулы радиокомбайннар — арзанлысы, кыйммәтлесе — акчаң гына булсын. Кием-салым, йорт җиһазлары, парфюмерия, савыт-саба, кызыл мал, көнкүреш машиналары, әллә ниләр. Күзгә бәрелеп торганы — алтын-көмеш һәм асыл ташлардан ясалган бизәнү әйберләре. Алар күп, күзеңнең явын алырлык, һәм шунда, синең күз алдында, көмешчеләр эшләп утыра. Шәрык җирендә генә очрый торган житез, йөгерек куллар синең күз алдында һушыңны алырлык могҗизалы матурлык тудырганда, түзә алмыйсың — кулларың кесәңә тыгыла, ләкин...

Комсызлык, чама белмәү җыйган шушы кадәр әйберне. Сәүдәгәрләрнең күбесе, кайтарткан товар кибетенә сыймый башлагач, тротуарга өеп куйган. Сатыламы-юкмы — белми ул аны. Товарларның күбесе кайнар кояш астында, тузанда аунап ятып, искерәчәк, турыдан-туры чүплеккә юл тотачак.

Без кайчакта әйбер юклыкка зарланабыз. Әйбер кирәгеннән артык булганда да кыен икән ул. Әйбер, әйбер, әйбер. Әйбер синең вакытыңны, рухи тормышка тотылырга тиешле егәрлегеңне суыра. Ул сине әсир итеп ала, колга әйләндерә. Акчасы булып, сатып алырга әйбере булмауны кеше җиңелрәк кичерә. Сатып алырга бар нәрсә булып, кесәңдә акчаң булмау — кимсетә, рәнҗетә икән. Кувәйт шикелле җирдә мин яши алмас идем.

Нефть тапканга кадәр бу җирләрдә бәдәви-күчмә кабиләләр яшәгән. Мал асраганнар, кәрван йөрткәннәр. Яр буенда яшәүчеләре балык тотканнар. Аларның көнкүреше Мөхәммәд пәйгамбәр заманыннан бирле үзгәрмичә даими саклана килгән. Нефть чыгару, бигрәк тә нефть сатудан елга булып акча агып керү мондагы тормышны танымаслык итеп үзгәрткән. Ил кечкенә. Кувәйтнең халкы тугыз йөз мең генә. Илдә эш эзләп килгән ике миллионнан артык чит ил кешесе яши. Кувәйт гарәпләренең бары тик унҗиде проценты гына эшли. Алары да әле дәүләт аппаратында һәм төрле рәис булып утыра торган җирләрдә

генә. Эшне чит илләрдән җыелган кешеләр башкара. Бу илнең сиксән өч процент халкы соры корт булып яши. Күвәйт гражданы булган өчен аларга акча түлиләр. Гаделлек белән, тигезләп бүлү юк, билгеле. Гади халык бер өлеш алса, Мөхәммәд пәйгамбәр нәселеннән саналган сәетләргә — күп өлеш, ә кабилә юлбашчылары шәехләргә гади халыкка караганда йөз мәртәбә артык түләнә. Күвәйт әмире үзе аена унбер миллион алып тора.

Шәһәр карап йөри торгач, без читкәрәк тайпылганбыз. Бервакыт машиналар зиратына килеп чыктык. Ташландык машиналар, җыела торгач, чакрымнан артыкка сузылган тимер мәетләр өемен хасил иткән. Машиналарның күбесе, череп, тутыкка әйләнеп беткән. Күптән түгел ыргытылганнары әле исән. Техника яныннан тыныч кына узып китә алмый торган егерменче гасыр балалары, безнең егетләр, шуларны тикшерергә керештеләр.

— Кара әле, менә бу «Форд»ның бар җире исән. Хәтта багында бензины да бар...— Моторист Перечепидорога капотны ачып, мотор эчендә чокынып карады.— Шайтан алгыры, аккумуляторы утырган. Аккумуляторы утырмаган булса, йөртеп карарга да була иде.

Матрос Корбут ак «Мерседес-бенц» янында кайнаша. Ул аны хуҗаларча җентекләп карап чыкты. Сакланып кына, тап төшерүдән, сыдырылдырудан куркып кына ишеген ачып карады.

— Мал кадерен белмиләр, вәхшиләр,— диде ул, ихлас рәнҗеп.— Мин бу машинаны ике көннән эшкә иңдерер идем.

Моторист Цуриков машиналар өеменә таш томырды:

— Рәхәтләнеп тәрәзәләрен дә ватып китә белмәгәннәр, маймыллар!— диде ул, сүгенеп.— Китереп ыргытыр-алдыннан мин боларны рәхәтләнеп «эшкәртер» идем.

Ташландык машиналар темасы портка кайтып җиткәнче, диңгезчеләрнең телләрендә булды.

## Бәхәс

Без шәһәрдән урап кайтуга бункеровщик рейдка килеп кирәк кадәр ягулык биреп өлгергән иде. Әйткәнемчә, Франциядә ясалган «Пилстик» двигателенә безнең май ярамый. «Шелл» заводларында чистартылган май китергәннәрен көтәбез. Инде корабка документлар хәзерләү өчен диңгез агентының клеркы килгән. Ул минем каютамда көтеп утыра иде. Таныштык.

Агентның клеркы (диңгез агенты, Күвәйт кешесе буларак, үзе эшләми, аның бар эшен клерклар башкара) Ибраһим Фазыл Төркиядән килеп эшли. Истамбул университетын бетергән. Семьясы — Истамбулда, үзе монда яши. Төркиядә контора ачып җибәрерлек акча туплагач та кайтып китәргә җыена.

Өстәлгә коньяк утырттым, закуска куйдым. Ибраһим бер рюмканы тәмләп йотты, кабатлаудан баш тартты.

— «Коры» закон монда,— диде ул.— Авызыңнан исе килгәнен сизеп алсалар, алла сакласын. Эш кешесе бит мин.

Чәй куйдым. Куе итеп ясап, Ибраһимны чәй эчердем. Чәй ярату — төрки халыкларга хас бер уртак сыйфат булса кирәк. Агентның ярдәмчесе мине тәмам ярата башлады. Теле ачылып китте.

— Сез менә социализм төзедегез, коммунизм төзергә җыенасыз. Ә Күвәйттә революция ясамыйча һәм күмәкләштерүләрсез генә социализм төзиләр,— диде клерк.

— Мин әле генә шәһәрдә йөреп кайттым, социализм дигән нәрсә күзгә чалынмады. Кайда икән аларның социализмы? — дидем мин.

— Сез бит түләүсез уку, дәвалану, түләүле ял белән мактанасыз. Уку монда да түләүсез. Өстәвенә, баласын югары уку йортына биргән

өчен этисенә стипендия түлиләр. Дәвалану да буш. Аермасы шунда, Кувәйт гражданы үзе теләгән илгә барып дәваланып кайта ала. Расходын тулысынча дәүләт түли.

— Ә хокук, тигезлек мәсьәләсе ничек монда? — дип сорадым мин тыныч кына.

— Хокук тигез. Кирәк нәрсәне гади фәллах та, әсир дә бер үк хак түләп ала. Патша акчасымы бу, хәерченекеме дип карап тормыйлар. Алырга әйбер булмаганда гына акчаның власть башындагы кешеләр кулындагысы кыйммәт, хезмәт ияләре кулындагы арзанрак йөри. Ә бездә акча кешеләрне тигезли.

Ибраһимның бу дәлиле миңа көлке тоелды. Карл Марксны укымаганлыгы әллә каян күренеп тора.

— Әйтик, син — Төркия кешесе һәм Кувәйт үз гражданы икегез дә бер төрле эш башкарасыз икән, ди. Сезнең икегезгә дә тигез түлиләрме соң? — дип сорадым мин.

— Юк, Кувәйт гражданына күбрәк түлиләр. Ике тапкыр артыграк диярга мөмкин.

— Шулай булгач, нинди тигезлек турында сөйләп азапланырга? Тагын бер сорау: агент фермасының рәисе үзе эшкә йөриме?

— Без аны сирәк күрәбез.

— Үзе эш хакын сезнең белән тигез ала торгандыр бит?

— Ферманың табышы аның кесәсендә кала инде.

— Ә нигә соң аны эшеннән чыгарып, үзегез генә эшләмисез?

— Контора ачып җибәрү өчен, Кувәйт гражданы булу кирәк. Бары тик аларга гына рөхсәт ителә.

— Шулай булгач, нинди тигезлек булсын бу чынбарлыкта? Бай буыннан-буынга бай булып, ярлы ярлы булып эшли.

Ибраһим минем дәлил белән килешмичә, өстәде:

— Ярлылар белән байлар арасын ислам дине тигезли. Һәр мөселман өммәте байлыгының уннан бер өлешен ярлыларга өләшә.

— Ул мал ярлылар кулына барып керәме соң?

— Анысы инде имамнар эше. Алар күзәтеп тора.

Дин турында фәлсәфә сату Ибраһимның иң яраткан эше иде. Бу темага күчкәч, ул миңа әңгәмәгә катнашырга да ирек бирмичә:

— Динне бетерү сезнең иң зур ялгышлыгыгыз булды,— дип сөйләп китте. Мин аның сүзен бүлдем:

— Без аны бетермәдек. Аң-белем үскәнлектән, ул үзеннән-үзе юкка чыкты.

— Белемнең дингә зыяны юк, киресенчә, ул динне көчәйтә генә. Сез данлыклы инглиз галиме Арнольд Джозеф Тойнбинең «Цивилизация төбәкләре тарихы»н укыганыгыз бардыр бит?...

Агент ярдәмчесенең тиз генә туктарга исәбе юк иде. Мин аны бүлдем:

— Кувәйт әмире ни сәбәп шәригатьне тотмый соң? Нигә ул миллионлаган акча сарыф итә? Ни сәбәп ул үзе белән төн уздырган Һолливуд җарияләренә виллалар бүләк итә?

— Безнең әмир бәйрәм көннәрендә ярлы кешеләргә миллионлаган динар хәер өләшә. Ул туган җирләреннән куылган Палестина мөһаҗирләрен туйдырып тора,— диде Ибраһим, әмирне яклап.

Кинәт бу кеше миңа кызганыч булып китте. Патшаңны мактамыйча булмый. Гади халыкны шуңа өйрәтәләр. Үз-үзеңне саклау, имин яшәргә тырышу кагыйдәсе мактарга мәҗбүр итә. Ибраһим чит ил патшасын мактый иде. Мин аның тиранга мәдхия укуының сәбәбенә төшендем: мескен клерк, мактамасам, эшемнән чыгарырлар, дип курка иде. Яратуны көчләп ихтыяҗга яраштыру — иман өчен иң куркыныч нәрсә. Тәлинкә ялауны акларлык сәбәп юк бу дөньяда. Мин бәхәсне туктатырга мәҗбүр булдым.

Корабкэ машина мае китерделәр. Ибраһим документларга кул куеп, үзен алырга килгән катерга таба юнәлде. Саубуллашканда миңа кул бирүе шактый салкын иде. Һәр дәлилен инкяр итеп тору аңа ошамады. Әңгәмә болай тәмамланыр дип көтмәгән иде ул.

«Академик Арцимович» якорь күтәрде.

Көн кичкә авышып килә иде. Телевизорны кабызып җибәрдек. Күвәйт телецентры тапшыруны коръән укудан башлады. Коръәнхафиз япь-яшь чибәр егет. Тавышы бай тембрлы, яңгыравыклы. Безнең Илһам Шакировка тартым. «Бездә яшәсә, бу бәндә данлыклы җырчы булыр иде»,— дип уйлап куйдым. Егетнең алдында — тышы ташлар белән бизәлгән коръән. Ул аңа карамый да. Кайвакыт, бигрәк тә озын итеп сузганда, нигәдер учы белән колагын каплый. Коръән сүзләренең тәэсирен көчәйтү өчен, телевизор экраныннан чылтырап чишмәләр акканын, кызарып кояш чыгуын, җимеш агачларының чәчәк атуын күрсәтеп алалар.

Коръән укыганнан соң соңгы хәбәрләр тапшыру башланды. Соңгы хәбәрләрдән соң — реклама, товарларны мактау, аны кешегә сылау. Реклама нәкъ Америка ысулында оештырылган. Бер чибәр яшь кыз белән яшь егет яхтага утырып диңгездә баралар. Алар күптән өйләнешергә тиешләр, һәм кинәт егет кызга карамый башлый. Кыз елый, өзгәләнә, егетнең ни сәбәп мәхәббәте сүнгәнен белмичә газаплана. Шундый авырлыклар кичергән чакта, кыз бер магазинда култык асты тирләгәндә сөртә торган лосьон күрә һәм шуны сөртә. Шул минуттан башлап, егет аны тагын ярата башлый, һәм алар өйләнешәләр. Реклама телевизор караучыларны: «Әгәр үзегезне яраттырасыгыз килсә, нәкъ шушы лосьонны сатып алыгыз,— дип ышандырырга тырыша иде.

Кичләрен Күвәйт телевидениесе Һолливудта төшерелгән кино күрсәтә. Кино, телевидение, магнитофон, төрле машиналар аркылы гарәп илләрендә мең өч йөз илле җиде ел сакланган торгынлыкка көнбатышның яшәү ысулы саркып керә. Ислам — көнкүреш кануннарына нигезләнгән дин. Капиталистик илләрдән килгән товарлар шәригать, динне әкренләп кимерә торалар. Шәрыкта Көнбатыш илләрендә төшерелгән порнография фильмнарын күрсәтмиләр әле. Аралашу шушылай барган очракта, аларының да үтеп керәчәгенә шик юк.

*

* *

Ниһаять, кораб портка керә. Җиргә чыгу мизгеле шундый татлы, шундый тантаналы. Морадка ирешү мизгеле бу һәм синең иллюзияләреңнең челпәрәмә килеп ватылу минуты. Күпме еллар шундый өметләргә бирешмәскә тырышып карадым. Булмый. Донкихотлык җиңә. Дон Кихот булып яралгач, үлгәнче «хәсрәтле рыцарь» булып яшәргә тиеш, күрәсең.

*

* *

Инде Фарсы култыгы да артта калды. Без океанга чыктык. Озаклмый Кызыл диңгез, Сүәеш каналы, Урта диңгез, Босфор. Алар бер-бер артлы күренеп үтәчәк, һәм бер таңда туган илнең ярлары ачылачак. Озакламый — кавышу һәм тагын аерылышу, тагын сәяхәт.

Кара диңгезгә җиткәч, радиограмма алдык: Жданов портында йөк төяп, Испаниянең Барселона һәм Валенсия портларына юл тотарга тиешбез. Безне яңа сәяхәт көтә.

Диңгезчеләр гомере хәрәкәттә.

*Беренче китап тәмам*

*1977—1981*

## Равил Фәйзуллин

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

## Палестина! Палестина...

*Израил гарәп илләренә карата геноцид политикасы уткәрә.*

(Газеталардан.)

Палестина! Палестина!
Диннәр бишеге.
Милләтләрнең халыкара
гауга ишеге.

Палестина! Палестина!
Изгеләр җире.
Кая изгелек? — таралгач
үтерү чире...

Палестина! Палестина!
Шигъри исем.
Бу җирләрдәге вәхшәткә,
Дөнья, ни дисең?

Палестина! Палестина!
Язмышың — гыйбрәт.
Аллалар күп чыккан җирдә
хаксызлык күбрәк...

Палестина! Палестина!
Көрәш учагы.
Гарәпләрнең берләшергә
ант эчәр чагы.

## Колонизатор әлифбасы

Куа да
бүтән ыру адәмнәрен
җиреннән-суыннан,
үз хатыны, балалары алдында
хозурланып әйтә тиран:
«Җиңдем!..» — диеп.

Бераз вакыт үткәч,
оныкларына тукый:
«Бу җирләрне азат иттем!..»

Соңрак —
иске зират урыннарын абзар иткәч,
оныкларының балалары:
«Ватаным!..» — дип шигырь яза.

●

*Жәлилләр, Кәримнәр истәлегенә*

Жирдә гөлләр-чәчәкләр күп!..

Каның тамып үскәне генә
синең халкың данын зурлый.

Корбан була алсаң гына —
тибрәнер исемең
Мәңгелекнең рәшәсендә.

## Җыерчыклар, бу ак чәчләр...

Маңгайдагы җыерчыклар?

Дәрьяларны ерып йөзгән чакта
дулкыннардан калган эзләр ул!..

Бу ак чәчләр?

Тупыл мамык очырган чакта
яланбаш озак торган идем бер...
Кагынырга оныткanмын!

## Иясез шатлык

*(Моңсу җыр)*

Уйный-оча күбәләкләр,
җанлы чәчкәләрмени!
Урманнарга, болыннарга
шатлык чәчкәннәрмени!

Күбәләк кунган чәчкәләр
матур да, горурлар да.

Кемгәдер кирәк булуың —
бәхет икән дөньяда!

...Мин дә куна алыр идем
кемгәдер аклык булып!
Жирдә күпме җаннар йөри
иясез шатлык булып!..

## Бүлмәләр

Чибәр бер ханым сүз катты:
иң матур бүлмә кайда?
Мин әйттем: матур бүлмәләр
бик күптер ул дөньяда.

Ул әйтте: иҗат итәргә
иң җайлы бүлмә — миндә!
Мин — кунак, әйттем җай гына:
бәлки, чыннан да синдә?

Никтер шулчак уйга килде
шыксыз бүтән бүлмәләр.
Бөекләр шул бүлмәләрдә
җан нурларын биргәннәр.

Баздай җирне дә үлемсез
итәр җаннар була бит!
Күз алдыма Жәлил килде.
Тынчу бүлмә — Моабит.

Һәм тагын килде күңелгә
Тукай. Кырыгынчы бүлмә.
Нинди бүлмәгә эләксәң дә,
Рухыңны икән бирмә!

Үзем уйлыйм. Күзем, барыбер,
төшә бүлмә ямена.
Бәллүрләргә, сүзләремне
йотар келәмнәренә.

...Оялырлык рәхәт иде
хуҗаның бүлмәсендә.

Киттем чыгып Казан буйлап —
«Болгар»лар тирәсенә.

## Ак кар күмә яшел уҗымнарны...

Үтә яшьлек! Үтә гомер!
Үрсәләнми кем генә!
Карлар кереп оялыйлар
уҗымнарның төбенә.

Суык — яшелне өнәми.
Картлыкка — дәрт төс түгел.

Изрәгән тән ятьмәсендә
тыпырчына яшь күңел!

...Уҗымнар суыктан көләр
язларын яңарганда.
Ә без яшьле өмет белән
карыйбыз балаларга.

## Кояш бер әйләнгән арада...

*(Июнь)*

Табут читен иртән яшь юды.
Җирләп кайткач халык өй юды.
Кичкә таба яңгыр җир юды.

...Ямансу төн бик кыска булды.

Сабантуйлы яңа таң туды.
Агач башларына нур тулды.
Берәүләрнең сабые туды.
Дөньяга янә ямь тулды.
Шатлык артып, кайгы онытылды.

●

Быел соңгы күк күкрәү
кайчан булды? Кем белә!..
Ә язгы тәүге гөрелте? —
ансы һаман күңелдә!

...Менә кабат без очраштык.
Бу — бәлки, соңгысыдыр?
Мәхәббәттә кавышу да,
аерылу да, барыбер, җыр!

## Иделдә. Теплоходта

Бөтерелә акчарлаклар!
Әйтерсең лә, җанлы әләм!

Кемдер суга аткан гөлләр
Каспийларга булыр сәлам!

Ярда — сылу кызлар! Безгә
әллә хәрам, әллә хәләл...

## Яраттым!

Мин түгелме зифа каеннарны
яшен эчә-эчә яраткан!
Мин түгелме ярны җелегемә
үтеп төшкән өчен яраткан!
Мин түгелме, ярдәм кулым
сузгач,
күпме заттан җанны кыйнаткан!
Мин түгелме, күпме алданып,
ялган матурлыкка җан аткан!..

Тик үкенмим: һәр нәрсәне ихлас,
ышанып һәм чынлап яраттым!

## Яшьлек дустым килде көтмәгәндә...

Буран эчләреннән килеп керде.
Йөзе карлы. Карлы киеме...
Күреште дә өй алдына чыкты,
кая әле, дип, кагынып керим!

Сабакташ ул. Күп ел күрешкән юк.
Керде. Күрәм: шактый чаларган!..
Карларны ул кагып кергән керүен,
ә елларын кага алмаган...

Утырабыз. Сораштырып чыктык
бергә йөргән шәриктәшләрне.
Яшьлек шуклыкларын искә алдык.
Һәм...
сөйләшер сүз бетте бер мәлне.

Тынып калдык. Тышта буран котыра.
Бокалларда шәраб җемелди.
Сизәм: икебезнең дә җанда ялгыз уй
күшеккән кош кебек дерелди.

Киткән икән алтын яшьлек еллар!
Кайтмаска дип киткән саф чаклар!
Күренеп килә бураннар аша
күңел генә күргән шәфәкъләр...

Һәм, әлбәттә, янә сүз башладык.
Бүгенге көн... һава хәлләре...
Кызыксызланганбыз... Безгә карап,
авыз ачып песи иснәп куйды.
Ахры, ул да безне жәлләде.

Буран котыра! Үткәннәрне күмә...
Булсын иде чыгып туктатып!
Безне котырткандай, урам буйлап
яшьләр узды гармун уйнатып.

## Юктыр димсез...

Куе томанлы күкләрдә юктыр димсез
адашкан, яралы бер-бер кош җаны?

...Кояшлар уйнаган чалт аяз күземдә
юктыр димсез сагышларның куе томаны?..

## Си минор

Октябрьда, көз тәс ташлаганда,
алтынлыгы беткәч дөньяның,
китми калган кошлар дөньясында
булып ала бер төр җанлану.

Шәрә куакларда чыркылдаша
чыпчыкларның соры көтүе.
Ала каргалар да өер-өер
түбән төшеп очып үтәләр.
Хәтта йорт казының бүтәнчәрәк
капка алдында канат җилпүе.

Киткәннәр язмышын көнләүме бу?
Сер бирмәүме? Эчтән сызумы?
Әллә суык кышлар алдыннан
сынау кебек ыгы-зыгымы?

Оча кошлар, оча... Өзелеп төшкән
яфраклар белән бергәләп.
Җилли-җилли яңгыр явып ала,
юеш ояларга бәргәләп...

Талпыналар кошлар! Безнең
кошлар...
Канатлары җиргә бик якын.
«Җиргә тугрылар!» дип фараз
итик...
Ә кем аклар гали Күк хакын?

...Кошлар төркеменә карап торам.
Алларында — томан, буп-буш кыр...
Күңелемдә — моңсу бер уй-җыр:
бәлки, безнең күтәрелүләр дә
шушындый бер көзге очыштыр?..

## Икебана

*(Әнием портретына штрих)*

Гомер букетында
нужалы эш яфраклары,
хәсрәт-кайгы кыяклары,
һәм берничә чәчәк урыны
(берсе бөредә үк корыган бугай...)
Өмет дигән көмеш савытта.

●

Җан тынлыгым бозып, дау булдым.
Үзәннәрдә торып, тау булдым.
...Килде көн: Син яннан үткәндә,
иелеп калыр өчен, тал булдым.

## Бәхет

Бер кочак бала!
Ун кочак бала!
Йөз кочак бала!..
Шуңа да чиксез
куана ата!
Куана ана!
Без — ишле бала!

Мин шул кочактан
бер бөртек бала!
Инде зур бала:
чал чәчле бала,
балалы бала,
һавалы бала,
яралы бала...

Шулай да минем
сөенеч җанда:
шушы тынгысыз
кискен заманда
әтием исән!
Әнием исән!
Туганнар исән!
Менә мин нинди
бәхетле бала!

## Карадагта кызыл җыйганда

Безнең якның чияләре кебек
якут җимеш сарган ботакны!

Ул кушбөртек каян килгән дисәм,—
Синең иреннәрең икән!

## Күктүбә комлыгында

Һәр дулкынның үз исеме бардыр кебек.
Ә бу дулкын Синең исемдәдер!

...Дулкынныкы кебек ак яллы атта
Сине урлап очтым түшемдә бер!

●

*Мәрхүм Т. истәлегенә*

Дәү әнине җирләп кайттык.
Озатып калды таллар...
Саубуллашырга кайтканнар
балалар, оныклар да.

Җыелыштык моңсу гына
өйалды болдырына —
Газиз Дәү әниебезнең
яраткан урынында —
яд итәбез төрле телдә,
кем ничек булдыра ала!

Оныклар туган телләрен
әй сындыра, әй вата...
Матәм көнне ят авазлар
ямьсез тойгы кузгата!
Диварлар өнсез калган күк.
Тирәкләр аптыраган.
Тәрәзгә кунган шөпшә дә
бызламый — тынып калган.

Моңарчы алар ишеткән
гел туган телне генә.
Алар шул телдә туганнар.
Алар шул телне белә!

Телләрне бутап сөйләүдән
авазларга оят кебек.
Бер карасаң, бу туганнар
бер-берсенә ят кебек...

Шунда аңладым: мәңгелеккә,
Дәү әни белән бергә,
Туган телнең дә бер моңын
күмгәнбез икән җиргә.

...Дөрес, һәммәбезнең дә
Дәү әни рухы истә.
Шулай да бер изге аһәң
җитмәде шушы кичтә.
Безгә кул селтәгән кебек,
җил исеп китте өстән...

## Марсель Галиев

# ҖИРДӘШЛӘРЕМ

### Гибралтар бугазында

Гибралтарга килеп, гыйбрәт ал син! —
Шаян рифма менә табылды.
...Урта диңгез җиле, күпер эзләп,
ташлы ярга килеп кагылды. —

Кул сузымы җитә Африкага,
комлы таулар калка еpактан.
Шушы төштән килеп маврлар бит
испан ярларына ук аткан.

Җир әйләнә. Халыклар да шулай
бөек күчеш ясап алганнар.
Көрәш тынган тыныч араларда
мәрмәр поэмалар салганнар.

Зур халыклар моны таный белә,
тарих бите тормый гел каннан.
Заманалар гел яулардан торса,
каян килер иде дастаннар?!

Егерменче гасыр күпер көтә,
бугаз аша кирәк тоташу.
Европа соң югалтканмы әллә
шәрык биргән фәлсәфә ташын?..

Үз чыгышын эзли һәммә халык,
таралса да бер үк тамырдан.
Күңелләрне кирәк тоташтыру! —
Континентлар күптән аерылган.

### Севилья

Севильяда әфлисуннар пешкән,
кояш нуры яна эчләрендә.
Ак болыттай күгәрченнәр төшкән
кипарислы мәйдан өсләренә.

Машиналар шавын читкә кагып
ишетелә тояк тавышлары.
Затлы фаэтоннар, ыспай атлар,
тик нигәдер моңсу карашлары.

Җилләр телен белгән Лорка үзе
килеп чыгар кебек борылыштан.
Гитараның күкрәгенә кулын
куеп, башлар җырын яңабаштан.

Баш очында зәңгәр касә кебек
тын күк йөзе ята онытылып.
Шагыйрь күңеле очып йөридер күк
шушы киңлекләрдә бер кош булып.

Ә мәйданда кошлар иңгә куна,
бала-чага, шау-гөр — мең тамаша.
Кошлар телен белгән шагыйрь тавышын
гүя эзли мәйдан еллар аша.

Севильяның күге шундый аяз,
шагыйрь җаны көйри үз җирендә.
Гвадалквивирга мин акча ташлыйм,—
тагын килим... Лорка шигырендә!

●

«...Агыла да болыт агыла
туган-үскән илләр ягына».

Андалузиянең күкләре
бер болытсыз аяз чагында,
ник соң шушы шигырь юллары
сагындырып куйды тагын да?

Туфанлы иде бит май ае...
Аның бик аз калган гомерен
җилләр әллә хәбәр иттеме,
сизеп ак чәчәкле күңелен?

Туган илгә кайтып килгәндә
калын болытларга күмелеп,
Сулкылдашып куйды йолдызлар,
белгән сыман аның үлемен.

Һаман шул җыр мине уята,
кагыла да хәтер ярына.
Агыла да болыт агыла,
Туфан үскән җирләр ягына...

## Көзге юл чатында

Олы юлдан чыгып киткәннәрнең
көзге яфрак кебек язмышлары.
Кай тарафка сибелмиләр җилдә...
Ә һавада торна тавышлары.

Көлдә пешкән бәрәңгеләр тәмен
алып килә төтен ызаннардан.
Каз мамыгы шыткан болыннарда
ак шәүләләр йөри узганнардан.

Ни авылда түгел, ни шәһәрдә —
уртаклыкта торган бу җанымны

калыргамы, китәргәме өнди
тузанымы юлның, томанымы?..

Көтә мине, көтә китәр юлым.
Озатканда һаман бер сүз әйтеп,
карт әтием бирә каты кулын:
— Бүтән күрә алмам, күңлем сизә,
соңгы тапкыр күрешәбездер, улым...

Ә һавада торна тавышлары,
ишетелә канат кагышлары;
кошларда да кеше язмышлары,
еракларга китеп барышлары...

●

Төнге урман. Агач башларына
тиеп-тиеп китә йолдызлар.
Алар өчен еллар, Вакыт ни ул? —
Ә җирдәге гомер тиз узар.

Күккә тамыр җибәргәндәй тора
мең тармаклы юеш имәннәр.
Авыр тамчы тамган ботакларны
сулы карлар җиргә игәннәр.

Төнге урман аша күккә карыйм;
бу дөньяның Олы серенә
төшенмәкче әллә нәни акыл?—
Йолдызларга кадәр үрелә.

Ә йолдызлар сине үртәгәндәй
күз кысышып яна, талпына.
Нәрсәнедер күптән белгән кебек
дәү наратлар тора якында.

Бу дөньяның бакыйлыгын тоям.
Төнге урман. Җиһан. Тамчылар...
Биеклеккә үрләр өчен баскан
агачлар да — гүя юлчылар.

Баш очында киек казлар юлы...
кайчандыр бер
әллә шуннан җәяү төшелгән?..
Әле ачылмаган Олы сергә
мин бүген дә ахры төшенмәм.

## Без яшь әле...

Җәй хәтерен коя көзге урман,
талгын гына яфрак сибәли.
Юлга чыккан фикердәшләр, туктап,
тезелгәнбез учак тирәли.

Йөзләр көләч учак яктысында,
чыртлап китә кызган күмерләр.
Без яшь әле. Мәңге яшәрбез күк,
кабатланмас безнең гомерләр.

Төбәлгәнбез учак йөрәгенә,
ялкын белән ялкын берләшә.
Һәммәбезнең артта күләгәсе,
алар аерым нидер сөйләшә.

Киләчәктә кемнең кем буласын
күләгәбез әллә беләме?!
Безгә кадәр дә бит шулай булган —
берләштерми учак кемнәрне...

Аерылганны аю ашар диләр,
аюлар юк икән урманда,
аның урынын башка җәнлек алыр,
чигенер... без бердәм булганда.

Бердәм тостлар, уртак шатлык бүген,
һәммәбез дә бөек фикерле.
Дәртсез кайтавазлы көзге урман
моңсу гына көлгән шикелле.

Сүнеп бара учак, йокымсырап...
Соңгы тост та тәкъдим ителгән:
— Еллар үткәч, тагын бергә килеп
җылы алырбызмы бу төннән?!

Ә күзләрне ник соң яшерәбез? —
Әллә инде әче төтеннән...

## Ак кәгазь каршында

*Разилгә*

Бүтән булмас кебек... Соңгы җырың
тәмамланмый утка ягылган.
Ак кәгазьнең керсез актысыннан
күзләр арган. Күңел ябылган.

Канатсыз кош кебек сүлпәнәеп
чыгып китәсең дә юлларга,
син йөрисең, әмма син түгел бу...
Тәрәзәдән төшкән утларга
төннең кара бәрхет итәгенә
теккән ямау итеп карыйсың.
Бөтен нәрсә матурлыгын җуйган,
син шулардан тәмам арыйсың.

Табигатьнең күз карашын тоеп,
ярдәм сорагандай килгәндә,
соңгы җырга нокта куелды бит,
бүтән мәңге булмас дигәндә,
кинәт кенә күңел упкынынннан
саркый башлый серле чишмәләр —
күкнең биек катларыннан гүя
тышауланган уйны чишәләр.

Сиңа кайта тагын яшәү көче,
сине үз артыннан ияртә.
Йөгәнләнә Вакыт сүзләр белән...
һәм син инде тагын иярдә!

## Яшәү — мизгел генә

Төн юрганын тарттың күкрәгеңә —
күмелде ай болыт арасына...
Тып-тын булмә. Күзләр генә сөйли,
чәч яңгыры төшкән карашыңа.

Түшәмнәрдә урам уты аша
бәргәләнә тополь шәүләләре.
Табигатьнең сүзсез алкышы бу,
япмыйк әле калын пәрдәләрне.

Язмышлардан эзләп бер-беребезне,
җир йөзендә менә табышканбыз.
Җиләс кенә тымызык бер төндә
«мәңге» дими генә кавышканбыз.

Мәңге түгел, яшәү — мизгел генә,
диеп моңсуланмыйк. Кабатланыр!
Безнең хисләр бездән соң да калыр,
иң матур төс булып канатланыр.

Күбәләккә әйләнеп бу җаннар
болын чәчәгенә кайтып кунар.
Яратамы, яратмыймы, диеп,
таҗын өзми генә тагын юрар.

Ә хәзергә алда — яшәү яме,
мәңгелеккә нигә табынырга?
Син юраган чәчәк таҗларына
төн карасы кыймый кагылырга...

## Син каршыла

Озатырга килмә, дисәм дә мин,
сине эзлим һаман перроннан.
Син килеп тә әгәр күрми китсәм,
поезд чыгар кебек юлыннан.

Төнге җилләр генә хушлашамы
айлы рельсларга сарылып.
Шәһәр инде күмеләдер дисәм,
Сөембикә карый каерылып.

Чакрымнарны саный тәгәрмәчләр,
күңел белән күңел арасын.
Икәү йөргән урам-мәйданнарга
хуҗа булып бер син каласың.

Шундый әмер бир син: ачсын барсы
тәрәзәсен, катлы пәрдәсен.
Сандугачлы шәһәр тынлыгыннан
үз-үзенә кайтсын һәммәсе.

Син йокласаң, бөтен шәһәр йоклар,
вакытында сүндер утларын.
Канат бир син кешеләргә төштә —
калдырсыннар биек йортларын.

Күк кабызган айлы шәмгә карап
төнге парлар торсын уйланып.
Ак түбәле, көмеш чыклы шәһәр
елмайсын бу таңда уянып.

Ә мин юлда. Тукталышым ерак.
Күңел кайтыр якка ашкына.
Миллионлы шәһәр синдә калды,
шәһәр булып чык син каршыма.

*1981—82*

## Рашат Низамиев

# ГАЛИЯНЕҢ БЕР КӨНЕ

хикәя



Иртә килгән коры, салкынча көз табигатьне генә түгел, кешеләрне дә ашыктырды. Авыл агайлары, сөйләшенеп куйгандай, дәррәү кубып, ишек-тәрәзәләрне нигыттылар, пычкы чүбе яисә балчык салып, йорт-абзар нигезен төпләделәр. Җәй буе диярлек ягылмый яткан мичләр, ниһаять, ялкын сулый башлады. Әнә, берьюлы морҗалардан төтен баганалары савылып чыга. Түбәләрдәге антенналарга тияр-тимәс булып агылган соры болытлар белән әлеге төтеннәрнең бер-берсенә тоташып, кушылып китүләрендә мәңгелек бер бәйләныш бар кебек.

Ферма юлыннан кайтып килүче тол хатын Галия, коймак пешерәсен хәтерләп, үзенең ничек итеп утынга чыгачагын уйлады. Ярымкараңгы абзар эчендә иң элек пөхтәләп өелгән утын әрдәнәсе төсмерләнер. Бераздан, күз ияләнә төшкәч, тонык кына яктырып, каен тузлары шәйләнә башлар. Кояш нуры сеңгән җәйләрне хәтерләтеп, борынга кайры исе, коры печән исләре килеп бәрелер. Аннары инде шылтырап кипкән эре, таза утыннарны берәм-берәм беләгеңә тезә башлыйсың.

Санап-санап кына җиде пүлән утынны кочагына төйи дә йорт ишегенә юнәлә Галия. Көзгә кергәч, һәркөнне шулай, юкса, ягылмаган өйнең ләззәте, рәхәте юк. Бер кочак утын дөньяңны сары май итә дә куя! Өйнең һавалары җиңеләя, түшәмнәре биегәеп киткәндәй була. Галия өчен ягарга утын алып керүдән дә шатлыклы, шуңардан да куанычлы мәшәкать юк...

Берәү... Монысы — мичнең урта бер җиренә аркылы салыначак. Икәү... өчәү... дүртәү... Болары — мич төбенә тезеп куелачак. Алтау... җидәү. Соңгы икесе... Чү! Галиянең дүртенче пүләнгә дип сузылган кулы, нииндидер тылсым көченә бирелгәндәй, һавада асылынып калды. Әрдәнәнең чокырланып килгән бер уентыгында, дөньядан бихәбәр булып, ярты литрлы шешә ята иде. Байтак посып ятканга охшый бу — өске ягын тузган каплаган. Шешәнең ачылмаган калай бөкесе дә, бизәкле этикеткасы да Галиягә яхшы таныш иде. Я аллам! Гайсаның исән чакта үз куллары белән яшереп куйган «ярты»сы лабаса бу! Яшерен-батырын түгел, салгалый иде Гайсә. Әмма эчкәнен буеча сеңдерә белде, гаиләдә һәм ил-көн каршында беркайчан да гауга чыгармады. Эштән соң, буыннар язылып китсен дип, тоткалый торган иде. Яшь

хатын Гайсаның әнә шул гадәтен өнәп бетермәде, хәмер исен сөймәде. Бу хакта күп тукый торгач, үзгәрде ире, шулай да сирәк-мирәк кенә «тота» иде. Монысы да кирәк-мазарга, дип яшереп куйган нәрсәсе булгандыр, күрәсең.

Галия, мәрхүменең ниндидер серен ачарга теләгәндәй, тырыша-тырыша шешә пыяласын кулъяулыгы белән сөртте. Аптырап калу галәмәте булдымы, шунда көтмәгәндә шешәсе кулыннан төште дә китте, ләкин ватылмады. Чистарып, яктырып калган әлеге табылдыкны, нишләрен дә уйлап бетермәстән, сак кына халат кесәсенә шудырды хатын.

Малайлар уенда иделәр. Өйдә тып-тын. Башка вакытта утынны, мич алдына чүгәли төшеп, берәм-берәм генә бушата торган иде ул. Бу юлы иелеп торасы итмәде — кесәдәге табылдыкның төшеп ватылуы мөмкин — кочагындагы утынны аягүрә килеш кенә мич алдына ташлады. Идәнгә дөбердәп төшкән пүләннәр урындыкта йокымсырап яткан мәчене һәм казан тактасы өстендәге чәйнекне сискәндерде. Мәче «лып» итеп идәнгә сикерсә, чәйнек капкачы исә сәер генә зеңләп алды... Күңел дә кайчак шулай сискәнеп куя бит, онытылган нәни генә вакыйгаларга чаклы хәтернең кайсыдыр почмагыннан убылып төшә дә, я елмаерга, я моңаерга мәҗбүр итә сине.

...Каравыл өенең беркайчан да ирләрдән бушап торган юк, тоз сипкәннәр диярсең. Эштән кайтышлый дистәләгән ир-ат шунда кереп тәмәке пыскыта, ил-көн хәбәрләрен, дөнья хәлләрен сөйләшә. Каравылчы аксак Закир карт «кунаклар»ының озаклап утыруыннан шулкадәр оста файдалана, хәтта кирәк чакта утынга да чыгып торасы булмый аңа. Сыңар аяклы кешене йөртү уңайсыз — каравыл өенең мәңге туз-мый, мәңге картаймый торган мичендә утынны күп вакыт ирләр чыгып алып керәләр. Тик тора торган җан түгел бит, берсендә шулай утынны Гайса күтәреп керә. Күтәреп керә дә, дөбердәтеп, кисәк кенә мич алдына ташлый. Ирләр, әлбәттә, сискәнешеп куялар, нинди чебен тешләде сине дигәндәй, Гайсага текәләләр.

— Беләсезме, егетләр, кичә хатын белән юктан гына үпкәләшкән идек. Соң... мендәр җылысы ләкмәде, аерым ятып йокладык. Бичәм мине бүген йокыдан әнә шулай дөбердәтеп уятты...— дигән ул, ирләрне бәхетле елмайтып.

Авыл җире бит, Гайсаның бу кыланышын Галия икенче көнне үк озын телләрдән ишетеп белде. Әйе, булган иде шул андый хәл. Ә хәзер... Чиләктән чайпалып төшкән су тамчыларын, бар, җыеп-тергезеп кара син!

Бик тә гаярь, бик тә уңган кеше иде Гайса. Кушсалар, комбайнга утырды, тау башындагы хәтәр участокларда ашлык суктырды. Кулына балта тотса, йомычка бураны уйнатты, кувалдага орынса, тимердән очкын чыгарды. Шулай да иң шашкан, җан аткан нәрсәсе трактор иде. Үзе салган нык, таза күпернең бүрәнәләрен трактор белән дөбердәтеп узганда аның йөзендәге елмаюны күрсәң икән — бераунең дә шушы табигый, крестьянча елмаюны кабатлый алганы юктыр әле, валлаһи!

Кичләрен эштән кайткач, билгә кадәр чишенә дә ишегалды читендәге яшел юынгычны шылтырата башлый. Табигать биргән йомры, хәрәкәтчән мускуллары, күрегез мине дигәндәй, әллә каян күзгә бәрелеп, уйнаклап тора. Иренең су чәчрәтеп юынуын карарга вакыт тапкан хатын — бәхетле хатын ул. Гайса әнә шуны тоеп, рәхәтләнеп елмая, Галиясе кулындагы чуклы сөлгегә үрелә. Үзе тәнен сөртә, үзе һаман тракторы турында сөйләнә:

— Беләсеңме, җаный, бүген сөт машинасын Бака сазлыгыннан тартып чыгардым. Тракторда адәм акыллары бар анда. Сыйпап-җайлап сөйләшсәң, сазлыкның үзен дә төбе-тамыры белән суырып алыр ул.

Сүгендеңме, тупас кыландыңмы — бетте диген! Я күпердән очасың, я баганага сәлам бирәсең...

Өйләнешкән елны ук йорт житкереп керделәр. Гыйнвар суыклары башлангач, эре йолдызлар чекрәеп янган кышкы кичләрнең берсендә Галия игезәк малай тапты. Ул төнне Гайса йокламады, капка төбенә чыгып, бик озаклап тәмәке пыскытты, көрт эченә күмелгән алмагачларга карый-карый, матур уйлар уйлады.

Гайса киләчәкне тоеп, ашкынып яшәде. Улларына жиденче яшь китте дигәндә, кыш башында ук район үзәгеннән икесенә дә пар мәктәп формасы, ак күлмәкләр, аяк киемнәре һәм ике «Әлифба» китабы алып кайтты. «Әлифба» китабы белән бәхетле йортның бусагасыннан беренче сентябрь тантанасы да атлап керде. Кече бакчадагы өр-яңа такта чолан, абзар тулы кышлык утын — болары исә Гайсаның соңгы бүләкләре. Чолан түбәсен япканда да, урманнан төшкән утыннарны турап өйгәндә дә нигәдер ашыкты, ашкынды Гайса, әйтерсең, күңеле нидер сизенгән аның...

Үлем агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри, диләр бит. Дөньяның нинди генә ялгышы, хатасы булгандыр инде: Гайсаны агач басып үтерде... Галиянең йөрәгендә, күкрәк турысында бертуктаусыз утлы күмер көйри хәзер. Пешерә, ялкыны жанны көйдерә, аяк табаннарына хәтле яндырып төшә. Әле дә ярый иренең төсе булып, игезәкләр калды,— күп вакыт шуларга карап юанасың. Ләкин кайчак аларның гөнаһсыз күзләренә туры караудан да кыен нәрсә юк: малайлар гомер буе «әти» дигән иң куәтле сүзне әйтә алмаячаклар бит. Нинди рәхимсезлек!

Ә беркөнне...

Сумаладай караңгы төн иде, малайларның тимер караватта таралып йоклап яткан, ә әниләренең оекбаш бәйләгән чагы. Көтмәгәндә ферма ягыннан авылга төнге трактор килеп кермәсенме? Куәтле мотор тавышы урамнарны күмеп китте, тәрәзәләрнең дымлы пыяласын зыңлата-зыңлата, өйгә бәреп керде.

Менә тимер аваз отыры якынайды, көчәйде. Куркынып йокыдан уянган малайлар, күзләрен уа-уа, саташулы сорау бирделәр:

— Әни, әллә әти кайттымы?

Сикереп торуын сизми дә калды Галия. Идәнгә атылган йомгагы, шарлы яшен сыман, өй бушлыгына тәгәрәде, болай да чайпалырга торган күңелен пыран-заран туздырып ташлады. «Я аллам, әле кайчан гына колакны иркәли, күңелне назлый торган сорау иде бит лабаса!..»

Ана, йоклагыз дия-дия, балаларның өстен япты, тамарга торган күз яшьләрен көч-хәл белән күңел төбенә йотты...

...Бу минутта тагын да көчәеп, куәтләнеп киткән хакыйкать ачысы Галиянең күзләрен томалады, кул-аякларының хәлен алды. Юк, юк! Үзенең кылган эше, төсе-кыяфәте, елмаюлары белән исәннәр хәтерендә яши икән, димәк, андый кешенең тере, исән саналырга хакы бар. Моннан нибары өч ай элек кенә ышкыланган чолан такталарында, абзардагы утын әрдәнәләрендә Гайсаның кул эзе, күкрәк көче ярылып ята. Үзләре салып кергән йортның сагызлы бүрәнәләрендә, тәрәзәләрнең челтәрле кәрнизендә аның елмаюы чагыла, мәңгелек рухы, жаны төсмерләнә. Хәтта әрдәнә арасыннан табылган шушы гөнаһсыз шешәгә дә Гайсаның уч жылысы йогып калгандыр шикелле. Тазалык шәп иде аның, беркайчан да сәрхүшләнеп, кылтаеп йөрмәде. «Төшергән» чакларында мулрак итеп елмаер, сүзнең жеген-жеккә китереп тәмләп кенә сөйләшер иде. Тәмәке исе килеп торган кешеңне әрләп алуның: «Әйдәле, бер-беребезнең кадерен белеп кенә яшик»,— дигәнрәк мәгънәдә әйтелүен аңлый, бик тә аңлый иде Гайса.

Галия шкафтагы стаканның ни сәбәпледер бизәклесен, юка пыялалысын сайлап алды. Өч бармак калынлыгы салынган усал эчемлеккә

баштарак кагылырга кыймый торды, ярамаган эш өстендә тотылгандай, чыгарган сулышын йота алмады. Аннары, тәвәккәл хәрәкәт ясап, утлы стаканны иреннәренә тигезде... Әмма йота алмады. Уң кулының бармак араларыннан саркып, эчемлек клеенка өстенә тамды. Күз яше белән кушылган бу тамчылар — хәтер тамчылары...

Менә алар — егет белән кыз — табигатьнең шул тиклем дә иркен, илаһи киңлегендә икесе генә канатланып йөгерәләр, арып-талып, чәчәкле болынга барып капланалар, бер-берсенең кайнар күкрәгенә баш куялар.

— Син мине нигә яраттың соң, Гайса?

— Йөрәгең яхшы синең, Галия!

«Йөрәгең яхшы синең...» Шушы сүзләрнең талгын кайтавазы ун тапкыр, йөз тапкыр кабатлана, әкрен-әкрен генә ераклашып, офыклар артына күчә. Бөтен дөнья салмак кына йөзә, тирбәлә. Күге — диңгез, болытлары — дулкын... Кинәт, калын-калын болытларны үтеп, саргайган чирәмле ишегалдына Гайсасы кайтып төшә. Өч ай элек кенә үз куллары белән юнган бүрәнәләрнең берсенә утырып тәмәке кабыза, моңсу күзләре белән Галиягә төбәлә.

— Йөрәгең яхшы синең, Галия! Сезне калдырып китүем өчен үз-үземне гафу итә алмый йөрим.

— Кирәкми, Гайса, безнең алда синең бернинди гаебең юк. Язмыштыр, күрәсең.

— Ялгызыңа кыен түгелме? Игезәкләрне укытасың, кеше итәсең бар.

— Ялгызлыкка ничек тә өйрәнермен, тик менә балаларның әтисез үсүен күреп йөрәк әрни. Рәхмәт инде, сыерны кышлату өчен колхоз бер трактор печән бирде. Малайларны сөттән, майдан аермам.

— Дөнья куам дип бик бетеренмә. Саулыктан да зур байлык юк...

— Ә гомер?

— Әйе, исән чакта гомернең кадерен белмибез икән. Гомер ике килә торган булса, мин тагын да сине сайлап алыр идем, Галия! Кешеләр гомер буе дөреслеккә җавап эзлиләр. Без синең белән аны иртәрәк таптык шикелле.

— Утыз яшемнән тол калдым. Шулмы дөреслек?

— Безнең өчен шулайдыр. Ә менә дөреслекнең барлык адәм балаларына да бердәй дәрәҗәдә кагыла торганы бар, ул — яшәү мәгънәсе. Үзең үлгәннән соң да җирдә якты эзең, җан байлыгың калырга тиеш. Кызганыч, мин боларына өлгерә алмадым.

— Ни сөйлисең, булмаганны! Син салышкан йортлар, күперләр, син сөргән басулар җирдә калган эзең түгелмени? Мин аларга карап узган саен һәрвакыт кул җылыңны, игелегеңне тоям. Ә малайлар... Сөйләшүләре, хәрәкәтләре — гел син. Аларда синең каның ага, Гайса!

— Анысы шулай. Малайлар димәктән, чоландагы балта, ышкы, чүкеч, кул пычкысы, өтергә кебек эш коралларын шуларга дип саклап тот. Минем кан ага икән, балта эшен яратырга тиеш алар. Ниме... бозаулар торагын чистартырга, дип ясаган агач көрәгем эшкә ярадымы соң? Юкса, байтак ич бозауларың, берүзеңә утыз.

— Фермага эшкә барган саен рәхмәт укыйм үзеңә, синең төсең дия-дия, дәртләнеп эшлим. Шул «өтер» борынлы бозаулар да юаныч кайчакта. Шуларның маңгаеннан сөйсәң, муен асларын кашысаң, бүген тагын җан иләрен сөендердем дип кайтасың.

— Эшеңнән юаныч табуың әйбәт. Ә менә мәхәббәттә нишләрсең соң?

— Син минем беренче һәм соңгы мәхәббәтем. Күзләрем күрүдән туктаса да, телем сине сөйләр. Телемнән язсам, йөрәгем синең исемне кабатлап тибәр, Гайса!

— Җан бар бит, җан. Син әле гомереңнең уртасында гына...

— Мин инде үзем өчен түгел, улларыбыз өчен яшим. Бәхетем — шуларда. Чөгендер Исмәгыйлен беләсең бит, күптән түгел аны ферма мөдире итеп куйдылар. Ирсез хатын дип уйлагандыр инде, берничә тапкыр аулакта сүз кушып, әрсезләнеп карады, кәнтәй. Башак болгаткыч таяк белән кундырдым үзенә. Ачу сакламый саклавын, шулай да электәге якты чырай юк аңарда.

...Ир белән хатын байтак сөйләштеләр. Әлеге хыялый сөйләшү җанда никадәрле яктылык, тәндә никадәрле җиңеллек калдырып китте! Агачлар һаман да шаулатып яфрак коя, аларның сап-сары яфраклары карасу бәрәңге бакчаларын яктыртып җибәргән. Күктә һаман да болытлар йөзә, әмма алар үткәннәрдән бүгенгегә таба агыла иде.

Болытларны җимереп кояш чыкты. Ничәнче көн инде кояш яктысы күрмәгән авыл өстендә, әйтерсең, күк капусы ачылды: йокымсырап утырган йортлар, урамнар, моңаеп калган ферма һәм басу юллары, юл читендә талгын гына гүләүче телеграмм баганалары уянып киткәндәй булдылар, тоташтан нурга күмелгән авыл киңлегендә табигатьнең үзе кебек тылсымлы бер аваз тирбәлеп торды.

..................

## *Бер сорауга — бер җавап*

*СОРАУ: Бүгенге әдәбиятыбызның нинди сыйфаты аеруча көчәюен телисез?*

*ӘМИРХАН ЕНИКИ:*

*— Белмим, бәлки табигатем, бәлки яшем белән бәйләнгәндер, әмма мин үзем әдәби әсәрләрдә гадилек, табигыйлек һәм җылылык булуын яратам. (Хәер, элек-электән үк бу шулай иде). Билгеле, әсәрләр бер-беренә охшап тумыйлар, алар күбрәк «хуҗаларына» охшап туалар. («Мал иясенә охшый», дигән мәкальне ишеткәнегез бардыр?!) Ләкин шулай да мин һәрбер язучы табигыйлек белән гадилеккә омтылырга тиеш дип беләм. Чөнки табигыйлек ул тормышчанлык дигән сүз, аңа һәрвакытта ныграк ышанасың. Ә гадилек әсәрне үтемлерәк итә, укуы җиңел-рәхәтрәк була.*

*Ихтимал, кайберәүләр моның белән килешмәсләр, «кайда монда образлы сүз, штрих, бизәк, матурлык? — примитивлыкка өндисең, абзый!» — диярләр. Һич тә дөрес түгел. Бөтен матурлык нәкъ менә гадилектә, әгәр дә ки, мәсәлән, ...Чехов кебек яза белсәң!!*

..................

# Кави Латыйпов

●

Язлар килер, сулар агар,
эрер тәрәздәге абагалар.
Тик онытылмас
икәү каршылаган кышкы таңнар.

Йөрәк янар.
Ә кайдадыр абагалар шаулар.

Һәм инде, түгел сурәттә —
табигатьтә...

Өзмә абагаларны,
мине сөйсәң, Бибигайшә.
Күңел — абага, ул да үсә.
Ләкин җил кисә...

●

Сөялле куллар
сука тотты, кылыч кысты
һәм җиңүче булып чыкты.
Сөялле куллар өчен
Күтәрәм мин бу тостны.

Алтын табылмас,
сарай салынмас,
йолдыз кабынмас —
булмаса сөялле куллар.

Ишетәсезме,
шома бармаклы,
алтын балдаклы
гамьсез яшь кызлар, яшь уллар?..

●

Йөрәк әрнүемне сизгәнсең,
Әйтәсең: «Ничек кенә
түзгәнсең?..»

Яшим дисәң,
чигенмим, җиңелмим дисәң,
түзәсең икән.
Тормышның тугызынчы
дулкынында
йөзәсең икән.

●

Төнге чишмә белән сөйләшеп утырам,
әйтерсең, ул — су кызы җаны.
Юктыр да чишмәләрнең саны,
су кызлары — санлы...
Су кызлары җанлы!

●

Кар ява зират өстенә.
Һәммәбез — җир баласы.
Һәммәбезнең үз йолдызы,
ләкин ничек табасы?
Кар-буранлы һавасы.
Һәркемнең үз йолдызында
бардыр серле тамгасы.

Ничек кенә табасы?..

●

Бер мизгел гомерле таң була,
бер мизгел гомерле җан була.
Берсе галәмдә, көмеш болытлар артында,
берсе җирдә, язмыш канатында.
Ә без, бәхетлеләр, яши бирәбез,
яшәү ямен күрәбез.

Таңнар, җаннар, зинһар, сүнмәгез!

●

Тормыш — диңгез,
гел айкала,
гел чайкала...
Алып чыгар
минем җилкәнне ул кая гына?
Бәрмәс микән
тормыш кыясына?

Айкалсын, чайкалсын дөньясы,
хыянәт итмәм күңелем кыйбласына!

АЭС — Казан утлары — әдәби пост

# Газиз Кашапов

# ...ҺӘМ БАШЛАНДЫ ЯҢА КӨРӘШ



Татарстан җирендә илебезнең мактанычы саналырдай яшь калалар бар. Аларның даны ерак-еракларда шаулый. Әлмәт һәм Лениногорск, Түбән Кама һәм колачының киңлеге, үсеш темпларының тизлеге белән тиңдәше булмаган КамАЗлы Брежнев шәһәре. Аларның язмышы Татарстан һәм туган илебез үсеше белән аерылгысыз бәйләнгән. Соңгы вакытта, илнең энергетика базасын ныгыту юнәлешендә, Татарстанда тагын бер зур төзелешкә нигез салына башлады. Ул — Татарстан атом электр станциясе, төзүчеләр һәм атом энергетикасы куәтләрен файдаланучылар шәһәре булып күтәреләчәк. Хәзергә әле шәһәрнең исеме юк, әмма озак та үтмәс, борынгы Чулман елгасының биек яр башында заманча бизәлгән, ак ташларга һәм мәрмәргә төренгән шәһәр калкып чыгар. Бәлки аңа яңа төзелеш янындагы борынгы Кама Аланы авылының исемен үк бирелер. Хикмәт анда түгел. Монда атом көчен тыныч хезмәткә җигә торган реакторларны төзүчеләр һәм станция хезмәткәрләренең туган йорты барлыкка килер. Утыз-утыз биш еллар элек, Татарстан нефтен үзләштерә башлаганда, һөҗүмгә баручылар өчен терәк булырдай бердәнбер Бөгелмә тимер юл станциясе бар иде. Әлмәт һәм Лениногорск, Азнакай һәм Җәлил, Зәй, аннары Түбән Кама нефть химиясе гигантлары, аның янәшәсендәге КамАЗ һәм Брежнев шәһәренә бара торган йөкләрнең иң күп өлеше Бөгелмә аша узды. Дөрес, бераз соңгарак калып булса да, борынгы Бөгелмә үзе дә яңарды, икенче яшьлегенә керде.

Ә менә Татарстан атомчыларының туган йорты берсеннән-берсе куәтлерәк туган абыйлары, иң яңа төзелеш индустриясе базасына ия булган Түбән Кама һәм Брежнев шәһәрләренә таяна. Яңа каланың нигезен алар сала, йортларын алар күтәрә, Атом электр станциясен алар кора. Чөнки аларның партия һәм совет хөкүмәте билгеләгән зур бурычларны намус белән үтәп чыккан һөнәр ияләре, энтузиазмы, яңа көрәшләргә омтылышы бар.

Партиянең XXVI съездында атом энергетикасын тизләтелгән темплар белән үстерү турында яңа программа кабул ителеп, унберенче бишьеллыкта Татарстан атом электр станциясен төзи башлау турында сүз чыккач, бу җаваплы эшне зур төзелешләрдә чыныккан «Камгэсэнергострой» производство берләшмәсенә тапшырдылар. Әле кайчан гына КамАЗның икенче чираты сафка кертелде — җиңүләрнең җиңүе яуланды. Инде шул төзүчеләр коллективы яңа бурычны шатланып кабул итте.

Шушы уңай белән берләшмә җитәкчесе, Татарстан АССР Верховный Советы депутаты, Социалистик Хезмәт Герое Евгений Никонорович Батенчук: «Безнең төзүчеләр гүзәл шәһәр һәм автогигант кордылар, аларга дан һәм шөһрәт! Алар белән без Татарстан атом электр станциясен дә, һичшиксез, корырбыз, барлык

бурычларны намус белән һәм партия куйган вакытка үтәп чыгарбыз!» — диде.

КамАЗны, Түбән Камадагы нефть химиясе корылмаларын хыялдан бар иткән төзүчеләр булачак Атом электр станциясе белән чын-чынлап кызыксындылар, бик күпләр анда барырга теләк белдерделәр. Зур төзелешләр сулышы белән, андагы киеренкелекне тоеп яшәргә өйрәнгән кешеләр өчен бу — хәтта табигый нәрсә иде.

Кама буенда башланып киткән яңа төзелеш биографиясеннән берничә өзек китерик.

**1982 ел.** Беренче февральдә Татарстан атом электр станциясенең төзелеш мәйданына Брежнев шәһәреннән КПССның XXVI съезды исемендәге, Өметгәрәй Наурбиев җитәкләгән механикалаштырылган комплекс килеп төште, һәм шушы ук көнне Түбән Кама районының Кама Аланы авылы янында АЭСнең беренчел таянычы булырлык корылмаларны салу башланып китте. Монда аларны пионер базасы дип йөртәләр. Төзелеш эшләре тиз арада үз эзенә төште. Ел башыннан алып билгеләнгәндәгегә караганда ике тапкыр күбрәк капитал салу үзләштерелде. Торак төзелеше башланды. «Атомэнергострой» исемле яңа төзелеш идарәсе булдырылды. Аның участоклары оештырылды, вагоннар куелды. Кама Аланына Зәй шәһәреннән һәм Ширәмәт авылыннан бетон юл салырга тотындылар.

**1982 ел.** Октябрь. АЭСнең пионер базасында измә-бетон узелындагы өч җайланманың беренчесе сафка басты. Ул сәгать саен 30 кубометр измә чыгара. «Атомэнергострой» төзелеш идарәсенең Л. Салецкий төзүчеләре, берләшмәнең электр челтәре предприятиесеннән килгән Н. Сәлимгәрәев җитәкчелегендәге участок монтажчылары аеруча зур фидакарьлек күрсәттеләр.

**1982 ел.** Беренче сентябрь көнне АЭСнең пионер базасын төзүчеләр беренче өч катлы йортны салып бетереп, аның бер өлешен мәктәп итеп җиһазладылар. Яңа мәктәпнең уңсигез бүлмәсендә кырык биш бала укый башлады. Аларның унбишесе — АЭС төзүчеләренең балалары.

Татарстан атом электр станциясен һәм Кама буендагы яңа шәһәрне кору өчен көрәш менә шулай башланып китте.

## Тарихи белешмә

«Каманың сул як ярында, Чишмә елгасы тамагыннан 20 чакрымда, 2500 кешесе һәм 500 мең пот ашлык, утын озата торган пристане булган Алан (Полянки) авылы урнашкан. Авыл янында гына Камага Уратма елгасы килеп кушыла. Ул елга буенда, Алан авылыннан 5 чакрым чамасында Нератов фамилияле алпавытның 6500 дисәтинә җире һәм Пановка авылы бар. Нератовларның Анатолий Иванович дигәне балачагын һәм яшүсмер елларын шушы авылда уздырган, ул крестьяннарны азат итү буенча шактый эшләр алып барган, сенатор дәрәҗәсенә күтәрелеп үлгән. Пановкадан 2 чакрым җир киткәч, Уратма, яки Ширәмәт, яки Богородское дип тә атала торган тагын бер авыл бар. XVII гасырда бу җирләр Үркәев фамилияле татар морзасының биләмәсе булган, ә инде XVIII гасыр урталарында граф Шереметов тарафыннан сатып алынган. Ширәмәт авылында 5 мең кеше яши, бу авыл губернаның промышленность белән шөгыльләнүче иң бай авылыннан санала. Бирегәге кешеләр иген игүдән тыш, тире эшкәртә дә беләләр. Мондагы 53 тире эшкәртү заводы һәм 70 дирбиялэр ясау остаханәсе, аяк киеме тегү, олтан, кызыл һәм ак йомшак күн, бозау күне, биялэйләр, йөгәннәр кебек товарларны елына 100 мең сумлык җитештерәләр. Авылда волость идарәсе, чиркәү, больница, ссуда биру-саклык кассасы, базар, 20 мең сумга кадәр товар сата торган Ивановка ярминкәсе бар»... («Очерки по родиноведению. Казанская губерния». Казан университеты типографиясе. 1912 ел. Төзүчесе — Н. Спасский).

## «Тормыш юлы...»

Бу яклардагы кешеләр элек-электән юлга чыгуны әҗәл белән очрашуга тиң күреп яшәгән. Чөнки алда коточкыч Ширәмәт тавы тора. Аңа җәяүлеләр көч-

хәл белән күтәрелгән, атлылар күпме арба-чана ваттырган, тәртә бавы өздергән, күпме атның аягы сынган, соңрак бирелә күпме машина ауган, фаҗигалар булган... Берничә ел элек, әле АЭС кору турында сүз дә чыкмаган чакта, Түбән Кама районы җитәкчеләре Ширәмәт тавына беренче һөҗүмне оештырдылар. Дөрес, башта әллә ни майтара алмадылар, ләкин күпмедер тәҗрибә тупладылар, аз-маз көч белән генә бу тауны җиңеп булмасын ачыкладылар. Ярдәмгә нефтехимиклар һәм шинчылар, төзүчеләр дә кушылды. Куәтле техника көндезләрен дә, төннәрен дә бөтен көчкә эшләде, Ширәмәт тавының таш катламнарына үтеп керделәр. Борынборыннан кешеләрнең җиңелүен күреп килгән тау акрынлап бирешә башлады. Меңләгән кубометр таш чыгарылды, тау сөзәгәйтелде, өстенә асфальт та түшәргә исәпләделәр. Шулай итеп, Ширәмәт тавы җиңелде. Кешеләр иркен сулап куйдылар. Ниһаять, юл ачык, теләсә кайсы якка чык та кит! — дип уйладылар. Озак та үтмәде партиянең XXVI съезды трибунасыннан бөтен илгә «Татарстан атом электр станциясен төзи башларга!» дигән күрсәтмә яңгырады... Аннары Ширәмәт тавы ягыннан моңарчы күренмәгән кораллар белән эзләнүчеләр килеп чыкты. Алар артыннан скреперлар һәм тагын әллә нәрсәләр уза башлады. Ширәмәт авылының үзәк урамына да асфальт түши башладылар, аннары Кама Аланы ягына таба юл өяргә керештеләр.

Юл салу... Безнең борынгы бабаларыбыздан, юл азабы — гүр газабы, дигән сүз калган. Ширәмәт тавы кебек җирләрне кичкән кешеләр чыгаргандыр аны... Хәзерге техника заманында, бер-бер артлы гигант заводлар калкып чыккан, шәһәрләр күтәрелгән чорда да юл узу кыенлыгы үзенең мәгънәсен саклый әле. Нинди генә куәтле булмасын, яхшы юлың юк икән, техника озак йөри алмый: бата, чума, ватыла...

Ширәмәт белән Кама Аланы авыллары арасы болай караганда әллә ни ерак җир дә түгел, нибары ун чакрым. Тик язын-көзен бу араны исән-имин үтүләре ай-һай авыр. АЭС төзүчеләр өчен бигрәк тә. Чөнки аларга бар нәрсәне дә Түбән Камадан, Зәйдән, Брежнев шәһәреннән ташырга туры килә. Шулай булгач... Хәер, төзүчеләр — кыенлыкларны кичерергә өйрәнгән халык, алар әлеге арага «Тормыш юлы» дип исем дә кушып өлгергәннәр.

Билгеле, тагын берничә елдан Татарстан атом электр станциясенә, аның янында калкып чыгачак шәһәргә асфальт-бетон юл гына түгел, тимер юл да тоташыр, елга порты да барлыкка килер, бәлки әле үзенең аэропорты да салыныр. Ләкин болар барысы да соңрак булыр, һәм аларны ясауда менә шушы беренче бетон юлның әһәмияте әйтеп бетергесез зур. АЭС төзүчеләрнең беренче терәк базасын сала башлаган көннәрдә барлык йөкне читтән китерергә кирәк. Димәк, бирегә йөзләгән-меңләгән тонна йөк агыла башлаячак.

Хәзер бу җиде метр киңлектәге асфальт-бетон юл әзер инде, аннан байтак кына машиналар узып өлгергән. Ләкин аны салган көннәр, АЭСне кора башлаучылар күңелендә озак сакланыр, чөнки аларның бик күп кыенлыклары, АЭС тарихының беренче елында кичергәннәре шушы юл булмауга бәйле иде.

1982 нче елның сыкы суык февраль ае. Без, бер төркем журналистлар, Татарстан атом электр станциясенең пионер базасы төзелешенә, Өметгәрәй Наурбиев җитәкчелегендәге скреперчылар бригадасы барасын ишеткәч, озын-озак уйлап тормыйча, юлга кузгалдык. Ширәмәт авылын чыгып, беркадәр баргач та, үр башында тупланган тракторлар, грейдерлар, автомашиналарны күреп, туктарга булдык.

Машинадан чыгып басарга өлгермәдек, чатлама суык битләрне чеметә дә башлады. Шәһәр эчендә, урманда яисә үзәнлек урыннарда утыз градуслы салкынны җиңел кичерергә була, әмма биредә, Ширәмәт янындагы үр башында ул суык икеләтә суыграк иде. Без этешә-төртешә вагон эченә керергә ашыктык. Бер төркем ир-атлар арасында юл салучылар бригадиры Валерий Чумаков та бар иде. Без аның белән берничә ел элек, авыр йөк автомобильләре берләшмәсенең кою заводындагы җайланмалар нигезен салган вакытта танышкан идек. Хәл-әхвәл сорашабыз. Дөрес, безнең хәл-әхвәл сорашуыбыз урында яткан авыру кешедән саулыгын сораган кебегрәк килеп чыкты. Чөнки болай да аңлашыла — эшчеләрнең кәефе шәптән түгел.

— Менә бүген әлегә кадәр бер генә машина да килмәде, бетон юк,— диде Ва-

лерий. Иптәшләренә, туктап торыгыз, дип, кул изәде.— Түбән Камадан китерәләр безгә бетонны. Бернинди график, бернинди тәртип юк әлегә. Башта, билгеле, андагы төзелешләр канәгатьләндерелә, аннары гына, артык калса, безгә... Күрәсең, андагы кайбер иптәшләр озакламый яз киләсен, АЭС төзүчеләрнең кыен хәлдә калачагын аңлап бетермиләрдер...

Ул көннәрдән соң яз житте, җәй көннәре үтеп китте. Икенче тапкыр юл салучылар белән Бөек Октябрьның 65 еллыгы җитеп килгәндә очраштык. Алар инде байтак үрләрне үтеп, менә дигән соңгы үргә менәләр. Кама Аланы янында зурзур хәрефләр белән «ТатАЭС» дип язылган билгегә җитеп киләләр, нибары 900 метр бетон түшисе калган иде.

Үч иткәндәй, көннәр бозылып, бөтен тирә-юнь пычракка күмелгән. Пионер базасына бары тик куәтле «вездеходлар» гына үтә ала, 900 метр юлсыз арада аларны да тракторлар тартып бара. Төзү материаллары — тимер-бетон конструкцияләр, әре панельләр, төрле җиһазлар төягән машиналар, шушы араны узалмыйча, кире борылып та киткәлиләр. Чөнки пионер базасына җитәргә башка бер генә чара да юк...

Валерий Чумаков бригадасында, КамАЗда чынығу алган кешеләр белән бергә, үзләренең беренче төзелешләрен башлаган яшьләр дә байтак. Көнне төнгә ялгап, башка бригадалар белән яныл-көеп, юлны ничек кенә булса да Октябрь бәйрәменә кадәр тоташтырырга тырышып эшли иде. Бетон төягән машиналар да чиратка тезелеп торалар шикелле, әмма Валерий барыбер канәгать түгел.

— Ул менә гел шулай килеп торса, тәүлек әйләнә эшләр идек. Вулыр-булмас бер чакрым җирне ике, ахыр чиге, өч-дүрт көндә узар идек, юлның бер ягын булса да тоташтырыр идек,— диде ул, аннары бездән гафу үтенде.— Булмый, егетләр, булмый сөйләшеп. Ике-өч көннән, юлны салып бетергәч, рәхим итегез, күпме кирәк шуның хәтле сөйләшербез.

1982 елның 6 ноябрендә Кама Аланына килүче машиналар яңа гына түшәлгән юлдан, пычракка чуммыйча, батып ятмыйча, җилдереп кенә уздылар.

Татарстан атом электр станциясенең пионер базасын һәм яңа шәһәрнең иң беренче йортларын торгызучыларның бик күп мәсьәләләре әнә шулай хәл ителде, нәтиҗәле эшләр башкаручыларга аяк чалучы юлсызлык чоры бетте!

## Пионер — «беренче» дигән сүз

Яңа төзелеш кайчан, кайсы мизгелдән яисә нәрсәдән башлана соң? Бу сорауга төрле кеше төрле җавап кайтара алыр иде. Миңа калса, яңа төзелеш ул кытыршы робалар кигән, арган-талган кешеләр вагоннарга кайтып тулып, сәндерәләргә егылган мизгелләрдән, мастер-прорабларның әдәби телдә йөрми торган сүзләр белән ачулана-ачулана төзү материаллары табарга ашыккан көннәрдән, читтән килгән кешегә баш җитмәслек ыгы-зыгы, хаос сыман тоелган тәртипсез тәртиптән башлана. Мин беләм: доньякүләм төзелешләрдә катнашкан кешеләр дә, еллар үткәч, әнә шул тәртипсез тәртип хөкем сөргән көннәрне сагынып искә төшерәләр. Чөнки нәкъ шул чорда төзүчеләрнең романтик күңелендә тыныч хезмәттәге бер генә кешегә дә кичерергә туры килми торган киеренкелек туа.

Хәзер Татарстан атом электр станциясе төзелешендә — шундый көннәр. Аны кемнәр төзи, аның беренчел терәк базасын кемнәр сала, алдагы һөҗүмнәрне кемнәр хәзерли соң?

## Курбатов

Виктор Иванович, «Атомэнергострой» идарәсенең баш инженер урынбасары. 1967 елда Куйбышев төзүче инженерлар институтын бетергән һәм Волга автомобиль заводын, Зәй ГРЭСен, КамАЗның көпчәк заводын салуда катнашкан. Халыклар дуслыгы ордены кавалеры. Мәһабәт гәүдәле, көч-гайрәте ташып тора, чынык-

кан йөзле, киң маңгайлы, коңгырт чәчле, эре адымлы кеше. Коммунист.

Без аның белән «Атомэнергострой» идарәсе партия комитеты секретаре Рифкат Кәшифович Кәтиев бүлмәсендә таныштык. Отчет-сайлау җыелышы башланырга тиеш иде. Виктор Иванович яңарак кына Кама Аланындагы төзелеш мәйданыннан кайткан.

— Барлык эш тоткарлана шул әле, әлеге дә баягы, юлга терәлә бөтен нәрсә, юлга... Шушы җиде-сигез йөз метр ара аяк чала. Дөрес, юл төзүчеләргә дәгъвабыз юк безнең. Чөнки алар көнне — көн, төнне төн димичә эшлиләр. Алар тырышлыгына сокланып узабыз, югыйсә, җил-яңгырлар аларга да комачаулап торалар...

Төзелеш идарәсе коммунистларының отчет җыелышында төп сүз партия һәм хөкүмәт ышанып тапшырган бу олы бурычны үтәп чыгардай коллектив туплау турында булды. Виктор Иванович Курбатов та чыгыш ясады. Аңа турыдан-туры АЭС төзелеше мәйданында яшәп эшләргә туры килә, шуңа күрә барлык коммунистлар да игътибар белән тыңладылар.

— Коллектив туплау — катлаулы нәрсә. Безгә, коммунистларга, кешеләрнең аңында бердәм теләк һәм бер максат белән яшәүгә омтылыш уятырга кирәк,— диде Виктор Иванович.— Без Зәй ГРЭСен, Чаллыдагы җылылык-энергия үзәген төзү чорында кешеләрнең бер-берсенә якынлыгы, иптәшләргә мөнәсәбәте, тапшырылган эш өчен җаваплылык тоюлары, җаваплы бурычны үтәгәндә, никадәр әһәмиятле икәнен яхшы аңладык.

Икенче көнне, иртүк, Виктор Ивановичның ярыйсы ук таушалган бәләкәй автобусы белән АЭС төзелешенә таба кузгалдык. Сүз кичәге җыелыштан башланып китте.

— Турысын әйткәндә,— диде Виктор Иванович,— быел без коллектив туплау белән чынлап шөгыльләнмәдек әле. Чөнки кешеләрне урнаштыру мәсьәләсе тулысынча хәл ителмәгән. Ләкин озакламый бу мәсьәлә белән ныклап шөгыльләнергә тиеш булачакбыз. Әлегә яңа кешеләрне күпләп кабул итүдән тыелып торабыз. Килергә теләүчеләр күп. Бигрәк тә яшьләр күп килә. Хәзер инде төзелеш мәйданындагы вагоннарда өч йөзләп кеше яши. Зәй, Брежнев шәһәрләреннән килеп эшләүчеләр дә бар. Алар атнага бер-ике тапкыр кайтып йөриләр. Су, җылылык мәсьәләләрен тизрәк хәл итәсе иде...

Виктор Иванович хаклы, аның борчылулары урынлы. Төзелеш идарәсе коллективлары алдына елдан-ел катлаулырак бурычлар куела, капитал салу арта бара. Пионер базасын салуны төгәлләгәч, төзүчеләр станциянең төп мәйданына күчәргә тиеш. Шуңа кадәр торак мәсьәләләрен хәл итәргә кирәк.

Көзге салкыннар башланган вакыт иде. Тизрәк котельныйларны эшләтә башларга кирәк. Соңгы вакытта андагы эшләр кызу темплар белән башланып киткән. Кама ягыннан салкын җил исә. Ул да, котельныйны эшкә җибәрү — иң мөһим мәсьәлә, дип кисәтә сыман...

*ИСКӘРМӘ: Төзүчеләр үзләренә йөкләнгән бурычны җиренә җиткереп үтәп чыктылар. Бөек Октябрь социалистик революциясенә 65 ел тулган көнне ике пар казаны эшкә җибәрелде һәм төзүчеләр яши торган вагоннарга, беренче торак йортка җылы биреле.*

Гасырлар буена тыныч бер тормышта яткан Кама Аланы авылы бу көннәрдә туздырып ташланган кырмыска оясыдай кайный. Бульдозерлар, скреперлар, экскаваторлар җирне актара, тегендә дә, монда да кран манаралары калкып чыга, куәтле «КамАЗ»лар, «БелАЗ»лар, «Шкода»лар, «КрАЗ»лар үкерешә. Төзелештәге иң мөһим урынны ачыклавы да шактый кыен.

Виктор Ивановичтан калышмаска тырышам, ул кая барса, шунда атлыйм. Һәм... ялгышмыйм. Виктор Иванович биредәге һәр кешене, һәр блок-панель, торба һәм тагын әллә нәрсәләрне биш бармагыдай белә. Биредәге һәр кеше һәм һәрбер нәрсә, иртәме-соңмы, Виктор Иванович Курбатовка килеп төртелә. Аңардан башка бирелә бер генә мәсьәлә дә хәл ителми. Ул — генподрядчының биредәге иң җаваплы вәкиле.

Бәхеткә каршы, төзелеш штабында резин итекләр бар икән. Виктор Иванович ниндидер оешмага шалтыратып, аңлашкан арада, шушы итекләрне киеп алам да бәхәснең сәбәбен белергә тырышам. Виктор Иванович та минем кызыксынуымны сизгән икән.

— Менә өченче көн инде кирпеч китермиләр,— дип тезеп китте.— Брежневтагыларның әйтүенә караганда, машиналар борылып кайтырга мәҗбүр булалар икән. Кичә дә шулай иткәннәр. Без кичә көне буена юл өзегендә ике трактор тоттык. Ә шоферлар алар янына килеп тә җитмәгәннәр, җайлы урыннан борылып киткәннәр. Өйрәнгәннәр, асфальттан йөгертергә...

Котельныйны сафка керткәннән соң төзүчеләр бетон измәсен әзерләү җайланмасын көйләп бетерергә тиешләр. Югыйсә измәне Түбән Камадан яисә Зәйдән ташыйлар. Бу хәл эшне тоткарлый, чөнки, беренчедән, андагы оешмалар иң башлап үз ихтыяҗларын кайгырта, икенчедән, кырык биш-илле километр килгәнче, измә куера, аңа өстәмә су кирәк була...

Су исә — пионер базасын төзүчеләрне шактый бимазалаган мәсьәлә. Кама суын тау башына менгезү өчен тиешле корылмалар кирәк. Аларны коралар, эш туктап тормый, ләкин мәсьәлә шунда ки, аларны корган чакта да су кирәк...

Пионер базасында кое бораударга булдылар. Виктор Иванович шундый тәкъдим кертте. Хәзер, 140 метрны тишеп үткәннән соң да, тиешле күләмдә су килмәгәнне белгәч, кайберәүләр әлеге эшне артык эш, файдасызга көч һәм вакыт сарыф итү дип бәя бирә башлаган. Сәгатькә 20 кубометр, нибары 20 генә кубометр су кирәк, әлегә 5—6 дан узмый. Виктор Иванович хәзер шунда юнәлә. Мин аның артыннан барам.

Бораулаучылар янына киләбез. Алар беравыздан: «Тагын унбиш-егерме метрдан да чыкмаса...» — диләр. Димәк, Виктор Иванович, йомшаграк итеп әйткәндә, бик күңелсез хәлдә калачак. Мин аның йөзенә карыйм. Каушау галәмәтләрен табалмыйм, аның бер генә мускулы да селкенми. «Бораулагыз, егетләр, дәвам итегез эшне!» — дип, алга таба атлый. Адымнары электәгечә ышанычлы, хәрәкәте җитез.

*ИСКӘРМӘ: Тагын бер атнадан пионер базасындагы коедан сәгать саен егерме биш кубометр су бәрә башлаганын мин «Камгэсэнергострой» берләшмәсендәге киңәшмә вакытында ишеттем...*

Кичкырын без Виктор Иванович белән атом станциясенә беренчел кирәк базаны төзүчеләрнең торак поселогындагы вагоннарны карап йөрдек. Ул вагоннар Брежневтан китерелгәннәр, аларда моннан ун еллар элек автоград төзергә алынган яшьләр рухы яшәгәндәй тоела. Виктор Иванович та шул хакта уйлап бара икән.

— Бу вагоннар игелекле вагоннар үзе,— дип сөйли башлый ул.— КамАЗны торгызыштылар, инде менә АЭСне коруга хезмәт итәләр.

Вагоннарның күбесендә монтажчы-төзүчеләр яши, калганнарына төзелеш штабы, ашханә, элемтә челтәре, кызыл почмак урнашкан.

Болар барысы да күптән түгел генә булдырылган. Тиздән мондагы төзелешнең колачы киңәячәк. Чөнки 1984 елда Атом электр станциясенең төп корылмаларын корырга киләчәкләр.

Хәер, Виктор Иванович Курбатов төп корылмаларны салучылар арасында да булачагына мин үзем бер генә минутка да шикләнмим. Бу тынгысыз кеше — яшәү мәгънәсен бары тик шушындый киеренке хезмәттә генә таба торганнар токымыннан.

## Сәләхов

Рәис элек «Камгэсэнергострой» берләшмәсенең Брежневтагы йортлар төзү комбинаты бригадиры иде. Коммунист. Кайчандыр чем-кара чәчләренә сизелер-сизелмәс кенә чал керә башлаган. Бераз гына моңсу күзләре белән кешеләргә туры карый, тыйнак, кирәк чакта, таләпчән, күңелләргә юл табарга сәләтле. Оештыру талантына ия. Татарстан атом электр станциясен төзүчеләр һәм аннары аны файдаланучы атомчы энергетиклар шәһәрен коручы Брежнев йортлар төзү комбинатының 63 төзү-монтаж идарәсенең 7 нче участогы начальнигы ул.

Ширәмәт ягыннан килгәндә Кама Аланы авылы күз алдында кинәт пәйда була. Үр артыннан үр менәсең, менәсең дә, ниһаять, соңгы үзәнлектә бер-бер

артлы тезелешеп торган таза агач йортлар күренә башлый. Алар озын-озын ике урамны тәшкил итәләр. Тагын бераз баргач, ике үр арасыннан Каманың киң, якты йөзе ачыла. Гасырлардан гасырларга күчеп килгән бу күренеш соңгы елда яңа төсмерләр алды, танымаслык булып үзгәрде.

Без, авылның киң урамыннан узып, уртадагы үзәнлеккә төшәбез. Моннан Кама өсте аерата матур, сокландыргыч булып күренә. Нәкъ шушында озын-озын борыннарын күккә чөйгән кран манаралары утыра. Алар янәшәсендә булачак шәһәрнең беренче йортлары күтәрелә. Куәтле машиналар һәм тракторлар изеп бетергән, күптән түгел генә Кама Аланы авылының мәктәп бинасы торган урыннан төзүчеләр куйган вагоннарга узабыз. Каршыда — яңа гына салынып беткән ике йорт. Менә-менә өлгерергә торганнары тирәсендә краннар әйләнә.

Таныш күренеш. Дөрес, Брежневтагы төзелеш панорамаларына күнеккән кешеләр өчен, биредә торгызыла торган биш-алты катлы йорт әллә ни искитәрлек тә түгелдер. Тик мондагылар яңа шәһәр тууын хәбәр итүләре белән кадерле. Ул нинди булырга тиеш соң?

— Атомчы энергетиклар шәһәрен коруның берничә проекты каралды,— дип сүзен башлады күптән түгел генә республика телевидениесе күрсәткән бер тапшыруда Брежнев йортлар төзү комбинаты начальнигы Марат Шакирович Бибишев.— Аларның берсендә шәһәрне элеге үрләр күкрәгендә торгызырга планлаштырганнар иде. Матурмы? — Матур! Елга ягыннан караганда, бигрәк тә матур шикелле. Ләкин бит шәһәрне болай корган очракта бу яктагы барлык уезл җилләр шушы йортларга килеп бәреләчәк. Кулай вариант түгеллеге аермачык күренеп тора моның. Аннары яңа шәһәрне хәзерге авылның чокырдагы өлешеннән башларга, табигый үзәнлекне, үрләрне файдаланырга кирәк дигән фикергә килделәр. Билгеле, төзүчеләрнең эш шартлары биредә беркадәр катлаулана, әмма киләчәктә бу шәһәрдә яшәргә килүчеләр безгә — хыялны чынга ашыручыларга — рәхмәт әйтерләр.

Хыялны чынга ашыручыларның берсе күптәнге танышым Рәис Сәләхов булып чыкты. Мин ул төзегән шәһәрдә, Брежневтагы ул салган йортта яшим, аның хыялы аша чынлыкка әверелгән урамнардан йөрим, киң һәм матур проспектларга сокланып туя алмыйм.

Яңа шәһәрнең торак йортларын төзүчеләр штабына кергәндә, иртәнге киңәшмәнең кызган чагы иде. Гадәттә сабыр, тыйнак күренгән Рәис ярыйсы ук кызган. Сүзнең асылына төшмәкче булып барлык игътибарымны туплыйм, бәхәснең очын эләктереп алам: салына торган йортлар арасында әчке юллар юк икән. Шуның аркасында гаять киеренке хәлләр килеп чыккалый. Брежневтан, комбинатның эре панельләр ясый торган заводыннан, берьюлы диярлек егерме өч машина җибәргәннәр. КрАЗларның тәгәрмәче күмелерлек пычрак, өстәвенә, әлегә сүтелеп бетмәгән иске йортлар комачаулый, панельләрне уздырып булмый. М..шиналарны тартып-тартып чыгарырга тиешле тракторларның берсе соңга калган... Рәис Сәләхов киләчәктә мондый нәрсәнең кабатланмаска тиешлеген аңлата. Ашыгыч чакта, кайдан, нинди тракторларны алырга мөмкин икәнлеген күрсәтә. Бу, билгеле, ярым-йорты чара гына иде. Рәис тә, аның тирәсенә тупланган прораб-мастерлар, бригадирлар да моны аңлый, шуңа күрә мәсьәләне тиешле җитәкчеләр алдында таләпчәнрәк куярга кирәк дигән фикергә киләләр.

Ул арада сүз җылылык бирүгә әйләнеп кайта. Монтажланган йортларны бизәргә керешергә кирәк — җылылык юк, эштән кайткач, рәхәтләнеп юынырлар иде — җылылык юк, эш арасында Брежневка йөрергә туры килә...

Киңәшмәдән соң Рәис белән булачак шәһәрнең беренче йортларын карап йөрибез. Менә мәктәп, шул ук өйдә — почта, саклык кассасы, телефон, телеграф, милиция бүлеге.

Рәис үзе минем белән булса да, уйлары узган киңәшмәне дәвам итә икән. Ул барган көйгә: «Булмый болай, озакламый мунча салырга кирәк! — дип куйды.— Котельный эшли башлагач, су да, мунча да булса, күпчелек монда яши башлаячак».

Рәиснең, күпчелек, дигәне — Брежнев һәм КамАЗ төзелешләрендә чыныккан кешеләр. Дөрес, яңалар да күп килә, ләкин хәзергә әйдәп баручылар — тәҗрибәле

төзүчеләр. Мәсәлән, Өлфәт Гайнуллин. Менә дигән монтажчы иде, аннан бригадир булды. Биредә дә сынатмый. Коммунистлар аны парторг итеп сайладылар. Сылаучы Люция Шәмсетдинова да КамАЗ төзелеше сынавын узды, аннары тынгысыз күңеле аны «Атоммаш» төзүчеләр янына, Волгодонск шәһәренә алып китте. Туган якларда АЭС төзелә башлагач, Брежневка яңадан кайтырга булдым, ди. Александр Киселев. 1971 елдан бирле Брежнев шәһәре төзелешендә техник инспекциядә эшли иде. Инде АЭС төзелешенә прораб итеп күчерүләрен сораган.

Рәис Сәләхов үзе — Брежнев һәм КамАЗ төзелешендә чыныгу алган кеше. Аның кешеләрне җитәкләргә сәләтле икәнлеге дә шул төзелешләрдә ачылган. Ул үзе җитәкләгән комплекслы агымда злобинчылар ысулын кертүдә гаять зур роль уйнады. Хәер, Сәләхов һәм ул җитәкләгән коллектив турында хәзер кабатлап торуның кирәге юк кебек, чөнки алар турында илебезнең иң күренекле журналистлары яздылар. Минемчә, Кама буйларындагы төзелешнең иң кызган һәм иң киеренке бер чорында Рәис Сәләховның гигант төзелештә эшләүчеләр исеменнән беренче тапкыр СССР Верховный Советы депутаты итеп сайлануын әйтү дә җитә. Брежнев шәһәре төзелеше әле дә киң колач белән дәвам итә, Рәис Сәләхов кына анда түгел инде. Җаен табып, аның Брежневтан ничек китүен сорарга булдым.

— Бик табигый килеп чыкты ул,— диде Рәис гадәтенчә тыныч кына.— Көннәрдән бер көнне йортлар төзү комбинаты начальнигы Марат Шакирович Бибишев мине чакырып алды да: «Рәис, син — безнең торак төзелеше буенча белгечебез. Сиңа, кем әйтмешли, җае чыгып тора»,— диде. Мин инде безнең комбинатның АЭС төзүчеләре өчен яңа шәһәр салырга алынганын ишеткән идем. «Шунда җибәрәсезме»,— дип сорадым. Марат Шакирович — утны-суны кичкән җитәкче, кирәкмәсә, җибәрмәс иде. «Үзебезнең коллектив беләнме?» — дип кенә сорадым. «Юк,— ди,— кайбер кешеләрне алырсың алуын, ләкин син анда участок начальнигы булып китәсең, торак төзүне башлап җибәрәсең...»

Башлап җибәрүчеләргә һәрвакыт кыен. Рәис Сәләхов ул кыенлыкларны КамАЗ һәм Брежнев шәһәре төзелешләрендә җиңеп чыккан. Әмма һәр төзелешнең үзенә генә хас үзенчәлекләре, кыенлыклары була.

Рәис белән атомчы энергетикларның булачак шәһәрендәге иң беренче йортларны карап йөрибез. Алар әле бизәлмәгән, төзелешләрдә була торган ыгы-зыгы, тәртипсезлек эченнән калкып кына киләләр. Ләкин Рәис инде аларны гүзәлләрнең гүзәле итеп күрә. Аларны гынамы соң?! Рәис инде гаҗәеп матур яңа шәһәрне дә күрә. Хыялында күрә, ул хыялның озакламый чынлыкка әвереләчәгенә шикләнми.

— Хәзергә ул шәһәрнең барлык сыйфатларын тәгәл атап булмый,— ди Рәис Сәләхов.— Быел торак комплекслар проектлаштыручы Үзәк фәнни-тикшеренү һәм экспериментлар институты шәһәрнең генеральный планын тәгәлләргә тиеш. Бу — Брежнев шәһәрен проектлаштырган коллектив. Яңа шәһәр дә аңардан кайтыш булмас дип уйлыйбыз, чөнки архитекторлар тәҗрибәсе елдан-ел арта бара бит. Иң беренче эскизлар белән таныштык, генпланның нигезендә шушы эскизлар ятачак, яңа шәһәрнең гүзәллеген чамалап була. Беренчедән, яңа шәһәр өчен сайланган урын бик матур, уңайлы...

Мин дә булачак шәһәрне күз алдына китерергә тырышам. Бу әллә ни кыен түгел, чөнки Рәис һәр нәрсәне күрсәтеп, аңлатып тора.

— Әгәр дә Кама ягыннан карасак,— дип сөйли ул, үзе ике үр арасыннан ерактагы офыкка таба атлый.— Өченче үрне күрәсеңме?! Анысы яр читеннән үк түгел, эчтәнрәк башлана. Булачак шәһәрнең төп ике магистрале менә шушы өченче үр сыртыннан түбәнгә, үзәнлеккә таба баш ала. Аның үзәк өлешен Җәяүлеләр проспекты тәшкил итәчәк. Монда иң матур биналар салынырга тиеш. Икенчесе — транспорт өчен. Ул магистраль торак йортларны, культура-көнкүреш биналарын промышленность-коммуналь хуҗалыклар зонасыннан аерып торачак. Үрнең түбәсеннән, Камага агып төшә торган бәләкәй елгалар уртасындагы шәһәр уч төбендәге сыман күренәчәк. Текә тау ягындагы, урман арасында шәһәр кешеләренең ял базалары, профилакторийлар, пионер лагерьлары булачак. Җәяүлеләр проспектында, нигездә, биш һәм тугыз катлы йортлар салыначак, 12 һәм 14 кат-

лы йортлар да каралган. Уртадагы үрнең үзәгендә шәһәрнең төп мәйданы, административ-культура үзәге калкып чыгачак...

Рәис Сәләхов булачак шәһәр турында онытылып, хыялга бирелеп сөйли дә сөйли. Шушы берничә минутта ул хәтта үзенең тавык чүпләп бетермәслек мәшәкатьләрен дә онытты бугай. Ул биредәге һәр карыш җирне йөреп чыгарга, өйрәнергә өлгергән. Генпланда булырга тиешле биналарны вак-төягенә кадәр күз алдына китерә.

— Менә монда,— ди ул,— шәһәр корыла торган үрнең көньяк битендә, икеөч катлы гына, бик матур йортлар салыначак... Кама яр буе аерата матур булыр кебек: елга порты, стадион, парк, комлыклар...

Рәис Сәләховның сүзләренә ышанмый мөмкин түгел.

Булыр, әлбәттә, барысы да булыр!

## Беренче концерт

Брежнев шәһәрендә яшәүчеләр белә инде: төзелешләрдә һәрчак җыр-музыка яңгырап тора, чөнки монда күпчелекне яшьләр тәшкил итә. Яшьлек исә музыка, җыр, шигърияткә тартылучан. Бу бик табигый хәл.

Татарстан атом электр станциясен төзүчеләр әлегә тупланып кына киләләр, аларның театрлары, мәһабәт Культура сарайлары юк әле. Әмма төзелештә җыр өзлексез яңгырый, яшьләр дә, олыраклар да җырлый-җырлый эшли. Борынгыларның «җырлап ачыла күңел» дигәне шулдыр, мөгаен.

Төзелешкә акрын-акрын Брежнев, Зәй, Түбән Кама һәвәскәрләре дә килгәли башлады. Концертлар вагоннарда, кызыл почмакларда була иде. Аларга иң күбе илле-алтмыш кеше сыя.

Бөек Октябрьның 65 еллыгына әзерлек көннәрендә исә төзүчеләр, пионер базасын торгызучы монтажчылар, «тормыш юлын» түшәүчеләр, причал эстакадаларын коручылар арасында «Казан артистлары килгән!» — дигән хәбәр таралды. Күп тә үтмәде, Кама Аланы авылының иске клубына халык җыела башлады. Иң җитезләре — торак төзүче кызлар булып чыкты: эш киемнәрен затлы күлмәкләргә дә алыштырып өлгергәннәр. Алар янәшәсендә үк төзүчеләр робасы кигән ир-егетләр тупланган. Кызларның, атнага, дип әйтмик, соңгы берничә айда беренче тапкыр кигән аллы-гөлле киемнәре егетләрне дә сагындырганлыгы әллә каян сизелеп тора...

— Бүген безнең алдыбызда, Татарстан атом электр станциясенең иң беренче объектлары салына башлаганнан алып иң беренче тапкыр Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт филармониясе артистлары чыгыш ясаячак! — диде «Атомэнергострой» төзелеш идарәсенең 3 нче төзелеш участогының цехком председателе Равил Хәлиуллин. Аның соңгы сүзләрен берәү дә ишетмәде, иске клубның тәрәзә пыялаларын зыңгылдатып, бердәм алкышлар яңгырады...

Ә бу вакытта танылган артистларыбыз ашыга-ашыга киемнәрен алыштыралар, сәхнәгә чыгарга әзерләнәләр иде. Хәер, сәхнәгә дигәннән, бу клубта махсус бүлмәләр, грим ясау, киенү бүлмәләре юк, шуның өчен артистлар сәхнәдә бизәнәләр иде.

Ниһаять, салмак кына пәрдә ачылды.

Рус, татар, украин һәм башка милләт халыклары вәкилләреннән тупланган төзүче-тамашачылар тын да алмый музыка-җыр тыңладылар, биюләр карадылар.

Татарстанның атказанган артисты З. Нурмөхәммәтов, Татарстанның халык артисткасы Ә. Заһидуллина, Р. Сибгатуллина, биючеләр К. Сираҗетдинова, Р. Габдрахманова, «Тантана» вокаль-инструменталь ансамбле чыгышлары һәркемгә тансык иде.

Бу күренештә дәүләткүләм мөһим эшләрне башкаручы совет кешеләренең бердәмлеге дә, хезмәтчәннәрнең сәнгатькә-культурага тартылулары да аерым-ачык чагыла иде. Әлегә Татарстан атом электр станциясен төзүчеләр янында Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең беренче вәкилләре генә булып китте.

Төзелешнең киләчәге шактый зур. Димәк ки, республикабызның культура работниклары, сәнгать осталары һәм, әлбәттә, язучылары алдында нинди җаваплы бурыч торганлыгын чамалавы авыр түгел. Бүгенге төзүче — белемле, югары культуралы кеше. Аның рухи ихтыяҗлары да шактый мул һәм нечкә. Шунлыктан әлегә торак һәм көнкүреш шартлары җитенкерәмәгән бер вакытта да төзелештәге яшьләр халык җырларын һәм композиторларыбызның әсәрләрен, Муса Җәлилнең һәм Пабло Неруданың үлемсез шигырьләрен ишетергә телиләр. Хәзерге шартларда, төзелеш мәйданнарындагы вагоннарда, күтәрелеп килә торган яңа йортларның түшәмсез бүлмәләрендә, куәтле «КамАЗ» һәм «БелАЗ» машиналарының әрҗәләрендә яңгыраучы ул җырлар һәм үлемсез шигырьләр энтузиастларны яңа җиңүләргә әйдәргә тиешләр...

Фидакарь хезмәт еллары үтәр. Кама буенда тагын бер яңа шәһәр калкып чыгар, аның янәшәсендә атомның иксез-чиксез көчләрен авызлыклаган реакторлар илгә энергия бирә башлар.

Шул чагында Кама ярларына сыенып яшәүче гүзәл шәһәр кешеләре яңа буын вәкилләренә: бу урында беренче төзүчеләрнең беренче вагоны куелган иде, монда беренче урамның иң беренче йорты салынды, диярләр. Үр башында, шоп-шома булып сузылган юлның алты-җиде йөз метрлык арасын, «тормыш юлы», дип, олылап телгә алганлыгы хакында да сөйләрләр. Шат күңелле кызлар һәм егетләр елга портының мәрмәр баскычлары буйлап күңел ачып йөрерләр, урам чатларындагы автоматлардан шербәт эчеп, сусыннарын басарлар, паркларда очрашырлар, комлыкларда су керерләр, ләкин шул вакытта алар: менә бу урында тирән сазлык булган, ә эшчеләр килеп, шушы сазлык аша унбиш метр биеклегендәге дамбаны, аның янында елга порты причалларын салганнар, төзүчеләргә су булмаганга күрә, беренче коены казыганда, төн йокыларын онытып эшләгәннәр, дип искә төшерерләр. Һәм үз чорларының тагын да олырак, колачлырак, масштаблырак яңа төзелешләрен башларлар. Алар арасында яңа буынның үз Курбатовлары, Сәләховлары, Кәтиевлары һәм бик күп бүтән каһарманнары булыр.

..................




## Җәүдәт Дәрзаманов

# ШӨГЕР—ГОМЕР СУКМАГЫ

ОЧЕРК



Атлас Кыямович Гыймаевның кәефе күтәренке, күңеле күр иде. Иртәнге утырышта хәтта кайбер эшләрен тәгәлләргә өлгермәгәннәрне дә уен-көлке белән генә кызартты. Идарәдәгеләр дә аңлый, бик аңлый председатель хәлен — дымга сусаган кырларны сугарып, бөтен тереклек дөньясын кинәндереп, төне буе шифалы яңгыр яуды. Киләсе елда амбарларга тук бөртекләр булып кайтасы яңгыр. Кара туфракта беленер-беленмәс утырган уҗым кыяклары туенып, көрәеп, көч-гайрәт ташып торган яшел нурлар булып, күккә үрелде. Хәвеф-хәтәрсез генә кышласалар, арыш киләсе елга да каерылып уңачак диган сүз. Димәк, дәүләткә сатарга да, орлыкка салырга да, терлекчелек өчен дә ашлык булачак.

Халык таралып, бүлмә бушап калуга, Атлас Кыямович телефонга карады — гадәттә бу вакытларда үзәктән шалтыратып, хуҗалыктагы хәлләрнең торышы белән кызыксына торганнар иде.

Председатель яңа гына тутырылган сводкага текәлде. Графаларга төшерелгән саннар, композитор каршында яткан нота билгеләредәй, бер-бер артлы телгә килеп, җанлана, хуҗалыкның төрле тармакларындагы хәлнең торышы турында сөйли. Ләкин ул матур симфония булудан ерак иде. Саннарның берләре күңелләрне назлый торган нәфис моң булып яңгыраса, икенчеләре көйләнмәгән скрипка тавышы шикеллерәк: сөт һаман артмаган. Мөмкинлекләр дә бар бит, югыйсә. Менә сарык караучыларга тел-теш тидерерлек түгел, ичмасам! Йон планы арттырып үтәлә.

Гамәлләрне күздән кичереп, мөһимнәрен куен дәфтәренә теркәп утырган арада, ике сәгатьләп вакыт үтеп тә китте. Кәгазьләрен өстәлнең бер тартмасына бикләп, председатель урамга чыкты. Җир инде ярыйсы ук җилләгән иде. «Нива» руле артына үзе утырып, туңга сөрүчеләр янына юл тотты ул. Тракторларның гөрләтеп эшләвен күргәч, тукталып тормаска булды, егетләрнең алтындай вакытларын әрәм итәсе килмәде аның.

Атлас Кыямович машинадан урман буендагы чишмә янында төште. Бала чактан ук ярата иде ул Зобай чишмәсен. Әтисе мәрхүм дә, җае чыкканда, чишмә янында хәл алырга ярата: шуның суын эчсәм, көч-гайрәт артканын тоям, ди торган иде. Атлас Кыямовичның кечкенәдән үк су кодрәтенә ышанасы килә иде. Әкиятләрдә сөйләнә торган тереклек суы хыялларда юкка гына тумагандыр ул!

Элек-электән үк халык каһарманнарына туган туфрак, саф сулы чишмәләр көч иңдергән. Бөек Ватан сугышы елларында дошманнарга каршы арысланнарча көрәшкән авылдашларына, Советлар Союзы Герое дигән югары исемгә лаек булган өч баһадирга да Туган җир, Туган туфрак, аларны сугарган инеш-елгалар гаярьлек биргәндер...

Атлас үзе дә малай чактан ук туган авылына, туган кырларына гашыйк. Беләкләрендә көч тоя башлауга, җәй башыннан алып, көз урталарына кадәр, кырдан кайтып кермәде: комбайнчы ярдәмчесе, сабанчы булып эшләде. Әвернәләр әйләнеп, игеннәр тезелмнәргә ятканда, күңелен шатлык тутыра иде аның. Шушы көннәрдә үк инде үзенең чын мәгънәсендә җир кешесенә, ата-бабаларның игеклелек һөнәренә тугрылыклы игенчегә әверелүен малай үзе аңлап та җиткермәгәндер, бәлки.

Иске Шөгер урта мәктәбен тәмамлагач, ул, шоферлар курсын бетереп, колхозда эшли башлады. Машина моторының тигез гөрелтесе һәрвакыт алга, каядыр еракка ашкындыра иде. Солдат шинеле кигәч тә егет техника янында булды. Армиядән кайткач, шофер һөнәре аны Глазово совхозына алып килде.

Руль тотып барганда ул һәрчак:

«...Юллар, юллар, авыр булса булсын,
Тик соңгысы гына булмасын...» —

дип җырларга ярата иде. Егет күңеленә башка уйлар да килә башлады. Әнә, классташларының берничәсе югары уку йортларына керде. Институт тәмамласа, ул да совхозга зуррак файда китерер иде бит, югыйсә. Һәм егет моны үзенә максат итеп куйды: ветеринария институтының зоотехника факультетына читтән торып укырга керде. Тора-бара аны туган авылы, басу-кырлары сагындыра башлады. Колхозларында белгечләр дә җитешми икән. Үз авылында әти-әнисенең нык нигезе була торып, нәрсә дип чит хуҗалыкларда тамыр җәяргә азаплана соң әле ул? Һәм Атлас үзләренең «Шушма» колхозына икенче зоотехник булып кайтты. Кыска гына вакыт эчендә байтак эшләрне җайга салырга өлгергәч, аны өлкән зоотехник итеп билгеләделәр.

Көннәрнең берендә Гыймаевны ашыгыч рәвештә КПСС райкомына чакырдылар. Шул ук сәгатьтә килеп җитәргә кушылганлыктан, ул, өс-башын да алыштырып тормыйча, мотоциклына утырып, Лениногорскига китте. Барган арада башына әллә ничә төрле уй килеп узды аның, тик үзеннән нәрсә таләп ителәчәген ул һич кенә дә тәгаенли алмады.

Райком секретареның беренче соравы да шактый серле килеп чыкты.

— Эшләрегез ничегрәк бара, Атлас Кыямович?

Әмма тел төбеннән үк сизелеп тора — райком секретаре бөтенләй башка нәрсә кызыксындыра иде. Шуңа күрә җавап та гомумирәк булды.

— Элеккечә, алга барабыз шикелле...

— Артка тәгәрәсәгез, сүзе дә башкачарак булыр иде,— диде секретарь.

— Әгәр дә сезне колхоз председателе итеп куйсалар, башкарып чыга алыр идегезме?

Дөресен генә әйткәндә, Атласның күңелен борчып, кулларын кычыттырып торган мәсьәләләр байтак иде колхозда. Тик бу хакта турыдан-туры ярып салырга батырчылык итмәде.

Тагын берничә көннән колхозчыларның гомуми җыелышында авыл халкы бертавыштан өлкән зоотехник, коммунист Атлас Гыймаевны хуҗалыкның председателе итеп сайлады.

Председатель камытын кигән беренче көннәрдән үк абайлады Атлас — бер елгызың гына тарта торган йөк түгел бу. Күмәк акыл, күмәк көч кирәк монда. Яшь «хуҗа», иң башлап, колхозның уставын җентекләп өйрәнде. Уставны белми торып, хезмәт дисциплинасын бозучыларга да тиешле чараны дөрес куллана алмыйсың. Средстволардан да дөрес файдалана белмисең, дигән сүз.

Белгечләр белән эшләүне дә акрынлап кына тамырыннан үзгәртте Атлас.

Элегрәк барысы өчен дә нәрәт вакытында бер председатель уйласа, хәзер һәркем үз өлкәсендәге мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итеп, председательне эшнең барышы белән таныштыра. Аеруча кирәк вакытта гына ярдәм сорый торган булып киттеләр. Бу исә, бердән, колхозчылар каршында белгечләрнең дәрәҗәсен үстерсә, икенчедән, белгечләр каршында да председатель авторитетын бермә-бер күтәрде.

Терлекчелекне күздән ычкындырмаган хәлдә, механизаторларның хезмәт шартларын яхшыртуны колхоз идарәсе алга изге максат итеп куйды. Заманча мастерской җитештерә башладылар. Аны аякка бастыруның кыенлыгын председатель үзе белә дә, идарә члennары белә. Төзим дип, нәрсәгә тотынсаң, анысы юк: я тиешле станокларын табып булмый, табылганының да чыкмаган җаны гына бар. Әмма нинди генә кыенлыклар булмасын, мастерской, котельный сафка басты. Техника җылы бинада ремонтлана башлады. Бу корылмалар — перспективадагы зур комплексның әлегә бер өлеше генә. Җылы гараж, складлар, ашханә, шунда ук кызыл почмак — болар инде якын елларда тормышка ашачак чынбарлык.

Алтмышынчы елларда салынган терлекчелек биналары соңгы елларда шулай ук зур мәшәкать тудыра башлады. Төзәтү эшләрен реконструкцияләү белән янәшә алып баруны хуп күрделәр. Нәтиҗәдә, терлек абзарлары җылытылды, яңа идәннәр түшәлде, автоэчергечләр куелды, кайнар су кертелде. Кичләрен ферма тәрәзәләреннән неон яктысы бөркелә башлады. Әнә шулай хуҗалык көннән-көн төзекләнә, ныгый барды.

Идарәне кадрлар проблемасы борчый иде. Шөгер нефте табылганнан соң, заман шаукымына бирелеп, күп кенә колхозчылар нефтьчеләр армиясенә кушылды. Заманында бу хупланды, вакытында бу кирәк иде. Әмма шушы кирәклек тудырган проблема хәзер дә катлаулана бара. Нииндидер көч бүген дә яшьләрне авылдан шәһәргә яки поселокларга тарта, эшче көч дефицитын елдан-ел арттыра.

Кадрларны авылда ныгытып калдыруда культура хезмәте күрсәтүнең дә әһәмиятле урын тотуын яхшы аңлап, колхозда ике катлы культура йорты салдылар. Циркачлар чыгыш ясарлык олы сәхнә, заманча җиһазланган зур тамаша залы, киң экранлы кино, бай китапханә, кече зал, бию мәйданчыгы, бильярд бүлмәсе — барысы да яшьләр карамагына бирелде. Шушы культура йорты яшьләрнең авылга карашын үзгәртте, дисәк тә, арттыру булмас шикелле. Кич җиттеме, механизаторы да, терлекчесе дә шунда ашыга. Яшьрәк гаиләләр генә түгел, өлкәнрәкләре дә өйдә утырмый, чөнки культура йортында колхозчылар күңеленә хуш килердәй чаралар оештырыла. Үзешчән сәнгать түгәрәкләре гөрләп эшли. Әле кайчан гына Иске Шөгер халкы, сәнгатькә булган сусынын кандырыр өчен, чакрымнар үтеп, район үзәгенә йөрсә, хәзер үз культура йортларына килә. Җырга сәләтең бармы, тумыштан колагыңа аю басмаганмы, җыр ансамбленә рәхим ит! Буш вакытларыңда музыка белән шөгыльләнәсең килә икән, оркестр бар. Рәхәтләнеп уйна, тик бер шарт белән — репетицияләр сәбәпсез калдырылмаска тиеш. Оркестр белән Рафаэль Әхмәтов җитәкчелек итә. Аның өлгерлегенә сокланып туялмый Атлас Кыямович. Менә егет дисәң дә егет ичмасам — үзе дә тынгы белми, башкаларга да тынгы юк. Мең төрле әмәлен табар, әмма оркестрга йөри башлаган кешене музыка белән тәмам сихерләмичә туктамас. Егетләр вокаль ансамбле үзени тора! Чыгышларын тыңлаганда, аларның көне буе майга батып сабан сөргән, ашлык урган егетләр икәнлегенә ышануы кыенлаша хәтта.

Менә Фәрит Гайнанов. Ул, армиядән кайтып, рәссам булып эшли башлаганнан бирле, колхоз идарәсе дә, башлангыч партия оешмасы һәм профсоюз комитеты да, комсомол оешмасы да кинәнде — теләсә нинди күргәзмә әсбапны, теләсә нинди рәсем яки плакатны коеп кына куя егетең. Аның тылсымлы пумаласы ярдәмендә культура һәм терлекчеләр йортының эчке бизәлеше дә, колхозның мактау тактасы да, ферма һәм кыр станнарының тышкы кыяфәте дә танымаслык үзгәрде.

Яшьләрне армиягә озату, каршы алу, кызыл туйлар, бәби туйлары, өлкәннәрне лаеклы ялга озатулар — боларның барысын да инде Иске Шөгер халкы гадәт итте, яңа йолалар алар тормышының күркәм бизәгенә әверелде.

Корал эшләр, егет мактаныр, дигәннәр халыкта. Бу мәкаль Атлас Кыямович-

ка яшьләр яратырлык тагын бер ачкыч бирде сыман. Ул яшь чакта техниканың иң начары, иң өметсезе яшь-җилкенчәккә бирелә иде. Имеш, әйдә, эшлиселәре килсә, башта төзәтеп карасыннар. Бу караш та яшьләрнең колхоз эшеннән күңелләре кайтуга аз йогынты ясамагандыр, мөгаен. Юк, бу хатаны кабатламаска тырыша председатель. Хәзерге иң куәтле машиналар — яшьләр кулында.

Председательнең яңа чаралары тылсымлы ишекне ачкандай итте. Җитмеш сигезенче елларда ук инде армиядән кайткан Фазыл Сәләхов, Рәшит Гайнанов, Роберт Хәйретдинов, Әсгать Хөббәтуллин, Нәфис Гыймаев, Илсөяр һәм Илгизәр Гәрәевләр кебек уннарча егетләр авылда төпләнеп калды. Тынгысыз көннәр һәм йокысыз төннәр тәүге җимешләрен бирә башлады. Роберт Хәйретдинов — районда иң яхшы кукуруз үстерүче буларак танылды. Аның звеносында шул ук яшьләр — Хөббәтуллиннар, Гайнановлар, Газизовлар... Әсгать Юнысов, Касыйм Хәмидуллин, Бәрый Миңнеахмәтов, Сәгыйть Шиһапов, Сәгыйть Фәтхетдинов, Рәис Гыймаев кебек өлкән механизаторлар, остаз буларак, шулай ук яшьләргә аталарча кайгыртучанлык күрсәтеп эшли.

Яшьләр дигәннән... Атлас Кыямовичның авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлау мәсьәләсе белән баш ватып йөргән көннәре иде. Кышын һәр механизатор үз өлешенә тигән машиналарны намус белән төзәтеп көйләп куя кебек. Үч иткәндәй, эшнең иң кызган чагында, механизмнар сафтан чыга. Кирәкле частьләрен, детальләрен тапканчы, кайчакларда икешәр, өчәр көн әрәм була.

Председатель янына баш инженер Сәгыйть Ганиев килде.

— Бер киңәш бар иде, Атлас абый,— ди ул.— Бу ремонт эшләрен баштанаяк аерым звенога тапшырсак, ничек булыр икән? — һәм ул үз фикерен дәлилли башлады. Атласның йөрәгә кысылып куйды хәтта! Менә бит, акыллы кешедән акыллы сүз чыга. Бу хакта председатель дә борчыла иде, ныклы карарга гына килә алмый йөрде. Бер карагында, дүрт механизаторны ел әйләнәсенә техникадан аеру дөрес тә түгел кебек. Әмма махсус ремонт звеносы даими эшли икән, машиналарның сафтан чыгуы сирәкләнәчәк. Запас частьләр булдыру, һәр агрегатны тагылма машиналар белән тәэмин итү өчен җаваплы коллектив туачак. Ватылган техника шунда ук төзеге белән алыштырыла, эштә өзеклеккә юл куелмый.

Идарә утырышында да бу тәкъдимне хупладылар. Звеновод итеп Гамир Галимовны билгеләделәр. Салих Хәлимов та звенода эшләргә бик теләп риза булды. Әхәт Каюмов белән Мөгътәсим Гыйльмановны шулай ук озак үгетләргә туры килмәде,— алар урынын техникага утырырга җан атып торган яшьләр алды. Звенога махсус бер трактор бирделәр — әйдә, рәхәтләнеп эшләсеннәр! Тагылма машиналарны кырга илтү, ватылганнарын мастерскойга алып кайту өчен дә уңай. Ремонт проблемасы гүя бөтенләй булмаган — шул чордан башлап, бүгенге көнгә кадәр колхозда тагылма машиналар турында сүз чыкканы юк. Оешканнан соң бер ел да үтмәде, бу звено белән районның башка хуҗалыклары кызыксына башлады, аларның да кайберләрендә шундый ук звенолар оештырдылар.

Атлас Кыямович өчен иң авыры, мөгаен, авылдашлары күңеленә үтеп керү булгандыр. Арада эленке-салынкы эшләүчеләр дә, акча артыннан куып «ил гизеп» йөрүчеләр дә, аз эшләп, күбрәк алырга теләүчеләр дә бар иде. Ничегрәк якын килергә үзләренә, ничегрәк сөйләшергә, ничегрәк аңлатырга? Берсе белән, малай чакта, йөкче булып йөрелгән, икенчесе белән — сабанчы, өченчесендә ярдәмче булып эшләнгән. Кайберләре — туган, башкасы — туганнан туганнар. Дуслар да күп. Һәрберсенең холык-фигылен биш бармагы кебек белә председатель. Әмма бу якынлыкның уңайсыз яклары да килеп чыкты. Малайсытып карарга теләүчеләр дә булмады түгел. Һәрберсенә ярап та бетеп булмый. Берсенә әйткән сүзең ошый, икенчесенә ошамый. Ошамаганы шулай ук йөрәктә нинди дә эз калдырып китә. Беркадәр уйланып, өйрәнеп, ныклы бер карарга килде Атлас Кыямович: иң беренче нәүбәттә эш, колхоз мәнфәгатьләре куелырга тиеш, аннан соң инде теләсә нинди мәсьәлә белән килсеннәр, ул аларга — туган да, дус та, авылдаш та...

Өлкән яшьтәгеләргә председатель тагын да зуррак ихтирам белән карый. Аңлый ул: алар — иң авыр елларда колхозны саклап калган, күмәк хуҗалык өчен вакытын да, сәламәтлеген дә аямаган кешеләр. Икенче яктан, алар — тәрбия чы-

ганагы. Өлкәннәргә никадәр хөрмәт-илтифат күрсәтелсә, ихтыяҗлары никадәр тизрәк канәгатьләндерелсә, алар колхоз белән тыгыз элемтәдә яшәсә, бу — яшь колхозчылар өчен күргәзмә дәрес кебек. Шуңа күрә өлкән буын — председательнең дә, идарәнең дә игътибар үзәгендә.

Туган як, туган авыл, туган колхоз... Үзләренең туган авылларында председатель булып эшләүчеләр сирәк очрый. Нилектән шулай? Бәлки урындагы кадрларны әзерләүгә игътибар җитмидер. Ә бәлки бу андый җитәкчеләрнең кайбер өстәмә кыенлыклардан азат булмавы белән аңлатыладыр. Атлас Кыямович моңа кистереп кенә җавап бирә алмый, әмма үз авылында эшләгән председательнең колхозчыларга зуррак файда китерүенә иманы камил аның. Һәрхәлдә, бу очракта бары тик план күрсәткечләре генә игътибар үзәгендә тормый. Андый председательне колхоз мәнфәгатьләре дә, авылның төзеклеге дә, урамнарның яшеллеге дә, колхозчыларның хезмәт-көнкүреш шартлары да бердәй кызыксындыра.

Зобай чишмәсе ага да ага. Тизрәк Шушмага кушылырга, аның гайрәтен арттырырга, куәтен ишәйтергә ашыга. Шушма — Камага, Кама — Иделгә, Идел — диңгезгә... Гади хезмәт кешесе шушы саф чишмә сыман. Куәтле дәрья үзенең көчен шундый чишмәләрдән алган кебек, хуҗалыкның куәте дә халыкның уртак тырышлыгыннан туплана. Һәм ул тырышлыкны, партиянең 1982 ел ноябрь Пленумында әйтелгәнчә, тагын да арттырасы, тагын да зуррак эшләргә юнәлтәсе бар. Шунлыктан бу мәсьәлә идарәнең оештыру эшчәнлегенең үзәгендә тора.

Хәл итәсе мәсьәләләр шактый әле: терлек азыгы базасын ныгытуны әзгә саласы бар. Берничә еллар элек 270 гектарлы мәйданда болын сазлыгын киптереп, культуралы көтүлек булдырганнар иде. Хәзер аның сугару җайланмаларын алыштырырга, көтүлектән өченче уңыш алуга ирешергә кирәк, бик кирәк, чөнки хуҗалык терлек симертү буенча специальләшә. Торак төзелешеннән дә канәгатьләнергә ярамый әле. Монысы үзе бер аерым мәсьәлә...

Машина кузгалып, кабат авыл ягына юл алды. Каршыда, сөекле баласын көткән ана сыман, колачын җәйгән Иске Шәгер күренә. Елдан-ел яңарып, яшәреп, киләчәккә кыю адымнар белән бара авыл. Һәм председатель, еллар үтү белән, туган авылының тагын да матураячагына, тормышының мулрак булачагына нык ышана.

Ләбибә Ихсанова

# ОЛЫ МАКСАТЛАРНЫ ОНЫТМЫЙК

Халыклар арадашлыгы, әдәбият, сәнгать арадашлыгы нык үскән бүгенге көндә кешеләр теләсә кайсы милләтнең генә түгел, теләсә нинди илнең культурасы белән якыннан таныша алган бу чорда үз әдәбиятыбызның иң югары биеклектә торуын күрәсе килү — табигый хәл.

Бәхәсне башлап җибәргән мәкаләләрендә бу мәсьәләгә икесе ике критерийдан — берсе ачу белән чаң сугып, икенчесе сабыррак тонда сүз йөртеп, булган уңышларны да барлау ягыннан килеп карасалар да, Аяз Гыйләҗев та, Рафаэль Мостафин да шул биеклеккә омтылуны алга куялар.

Әдәбиятыбыз артта кала дип, бар булганны күрми узу да дөрес түгел. Ел саен күпләп-күпләп күренмәсәләр дә, ун-унбиш елга сузылган ара эчендә тугандаш халыкларның теләсә кайсына уңайсызланмый тәкъдим итәрлек роман, повестьларыбыз булмады түгел бит, булды. Әгәр алар рус телендә җитәрлек яңгыраш тапмаганнар икән, монда инде оештыру эшләренең кирәк кадәр булмавы комачаулагандыр дип уйларга да мөмкин. Бик әйбәт тәрҗемәчеләр кирәк булган кебек, әдәбиятыбызны белә, ярата, шуның белән яши, укучының игътибарын үз вакытында шуңа юнәлтә, аны аңларга ярдәм итә торган абруйлы тәнкыйтьчеләребез булу да кирәк дип уйлыйм.

Ә шулай да, ирешелгәннәр белән канәгатьләнмичә, тагын да югарырак биеклекләрне яуларга телибез икән, мин үзем Аязча ярсып чаң сугучыларны яклар идем. .

Бөтенсоюз мәйданына чыгуны, әсәрләребезнең рус теленә тәрҗемә ителеп, Мәскәү нәшриятларында, үзәк газета-журналларда басылуын алабыз икән, Аязның борчылуы урынлы кебек. Чыннан да, әдәби журналлар актарганда башка халыкларның әдипләре белән беррәттән мең елга якын тарихы булган татар әдәбияты вәкилләренең дә әсәрләре күренмәү, я бик сирәк очрап куюлары аяныч. А. Гыйләҗев та шуңа көенәдер, шуның өчен прозабызны иң зур биеклектән торып хөкем итәдер. Аягына яңа гына баса башлаган әдәбият турында сүз барса, билгеле, кулын талдырып, вакыт уздырып язып та тормас иде. Әгәр инде ул әдипләребезгә каты-каты шелтәләр белдерә икән — аларның көченә, сәләтенә ышаныч белдерә, олы әдәбият белән бер сафта барырлыкларына ышанып әйтә. Йөкне дә бит тарткан атка гына күп салалар.

А. Гыйләҗевның әдәбиятыбызда иң югары казанышлар дип берничә исемне генә атавын да, минемчә, башка әдипләребезне кимсетеп карау дип аңламаска кирәктер. Кайсы гына милләт прозасын алсак та, аның тау түбәседәй калкып торган берничә генә язучысы белән олы икәнен беләбез бит. Белорус әдәбияты дигәндә без, мәсәлән, иң элек В. Быковны һәм И. Шамякинны искә алабыз. Ут күршебез Башкортстанда кызыклы язучылар күп кенә булса да, бөтенсоюз укучысы М. Кәримне белә. Балтик буе әдәбиятларында, украин, кыргыз әдәбиятларында һәм башка республикаларда да ул шулай. Тик менә шушы биек таулар янында авыр йөкне иңнәренә бүлешеп салган тәбәнәк таулар барын да онытмыйк. Тау түбәләре бит алар тигез җирдә калкынып, бер үзләре очлаеп тормыйлар, алар шушы тәбәнәк таулар иңенә басып, шулар ныклыгына таянып торалар.

А. Гыйләҗев үзенең мәкаләсендә өч биек тауны атаган икән, моңа кем каршы килер? Барыбыз тарафыннан да хөрмәт ителгән талантлы, зур әдипләр. Ләкин бит әле барыбыз да йөз тоткан, әлеге дә баягы бөтенсоюз укучысы бар, күрерләрме алар безнең тауларны? Башка биеклекләрнең күләгәсе каплап китмәсме үзләрен?

Бүгенге бәхәстә прозабызда барган кайбер кызыклы күренешләрне искә алмасак, тауларыбызны тау иткән сәбәпләр ачылмый калыр, булганны югалту, сыйфат үзгәрешләрен күрмәү булыр иде. Мисал өчен сатира-юморны гына алыйк. Без әлегә кадәр халкыбызга хас тыйнаклык һәм хәтер саклау хисе беләнрәк, мыек астыннан гына елмаеп язылган юмор әсәрләрен укып өйрәндек. Аның М. Әмир, И. Гази, Ф. Хөсни, соңгы елларда Ф. Шәфигуллин кебек кабатланмас осталары бар иде. Бүгенге көн язучыларының бу өлкәдә кыюлыклары, тәвәккәллекләре җитәрлек булды ахры, сатира, хәтта сарказмга якын сатира белән язылган әсәрләр бер-бер артлы дөнья күрде. Хикәяләр генә түгел, күләмле-күләмле повестьлар да басылды.

Киң колачлы, масштаблы эпик әсәрләргә килсәк тә шулай. Чорлар алышынган, иҗтимагый системалар үзара бәрелешкән давыллы еллардагы кешеләр язмышын биргән Г. Ибраһимов, Ш. Камал, К. Нәҗми, И. Гази романнары кебек әсәрләр сагындыра башлаган иде инде. Ниһаять, без Н. Фәттахның «Сызгыра торган уклар», Г. Ахуновның «Идел кызы» романнарын, А. Расихның «Ямашев» трилогиясен укыдык.

Бөтенсоюз әдәбиятында бер яңалык бар. Реаль җирлектә язылган повесть һәм романнарга төрле-төрле формаларда фантастик элементлар килеп керә башлады. Әзербайҗан, грузин һәм кайбер башка халыкларда аның кызык кына үрнәкләрен күрәбез. Олы тәнкыйтьчеләр тарафыннан бу яңалык игътибарсыз калмады. Әдәбият белгечләренең кайберләре аны яклап, кайсылары исә, киресенчә, тәнкыйтьләп чыктылар. Әмма ничек кенә әйтсәләр дә, бу алымның аерым язучылар уйлап тапкан мавыгу гына булмавы, аның киләчәге барлыгы раслана. Ул бүгенге заман язучысының һәм укучысының фикер сөреше катлаулана баруын күрсәтә, төрле кызыклы формалар эзләү турында сөйли.

Уйлап карасаң, бу алым безнең үз прозабызда әлегрәк тә күренә башлады түгелме соң? Моннан ун еллар элек Ә. Баянов үзенең «Ут һәм Су» романында Кама белән Камиләнең ярым фантастик образларын биргән иде инде. Шул юнәлештәге тәҗрибәләрен ул аннан соңгы повестьларында да дәвам итте. Әлбәттә, тәнкыйтьчеләрнең, әдәбият белгечләренең күзенә чалынырга тиешле вакыйга иде бу. Аерым җыелышларда кайбер фикерләр әйтелгәләсә дә, әдәби тәнкыйть аны ни өчендер игътибарсыз уздырып җибәрде.

Инде, алдагы авторлар язып чыкканча, повестьларыбызның күләме кыска, ә фикергә баерак була баруларын да, шуның кебек башка кызыклы күренешләрне дә искә алсак — бөтен бәхәсле һәм каршылыклы яклары белән булса да — тауларыбызны тау иткән ныклы нигез ташлары болар дип әйтә алабыз.

Тагын шунысы да бар бит: Чыңгызы, Мостае, Нодары булу белән генә ул халыклар әдәбиятында да барлык проблемалар хәл ителеп беткән дип уйламыйбыз. Күтәрсәләр, ул әдәбиятлар да кызып бәхәсләшерлек, кылычка кылыч бәрелешерлек мәсьәләләр табарлар иде. Андый бәхәсләрне без «Литературная газета» битләрендә күрә дә киләбез. Уңышлар гына түгел, кимчелекләр дә уртак. Прозабызның артка калу сәбәпләрен бөтен ил әдәбияты яктылыгында каравыбыз да шуннан.

Нигә соң артка калабыз? Олы әдәбиятлар сафында татар әдипләренең исемнәре нигә күренми? Бу сорау, билгеле, һәркайсыбызны борчый. Басылып чыккан һәр яңа әсәрне укып барырга тырышучы, аның өчен куанып һәм борчылып яшәүче буларак, мин дә уйланам ул турыда.

Һәр нәрсәнең кыйммәте чагыштырып карауда беленә. Атаклы Эйнштейн теориясен татар халкы үзенчә бик гади генә итеп: түбәнгә карап шөкер ит, югарыга карап фикер йөрт, дип әйтмәгәнмени?! Бүгенге көн укучысы бары тик татар әдәбиятын уку белән генә канәгатьләнми, аларның күбесе дөнья әдәбияты үрнәкләре белән дә танышып бара. Һәм алар, югарыга карап фикер йөртсәләр дә, түбәнгә карап шөкер итәргә теләмиләр. Кайчагында без, укучы тарафыннан журналда укыр әйбер юк, дигән шелтә дә ишетәбез. Ә үзебез, ел йомгакларында булсын, иҗат мәсьәләләренә багышланган башка төрле утырышларда булсын, фәлән хәтле повесть, фәлән роман басылып чыкты дип саный башлыйбыз. Ләкин алар югарырак зәвыклы укучы күзенә

күренмиләр икән шул. Әдәби әсәрләрне эч пошканнан, күңел ачу, вакыт үткәрү өчен генә укымый хәзер укучы. Һәр укылганнан үзенә яңа бер дөнья ачарга тели, тапмый икән, ни кадәр генә чәчәкләп-чуклап, шикәрләп-баллап язылмасын, әсәр аның күңелен җәлеп итми. Эчне күптереп тә, тамакны туйдырмый торган кысыр аш кебек, укуга, онытыла ул.

Кайчандыр безнең җыелышларда аерым язучыларны урта кул укучы зәвыгына яраклашып язганнары өчен тәнкыйтьлиләр иде. Ул заманнардан бирле күпчелек укучыларыбызның рухи дөньялары нык үсте. Ә кайбер язучыларыбыз иҗатын күтәрә алмады, һаман бер дәрәҗәдә калып, бертөрле талантсыз, яки урта кул әсәрләр калыплап торуын дәвам итте. Нәтиҗәдә, кайчандыр ярарга тырышкан укучысыннан үзе дә артта калды. Әгәр алар талантлы гына әдипләребез иҗатына да тәэсир итмәсәләр, бу турыда бәлки сүз күтәреп сөйләп тә торырга кирәк булмас иде.

Җиңел кулдан язылган, игезәк балалар кебек бер-берсен хәтерләткән, стандарт калыптан коелган әсәрләр күбәеп китте соңгы вакытта. Авторлары да төрле, материаллары да бер-беренә охшамаган, ләкин темасы бер, идеясе бер үк. Бу бертөрлелек әхлак темасына язылган повесть һәм хикәяләрдә аеруча күзгә нык бәрелә. Кайбер авторлар кешеләрнең әхлак сыйфатларын ни өчендер хатын-кызга булган мөнәсәбәттә, гаилә мәсьәләләрендә генә сынарга яраталар. Үкенечле мәхәббәт мотивлары соңгы еллар поэзиясендә (бигрәк тә җыр текстларында) күбәеп китеп, тешкә тиеп беткәннәр иде инде. Хәзер шул прозага да килеп керде. Бераү икенче бераүне ярата, ләкин алар бергә була алмыйлар (ярый ла сәбәбе ышандырса), еллар үтүгә, сагыш башлана, әлеге бераү икенче бераүгә омтыла. Әсәрнең финалы язучы ихтыярында. Тели икән, кавыштыра,— теләмәсә, очраштырмый да кала.

Мондый җиңел схемага корылган әсәрнең геройлары китаптан-китапка күчеп йөриләр, шомарып беткән сүзләр сөйлиләр, таныш хисләр белән хисләнәләр. Мәхәббәт — сүрән, хисләр — салкын, яндырмый гына түгел, җылытмый да. Канаты сынган күгәрчен кебек очып китә алмыйча җирдә бәргәләнә. Мәхәббәтнең кешене Мәҗнүн иткәнен дә, шагыйрь иткәнен дә, батыр иткәнен дә, сагышка салып хаста иткәнен дә беләбез. Моннан берничә ел элек Ю. Рытхэуның «Тэрэкэ» исемле повесте «Дружба народов» журналында басылып чыккан иде. Тэрэкэ безнеңчә өрәк дигән сүз икән. Төньяк халыкларында боз белән агып киткән балыкчыны һәлак булганга санныйлар, мең бәлаләр белән туган җиренә кире әйләнеп кайтса да, кабул итмиләр, балыкчы үзе түгел, тэрэкэ, ягъни аның өрәге кайтты, дип ышаналар. Повестьның герое нәкъ менә шушы ачы язмышка дучар ителә. Әмма аның яшь, чибәр хатынында сөю хисе шул хәтле көчле була ки: ул шыр сөяккә калган, сакал-мыек баскан, өс-башы теткәләнеп беткән, нәкъ тэрэкэ рәвешенә кергән кешенең үз ире булуын эчке бер сиземләү белән аңлый, бөтен кабилә халкы кире каккан да аннан баш тартмый, язмышын уртаклаша, аның белән бергә һәлак тә була. Ярый, легендага якын бер вакыйга да булсын ди бу. Язучыларыбыз фольклор материалларыннан кыюрак файдаланырга өйрәнмәгән дә булсыннар ди әле. Ә соң Ч. Айтматов романында бүгенге көннең гап-гади бер кешесенең ярату көче аңардан киммени? Ч. Айтматов җир хакыйкатен язган, әмма җиргә төшермәгән.

Мәхәббәт темасына язылган әсәрләребездә күп вакыт сөю дигән бөек, изге хиснең үзен түгел, геройларның рухи шакшылыгын күреп, күңел рәнҗи. Кайбер яшь авторлар моны бүгенге яшь кешенең каршылыклы рухи дөньясын бирү дип аңлаталар. Ләкин шулаймы икән? Яшьләребез тәмам бозылып беттеләрмени, матур итеп сөя дә белмиләрмени инде? Андый әсәрләрнең талантлы автор кулыннан язылуы аерата куркыныч. Алар мәхәббәт маҗараларын шундый итеп тәмләп сөйләп бирәләр, яшь укучыда нәфрәт урынына кызыгу хисенең уянуы да гаҗәп түгел.

Мәхәббәттә хатын-кызларны җиңел акыллы итеп күрсәтү модага кереп бара. Ә бит дөнья әдәбияты тарихыннан алып бүгенге көнгә кадәр килсәк тә, бер генә олы язучының да хатын-кызларны алай түбән төшергәннәрен күрмәбез. Хаятка җан биргән бу изге затларның гүзәллегенә күпме генә даннар җырланмаган. Ә үзебезнең татар әдипләре! Алар иҗат иткән Галиябанулар, Нәфисәләр, Гөләндәмнәр!

Ә менә соңгы вакытларда кайбер язучыларның иҗатында күренгән (алар күбәеп бара кебек) җилбәзәк, җенси тотнаксыз, җилкуар хатын-кыз образлары прозабызны берничек тә зурламый.

Иң гыйбрәтле мисал булганы өчен түгел, әле генә укылганга күрә телгә алам: Ә. Гаффарның «Бишек» исемле повестенда Сөмбел белән Аитның очрашулары гына да ни тора. Ул сүз уйнатулар, ул диалоглар! Төнге яңгыр вакытындагы ярым фантастик күренеш гаҗәп оста сурәтләнгән. Сүз дә юк, мавыгып укыйсың. Ләкин бу осталык — повестька уңыш китерми торган осталык. Киракссез мәхәббәт уены шул хәтле озынга сузыла ки, повестьның символик рәвештә алынган «Бишек» исемен шәрехләргә авторның егәре дә, вакыты да җитми кала.

Прозабыздагы канатсызлык чиренең бер төре интеллектуаль темага язылган әсәрләрдә дә күзгә чалына. Кайбер әсәрләргә аерым фрагментлар булып, фән, культура, сәнгать мәсьәләләренә бәйле күренешләр килеп керә башлады. Ләкин нәкъ менә шул фрагментарлык әсәрнең уңышсызлыгы булып тора да. Әсәрнең бөтен бер канвасына органик бәйләнмәгән, язучының үз каны, үз җанында яралмаган материаллар төрле энциклопедияләрдән чүпләнгән әзер белешмәләр икәнлеген нык сиздерәләр. Бүгенге көн әдәбиятында күренгән геройларның халыкара конференцияләрдә, фәнни симпозиумнарда катнашуы да, татар халкының чит ил туристлары белән күрешүләре дә табигый хәл. Ләкин алар сюжет сызыгынамы, фикер сәрешенәме нык бәйләнгән булсыннар. Юкса, андый гына белешмәләрне укучы, кирәк булса, йөз җирдән таба ала. Ә бу көе укуы кызык түгел. Киракссез җиргә кадалган арзанлы брошкага караган кебек, ирония белән генә карап үтә аны укучы.

Бу өлкәдә эзлекле рәвештә эшләүче, һәр әсәрендә яңа бер проблема күтәреп язучы А. Расих кебек әдипләр иҗатына кагылмый бу, әлбәттә. «Дустым Мансур», «Ике буйдак», «Сынау» һ. б. роман, повестьларында ул татар интеллигенциясенең шактый гыйбрәтле тормыш картиналары белән таныштырды. Язучының үзенә бер язу алымы бар. Күпчелек әсәрләрендә ул укучының игътибарын бер яки ике персонажга юнәлтә дә әсәрнең башыннан ахырына кадәр шуларның мәшәкатьләре белән яшәтә. Ләкин шуны да әйтәсе килә: күп планлылыкны таләп иткән роман жанрын бу алым бераз тарайта. Гыйльми дөньяның гомуми панорамасын күрергә, фәнни атмосфераны бөтен тулылыгы белән тоярга комачаулый.

Ә бит рус әдәбиятын укыганда югары интеллектуаль тормыш белән яшәп калгандай буласың. Геройларның эрудициясенә, рухи байлыгына, интеллигентлыгына кызыгасың. Аннан соң хикмәт кешенең зур эшләр майтаруында, дәрәҗәле урыннарда эшләвендә, көн саен крахмалланган чиста күлмәк алыштыруында гына да түгел. Әнә бит Ч. Айтматов геройлары. Ул гомере буе гади кешеләр турында яза. Аның геройлары игенчеләр, мал көтүчеләр, шоферлар. Инде менә соңгы әсәрендә буш далада адашып калган ялгыз полустанокта яшәп ятучы тимер юл эшчеләре. Гап-гади кешеләр. Әмма ул кешеләрне язучы шундый биеклеккә күтәргән, А. Гыйләҗев тәкъдим иткән биеклектән торып караганда да башыңнан бүркең төшеп китәрлек! Ә безнең кайбер әсәрләрне укыган укучыдан: мондыйны мин тормышта да күреп түйдым инде, дигән сүзне ишетергә туры килә.

Юк, хикмәт геройларның кем булуында түгел, ничек сурәтләнүендә, күрәсең. Әдипләребез тәвәккәл түгел, зур мәсьәләләр күтәргәндә артык кыюсыз, җирдән күтәрелеп китә алмыйлар, фикерләренә канат куя белмиләр кебек. һәр язганны бастырып чыгарырга тырышу да комачаулыйдыр инде. Фәндә бит төрле сынаулар, тәҗрибәләр яңа ачышка китерә. Әдәбият та — шул ук фән, кешелек дөньясының чирләрен дәвалый торган фәннәрнең берсе. Шулай булгач, нигә соң безнең әдипләребез үзләренең өстәл яннарында гына булса да кыю-кыю тәҗрибәләр ясап карамыйлар? Әлбәттә, тәҗрибәнең уңышсыз чыгуы бик ихтимал, дөнья хәтле вакыт, көч сарыф ителде дип уйларга да мөмкин. Кемдер ачкан юлдан бару ышанычлырак бит, андый әсәрләр басылып тора, әйдә тагын берсе өстәлсен, дип тынычлана ахры кайберәүләр.

Язучылар авылда туа, шәһәрдә үлә дигән канатлы сүз бар. Татар язучыларының да 90 процентка якыны — авыл туфрагын таптап үскән егетләр. Инде аларның авылдан аерылуларына 20—30 ел, тәмам шәһәрләшеп беткәннәр, Фәиз Зөлкарнәев китергән мисалдан күренгәнчә, хәтта, балалары авыл өйләрен күз алдына да китерә алмыйлар. Шулай да язучыларыбызны кан авазы һаман авылга тарта, кул астына гел авыл материалы килеп керә. Яшел чирәмле урамнары, аулак өйләре, каз бәбкәләре, кәр базыннан менгән каймаклы чүлмәкләре белән күз алдында тора авыл. Ә бүген-

гесе! Агрошәһәрләре, терлекчелек комплекслары һ. б. яңалыклары белән бүгенге авыл ерак, бер айлык ялга кайтып кына аңлавы кыен әле аны. Кешеләре дә без яшь чактагыча самими күңелле, булганга канәгать, беркатлы кешеләр түгел.

Кукмара районының «Урал» колхозы сөтчелек фермасында ике сменалы эш оештырыла башлагач, сыер савучылар бу эшкә каршы төшәләр. Иртәнге дүрттән кичке җидегә кадәр алны-ялны белми эшлиләр югыйсә, өй карарга, бала багарга, дөнья күрергә дә вакытлары калмый. Ә менә, шуларның барысына да җайлы шартлар туарга торганда, шатланмыйлар. Колхоз җитәкчеләренә шактый изаланырга туры килә үзләре белән. Ә ике савымчы шулай да фермадан китә, яңалыкны кабул итә алмый. Урыннарын яшьләргә бирәләр.

Авылдан яшьләр китү мәсьәләсен дә гади баштан гына аңлап була торган түгел. Ни өчен кызлар китә дә, егетләр кала? Механизация белән генә бәйләнгәнме бу? Әллә башка сәбәпләре дә бармы? Чыннан да каты чикләвек ахры бүгенге авыл кешеләре. Бар, аңлап кара син аларны. Бер язучыбыз әйткәнчә, КамАЗ тирәсендә юргалап йөргән кебек ук, язучыларыбыз бүгенге авыл тирәсендә дә әйләнгәләп йөриләр, әмма эченә керә алмыйлар. Тракторлар таптап, бозып бетергән юлларын күрәләр, суы кипкән инешләрне күрәләр, сандугачлар тавышын, чишмәләр чылтыравын ишетмәгәнгә көенәләр. Болар барысы да, һәм шуның кебек башка күренешләр дә — бүгенге заман галәмәтләре, язучы булмаган кешеләр дә күрә ала торган билгеләр. Ә язучының миссиясе гади күз белән генә күреп булмаган эчке процессларны ачу. Тик хәзергә әле әдипләребезгә яңалыкны үз вакытында тотып алу сәләте җитенкерәми кебек. Күбебез авыр сөякле, авыр кузгалабыз, элекке белгәннәребез, иске багажыбыз җилкәне басып тора. Гафу ителмәслек инертлык кулны тота.

Бу урында И. Купринның бер фикерен искә төшерәсе килә. «Яма» дигән повестенда геройларының берсенең авызыннан менә нинди сүзләр әйттерә ул: «Сез уйлаган андый зур китапны язу өчен, бик җиренә җиткереп сөйләнгән булса да, чит кешенең сүзләре генә аз. Язу кенәгәсе һәм карандаш тотып күзәтүләр генә дә аз. Хәйләләп акыл сатмыйча, һәртөрле астыртын уйларга бирелмичә, шул тормыш белән үзең яшәргә кирәк».

Безнең һәр җыелышыбызда дип әйтерлек кабатлана торган сүзләр түгелме соң бу?

Ни өчен сугыш вакыты һәм сугыштан соңгы авыл тормышы ярыйсы ук тулы яктыртылды. Аяз Гыйләҗевның гына да биш-алты повесть иҗат иткәнен беләбез. Аларның «Язгы кәрваннар» кебек классик дәрәҗәдә торганнары да, бераз кайтышраклары да булды. Әмма ул шул еллардагы кешеләрнең, башлыча яшүсмерләрнең, матур сыйфатларын әдәбият тарихына язып калдыра алды. М. Мәһдиев куздән яшь китерерлек бер ярату белән сугыш елларындагы кешеләрнең гаҗәп сөйкемле образлар галереясын тудырды. Уңышларның сәбәбе бик гади иде. Бу тормыш язучыга бик якын, олы һәм кечкенә шатлыклары, йөрәккә салган яралары белән газиз иде алар өчен. Аларның биографиясе иде ул.

Бүгенге авыл кешеләренең күңел дөньясын крестьян тормышындагы үзгәрешләр белән бәйләп ачкан әсәрләребез бармы соң хәзер? Әйе, аз булса да бар алар. Г. Бәшировның «Җидегән чишмә»се, А. Гыйләҗевның «Әтәч менгән читәнгә» исемле сатирик повесте, В. Нуруллинның «Аккан су юлын табар» (әй шул исем әзләүнең кыенлыклары: «Әтил суы ака торур», «Агым суларга карап», «Аккан су юлын табар», «Сулар үргә акса да...» батып үләрсең, биллаһи), М. Юнысның «Табу һәм югалту» һәм тагын берничә әйбәт әсәр дөнья күрде дип әйтә алабыз.

М. Юныс художестволы анализлау объекты итеп олы бер проблеманы ала. Шәһәрләшү процессының авылга китергән яңалыклары һәм шуның белән бергә үк үкенечле югалтулар турында уйлана. Шәһәр тибындагы авылларда яшәү җайлы да бит, кешеләрне табигатьтән ераклаштырмасмы, туган туфрактан алган йомшак холкын, самимилеген, ихласлыгын җуйдырмасмы? Төрле-төрле машиналар эшләребезне җиңеләйтә дә бит, кырларыбызны, урман-суларыбызны пычратып, бозып бетермәсләрме? Ата-бабаларыбыздан килгән матур гореф-гадәтләр онытылмасмы? Бу үзгәрешләрне авыл халкы үзе сизеп-аңлап та бетерми торгандыр әле, табышларга да, югалтуларга да күнегелгән. Бу үзгәрешләр бит көне-сәгате белән килми, акрынлап-акрынлап тормышыңа, җаныңа керә бара. Ә читтән караган кешегә күренә, сизелә.

Инде тагын да ерактанрак алсак: километрлар белән түгел, дистә еллар, хәтта йөз еллар белән үлчәсәк, аянычлар зуррак булмасмы, оныкларыбыз безгә ни әйтер?

Шушы фикерләрне укучыга җиткерү өчен М. Юныс кызыклы форма тапкан. Әсәрнең герое туган авылына кечкенә кызы белән кайта. Иҗатын балалар өчен китаплар язудан башлаган әдип, нәниләр күңелен, аларның психологиясен яхшы белә. Бу повестенда да ул кызыкайның бар нәрсәне дә белү, бөтен әйбер белән кызыксыну сыйфатын шактый уңышлы файдалана. Нәни башта мең төрле сорау, ул дөньяны аңларга тели, ә җавабын бары тик зурлар гына белә дип уйлый.

Бу дискуссиядә чыгыш ясаучылар прозабызда картлар образларының күбәеп китүен әйткәннәр иде. Картлар гына түгел, соңгы елларда балалар образлары да күренә башлады. Начар түгелдер ул, уңай күренештер. Прозабызның күп планлы, катлаулана баруын гына сөйлидер. Әсәрнең үзәгендә җигелеп эшләүче җегәрле яшьләр һәм урта буын торганда, вакыйгаларга аксакаллар һәм балалар килеп катнашу күп буынлы олы гаиләне генә хәтерләтә бит. Элегрәк елларда проза әсәрләребездәге картлар көлке объекты булып кына алына иде. Аларга йөкләтелгән бөтен нагрузка шул — язганнарың эчпошыргычка әйләнеп, укучыны ялыктыра башласа, аны бераз ял иттереп, көлдереп алу.

Балалар образлары белән дә шулай ук. Бала тәрбиясе турындагы әсәрләрдә дә без баланың үзен күрмибез, кечкенә булса да, кеше буларак вакыйгаларга ул үзе катнашмый, ә без, укучы исә аның турында барган сүзләрне генә ишетә, аның язмышын зурлар аша гына белә торган идек. Өлкән буын әдипләребез балалар язучыларын да көнләштерерлек осталык белән нәни геройларның шактый сөйкемле образларын тудыра башладылар. Күптән түгел генә без Г. Башировның «Бибек нигә елый?» дигән моңлы хикәясен укыдык. Гомәр ага үзе бу хикәясе турында: «Мин дә балаларга бер әйбер яздым әле»,— дип әйткән иде. Әйе, бу әсәрне балаларга уку бик файдалы булыр. Бер яктан табигать белемен бирсә, икенче яктан кешелек гыйлеменә өйрәтә торган, өстәвенә олы зәвык белән язылган әсәр ул. Шулай да проблемасы зурлар өчен дип уйлыйм. Каян килә ул Баламут кебек сөрхәнтәйләр? Җәмгыятебездә андый әшәкелекләр туардай шартлар да юк кебек. Мәктәп тәрбиясе күргән, пионер галстугы тагып йөргән балалар бит югыйсә. Тирә-юньнәрендә хикәянең башка геройлары кебек изге күңелле әйбәт кешеләр яши. Нигә шулай рәхимсез ул баламутлар? Тиешлесен мәктәп биреп җиткермиме, әллә гаепнең зурысы гаиләдәме? Әсәрне укыгач, шуның кебек бик күп төрле сораулар башка килә. Җавап эзлисең.

А. Расихның зур бәхәсләр кузгаткан «Сынау» романында да сөйкемле генә сабый бала образы бар. Оеклары сыдырылып төшкән, чәчләре тузгыган, ана җылысын күрмәгән бу кыз баланың йокысыннан уянып, бабасы бүлмәсенең ишек төбендә басып тору картинасы ук укучыны сискәндерә. Бу нәни образның романга юкка кертелмәгәнлеген абайлыйсың. Һәм ул шулай була да. Сабый бала һәм әхлаксызлык төшенчәсе — бер-берсе белән һич сыеша алмый торган ике нәрсә. Берсе — кешенең саф, кер кунмаган, гөнаһсыз вакыты булса, икенчесе иң авыр җәзага хөкем ителергә тиешле әшәке сыйфаты. Сабый бала аркылы автор Сафураны чыннан да нә шундый җәзага дучар итә. Укучы нәфрәтеннән дә зуррак хөкемнең булуы мөмкинме соң? Баласына карата булган мөнәсәбәтеннән без шушы адәм образындагы әхлаксызлыкка каршы чыгабыз. Шулай итеп, балалар образлары да өлкәннәр прозасында шактый лаеклы урын алып торалар, үзләренең нәни җилкәләренә зур гына фикер йөген күтәрәләр.

Әйе, әдипләребезнең җигелеп эшләрлек көчләрен раслый торган уңышларыбыз да бар прозабызда. Артык күп дип әйтеп булмый, шулай да бар. Генераль план кебек олы максат куеп эшләүче әдипләребезне дә беләбез. Әдипләрнең күбесе иҗат планнары белән алай ачыктан-ачык бүлешергә яратмыйлар, егет кешенең күңелендә йөгәнле ат ята, диләр борынгылар. Шулай да басылып барган әдәби продукциянең күбесен күзәткәндә олы максат куеп эшләүчеләребез күп түгел сыман тоела. Көнем бушка үтмәсен, нәрсә булса да язарга кирәк дигән уй алданрак йөри кебек.

Бер көнлек максат белән эшләү, яңалыкны вакытында тотып алырга тырышмау, төрле-төрле формалар эзләмәү, халык авыз иҗатыннан җитәрлек файдаланмау, хисләрнең канатсызлыгы... Әзмени сәбәпләр. Шуның өчен бәхәс ачылды да бит. Ә хакь йкать бәхәстә туа диләр.

Әхмәт Сәхәпов

# КҮЛӘГӘЛӘР ЯКТЫДА ЮГАЛА...

Прозабызның язмышы өчен борчылып сугылган чаңның көчле авазы һәркайсыбызны да уйланырга мәҗбүр итте.

Әйе, көнкүрешебез әйбәтләнә барган саен, рухи тормышыбыз да катлаулана төшә. Адәм баласының күңеле рухи хәзинә белән матди байлык арасындагы тартыш аренасына әйләнеп бара. Кызганычка каршы, еш кына очракта тартыш нәтиҗәсе бу ике дөньяның килешүе белән тәмамлана, һәм кайчандыр тормышта актив позицияле булган кеше «үз күлмәген тәненә якынайткан» берәүгә әверелә, актив җан тормышы белән яшәүдән туктый.

«Үз кайгым үземә җиткән» принцибына иярәшеп, без үз кабыгыбызга ныграк бикләнә бармыйбызмы? Бу җитди сорауга җавапны әдәбияттан эзлибез. Аның киләчәген тәшкил итүче яшьләр иҗатыннан эзлибез. Җитмешенче-сиксәненче елларда әдәбиятка килгән яшь язучылар заман героеның нинди чалымнарын аерып алалар соң? Җәмгыятебез үсеше тудырган яңа сыйфатларның замандашыбызга йогынтысын ничек ачарга омтылалар алар? Яшьлек иҗат иткән әсәрләрдә замандашыбызның характеры, кылган гамәлләренең асылы нинди бизмәннәр белән үлчәнә?

Соңгы еллар яшьләр прозасындагы конкрет әсәрләргә, әйтик, Разил Вәлиевнең «Яшисе килә» повестена игътибар итик.

Әсәрнең нигезендә реаль вакыйга ята. Хәрби өйрәнүләр барышында шартлаган гранатаны күкрәге белән каплап, яшь солдат Рифкать Миргазизов иптәшләрен үлемнән коткара. Үз гомере бәрабәренә. Суынып өлгермәгән вакыйгалар тәэсирендә язылган бу әсәр әдәбиятыбызның героик шәхесләр галереясын кыю солдат образы белән баетты.

Язучы Рифкать образын нәкъ менә шул яктан ачарга омтылган. Кайда гына булмасын, нинди генә шартларга эләкмәсен, Рифкать үз иманына тузан кундырмый, намусын саф килеш саклый. Акрынлап тәне үлеп бара, ә көчле рухы, олы җаны исә тормыш эчендә кайный, «урам хулиганнары шикелле һич көтмәгән җирдә сагалап торып, якага килеп ябышкан үлем» белән ярсып көрәшә. Үлем фәрештәсе баш очында канат кагып тора, ә ул армия хезмәтен тутырып кайткач укырга керү турында хыялланып ята... Йөрәкне тетрәтерлек, бәгырьне телерлек кичерешләр... Кеше рухының ныклыгы сынала торган авыр минутлар...

Ул сынмый да, сыгылмый да. Үзе шундый хәлдә була торып та, кешеләр язмышын кайгырта. Разил Вәлиев әсәренең көче, үзенчәлеге дә шунда: ул Рифкатьнең батырлыкны хәрби өйрәнүләрдән дә бигрәк, бередә — госпиталь койкасында янә бер тапкыр кабатлавын күрсәтә. Тәне белән түгел, ә рухы белән! Тормышка булган чиксез мәхәббәте һәм олы дөньяны сыйдыра алган кайнар йөрәге белән! Минут саен зур ихтыяр көче, көчле җегәр, корычтай сабырлык сорый торган даими батырлык! Бу — олы җанлы кешеләр генә эшли алган, зуррак, олырак батырлык — рухи батырлык!

Рифкатьнең бу батырлыгы очраклы гына эшләнгән күренеш түгел. Аның бер тамыры халык бәхете өчен кан түккән Солтаннарга, терелэй утта яндырылган Шапбазларга (Г. Ибраһимов. «Кызыл чәчәкләр»), илебезнең нигез ташларын ныгыткан Ардуан батырларга (Г. Ахунов. «Ардуан батыр»), Ватаныбызның намусын яу кырында яклаган Газинурларга (Г. Әпсәләмов. «Газинур») барып тоташса, икенче тамыры исә җәмгыятебезнең таза һәм нык асылында, аның идеалының көчендә. Бу әсәр — Разил Вәлиевнең уңышы! Язучы тормышның бер кисәген әсәргә фотокүчермә итеп салмый, ә сәнгать югарылыгына күтәрергә омтыла. Һәр адымда сентиментальлек сагалап торса да, мина кырын хәвеф-хәтәрсез үтә алган тәҗрибәле сапер кебек, «сугышчан бурычын» әнә шулай намус белән башкарып чыга ул. Тормыш агымына тәэсир итәрлек көчле рухлы егет образын тудыра.

Разил Вәлиевнең «Иске сәгать дөрес йөри» дигән икенче повесте да замандаш

алдында торган җитди әхлак проблемаларын күтәрүе белән игътибарны җәлеп итә. Иманың ныкмы, яшьлек идеалларыңа турылыклымы син? Язучы бу сорауга җавапны Искәндәр, Сөмбел, Хәмит, Фидан, Интизар, Рүдәл кебек яшьләрнең эш-гамәлләреннән эзли.

Әсәрнең үзәгендәге яшь музыкант Искәндәр образы шактый тулы ачыла. Ул яшәүнең олы мәгънәсен сәнгатьтән эзли, үлемсез көй иҗат итеп үзен расларга омтыла. Бу хыялына ирешү юлында аңа шактый зур киртәләр аша узарга туры килә. Иң элек хатыны Сөмбел ташлап китә, дус дип йөргән яшьтәшләре йөз чөерә... «Дөрес уйлап», дөрес яшәүче дуслары да, үзен генә яратучы Сөмбел дә аны үз идеалына турылыклы булып калганы өчен гафу итә алмыйлар, тормышның һәр үзгәрешенә хамелеондай яраклашмавын күрәлмыйлар. Алар тормыштан майлы кәлҗә умырып алу өчен үз намуслары белән алыш-биреш ясарга да тартынмыйлар.

«...Хәмитләр, Интизар, Альфред, Рүдәл, Фиданнар — барысы да үз өннәренә кереп качкан йомраннар. Алар, тышта кар эреп, дөнья җылынмыйча, шул өннәреннән чыкмаслар, җыйган ризыкларын эшкәртеп ятарлар кебек. Ә ул аларның өендә яши алмый, аның йомран өенә керәсе килми, аны анда кабул итәргә әзлыгып торучы да юк!!!»

Ике тормыш идеалы әнә шулай бәрелешә. Менә шундыйларның яшәү принципларын сынарга туры килә Искәндәргә. Замана Искәндәрне үз намусын «сейф-бүлмә» эченә бикләгән Фиданнар, җиргә бурычыбыз юк дип тынычланып калган Хәмитләр, иманын акчага әйләндергән шабашник Мотыйгуллаларның битараф карашы белән, Сөмбелләр белән сыный. Үз мәнфәгатьләре белән генә мәшгуль булган бу кешеләрнең шәҗәрәсе кайчандыр тамырлары көйгән мещанлыкка барып тоташа. Әйе, иҗтимагый тормышыбызга сизелерлек йогынты ясый алмасалар да, алар җәмгыятебезнең рухи тормышына күпмедер дәрәҗәдә тәэсир итәләр. Искәндәрдә заман героена хас кайбер чалымнарны сиземләргә мөмкин. Бик үк ачык булмасалар да, бу билгеләр заман героен табарга омтылган язучының дөрес юлдан баруы турында сөйлиләр.

Әдәбиятыбыз тарихы Фидан, Хәмит кебек гыйбрәтле геройларны шактый белә. Гомәр Бәшировның «Намус» романында чулак Сәйфи, Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романында Яңгура белән Саматов, Әмирхан Еникинең «Рәшә» повестенда Зөфәр Сабитов, Гариф Ахуновның «Хәзинә» һәм «Хуҗалар» дилогиясендә Мөстәкыймов, Рафаэль Төхфәтуллинның «Йолдызым» повестенда Давыт, Аяз Гыйләҗевның «Урталыкта» повестендагы Сәгыйть кебек кешеләр үз чорының гыйбрәтле якларын шактый чагылдырдылар. Мондый кешеләр бүгенге тормышта һәм яшьләр иҗатында да төрле кыяфәтләргә кереп яшәүләрен дәвам итәләр. Язучы Азат Ганиевның «Иман» хикәясен генә искә төшерик: «игелек» эшләргә яратучы мәктәп директоры Әкрам укытучы Сабир абыйны мәктәптән куу турында хыяллана. Шунда ук, икенче бер герой Мансурның акча мәсьәләсендә профан булуыннан файдаланып, дәүләт кесәсен саварга да исәп тота... Марсель Галиевның «Кар абагалар» повестендагы Лениза, Нигъмәт, Әхәт Гаффарның «Кашан җыры» повестендагы циник Билал, Әсрар Галиевның «Йөрәгем хәзинәсе» повестендагы Зәбир, Камил Кәримовның «Бер арбада» хикәясендәге каты бәгырьле Эльза кебек персонажларны искә төшерик.

Нигә кирәк соң мондый геройлар? Тормышыбызның мондый күләгәле якларын яктырту ни бирә безгә? Аларның классик тибын Әмирхан ага Еники — «Саз чәчәге» повестенда Байгузиннар гаиләсе, Аяз Гыйләҗев «Урталыкта» повестенда Сәгыйть образы аша сурәтләп үз чорында чаң суктылар түгелме соң? Игътибар итик: яшь язучыларның әсәрләрендәге геройлар яңа шартларга яраклашкан. Әнә, Марсель Галиевның «Кар абагалар»ындагы Фирзан фәлсәфәсе нинди: «... Мещанлыкны гаепләгән кешеләрнең берсе дә тау куышында тормый», — ди ул. Үзенчә логикага нигезләнгән аның бу фәлсәфәсе. Сүз кермәштереп кара! Әйе, бүгенге көннең Сәгыйтьләре, Байгузиннары, Мостафиннары — башкарак кешеләр, аларның тышкы кабыгы да, эчке фәлсәфәсе дә яңа. Аларның ишеген ачарга үзгәрәк ачкычлар кирәктер. Ләкин әлегә яшь язучыларның бу өлкәдә үз ачышлары азрак. Алар сыналган үрнәкләрне, классик әдәбиятыбыз традицияләрен кабатлап кына канәгатьләнмиләр микән?

Тормышыбызның уңай идеалларын чагылдырган геройлардан бүген бик зур фидакарьлек сорала. Ә чынбарлыкта мондый геройларның эчке җегәре нинди соң?

Бу сорауга җавап табу өчен, яшь геройларның күбесенә хас уртак сыйфатларны

эзлисең, һәм сәер генә күренеш ачыла. Чорыбызның уңай идеалларын чагылдырган геройлар яшь авторларның күп кенә әсәрләрендә ни өчендер мескенрәк, кызганычрак кыяфәттә тасвирлана икән, тискәре типлар тормышка яраклашкан саен, бу намуслы затлар кыюсызлана гына бара. Алар тормыш кыенлыкларының көчле басымына каршы тора алмыйлар.

Кайбер язучылар иҗатында сурәтләнгән уңай геройлар, заман билгеләрен чагылдырсалар да, алар еш кына заман таләбенә җавап бирерлек югарылыкта тормыйлар. Мәсәлән, Азат Ганиевның Мансуры Әкрам кебек имансызларның әрсезлегенә актив тормыш позициясен каршы куя алмый. Марсель Галиевның Данияры да, принципсыз Нигъмәтләр белән бәрелештә җиңелеп, институтны ташларга мәҗбүр була. Аның бунты бөрәнә артыннан торып бүре куркытуга гына кайтып кала. Нәбирә Гыйматдинованың «Ата һәм бала» повестенда әйбәт күңелле Галләм агай белән аның ягымлы кызы Гөлүсә явызлык корбаннары булалар, үзләрендә оятсыз бәндәләргә каршы торырлык көч тә, җегәр дә таба алмыйлар. Бик тә кешелекле, бик тә мөлаем булган бу геройлар бездә кызганудан башка хис уятмый. Уңай герой шундый кызганыч, мескен булырга тиешмени соң?!

Актив позициядән, явызлыкка каршы актив көрәштән китү, тайпылу мотивларын берничек тә аклап булмый. Язучы үзенең иҗаты белән заманыбызның якты идеалларын раслауга хезмәт итәргә тиеш. Әнә шуңа күрә ул әдәбиятта тормыш агышы буенча гына түгел, ә аңа тиешле юнәлеш бирерлек геройлар да иҗат итәргә тиеш. Чорыбызның намусын яклап көрәшү урынына, мескенлек, битарафлык күрсәтеп читкә тайпылган геройлар заманыбыз әдәбиятын яңарта алмыйлар.

Геройның явызлыкны җиңүе дә зарури түгел. Аның шул алыш барышындагы абыну-сөртенүләре, рухи тәҗрибәсе һәм иманының сыналуы кыйммәтрәк безгә... Тик яткан таш астыннан су акмаган кебек, тормышның җитди сынауларына аркасы белән борылган, аны читтән генә күзәтеп акыллы нәтиҗәләр ясап утырган герой дә заман укучысының күңеленә яңа рухи хәзинәләр өсти алмый.

Мондый геройлар кызганычка каршы бер яшьләрдә генә түгел. Ул урта буын язучылары иҗатында да күзәтелә. Әхсән Баяновның «Яшьлегемне эзлим» повестендагы Әнис Бадигин, Мәдинә Маликованың «Казан каласы таш кала» повестендагы Шәүкәт образлары үзенчәлекле булулары белән аерылып торсалар да, алар — яшьләр иҗатында чагылган әлеге пассив геройларның рухи кардәшләре. Олы тормышның зур басымына түзәлмиләр алар. Менә шуңа күрә дә без бу геройларны заманыбызны яңартучы актив шәхесләр дип кистереп әйтә алмыйбыз. Чөнки, рухи кыйблалары нык булган кешеләр генә тормышыбызны уңай якка үзгәртергә сәләтле.

Хатын-кыз образларын иҗат итүдәге кайбер тискәре күренешләр дә күңелне борчый. Дискуссиядә чыгыш ясаган язучы Ләбибә Ихсанова хаклы: соңгы вакытта әдәбиятыбызда, бигрәк тә урта буын һәм яшь язучылар иҗатында хатын-кыз образын, мәхәббәт хисләрен сурәтләгәндә гүзәллекнең ямен-тәмен җую, ялангач эротика белән мавыгу күренеше күзәтелә. Әлбәттә, бирегә обыватель зәвыгына җайлашу, кино сәнгатенең дә тискәре йогынтысы юк түгелдер. Бу яңа сыйфат, заман билгесе дип әйтүчеләр дә булыр. Тик, безнең әдәбиятыбызны, ничәмә гасыр буена кеше күңеленең, тәненең пакьлеген саклап килгән тыйнак әдәбиятыбызны мондый ямьсез күренешләр баета алыр микән? Әгәр инде аңа күләгә төшерүче кайбер күренешләр тормышыбызда очраштыргалый икән, бу әле язучыга һәр «чүп»не әдәбиятка алып керергә, типиклаштырырга хокук бирми. Күңелне алдавыч арзан алымнар белән укучының игътибарын җәлеп итәргә омтылганда әдәбият, әдип дигән олы төшенчәләрнең асылын онытып җибәрмәскә иде.

Әйе, әдәби геройның нинди булуы, беренче чиратта, язучының үзенә бәйле. Әгәр ул үзе тормышны актив өйрәнмәсә, җәмгыятебезнең үсү-яңару процессында хәләл көче һәм бөтен күңеле белән катнашмаса, башка юл белән генә аңа зур уңышка ирешү кыендыр. Ярда утырып кына йөзәргә өйрәнеп булмаган кебек, тормышыбызның тирән катламнарын актарырга иренгән, фикер «мускуллары» йомшак язучы да чорыбызның йөзен, заманыбызның рухын билгеле торган көчле шәхесләр иҗат итә алмый. Чын кеше, заман герое белән очрашу безне һәрвакыт баета, рухи дөньябызның офыкларын киңәйтеп җибәрә.

...Мәгълүм хакыйкать тагын бер кат искә төшерүдән үзенең көчен югалтмый.

Фәрит Хатипов

# КҮҢЕЛ ХӘЗИНӘЛӘРЕН АЧКАНДА

Гомәр Бәширов иҗаты совет кешеләренең рухи тормышында хөрмәтле урын биләп тора. Инде менә күпме еллар буена аның әсәрләре әдәбиятыбызның җитди казанышларын, югары үрләрен раслап килә. Ул татар совет әдәбиятын якты образлар, тирән уй-фикерләр, хис-тойгылар белән баетты, проза өлкәсендә сәнгатьчә фикерләүне яңа баскычка күтәрде. Аның иҗаты — чынбарлыкка актив мөнәсәбәт үрнәге, ул турыдан-туры көрәшкә булыша, укучыларны тәрбияләүгә ярдәм итә. Әдипнең әсәрләре тормышны тирәнрәк аңларга өйрәтәләр. Шуңа күрә дә аның иң яхшы әсәрләре дөньядагы күп телләргә тәрҗемә ителде, классик әсәрләр рәтеннән урын алды.

Г. Бәширов иҗаты үзендә социалистик реализм методының иң көчле сыйфатларын, уңай тенденцияләрен туплаган.

Ә шулай да бу иҗатның аеруча мөһим үзенчәлеге нәрсәдә соң? Моны бәлки бер генә сүз белән әйтеп бетереп тә булмый торгандыр... Соңгы елларда миңа әдипләребезнең иҗатын күңел дөньясының яктыртылышы ягыннан күзәтеп чыгарга туры килде. Г. Бәширов геройлары арасына кереп киткәч, язучы иҗатының бу җәһәттән шактый тирән мәгънәле булганлыгы күренде. Шуңа күрә бу мәкаләдә сүзне дә башлыча рухи хәзинәләрнең чагылышы турында йөртмәкче булам.

Г. Бәширов әдәбиятка, өлкән буын язучыларының күпчелеге кебек, шактый озын тормыш юлы үтеп, буразнада тир түгеп, утлар-сулар кичеп килде. Ул гражданнар сугышы фронтларында революция казанышларын яклап көрәште, авыл хуҗалыгын күмәкләштерү хәрәкәтенә катнашты, халык язмышын хәл итә торган вакыйгаларның үзәгендә кайнады. Кыскасы, күпләр белән бергә ул илебезнең яңа революцион тарихын тудыручы да, шуны сәнгатьтә чагылдыручы да булды. Чынбарлыктан алган сабак, тәэсирләр аның каләменә реалистик ышандыру көче, бизәкләр төгәллеге, романтик күтәренкелек бирде.

Бай тормыш тәҗрибәсенә караш үткенлеге, зирәк акыл, әдәби сәләт, зур тырышлык, эш сөючәнлек килеп кушылды. Әдип халык тормышын, кешеләр характерын бөтен барлыгы, катлаулылыгы, каршылыклары, матурлыклары белән күрергә тырышты, тирә-юньдәге төсләр балкышын күңеленә беркетә барды. Аның бер герое, сәнгать кешесенә дәшеп, болай ди: «Син бит музыкант кеше, яхшылабрак тыңлап кара әле, туган иленнең йөрәге ничек тибә икән?» («Намус». Татарстан китап нәшрияты, 1952 ел, 31 бит.) Бу таләпне Г. Бәширов барыннан да бигрәк үзенә куйды. Ул халыкның рухи йөзен, күңел хәзинәләрен төпкә төшеп өйрәнде, аларның һәр тармагын гүя кулы белән тотып, капшап карады. Нәкый Исәнбәт кебек, күп санлы фольклор экспедицияләренә катнашты, авыз иҗаты әсәрләрен беренче чыганактан — җанлы сөйләмнән язып алды, шунда халык иҗатының чын поэзиясен, гүзәллеген, тылсымлы көчен тойды. Ул әкият җыентыкларын туплап чыгаруда катнашты, «Туксан тугыз мәзәк», «Мең дә бер мәзәк» китапларын бастырды. Н. Исәнбәт, А. Әхмәтләр белән бергә халык тапкырлыгын, шаянлыгын, күңел көрлеген җыйнады һәм иясенә кайтарып бирде.

Бер үк вакытта ул халыкның рухи байлыгын фәнни тикшерү, аның тарихын, фәл-

сәфәсен, сәнгатьчә үзенчәлекләрен ачыклау эшенә дә кереште. Әдип халыкның әкиятләре, мәзәкләре, җырлары, көе-моңы, гореф-гадәтләре, ювелирлык һөнәре, табигатькә, матурлыкка мөнәсәбәте, эстетик, этик карашлары, теле турында тирән эчтәлекле фәнни хезмәтләр язды. Тел күренешләрен Г. Бәширов берничә мәкаләсендә анализлап чыкты. Аларда ул телнең бик зур художество мөмкинлекләрен ачып сала, аның бик тә газиз, җанга якын уртак хәзинә булуын, тел белән үтә сак, кадерен белеп эш итәргә, сүзләрне тик үз урыннарында гына файдаланырга кирәклеген искәртә, гаҗәп нечкә сиземләп, аларның мәгънә төсмерләрен, кайда ничек кулланылуларын аңлата, әдәби телебезне үстерүдә күренекле сүз осталары Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Әмир, Ә. Еники, Ф. Хөсни, И. Гази, Н. Исәнбәт, Х. Туфан, С. Хәким, Г. Афзалның, урта буын язучыларының ролен күрсәтә, үзенең бу юнәлештәге гыйбрәтле иҗат тәҗрибәсе белән уртаклаша. Өлкән әдип әдәби әсәр бинасының төп төзү материалы булган телгә битараф, салкын мөнәсәбәтне, шапшаклыкны үтемле итеп битәрли, моның язучы этикасы белән сыеша алмавын төшендерә.

Шулай итеп, халык рухын өйрәнү эшен Г. Бәширов бик нык нигездә, гыйльми җирлектә алып барды. Шуңа күрә аның җимеше дә мул булды. Халыкның күңел хәзинәсеннән чумырып алынган байлык, язучы аңында эшкәртелеп, әдипнең үз иҗатына күчте, аның әсәрләренә фикер тирәнлеге, хисләр муллыгы өстәде, тапкырлык-зирәклек, ягымлы юмор төсмерләре белән бизәде, теленә образлылык, җегәрлек бирде, әсәрләрен халыкчан тәгъбирләр белән баетты.

Г. Бәширов теле — гаҗәп бай, төгәл, күп бизәкле, музыкаль, лирик яңгырашлы тел ул. Бүгенге прозабызда Г. Бәширов — иң таләпчән сүз осталарыннан берсе. Аның халыкчан теле тирән фикерләрне, катлаулы халәт-кичерешләрне, шаян юморны, чынбарлыкның үтә катлаулы якларын да бердәй җанлы, образлы итеп сурәтләп бирә ала.

Аның күп кенә әсәрләренә музыкант образлары, җыр-музыка килеп керә. Әдип еш кына чынбарлыкны музыкант сиземләвенә нигезләнеп тасвирлый, музыкаль башкаруларның, ягымлы көйләрнең герой күңеленә ничек тирән эз салып узуын сиздерә. Оста сурәтләнгән музыкаль аһәңнәр аның әсәрләренә үзенә бер төрле моң сирпиләр.

Г. Бәширов шулай ук каләмдәшләренең иҗат тәҗрибәсен дә җитди игътибар белән өйрәнә. Аның берничә мәкаләсе әдәбиятыбыз тарихындагы аеруча күренекле затлар эшчәнлеген яктырта. Боларда ул М. Горький, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Җәлил, Г. Кутуй, Х. Туфан, Ф. Хөсни кебек әдипләрнең иҗат портретын рәсемләп бирә, аларның иң үзенчәлекле сыйфатларын калку итеп күрсәтә. Бу мәкаләләр мәгълүм дәрәҗәдә гәрәбәдәй эре бодай көшелләрен хәтерләтәләр. Һәр көшел эре, тук бөртекләрдән — фикерләрдән тора. Үзенең мәкаләләрендә Г. Бәширов укучыларны шулай ук мавыктыргыч иҗат лабораториясенә алып кереп китә, әсәрләренең ничек бөреләнүе, тернәкләнүе хакында, сәнгать законнары турында сөйли.

Г. Бәширов үзенең әсәрләрендә ил тормышындагы иң мөһим, мәгънәле, дулкынландыргыч күренешләрне сурәтли, җанлы образлар ярдәмендә шуларның тирән фәлсәфәсен, матурлыгын ача. Аның иҗаты халык тормышы, рухи гүзәллеге турындагы җитди уйланулардан, чынбарлыкны тагы да ямьлерәк, матуррак итәргә омтылудан гыйбарәт.

Геройларның иҗтимагый йөзен, кешелек кыйммәтләрен билгеләгәндә, әдип һич тә арзан модалы карашлар белән мавыкмый, бу мәсьәләдә ул халык этикасына нигезләнә, уңай типларын тормышта гасырлар буена сыналган, хезмәт иләре аңында чыннан да күркәм дип саналган сыйфатлар, холык-гадәтләр белән характерлый.

«Туган ягым — яшел бишек» повестенда (бу әсәр русча 5 мәртәбә басылды, хәзер аны Венгриянең «Европа» нәшрияты дөньяга чыгару өчен әзерли) язучы үзенең сабыйлык чорын, балачакның кайгы-хәсрәтсез, ваемсыз елларын тасвирлый. Үзенә күрә сөенечләре, якты хатирәләр кичкәнә Гомәр тормышында да булган, әлбәттә: кара бияңең бик матур колын алып кайтуы, кичләрен шәкерт абыйсының китап укыганын тыңлап утыру, сабантуй бәйрәмнәре... Бар алар. Әмма шул ук вакытта җир кысынкылыгы, җирдән өлешсез калу, салымнарның күплеге Гомәрләрнең тырыш, эшлекле семьясына күп нужалар китерә, даими мохтаҗлыкта яшәргә мәҗбүр итә.

Социаль-экономик тигезсезлек, хезмәт кешеләренең моңа ризасызлыгы повестьта реаль картиналар булып чагыла.

Үткәнне тасвирлаганда Г. Бәширов чама хисен дә истән чыгармый. Мәгълүм ки, билгеле бер авторлар, элекке белән хәзергенең контрастын ачыграк сиздерер өчен, узган тормышта гел ямьсезлек, караңгылык, кыргыйлык кына күрәләр, борынгы кешеләрне ничектер томанарак, булдыксыз, мәгънәсезрәк итеп тасвирлыйлар. Социаль изүгә, экономик тигезсезлеккә, эксплуатациягә нигезләнгән тәртипләрнең нәрсә икәнен, хезмәт кешесен даими басып, кысып торуын, намусын таптавын Г. Бәширов та яхшы хәтерли. Тормыш авырлыгын ул үз җилкәсендә татып үскән, әмма шулай да аның бу автобиографик повесте тоташ кара җепләрдән генә тукылмаган. Рухи традицияләрне бәяләүдә Г. Бәширов үз концепциясен китереп куя. Китапта ул хезмәт иясе фәлсәфәсе турында сүз йөртә. Хезмәт кешесе — ул иң дөрес, нормаль яшәүче, рухи һәм материаль байлыкларны, сәламәт әхлак нормаларын тудыручы. Гореф-гадәтләргә мөнәсәбәттә Г. Бәширов В. И. Ленинның ике культура турындагы өйрәтүенә таяна. Социаль, экономик, дини, рухи изүгә корылган йолаларны кире кага, хезмәт җирлегендә шытып чыкканнары, ягъни демократик, сәламәт гореф-гадәтләр бүгенге яшәешебезне тагын да мәгънәлерәк, тагын да матуррак итәргә булыша дип саный. «Совет илендә яшәүче халыкларның гасырлар буена камилләшә һәм тормышка ямь кертә килгән күп кенә гореф-гадәтләре һәм күркәм традицияләре бар. Алар безнең заманда да яраклы булып чыгар һәм кешеләрне коммунизм рухында тәрбияләргә, һичшиксез, ярдәм итәр иде»,— ди әдип «Бүген дә, иртәгә дә» дигән китабында (13 б.), ә икенче урында ул болай дәвам итә: «һәр халык киләчәккә үзенең иң якты йолдызын, гасырлар буена тупланып килгән зирәк акылын, иң кадерле рухи байлыгын алып барырга омтыла» (42 б.). Аның рухи, этик мирас турындагы карашлары Ә. Еникинең «Җиз кыңгырау», «Әйтелмәгән васыять», А. Расихның «Сынау», А. Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән», Р. Гамзатовның «Минем Дагыстаным», В. Распутинның «Соңгы срок», Ч. Айтматовның «Гасырлардан озын көн», М. Кәримнең «Озын, озак балачак» әсәрләрендәге фикерләр белән аваздаш яңгырый.

Чын матурлыкны Г. Бәширов беренче нәүбәттә игенчеләрнең эшкә мөнәсәбәтендә, басу, болын эшләрен җиңел, дәртләнеп башкаруында, чыдам, булдыклы булуларында, туган туфракка ихлас мәхәббәтендә, әхлак критерийларының ныклыгында һәм сафлыгында, туганлык җепләренең саклануында, олыны олы, кечене кече итә белүендә, күңел байлыгында, күркәм кешелек сыйфатларында күрә, гади күренешләрнең үз поэзиясен, үз хикмәтен тойдыра. Аны «имәндергеч тормыш сазлыгында яшәп тә, рухын гарипләндермичә, күңел сафлыгын саклап калучылар» сокландыра («Бүген дә, иртәгә дә». 132 б.), ә физик хезмәттән аерылу, аңа теләкне һәм сәләтне югалта бару әдип күңелендә моңсу кичерешләр уята.

Г. Бәширов, Ә. Еники, М. Кәрим әсәрләреннән күренгәнчә, ата-бабаларыбыз беренче карашка шактый гади тормыш белән яшәгәннәр, фәнне белмәгәннәр, аларның эш кораллары примитив булган, хәзерге көнкүреш уңайлыклары төшләренә дә кереп чыкмаган. Әмма язучылар рухи байлыкны тышкы уңайлыклар һәм информация суммасы рәвешендә генә күз алдына китермиләр. Алар үз геройларының тормышчан зирәклеген, фәлсәфи, эстетик, этик карашларының тирәнлеген басым ясап күрсәтәләр. Бу тирәнлек хезмәткә нигезләнеп, күп гасырлар буена катлаулы табигать белән бәйләнештә яшәгәнгә, аның сулышын, серләрен зирәк тою нәтиҗәсендә барлыкка килгән, дип раслыйлар. Тормыш шартлары борынгылардан күп һөнәр белүне таләп иткән. Ә һәр яңа һөнәрне үзләштерү кешене рухи баета килгән. Хезмәт активлыгы, аларның үзләренә дә сиздермичә, интеллектуаль активлык китереп чыгарган.

«Туган ягым — яшел бишек», гәрчә автобиографик повесть булса да, аны укып чыккач, безнең күз алдына халык тормышы, авыл кешеләренең күп кенә үзенчәлекле характерлары, драматик язмышлары килеп баса. Алар арасында авыл юлларын, чишмәләрне караштырып, төзәтеп, чистартып йөрүче, сабан туена бүләкләр җыючы, анда тәртип саклаучы Гыйбаш абзый, моңлы итеп, өздереп җырлаучы ялчы Әхмәт, врачлар күрмичә сыза баручы авыру Фазулла, ачык фикерле Мөхәммәтҗан солдатлар бар. Әсәрне хикәяләүче персонаж әнисе турында бик җылы итеп сөйли, аның үтә йомшак табигатьле, киң күңелле, бик тә бала җанлы, сабыр холыклы булуын күрсәтә. Апасы Өммикамал, әтисе Бәшир агай аз гына кыркурак холыклы, әмма саф

вөжданлы, сүздә һәм гамәлдә тугрылыклы, намуслы, эштә бик уңган итеп сурәтләнәләр. Хезмәтнең теләсә кайсы төрен җиренә җиткереп, яхшы сыйфат белән үтәүчеләрне Г. Бәширов аеруча хөрмәт итә. Аның геройлары катлаулы иген эшен гасырлар буена чарлана килгән зирәклеккә таянып башкаралар.

Якташларының сәяси җитлеккәнлекләре хакында да Г. Бәширов сокланып сөйли. Әгәр дә авылдашлары революция көрәшенә Мәскәү, Казан белән бер үк көннәрдә күтәрелеп чыкканнар икән, аларның акны карадан аера белү сәләте, социаль аңы шактый югары үскән дигән сүз.

«Туган ягым — яшел бишек» повестеның поэтик кыйммәте, фикер һәм хисләр байлыгы, мәгънәсе, кат-кат укыган саен, һаман тирәнрәк ачыла бара. Беренче карашка гади генә тоелган детальләрдә дә зур художник каләме сизелә. Менә аның ягымлы, йомшак юморына бер мисал. Шиһап җизни белән Җиһан тәтәй тегүдән кайтышлый Гомәрләргә сугылганнар. Кечкенә Гомәрне күргә, Җиһан апасының йөзе балкып китә, ул энесен мактарга тотына, әллә сөйли, әллә җырлый, әллә икесе дә бергә шунда, сөяргә керешә, кучтәнәч бирә:

«Ул күлмәк кесәсенә тыгылды, кулына күп булып ияреп чыга башлаган чуклы конфетларның байтагысын кире төртеп төшерде дә ике-өчләбен миңа сузды»,— ди автор. Бу детальдә Җиһан апасын эчкерсез ярату, хөрмәтләү дә, мыек астыннан елмаю да күренеп кала. Автобиографик повесть художестволы фикерләүнең бөтен мөмкинлекләрен үзендә җыйган.

Әдипнең «Сиваш» повесте, «Намус», «Җидегән чишмә» романнары социалистик җәмгыятьне саклап калу, ныгыту, чәчәк аттыру өчен барган көрәшнең төрле этапларын гәүдәләндерәләр. Г. Бәширов аларны дәртләнеп, романтик күтәренкелек белән тасвирлый.

«Сиваш» повесте гражданнар сугышының финал өлешен яктырта. Әмма әсәр, никадәр генә күтәренке рухта язылмасын, тоташ тантаналы аккордлардан гына тормый. Барон Врангельнең яхшы коралланган, ныгытылган һәм уңайлы позицияләргә урнашкан сайланма гаскәрләрен туздыргančы, Шәмси, Әхмәди, Исмаев кебекләргә зур кыенлыклар күрәсе, тозлы Сиваш сазлыгын кичәсе, хәтсез корбаннар бирәсе бар әле. Әнә шунда кызылармеецларның революцион идеалга тугрылыгы, патриотизмы, чыдамлыгы, ярдәмчеллеге сынала. Бу сугыштагы тиңсез батырлыкны автор хезмәт ияләре табигатендәге иң күркәм сыйфатларның чагылышы, шуларның бер ноктага җыелып, революцион ялкын хәленә килүе дип бәяли.

Г. Бәширов «Сарут» хикәясендә дә болгавыр елларны тасвирлый. Ләкин ул монда социаль үзгәрешләр дәверендәге Мифтах Шәмгунов кебекләрнең чаялыгын беркадәр башкачарак бәяли, аның эчке драмасын күрсәтә. Унтугыз яшьлек Мифтах — һич тә төшеп калганнардан түгел. Аның трагедиясе — халык этикасына кизәнүдә, аны кире кагарга омтылуда. Автор сурәтләвенчә, аның кылган гамәлләре генә түгел, уйниятләре дә бик ямьсез. Әсәрдә аңа карата халык ачуы бөтен табигатьнең протесты төсен ала. Табигать үзе аны җәзалый.

Совет кешеләренең яңа шартлардагы патриотизмын, рухи гүзәллеген, уй-кичерешләр киеренкелеген, геройларның күркәм образларын рәсемләп бирү җәһәтеннән аеруча «Намус» романы тирән эз калдырды, совет әдәбиятында күренекле вакыйга булды. Аның төп пафосы социалистик хезмәт фидакарьлеген, интим-лирик тойгыларны романтик күтәренкелек белән, чын сәнгатьчә оста итеп сурәтләүгә кайтып кала. Ил язмышы хәл ителгән мәлдә, мөмкинлекләр соң дәрәҗәгә җитеп чикләнгән чакта Нәфисә һәм аның иптәшләре мул уңыш үстерүне җиңүгә өлеш кертү дип карыйлар. Киеренке хезмәттә геройларның чын патриотизмы, характерларының ныклыгы чагыла. Кешенең намусы хезмәтендә сынала. Бригада членнары үзләренең бөтен рухи һәм физик көчләрен эшкә җигәләр, катлаулы игенчелек шөгылен иҗади башкаралар, бай күңелле булганлыкларын раслыйлар. Ата-бабадан килә торган иген игү һөнәрен Г. Бәширов изгеләштереп сурәтли, дөрес тәрбиянең нигезендә хезмәт ята, дип саный. Аның геройлары, карты, яше, чәчүгә зур бәйрәм каршылагандай әзерләнәләр, ләззәт, ямь табып эшлиләр. Г. Бәширов киеренке хезмәтнең — физик һәм рухи сәламәтлек чыганагының — чын поэзиясен тойдыра, ил яшәешенең, куәтенең, чәчәк атуының иң мөһим шарты булуын күрсәтә. Хезмәттә геройларның иң матур сыйфатлары ачыла. «Намус» романы социалистик җәмгыятьтәге хезмәт эстетикасын аеруча

югары художестволы итеп, сәнгатьчә үтемле итеп гәүдәләндергән әсәрләрнең берсе булды.

Автор халык күңеленең киңлеген, сафлыгын, уйларының масштаблылыгын, хисләренең кайнарлыгын чагылдыра. Романның бөтен тукымасына ягымлы лиризм, музыкаль аһәң хас. Аның лирик моңын көчәйтүдә бигрәк тә матур сурәтләнгән интим кичерешләрнең роле зур. Биредә күңел дөньясын тирән, җентекле яктырту белән җитез, җыйнак психологизм органик үрелеп бара. Бу мәгънәдә роман Л. Толстой казанышларын да, А. Чехов, М. Шолохов традицияләрен дә уңышлы дәвам иттерә, аларны үзендә берләштерә, эретә. Әдипнең геройлары әсәрдә эчтәлекле, мәгънәле тормыш белән яшиләр. Бу романда Г. Бәширов совет власте елларында үсеп чыккан, ил тормышында үзенең лаеклы урынын тапкан, халыкның җылы карашын яулап алган татар хатын-кызының масштаблы образын зур художество көче белән гәүдәләндерде. Роман безнең прозабыздагы образлы фикерләү эволюциясенең югары нокталарыннан берсен тәшкил итә. Ул дөнья классикасы ирешкән художестволы фикерләү дәрәҗәсендә иҗат ителгән һәм әле дә әдәбиятыбызны югары сәнгать биеклекләренә дәшеп тора.

Моннан соң байтак еллар буена Г. Бәширов «Җидегән чишмә» дилогиясен язды. Яңа романны укырга керешү белән, үзеннән-үзе күңелгә шундый сорау килә: автор «Намус»та яулап алган сәнгать позицияләреннән чигенмәгәнме? Прозабызга нинди яңалык өстәгән? Дилогиянең үзендә үк әлеге сорауга җавап та табабыз. Монда бик күркәм холыклы, халыкның ихлас хөрмәтен казанган язучы Камил Дусаев образы бар. Бу персонажның үзенчәлеге шунда ки, ул шушы әсәрне язу процессында үз геройлары белән аралашып яшәүче әдип буларак тәкъдим ителә. Шуңа күрә роман сюжетында бер-берсенә бик якын торган ике план — автор исеменнән сөйләү һәм Камил Дусаев позициясеннән карап хикәяләү аралашып бара. Һәр ике план да бердәм сюжетны дәвам иттерә, үстерә. Шушы юл белән язучы хезмәтенең нечкәлекләре, тормыш белән бәйләнеше, китапның туу, характерларның кристаллашу процессы ачыла. Г. Бәширов әсәрдә тасвирланган хәлләрнең реальлегенә, турыдан-туры тормышның үзеннән алынганлыгына басым ясый.

Камил Дусаев, автор сурәтләвенчә, әдәбиятка, сәнгатькә һәм гомумән иҗат эшенә бик җаваплы, таләпчән карый торган художник. Әптелгани Хисмәти ишеләрнең әдәбият мәйданына «ел саен бер уфалла әдәби продукция» китереп аударулары, әштерөштер әтмәлләгән чиле-пешле язмаларның тоткарлыксыз басылып чыга торуы аңа бик сәер тоела. Аның үз әсәрен ничек язуы турында Г. Бәширов болай ди: «Бу әсәренә ул бинаһая көч салды. Халкына җиткерәсе иң мөкатдәс, иң кадерле уйларын ул, тиен оясына чикләвек ташыгандай, шушы әсәренә ташыды, аларны халкына булган мәхәббәте белән җылытып, бер бөтен итәргә тырышты» (52 б.). Бу бәя тулаем «Җидегән чишмә»нең үзенә дә бик туры килә. Г. Бәширов заман рухына авазлаш, өлгергән фикерле, интеллектуаль яктан бай, эмоциональ аһәңле кыю китап иҗат итте. Сигезенче дистәне тутырып барганда әнә шундый: яшьләрчә лирик яңгырашлы, өлкәннәрчә тирән мәгънәле ике китаптан торган роман тудыру, аны кат-кат эшкәртү — үзе үк зур иҗади батырлык ул. Биредә фәлсәфилек белән төсләр муллыгы органик рәвештә бергә үрелеп бара. Бу уңайдан бер детальне искә төшереп үтәсе килә. Әсәрнең беренче китабы басылып чыгу белән үк, композиторлар Сара Садыйкова һәм Әнвәр Бакиров, һәрберсе аерым-аерым, Г. Бәширов сүзләренә матур музыка яздылар, озак та үтмәде Зөһрә Сәхәбиева, Нәфисә Василова башкаруында «Җидегән чишмә» җыры яңгырый башлады. Шуңа күрә, ахрысы, тулаем «Җидегән чишмә» романы үзе дә укучы аңына лирик җыр кебегрәк барып җитте.

Әсәрнең үзәгендә — хәзерге авыл кешеләре, аларның уй-хисләре. Биредә шактый кыю һәм тирән рәвештә илебез табигатен киләчәк буыннар өчен саклау мәсьәләсе куела, аны саклауның күп кенә яклары яктыртыла. Табигать әсәр сюжетына геройлар белән бер рәттән катнашып бара. Аның үз язмышы бар — кешенең кешелеклелегенә, мәхәббәтенә, рәхим-шәфкатенә бәйле язмыш. Биредә табигать юмарт, риясыз, ләкин үзен саклау мөмкинлекләреннән мәхрүм булган, кешеләр ярдәменә мохтаҗ булган яшәү нигезе, матурлык һәм рухи байлык чыганагы итеп карала. Шуңа күрә персонажларның табигатькә мөнәсәбәте бер үк вакытта аларның гомумән яшәешкә мөнәсәбәтен дә билгеле, мораль-этик, интеллектуаль йөзен чагылдыра.

Шулай итеп, табигать язмышы, тирә-юнь куркәмлеге әсәрдә фәлсәфи-әхлакый планда карала. Романның художество системасында фикерләр көрәшенә дә зур гына урын бирелә. Бәхәсләр гыйльми-фәлсәфи казанышлар югарылыгында алып барыла һәм алар әсәрнең интеллектуаль йөзен билгеләүдә әһәмиятле роль уйныйлар.

Әсәрдә табигатькә мөнәсәбәттә колхоз председателе Ризван Чурмантаевның шактый катлаулы, каршылыклы характеры яктыртылган, аның үзенчәлекле эчке дөньясы чагылдырылган. Ул үзенең җитәкчелек стиле заман таләпләренә тулысынча җавап бирә дип фараз кыла. Ул, заводлардагы шикелле, урта звено җитәкчеләре белән эш итә. Читтән китереп куелган председатель буларак, Җидеган авылында төпләнеп калырга ниятләми, мондагы эшен тагы да югарырак биеклеккә сикерер өчен старт мәйданы дип карый. Ризван хәзер үк инде үзенең кабинетын нәкъ менә райкомның беренче секретаре кабинетына охшатып бизәгән, шундагы нише мебель тезеп куйган. Аның фикер сөреше дә үзенчәлекле. Күренекле язучы Камил Дусаев белән очрашкач, башта ул аңа ниндирәк мөнәсәбәт күрсәтергә белми аптырый. Зур бер республика киңәшмәсе президиумында язучының урыны беренченең үзе янына туры килгәнлеген исенә төшергәч, йөзе яктырып китә, әдипнең дәрәҗәсе чама белән министрныкына тиңләшә икән дип күңеленә беркетеп куя һәм шундыйрак хөрмәт тә күрсәтелергә тиеш икән дигән нәтиҗәгә килә. Ул Камилнең җиҗат эшенә актив булышырга әзер тора, геройларның уңаен, тискәреләрен табып бирергә вәгъдә итә. Тискәреләр рәтенә үзенә хәтле эшләгән барлык председательләрне кертә, ә үзенә язучы китабында үрнәк җитәкче ролен әзерләп куя.

Ык буеның матурлыгы җырларда җырлана торган тиңсез Алтынбикә тугаенда, Җидеган чишмәдә гәүдәләнә. Чурмантаев исә халыкның табигатькә булган керсез мәхәббәтендә тик хосуси милек психологиясе чагылышын гына күрә. Урман аңа төзү материалы һәм утын булып кына, болыннар — силос өчен яшел масса булып кына күренә. Ул, рентабельле түгел дип, куркәп утырган болынны сөрдереп ташлый, урманнарны кистерә, чәчү вакытында тургайларның агулануына юл куя, аларны саклап калу өчен кыл да кыймылдатмый. Әмма табигать үз хөкемен чыгара. Язгы ташкын сөрелгән болынның барлык уңдырышлы туфрагын алып китә, зәңгәр күктә тургайлар сайравы тына.

Әсәрдән күренүенчә, табигать язмышына уйланмый-нитми куплар йогынты ясый, ә аңа китерелгән зыян өчен конкрет берәү дә җавап бирми. Шуңа күрә колхозчыларда сорау туа: «Кем хуҗа соң безнең җиргә? Җидеганга аяк та басмаган әллә кайдагы профессормы, әллә без үзебезме?» — диләр алар (159 б.).

Чурмантаевның күңелле бәйрәм сабантуйга мөнәсәбәтеннән дә җан өшеткеч салкынлык бәрелеп тора: «Әгәренки егерме бишенче июньгә кадәр ит, сөт планы үтәлмәсә, сабан туен бәйрәм иттермибез»,— дип кистереп куя ул.

Табигатькә, гореф-гадәтләргә мондый мөнәсәбәттә, электән килә торган кайбер матур традицияләрнең өзелеп калуында язучы кайберәүләрнең рухи ярлылану билгеләрен күрә.

Чурмантаев киләчәктәге авыл хуҗалыгы эшен үтә җиңеләйтеп, тоташ күңел ачу рәвешендә күз алдына китерә: «— Әйтик, яшел кнопкага бастың, печән килеп төшә терлек алдына, зәңгәренә бастың — су, сарысына бастың — комбиазык...» — ди (163 б.).

Ризван Чурмантаев, профессор Фазыл Шәмсиев ишеләр фонында мөлаем табигатьле егет Гайнан, ил хәстәрен кайгыртып яшәүче зирәк Минһаҗ карт, чынбарлыкка актив катнашып яшәүче язучы Камил Дусаев, район газетасы редакторы Дәрҗия, күренекле галим Дормидонтов Аполинарий Авдеевич образлары сурәтләнгән. Алар үзләренең кешелекле, сизгер күңелле булулары белән укучыда җылы хис уяталар.

Гайнан — тормышка әле яңа гына аяк баскан яшь буын вәкиле. Ул туган ягын, урман-суларын, чишмә-тугайларын, кош-кортларын, җәнлекләрен ихлас ярата, аларны кимсетмәү, киметмәү өчен актив көрәшә. Ул авыл хезмәтеннән тәм таба. Университетка керә алмавына һич тә уфтанмый, «ак эш» эзләми, авылда умартачы ярдәмчесе, көтүче булып эшли. Авылдашларының хөрмәтен казана. Бер үк вакытта белемен дә күтәрә.

Гайнанга фикерләрнең өлгергәнлеге, үткенлеге, хисләренең сафлыгы, самимилеге

хас. Ул үзен җирнең, үз язмышының, киләчәкнең хуҗасы итеп тоя. Аның рухи йөзен әхлак критерийларының ныклыгы бизи.

Табигатьнең бөтенлеге, сәламәтлеге, матурлыгы турында кайгырту — ул, автор карашынча, гомумән кешенең үз яшәеше, җәмгыять тормышы хакында хәстәрлек күрү, киләчәк турында ваем чигү дигән сүз. Менә шушы хәстәрлек, авылларны төзек, ямьле, яшел итү, йорт-җирне зәвык белән салу, тирә-юньдәге чишмә-инешләрне карап, тәрбияләп тору, ил байлыгын исраф итмәү хакындагы фикерләре язучының публицистик мәкаләләрендә дә чагыла.

Әйе, Г. Бәширов иҗатының иң көчле сыйфаты да әнә шунда — тормышның әһәмиятле проблемаларын, мәгънәле күренешләрен алып сурәтләүдә. Тагын бер күркәм ягы — әсәрләренең сәнгатьчә камиллегендә, җиренә җиткереп эшләнгән булуында. Икенче төрле әйткәндә, Г. Бәширов иҗатында без идеялелек белән гүзәллекнең бергә кушылуын, эчтәлек белән форманың сәнгатьчә матур бердәмлек алуын, әсәрләренең эстетик тәэсирле булуын күрдек. Аның иҗат эшчәнлеге тагын бер тапкыр бик ачык хакыйкатьне раслый: сәнгать әсәрен камилләштерүгә салган көч, сәләт, рухи киеренкелек бер вакытта да әрәмгә китми, һәрчак үзен аклый. Алар әсәрне озын гомерле итә. Г. Бәширов иҗаты үзенең абруе белән татар совет әдәбияты үсешенә уңай йогынты ясый, аны яңа иҗат биеклекләренә өнди.

# *Бер сорауга — бер җавап*

*СОРАУ: Сез хәзер нинди әсәр язасыз?*

*САМАТ ШАКИР:*

*— Узган ел «Исемнәре мәрмәрдә» дигән китап чыгарган идем. Бу китапка карата шактый хатлар алдым. Аларны укыгач тагын да рухланып киттем һәм «Үлемсезлеккә адым» дигән яңа әсәр яза башладым. Анда гражданнар һәм Бөек Ватан сугышы батырлары турында языла. Аерата зур каһарманлык күрсәтүчеләрдән: 18 нче армиянең рота парторгы, күкрәге белән дошман дзотын каплап һәлак булган Сәләхетдин Вәлиуллин, 1936—39 елларда Испаниядә немец һәм Италия фашистларына каршы сугышкан очучы Мөхәррәм Галимов, Франциядә каршылык күрсәтүчеләрнең партизан отрядында гитлерчыларга каршы көрәшкән Мидхәт Гайсин, Норвегиядә гитлерчыларга каршы көрәшкән Гиззулла Габидуллин һәм башкалар бу китапның төп геройлары булып торалар.*

*Шул ук вакытта Идел буе аерым укчы бригадасы турында материаллар җыям һәм «Утлы юллар» дигән очерклар сериясе язарга да әзерләнәм...*

# КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

**Яхъя Абдуллин,**
философия фәннәре докторы,
профессор, Татарстан
АССРның атказанган фән эшлеклесе

## БОРЫЛЫШ

*(Материализм һәм диалектикага йөз белән)*

Тормыштагы социаль-экономик шартлар үзгәрү сәбәпле, XX йөз башында татар халкының иҗтимагый аңы үсешендә дә тирән үзгәрешләр барлыкка килә. Әле XIX йөздә үк башланган һәм Г. Ибраһимов тарафыннан урта йөзләрнең схоластикасыннан тәҗрибәгә, тикшерүгә күчү, «тәкълиддән иҗтиһадка, нәкыльдән акылга, алладан бәндәгә, күктән җиргә, хыялдан тормышка, диннән гыйлемгә, ахирәттән дөньяга»[1] күчү процессы дип бәяләнгән хәрәкәт тагын да көчәя һәм активлаша төшә. Дөрес, дөньяга дини-клерикаль караш тарафдарлары да үз позицияләрен бирергә теләмиләр. Ишми ишан кебек мәгълүм дин әһелләре, ислам диненең сафлыгын саклау пәрдәсенә төренеп, тормыштагы һәр төрле яңалыкка һәм яңарышка каршы каты көрәш алып баралар, бөтен көчләрен куеп, халыкны урта гасырлардан калган дини карашлар тәэсирендә тотарга тырышалар.

Шулай да XX йөз башында, унтугызынчы гасырның икенче яртысы белән чагыштырганда, татарлар арасында хәлләр нык үзгәрә. Мәгърифәтчеләрнең күпьеллык эшчәнлеге нәтиҗәсендә халык арасында рационализм идеяләре ныклы тамыр җәя, фәнни карашлар юл ала, ахыр килеп, болар һәммәсе дөньяга саф дини-идеалистик карашның позицияләрен какшатуга китерә. Төбәкнең социаль-экономик үсеше, товар-акча мөнәсәбәтләренең киңәюе һәм, шуның бер нәтиҗәсе буларак, татарларның төрле регионнарда яшәүче башка халыклар белән күпьяклы бәйләнешләргә керүләре дә әлеге процессны көчәйтүгә хезмәт итә. Социаль каршылыкларның көчәюе һәм революцион-азатлык хәрәкәтенең торган саен киңрәк колач ала баруы идея тормышының куәтле этәргеченә әйләнә.

XX йөз башында фәнни белемнәрне пропагандалау эше тагын да активлаша төшә, дөньяны фәнни күзалларга омтылыш көчәя, халыкның төрле катлаулары, бигрәк тә яшьләр әлеге тәэсир йогынтысына эләгә. Әнә шундый шартларда иҗтимагый аңга акрынлап, әмма эзлекле төстә, материалистик һәм диалектик карашлар үтеп керә. Марксистик-ленинчыл идеяләрнең массалар аңына үтеп керүен татар халкының XX йөз башындагы рухи тормышына хас үзенчәлекләрнең берсе, дип санарга кирәк. 1909 елда В. И. Ленинның «Материализм һәм эмпириокритицизм» дигән китабы басылып чыга һәм ул Казан большевикларының реакцион һәм реформистик идеологиягә каршы көрәшләрендә идея коралына әйләнә. Марксизм тәгълиматын баетуга зур өлеш керткән бу әсәр татар теленә Октябрь революциясеннән соң гына тәрҗемә ителә. Әмма аның русчасы безнең төбәктә киң тарала, тиз арада Казан марксистларының сугышчан коралына әйләнә, интеллигенциянең алдынгы карашлы

---

[1] Г. Ибраһимов. Каюм Насыйриларның тарихи урыннары. «Каюм Насыйри мәҗмугасе». Казан, 1922 ел, 6 бит.

вәкилләренә, шул исәптән татарларга да зур йогынты ясый. Татар зыялыларының иң яхшы вәкилләре, тырышып һәм җентекләп, Ленин хезмәтен өйрәнә башлый.

Фәнни белемнәр, материалистик һәм диалектик карашлар киң таралган мондый шартларда дини-клерикаль идеология тарафдарларының позицияләре дә, дини идеалистик карашларны пропагандалау формалары да шактый үзгәрә. Массалар аңына дөньяны фәнни нигездә аңлаткан карашлар кереп барган бер чорда дин әһелләре үз тәгълиматларының реакцион асылын ныклап яшерергә, дини тәгълиматка кайбер төзәтмәләр кертергә мәҗбүр булалар. Бу яктан мәгълүм дин галиме Ж. Абизгильдинның «Рух хакында фәлсәфәи җәдидә вә исламияткә бер нәзар» исемле китабы аеруча характерлы. Әлеге китабында ул, дөньяви фәннәрнең туктаусыз үсүе турында ачынып яза да, шушы хәлдән файдаланып, ислам диненең позицияләрен ныгытырга калырга чакыра. «Моңа кадәр күп фәнүн вә голумнән гафләт итдекебез кеби,— дип яза Ж. Абизгильдин,— моннан соң да заман хазирның хикмәт, фәлсәфә вә голум көниялрендән гафләт идәр исәк вә шәргъ шәриф илә араларында улан мөнәсәбәтләрне белмәс вә белдермәс исәк, фән илә шәригать бик аз гына вә заһири мөхаләфәт булган урыннарда кагыйдәи фәнияне тәкзиб итсәк, югарыдагы тарикъ илән ике арасыны татбийкъ вә тәуфыйкь итеп исляхә чалыштырмасак, әһел фән илә әһел шәргъ арасында бетмәс-төкәнмәс низагъ вә мөҗадәләрнең дәвамына, һәм дә әһел фән тарафдарларыннан башка күп диннәр тәкзиб ителдеге кеби гайн хакыйкать, гайн хикмәт улан дин мөбәйян исламны тәкзиб вә тәхкыйрь иттерергә сәбәп булырбыз вә заманыбызның хөкәмәэ голәмасы гыйндында шәргъ шәрифнең кыйммәт вә мәзиятен изһәр итмәгән булырбыз».[1]

Әлеге өзектән күренгәнчә, дин галиме шәригатьне фән белән, фәнни ачышларны дин белән яраклаштырырга, бер сүз белән әйткәндә, фәнне дини тәгълиматның хезмәтчесенә әйләндерергә өнди.

Табигать фәннәре өлкәсендәге иң яңа ачышлар, әйтик, атомнарның таркалышы, радиоактивлык, электроннар һәм рентген нурлары кебек ачышлар да дин галимнәре игътибарыннан читтә калмый. «Материализм һәм эмпириокритицизм» исемле хезмәтендә В. И. Ленин әлеге ачышларның диалектик материализм карашларын раслаучы тагын бер дәлил һәм диалектик материализмның алга таба үсүе өчен фәнни нигез булып торуын аңлатып биргән иде инде. Шулай да материянең төзелеше турындагы элекке, иске карашларның юкка чыгуы табигать фәннәре тирәсендә төрле идеалистик карашлар активлашуга бер этәргеч була. Табигать фәннәре өлкәсендә туган әлеге хәлне В. И. Ленин физиканың кризисы, дип бәяли. Материя юкка чыкты,— дип язды ул,— әлеге кризисны тудырган кыен хәлне кыскача гына әнә шулай аңлатырга мөмкин.[2] Шушы ситуациядән файдаланып, «энергетизм» дигән идеалистик концепция барлыкка килә, һәм ул яшәешнең асылын мәңге хәрәкәттә һәм үзгәрештә булган материя түгел, ә бәлки энергия тәшкил итә һәм ул материяне кысырыклап чыгара, дип расларга азаплана. Модада булган шушы идеалистик концепцияне дин галиме әл-Кадыйри да күтәреп ала. Үзенең 1910 елларда басылып чыккан «Кәлям буенча дәресләр», «Куәт вә рух» кебек хезмәтләрендә, энергетизм карашларына таянып, ул материализм һәм атеизмны «юкка чыгарырга» алына. Тойгылар ярдәмендә кабул ителә торган бөтен нәрсә, ди әл-Кадыйри, материядән һәм куәттән гыйбарәт. «Бу куәт вөҗүдне мәйданга чыгарып. Моның (куәтнең — Я. А.) җәелгән кыйсемнәре бер-беренә тәэсир итеп мадданең җәүһәрләрен, маддә җәүһәрләре гонсырларны, гонсырлар (элемент, өлешләр) бөтен җисемнәрне, йолдызларны, хәтта адәм вә хайванны барлык мәйданына чыгарып»[3]. Моннан күренгәнчә, әл-Кадыйри материяне матдәгә, әйбергә кайтарып калдыра, ә соңгысын исә куәтнең (энергиянең) материядән аерым яши торган ниндидер укмашмасы хәлендә күз алдына китерә. Шул хәтлесен истән чыгармаска кирәк, куәтне материядән аеру дин галименә алланың яшәвен дәлилләү өчен кирәк. Куәт, ди ул, табигатьтән өстен вә матди булмаган көчнең ярдәменә мохтаҗ, чөнки мөстәкыйль яшәештән мәхрүм булганлыктан, ул, матдә кебек үк, зарурият була алмый, ә бәлки табигатьтән өстен көчнең ярдәменә мохтаҗ булган бер нәрсә хәлендә кала.

---

[1] Ж. Абизгильдин. Рух хакында фәлсәфәи җәдидә... Уфа, 1909, 4—5 битләр.
[2] В. И. Ленин. Әсәрләренең тулы җыелмасы. 18 том, 273 бит.
[3] Әл-Кадыйри. Куәт вә рух. Казан, 1910 ел, 24 бит.

Ортодоксаль мөселман идеологиясе татар интеллигенциясен канәгатьләндерми башлый, хакимлек иткән идеологиянең кризисы тирәнәя барган шушы шартларда интеллигенция арасында дөньяга карашның яңа ориентирларын эзләү процессы башлана. Интеллигенциянең аерым вәкилләре шул чорда Көнбатышта модада булган философик мәктәпләргә йөз боралар, матбугат битләрендә Шопенгауэр һәм Ницше кебек буржуаз философларның исемнәре телгә алына башлый. Аерым кешеләрне Ницше алга сөргән көчле шәхес идеясе кызыктыра, үзенә тарта. «Кем көчле, кем үзенең «мин»леген югары чыгара, кем үзенең «мин»легенә табына,— диелә «Тормыш» газетасында басылган бер мәкаләдә,— шул кеше яшәргә тиеш. Сугыш та кирәк, хәтта лязим бер нәрсә. Сугышта көчле җиңә, зәгыйфь бетә. Моның нәтиҗәсендә дөнья тазара. Иң сайландык, иң кирәклеләр дөньяда калалар. Бу фикер, бу фәлсәфәләрнең башлыгы, аны иң күп таратучы Ницшедер».[1]

XX йөз башындагы катлаулы социаль шартларда яңа юллар, яңа идеяләр һәм фикерләр эзләү мәдәният әһелләренең демократик даирәләре өчен дә хас күренеш була. Алар урта гасырчылык идеологиясенең искергән догмаларын кире кагалар, иҗтимагый тормышның яшәп килгән тәртипләренә кискен протест белдерәләр, дөньяга карашның заман таләпләренә хас яңа маякларын эзлиләр. Шул юлда алар еш кына табигатькә һәм кешенең асыл көченә мөрәҗәгать итәләр. Татар иҗтимагый фикеренә антропологик тенденцияләр үтеп керә. Антропологик агым һәм социаль проблемаларны хәл итү юлларын табигый гармониядә табарга омтылу татар иҗтимагый фикеренең Г. Ибраһимов, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, М. Гафури кебек күренекле вәкилләре иҗатында да ачык күзәтелә. Моны, күрәсең, философик эзләнүләрне рухи өлкәдән җиргә күчерүнең, тормыш мәгънәсен анык үз яшәешеннән табарга омтылуның бер билгесе, дип карарга кирәктер.

Материяне һәм рухны дуалистик төстә бер-берләреннән аеруга, материаль нәрсәләрне идеаль нәрсәләргә буйсындыруга каршы юнәлтелгән антропологик принцип үзенең классик хәлендә кешенең аңы формалашуда иҗтимагый-тарихи практиканың ролен искә алу дәрәҗәсенә ирешмәгән материализмның — Марксчага хәтле булган материализмның — бер формасы булды. Алдынгы татар иҗтимагый фикеренең алда телгә алынган вәкилләренә, аларның идея-теоретик мирасына килгәндә дә эш нәкъ шулай тора. Кешедәге кешелек сыйфатларын формалаштыруда иҗтимагый-тарихи практиканың ролен аңлау югарылыгына күтәрелеп җитмәгәнгә күрә, алар үз карашларын кеше тормышының табигый нигезләренә юнәлтәләр. Шул ук вакытта алар кешенең материаль тормышын дини-идеалистик төстә аңлатудан арынырга тырышалар. «Мин,— ди М. Гафуриның «Хәмитнең хәяте» исемле әсәрендәге герой,— һөнәр вә сәнагыъның, фәннең вә әдәбиятның дингә бер тиенлек тә тәгаллекъе юк, шулай ук диннең дөнья мәгалләмәләре, кешеләрнең кәсеп вә һөнәрләре белән эше юк фикерендә идем»[2].

Дөрес, мондый төр антропологик эзләнүләр һәм социаль проблемаларны чишү юлларын табигать гармониясендә табарга тырышулар һәр очракта да материалистик юнәлештә генә бармый. Бу яктан, татар язучыларының демократик лагерьга караган башка вәкилләре кебек үк социаль гаделсезлеккә, шәхес ирекен кысуга, шәхеснең хокуксыз булуына һәм хәерчелеккә кискен каршы чыккан Н. Думави иҗаты характерлы. Социаль проблемаларны чишү юлын ул социаль даирәдән тышта эзли, әсәрләрендә табигатьтәге гармониягә һәм кешенең психикасына мөрәҗәгать итә. «Шура» журналының 1910 елгы санында ул «Хакыйкать эзләгәндә» дигән зур булмаган бер хикәя бастыра. Хикәянең герое, явыз кешеләр тарафыннан кыерсытылудан туеп, гаиләсе белән джунглига күчеп китә, шунда табигать кочагында яшь башлагач кына, җанына тынычлык таба. Н. Думави фикеренчә, табигатьне танып-белү һәм табигать гармониясе белән яшәү — кеше өчен иң югары бәхет. Хакыйкатьне бары тик табигатьтән эзләргә кирәк. Җәмгыятьтә, кешеләр арасында берниндн хакыйкать юк. Анда сатылу, бер кешенең икенчесен изүе, авторитетларга сукырларча ышану, күп төрле башка бозыклыклар хөкем сөрә. Чын тормыш дөреслеге бары табигатьтә очрый, хакыйкатьнең бердәнбер чыганагы — табигать. Шуңа күрә тормыш гаделлегенә табигатьтән өйрәнергә кирәк. Әмма ләкин табигатьне та-

---

[1] «Тормыш» газетасы. 1915 ел, 347 сан.
[2] М. Гафури. Әсәрләр 4 томда. 2 том, 217 бит.

ныл-белүдә акыл да, хисләр дә ярдәм итә алмый, чөнки хисләр «безне алдый, ә акылыбыз дисәк — бөтенләй шаштыра. Чөнки гакыл һәр кемдә башка. Дөресен генә әйтсәк, һәр кемнең үзенә файдалы якны гакылы хакыйкать дип күрсәтә. Менә шуның өчен дә мәмләкәтләр, милләтләр бер-берсе илә дошман булып беткәннәр... Хәтта ике адәм шул гакыллары аркасында тәзек тора алмыйлар» [1]. Шулай итеп, Н. Думави кешенең танып-белү мөмкинлекләрен интуитив төстә генә аңлата торган иррационализм юлына килеп чыга. Н. Думави фикеренчә, хакыйкатьне танып-белүгә кешене ниндидер аңнан тыш көчләр, аның саф эчке дөньясы, хыял көче һәм сизмләве илтә. «Минемчә,— ди әсәр герое,— хакыйкатьне хәвас илә дә түгел, гакыл илә дә түгел, бәлки сәламәт кальб илә эзләргә тиешле»[2]. Интуитизмны, хакыйкатькә бары аңнан тыш көчләрнең ярдәме белән, бары күңел һәм хыял көче белән генә ирешүне Н. Думави шулай ук «Уйланулар» («Йолдыз», 1915, 14 октябрь) һәм «Шәрекъгән гарепкә уңае белән» («Аң», 1916, 9 сан) исемле мәкаләләрендә дә яклап чыга.

*

* *

Шулай да дөньяга караш мәсьәләләре үсешендәге төп тенденция материализмга һәм фәнгә юнәлтелгән иде. Татар иҗтимагый фикеренең Х. Ямашев һәм Г. Коләхметов кебек марксистик юнәлеш вәкилләре ныклы материалистик позицияләрдә тордылар. 1909—1910 елларда Г. Коләхметовның «Тарих сәхифәләреннән» дигән өч кисәктән торган әсәре басылып чыга, анда ул тарихи процессны материалистик позицияләрдән чыгып аңлатып бирә. Бу хезмәттә иҗтимагый тормышның һәм анда барган процессларның закончалыклы характерда булуына басым ясала. «Халыкның тормышы,— дип яза Г. Коләхметов,— үзгәрә, халык тәрәккый итә. Әгәр без сигез яки ун мең ел әүвәл булган заманга әйләнеп караса идек, ул вакыттагы халыкның безнең кебек тормаганын ап-ачык күрер идек» [3]. Өстәвенә, кешелек җәмгыятенең кыргыйлык хәленнән югарырак баскычларга булган үсешен, кешеләрнең социаль бүленешен, гаиләнең, дәүләтнең, диннәрнең килеп чыгышын автор материаль һәм экономик факторларга, төрле социаль группаларның сыйнфый мәнфәгатьләренә бәйләп аңлата. Иҗтимагый тормышның бөтен яклары үсешендә, дип басым ясый ул, җитештерү көчләренең һәм кешеләр материаль байлыклар җитештергәндә кирә торган җитештерү мөнәсәбәтләренең үсеше мөһим роль уйный. Тәмамланмыйча калуына һәм өзек-өзек характерда булуына да карамастан, бу хезмәт Г. Коләхметовның марксистик социологияне кешелек җәмгыяте үсешен аңлатуда оста куллана алуына менә дигән мисал була ала. «Тарих сәхифәләре»нә җентекле анализ ясаганда бу әсәрнең авторы Ф. Энгельсның «Гаиләнең, хосусый милекчелек һәм дәүләтнең килеп чыгышы» исемле хезмәтен яхшы белгән һәм үз хезмәтен язганда андагы фикерләргә таянган, дигән нәтиҗәгә килергә мөмкин.

Антропологик эзләнүләр аша материалистик тенденцияләр татар иҗтимагый фикерендәге революцион-демократик юнәлешнең Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов һәм М. Гафури кебек күренекле вәкилләре иҗатына да үтеп керә. Аңның яшәешкә һәм рухның табигатькә мөнәсәбәте турындагы мәсьәләне алар материалистларча, табигатьнең, реаль әйберләр дөньясының беренчел, аңның икенчел булуы файдасына хәл итәләр. «Хәят безнең теләвебез белән йөрми,— ди Г. Ибраһимов.— Аерым бер груһның фикер вә хезмәте һичбер вакыт хәят агышын туктата алмыйдыр» [4].

Демократик татар интеллигенциясенең башка вәкилләренең философик эзләнүләре дә материализмга юнәлтелгән иде. Әйтик, «Аң» журналының 1916 елгы берничә санында күренекле әдәбият белгече Җ. Вәлидинең «Шәрекъгән гарепкә» исемле зур күләмле хезмәте басыла, анда ул Н. Думавиның татар халкы бары Шәрыкъкә генә карый, татарлар өчен Көнбатышның фәнни-философик идеяләре ят, дигән концепциясен нык тәнкыйть итеп итеп чыга. Шуның белән бергә, Җ. Вәлиди Шәрык

[1] «Шура» журналы, 1911 ел, 2 сан, 40 бит.
[2] Шунда ук, 41 бит.
[3] Г. Коләхметов. Тарих сәхифәләреннән. Казан, 1910 ел, 3—4 битләр.
[4] Г. Ибраһимов. Телләре башка булса да күңелләре бер. «Аң» журналы. 1916 ел, 5 сан, 89 бит.

халыклары, шул исәптән татарлар арасында да материалистик философиянең котылгысыз төстә таралачагына басым ясый. Аның фикеренчә, заманның агышы шундый. Кешеләр, дип яза ул, пространство һәм вакыт эчендә яшиләр, шуңа күрә үзләрен чолгап алган чынбарлыкның йогынтысына бирелергә мәҗбүрләр. Ә чынбарлык үзгәрүчән. Гомум Россия чынбарлыгының тәэсирендә татар халкының тормыш шартлары да үзгәрә. Ә тормыш шартларының үзгәрүе кешеләрнең рухи дөньясына йогынты ясамый кала алмый[1].



Татар иҗтимагый фикеренең дөньяга караш аспектлары дөньяның бердәмлеге турындагы фәнни карашның таралуында да ачык чагыла. «Матдә вә аның серләре» исемле мәкаләдә («Шура» журналы, 1908 ел, 8 сан) органик булмаган табигать, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы турында фәнни-табигый мәгълүматлар бәян кылына, алай гына да түгел, җитди генә үзенчәлекләре булуга да карамастан, аларның бер берләреннән аерылмаган, ә меңнәрчә җепләр белән бер-берләренә бәйләнгән булуына басым ясала. Әлеге һәр ике дөньяның әйбер һәм күренешләре иң вак кисәкчәләрдән — атомнардан тора, менә шушы хәл мөстәкыйль ике дөнья бердәмлегенең чагылышы булып тора. Мәкалә авторы материаль дөньяның бердәмлеге хакында турыдан-туры әйтми. Әмма шул ук вакытта ул бу бердәмлекне илаһи башлангыч белән дә бәйләп карамый. Аның фикеренчә, дөньяның барлык әйбер һәм күренешләре материянең бер үк иң вак кисәкчәләреннән тора, дөнья әнә шуңа күрә бердәм. Шул ук «Шура» журналында басылган «Табигатьтә хәят» исемле икенче бер мәкаләдә (1909, 3 сан) табигать күренешләре генә түгел, ә иҗтимагый тормыш күренешләре дә бердәмлектә яши, дигән идея уздырыла. Җанлы табигать җансыз табигатьнең үсеш нәтиҗәсе булган кебек үк, кешелек җәмгыяте дә хайваннар дөньясының үсеш нәтиҗәсе булып тора. «Хәят табигать, хәят хайвани, хәят инсани арасында катгый бер фасыйлә юктыр,— ди мәкалә авторы.— Ягъни бу хәятлар аерым-аерым хәятлар түгел, бәлки бер-береннән дәһа алга барган, фәкать әсаста бер хәяттән гыйбарәттер» («Шура», 73 бит). Шулай итеп, мәкалә авторы фикеренчә, кешеләр ыруын да үз эченә алган материаль дөнья бер бөтенне хасыйль итә, ә материаль чынбарлык законнары гомум характерга ия булып чыга.

XX йөз башындагы алдынгы карашлы фикер ияләренең философик эзләнүләрендә сәбәплелек проблемасы ныклы урын алып тора. Әйтик, Г. Тукай: «... бу дөнья йортында бер-бер нәрсә вакыйгъ булса, ул нәрсә һичшиксез икенче бер нәрсә өчен яки бер нәрсә сәбәпле вакыйгъ буладыр... Бу галәм галәм әсбабтыр»[2],— дип яза. Бу өзектән күренгәнчә, фикер иясе булган шагыйрь сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләренең объектив характерда булуларын гына танып калмый, аларның гомум характерга ия булуларына, берсенең икенчесенә күчә алуына да басым ясый. Объектив сәбәплелекне һәм закончалыкны тану теге яки бу формада, теге яки бу дәрәҗәдә алдынгы карашлы башка культура әһелләренә дә хас.

Материалистик тенденцияләр татар фикер ияләренең дөньяны танып-белүгә карата булган карашларында да сизелә. Иҗтимагый аң өлкәсендә дөнья күренешләрен танып-белергә мөмкин дигән караш ныклы тамыр җәя. Аллага ышануны иң югары рухи байлык дип санаган дин галимнәреннән аермалы буларак, татар мәдәниятенең алдынгы вәкилләре кешенең фикер йөртергә һәм актив иҗади эшчәнлеккә сәләтле булуын беренче планга күтәреп чыгалар, фән ярдәмендә кеше табигать серләрен торган саен тирәнрәк үзләштерәчәк һәм аларны үзенә хезмәт иттерәчәк, дигән ышаныч белдерәләр. «Фәкать голум табигыя мәгълүм бер мәртәбәгә ирешеп булмадыгы сәбәбеннән,— диелә «Шура» журналында басылган бер мәкаләдә,— һәмишә тәрәккый итачәге мөмкин улдыгыннан дәхи бик күп мәҗһүл шәйләр ачылачагын зан итәләр»[3]. Җ. Вәлиди кеше акылын, фәнне, белемне турыдан-туры илаһи акылга һәм дини догматикага каршы куя. «Без хәзер,— ди ул,— дөньяга иман китердек. Дини куәттән тыш, бер гыйлем вә фән куәте барлыгына вә шуның үземезгә кирәклегенә ышандык»[4]. Бу куәт кешеләргә табигать серләрен ача һәм ул серләрне кешеләр мәнфәгате өчен файдаланырга мөмкинлек бирә.

З. Хәмидинең «Шура» журналының 1912 елгы саннарында басылган «Фәлсәфәи

---

[1] Җ. Вәлиди. Шәрекътән гарепкә. «Аң» журналы, 1916 ел, 4 сан, 69 бит.
[2] Г. Тукай. Әсәрләр. III том. Казан, 1976 ел, 354 бит.
[3] «Шура» журналы, 1908 ел, 9 сан, 286 бит.
[4] Җ. Вәлиди. Шәрекътән гарепкә. «Аң» журналы, 1916 ел, 3 сан, 47 бит.

гакылиядән гыйльме рух» исемле хезмәте танып-белү проблемаларына мөнәсәбәттә туган тенденцияләрнең бер ачык чагылышы булып тора. Әлеге күләмле хезмәтнең авторы дөньяны танып-белергә мөмкин дигән принциптан чыгып эш итә, алай гына да түгел, агностицизмның ачык дошманы буларак чыгыш ясый. З. Хәмиди фикеренчә, табигать күренешләрен танып-белү — үзеннән-үзе аңлашыла торган нәрсә, әмма чынбарлыкның кеше психикасы кебек катлаулы күренешләрен танып-белү мөмкинлегенә дә бары агностиклар (мөнкирләр) гына шик белдерәләр.

Рухи характердагы күренешләрне танып-белү мөмкин түгел дип раслаганда, дип яза З. Хәмиди, агностиклар (мөнкирләр) аерым кешеләрнең үз-үзләрен тотышында һәм тирә-якта барган вакыйгаларны бәяләүдә булган субъектив тайпылышларга таяналар. Чыннан да, кешеләрдә субъектив тенденцияләр һәм, шуңа бәйле рәвештә, күренешләргә бәя бирүдә берьяклылык, үз ялгышын аңлый алмау очраклары күзәтелә. Тик психик күренеш проблемасы — ул аерым бер шәхескә карый торган проблема гына түгел, ә гомум кешелек проблемасы. Шуңа күрә, психик күренешнең асылын ачыклау өчен, үз-үзеңә анализ ясау яки аерым бер шәхеснең рухи дөньясын өйрәнү белән генә чикләнеп калырга ярамый, ә бәлки бик күп кешеләрнең психик халәтен һәм рухи эшчәнлеген өйрәнергә кирәк [1].

З. Хәмиди танып-белүнең табигате турындагы мәсьәләгә материалистик чагылыш теориясе позициясеннән чыгып якын килә. Аның фикеренчә, объектив дөньядагы әйбер һәм күренешләр кешедән бәйсез рәвештә яшиләр, безнең белемнәребез шуларның безгә ясаган тәэсиренең нәтиҗәсе булып тора.

З. Хәмиди кешенең танып-белү мөмкинлекләрен җентекләп анализлый, шуның белән бергә, фикерләү эшчәнлегенә аеруча нык басым ясый. Әмма танып-белү процессының башлангыч чыганагын ул тойгылар һәм сизү органнарында күрә. Тойгылар ярдәмендә без әйберләрнең индивидуаль сыйфатларын, тышкы чагылышларын беләбез. Аларның эчке табигатен, алар арасындагы закончалыклы бәйләнешләрне һәм мөнәсәбәтләрне исә без бары акыл ярдәмендә, фикерләү процессында гына белә алабыз. «Хис хариҗи — бәдәнебездән тыштагы нәрсәләрне сизү — үзебезгә якын гына тыштагы нәрсәләрне белүгә тәгъриб итдеги кеби,— ди З. Хәмиди,— куәи гакылиябезне дә уятадыр» [2]. Акыл исә тойгылар ярдәмендә тупланган мәгълүматларны аңлатып һәм тәртипкә салып бирә, әйбер һәм күренешләрнең күзгә күренми торган эчке якларын, алар арасындагы бәйләнеш һәм мөнәсәбәтләрне ачып күрсәтә. Акыл ярдәмендә без гомуми хакыйкатькә ирешәбез. «Гакылның хезмәте безнең өчен олугдыр. Хисләрнең биргән мәгълүматыны заһири садәлекләреннән чын хакыйкать хәленә куйган нәрсә гакылдыр... Гакылның хөкеме дөрес, шуның өчен гакыл һәрвакыт таяныч вә киңәшчемездер. Хатаны дөрестән тәмиз иткән, инсанның һәр эшеннән мәсьүл улып низам вә канун тәхтендә яшәдекене белдергән, адәм өчен күп җиңеллекләр, кыйммәтле нәрсәләр кәшеф кылган нәрсә шул гакылдыр» [3].

Танып-белү процессында кеше акылы,— ди З. Хәмиди, беренчел мәгълүматларга таяна, аларның аеруча мөһимнәре түбәндәгеләр: а) яши торган нәрсә белән яшәве мөмкин булган нәрсәне тану; б) өзлексез үзгәреп торган күренешләрнең даими һәм мәңгелек нигезен, материяне тану; в) дөньядагы бер генә күренешнең дә мәгълүм бер сәбәптән башка барлыкка килә алмавын күрсәткән сәбәблелекне тану; г) чиксезлекне тану; д) вакыт һәм пространствоны тану. Үзләреннән-үзләре күренеп торганлыктан, әлеге принциплар хөкем йөртү, нәтиҗә чыгару һәм танып-белүгә бәйле башка эшләрнең нигезендә ята, акылны хакыйкать юлына илтүче маяк булып торалар. Алар безгә күргән һәм тойган нәрсәләребезне бер төенгә бәйләргә, күренешләр арасындагы закончалыкны мөнәсәбәтләрне ачыкларга мөмкинлек бирәләр.

Әлеге башлангыч принциплар ничек барлыкка килә соң? З. Хәмиди фикеренчә, бу сорауга дөрес җавап табу дөньяга караш һәм методология ягыннан мөһим әһәмияткә ия. Бу мәсьәлә буенча философлар тудырган буталчыклык ислам дөньясындагы китапларда ныклы урын алган, ди З. Хәмиди. «Бу мәсьәлә озак заман хөкәманың саф фикерләрене чобалтдыгы кеби, безнең ислам китапларына да кереп гакыллы башларыбызның дүрт йөз еллар мөддәтендә эшсез калуына сәбәп булмаштыр» [4].

---

[1] З. Хәмиди. Фәлсәфәи гакылиядән гыйльме рух. «Шура» журналы, 1912, 10 сан, 298—299 битләр.
[2] Шунда ук, 336 бит.
[3] Шунда ук, 14 сан, 428 бит.
[4] Шунда ук, 14 сан, 429 бит.

Бу принциплар тәҗрибәгә хәтле үк, ягъни кешелек җәмгыяте барлыкка килгән моменттан ук булган, дигән фикер яши. Икенче берәүләр әлеге принциплар кешеләрнең индивидуаль тәҗрибәсе вакытында булдырылган, дип саный. З. Хәмиди беренче карашны да, икенчесен дә кире кага. Ул танып-белүнең беренчел принциплары тәҗрибә нигезендә барлыкка килгән, ләкин изоляцияләнгән бер шәхеснең тәҗрибәсе нәтиҗәсендә түгел, ә бәлки бөтен кешелекнең тарихи тәҗрибәсе нәтиҗәсендә барлыкка килгән, дип саный.

Шуның өстенә, әлеге тәҗрибәнең нигезендә кешеләрнең предметлы чынбарлык белән эш итүе ята, бу соңгысында исә кешенең хисләре дә, акылы да катнаша. Шул рәвешчә, кешелек җәмгыяте туплаган барлык белем запасының чыганагы булып тышкы дөнья тора, танып-белү процессы үзе дә шул тышкы дөньяның закончалыкларын белүгә нигезләнә.

*

* *

Татар иҗтимагый фикерендә философик карашларның үсеш тенденциясе аның алдынгы вәкилләренең фәлсәфи мираска булган мөнәсәбәтләрендә дә ачык чагыла. XX йөз башында татарлар арасында үткән чорларның аеруча күренекле фикер ияләрен пропагандалау сизелерлек көчәя. Вакытлы матбугат битләрендә антик чорның Аристотель, Демокрит, Сократ, Платон кебек философларының тормышы һәм иҗаты турында мәкаләләр басыла. Шәрыкның әл-Фараби, Әбугалисина, Ибн-Рөшд, әл-Кинди, әл-Мәгари, Ибн-Туфәйль кебек күренекле фикер ияләренең идея-теоретик мирасын пропагандалау буенча XIX йөз мәгърифәтчеләре башлаган эш дәвам иттерелә.

Үткән чорларның философик мирасын пропагандалау эшендәге бер мөһим үзенчәлек Көнбатыш Европа философларының мирасына йөз белән борылудан гыйбарәт. «Шура», «Аң» һәм башка вакытлы матбугат органнарында басылган материаллар аша татар укучылары Көнбатыш Европаның Ф. Бэкон, Р. Декарт, Руссо, Лейбниц кебек яңа дәвер фикер ияләренең философик идеяләре белән танышу мөмкинлеге алалар. Ул мәкаләләрдә, XVII—XVIII йөзләрдәге Көнбатыш Европа философиясен урта гасырлар философиясеннән аерган бер үзенчәлек төсендә, аның схоластикага каршы булуы, дини кысалардан котылырга омтылуы билгеләп үтелә. Әйтик, «Шура» журналының 1915 елгы 16 санында басылган «Бэкон» исемле мәкаләдә XVII йөздә яшәгән әлеге инглиз философы кеше акылын үткәннең ялгышларыннан һәм хорафатларыннан коткарган, беренче тапкыр, башка фәннәр кебек үк, философиянең дә нигезен тәҗрибә тәшкил итә дип күрсәткән һәм фикерләүнең индуктив методын тәкъдим иткән фикер иясе, дип атала. Фикерләүнең схоластик методын кискен тәнкыйть итеп, дип яза мәкалә авторы, Ф. Бэкон фәннең үсешенә көчле этәргеч биргән кеше.

Алдынгы татар иҗтимагый фикеренең күренекле вәкиле Г. Ибраһимов «Аурупа фәйләсофы Декарт вә аның фикере» дигән хезмәт язып бастыра, анда ул француз философының «Метод хакында фикер» исемле трактатының эчтәлеген бәян кыла. Р. Мөхәммәтшин бик дөрес язганча, Г. Ибраһимовның француз фикер иясе Р. Декартка һәм аның философиясенә мөрәҗәгать итүе татар галименең «кешелек җәмгыяте серләрен тирәнрәк ачарга омтылуы, барыннан да бигрәк, тарихи барышның нигезләрен ачарга, кешеләр эшчәнлегенең чыганак һәм сәбәпләрен танып-белергә омтылуы белән аңлатыла... Декарт тәгълиматы һәр төрле традиция — схоластик традиция белән дә, дини традиция белән дә — ачыктан-ачык каршылыкта була, һәм бу мөстәкыйль фикер йөртергә, дини авторитетларны кире кагарга теләгән буынны һичшиксез үзенә җәлеп итә».[1]

Татар авторлары язган мәкаләләрдә материалистик философларның мирасы лаеклы урын алып тора. 1915 елда «Шура» журналында Б. Спиноза хакында бер мәкалә басыла. Тулаем алганда, мәкаләдә күренекле философ тәгълиматының эчтәлеге дөрес бәяләнә, аның әсәрләренең материалистик характерда булуына басым ясала. «Барлыгы үзеннән генә аңлашыла торган, һичбер нәрсәдән ярәтылмаган мәң-

[1] Р. Мухаметшин. Начальный этап в становлении мировоззрения Галимджана Ибрагимова. «Из истории татарской общественной мысли» дигән җыентык. Казан, 1979 ел, 123 бит.

гелек, чиксез вә ялгыз субстанция бардыр ки,— диелә мәкаләдә,— һәммә нәрсә шуннан садыр булып, шуңа кире кайтмактадыр. Рух белән матдә һәр икесе шул бер затның барлык формаларыдыр, димәк, матдә берлә куәтнең асылы бердер. Җан хәрәкәте — тән хәрәкәтедер. Моңа дәлил итеп, тән хәрәкәтеннән башка, җан үзенең барлыгын белдерергә һичбер куәте юклыгын күрсәтә. Тәннән аерым җан — аңлашылмый»[1].

«Аң» журналының 1913—1914 елларда чыккан берничә санында М. Хәнәфинең «Хәят вә фәлсәфә» исемле мәкаләсе басыла, анда борынгы дәвердән алып хәзерге заманга хәтле булган фәлсәфи фикергә, бигрәк тә антик философиягә тәпле бәя бирелә. Шуның белән бергә, автор төрле фәлсәфи мәктәпләргә ярыйсы ук тирән анализ ясый, философик идеализмның асылын ачып бирә һәм милетчыларның материалистик мәктәпләрен, Гераклитны, Левкипп һәм Демокрит фикерләрен җентекләп тикшерә. Бу хезмәтнең иң мөһим ягы — философик идеализмны тәнкыйть итү, материалистик философиянең, идеалистик философия белән чагыштырганда, өстенлекләрен ачып күрсәтү.

М. Хәнәфи карашынча, философик идеализм кеше фикерен реаль чынбарлыктан аеру нәтиҗәсендә барлыкка килгән булса, материализм исә дөнья ничек бар, аны шулай аңлауга нигезләнгән. Материалистик философия дөньяның һәм аның күренешләренең беренчел нигезе төсендә материяне ала һәм аның вәкилләре, идеалист философлардан аермалы буларак, фәннилек ноктасыннан карап эш итәләр. Антик Грециядә бу философик юнәлешнең беренче вәкилләре булып Фалес, Анаксимандр һәм Анаксимен торган. Аның аеруча күренекле вәкиле — Демокрит. Соңгысын М. Хәнәфи «атаклы шәхес һәм бөек философ» дип бәяли. Демокрит күтәргән «фикерләрнең фән өчен булган әһәмияте турында әйтми булмый... Демокритның фикерләре тирән мәгънәле, әхлакый җәһәттән ышанычлы, фәлсәфи җәһәттән гаҗәеп тә дәрәҗәдә тәпле»[2].

*

* *

Күргәнегезчә, XX йөз башында татар иҗтимагый фикеренең алдынгы вәкилләре шул чорда кешеләр аңында өстенлек иткән дини-идеалистик караш белән мөнәсәбәтне үзү юлына ныклап аяк басалар. Алар материаль дөньяның объектив характерда булуын таныйлар, үзләрен чорнап алган чынбарлыктагы әйбер һәм күренешләрнең кешегә бәйсез рәвештә яшәвен, ә анда барган процессларның объектив нигезе булуын аңлыйлар. Аларның дөньяга карашындагы материалистик тенденцияләр шулай ук сәбәплелек категориясенә якын килүдә, танып белү һәм фәлсәфи мирас мәсьәләләрен яктыртуда ачык күренә. Шул ук вакытта бер нәрсәне билгеләп үтми булмый: ул чорда яшәгән күпчелек татар зыялыларының материализмы эзлекле характерда булмый. Күп кенә очракларда дөньяга караш мәсьәләләрен ярым-йорты һәм каршылыклы характерда хәл итү белән бәйле стихияле материализм була. Мондый эзлексезлек һәм каршылык татар иҗтимагый фикеренең хәтта революцион-демократик идеология позицияләрендә торган иң күренекле вәкилләренә дә хас була. Үзенең фикер сөрешендә Ф. Әмирхан, мәсәлән, тышкы дөньяның күренеш һәм закончалыкларыннан этелеп китсә дә, аларны тудырган илаһи көчнең булуын таный. Бу уңайдан аның астрономиягә караган «һәйәт... аллаһның шулкадәр зур хикмәт вә кодрәтләрен белдереп, адәмне тәгаҗҗеп вә хәйрәткә сала торган фәндер»[3] дигән сүзләрен искә төшерү дә җитә. М. Гафури үз кардәшләрен бәхетне алла кодрәте белән барлыкка килгән җирдән эзләргә чакыра:

Шуны әйтмәк булам: таңре җир өстен безгә биргән,
Бәхетне ошбу җирдән эзләсеннәр инде һәр бәндә[4].

3. Хәмиди кеше психикасы һәм танып-белү хакында бик тә анык материалистик фикерләр әйткән кеше. Шул ук вакытта кеше табигатенең бу сыйфатын ул аллага

---

[1] «Шура» журналы. 1915 ел. 24 сан, 737 бит.
[2] М. Хәнәфи. Хәят вә фәлсәфә. «Аң» журналы, 1914 ел, 2 сан, 38 бит.
[3] Ф. Әмирхан. Сайланма әсәрләр. 2 том. Казан, 1958 ел, 136 бит.
[4] М. Гафури. Сайланма әсәрләр. 1 том, Казан, 1954 ел, 96 бит.

кайтарып калдыра: «гыйлем рух аллаһы тәгаләнең бездә яраткан нигъмәтләренең иң кадерлесе улган җаннан бәхәс итдеке»[1], дип яза.

Татар халкының фикер ияләре яшәгән һәм иҗат иткән мөселман дөньясында илаһи көч турындагы теория ифрат популяр була. Шушы мәсьәләгә тукталып, К. Маркс: «...творение является таким представлением, которое весьма трудно вытеснить из народного самосознания. Народному сознанию непонятно чрез себя — бытие природы и человека, потому что чрез себя — бытие противоречит всем сознательным фактам практической жизни»[2], дип язды. Фән белән танышу һәм XX йөз башындагы давыллы вакыйгаларда катнашу татар халкының алдынгы карашлы фикер ияләрен дини-идеалистик күзаллауларның дәрәҗәсләгенә шикләнеп карарга мәҗбүр итте, тик татар халкы тормышының специфик шартлары һәм иске традицияләрнең көче аларга, дини-идеалистик караш белән мөнәсәбәтне тәмам өзеп, эзлекле материалистик позицияләргә басарга комачаулый иде.

XX йөз башындагы алдынгы карашлы фикер ияләренең дөньяга карашындагы эзлексезлек деистик характерда иде. Алар алланы кире какмыйлар, әмма аңа алга таба үзенең табигый законнары буенча үсәчәк дөньяга тормыш биргән беренче этәргеч көч ролен генә калдыралар. Алар алланы танысалар да, аларның алласы дөньяда барган вакыйгалардан читтә тора, ул җан ияләре барлыкка килүнең беренче актында гына катнаша, соңыннан чынбарлыкта барган вакыйгаларда аның роле күренми.

Бу җәһәттән Г. Тукайның сәбәплелек категориясен аңлавы кызыклы. Ф. Әмирхан белән М. Гафури кебек үк, ул алланы таный. Тик аның алласы сәбәплелек законына буйсынган реаль вакыйгалардан читтәрәк тора. Реаль тормышта, дип фикер йөртә Г. Тукай, аллаһы тәгалә һичкемгә бернинди миһербанлык күрсәтмидер. «Аллаһы тәгаләнең рәхмәте һичкемгә хас түгелдер, һәм бу галәм-галәмел әсбабтыр. Һәм дә ялган сөйләмәсе мөхаль вә мәмнүн мөхбире Садыйкъ әфәндемез дә: «Кеше тырышса, табар»,— боермышлардыр»[3]. Моннан күренгәнчә, XX йөз башында яшәгән алдынгы карашлы башка фикер ияләре кебек үк, Г. Тукай да, дөньяны яраткан алланы таныса да, дөнья белән идарә итүче алланы инкарь итә. Кеше яшәгән бу дөньяда сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләре генә хакимлек итә, кеше тормышта бары уңганлыгы аркасында гына уңыш казана ала, дип уйлый. Аерым бер мәсьәлә буенча Г. Тукайның тоткан юлына кыскача гына анализ ясау да, фикерендә каршылыклар булуга да карамастан, аның күз карашы дөньяны материалистик аңлауга юнәлгән булуын раслый. Каршылыклы раслаулар һәм күп кенә мәсьәләләрне эзлексез хәл итүләр аша дөньяга материалистик караш Ф. Әмирхан, М. Гафури һәм татар мәдәниятенең башка вәкилләре аңына үтеп керә.

Эзлексез характерда һәм каршылыклы булуларына карамастан, XX йөз башында яшәгән алдынгы фикер ияләренең дөньяга карашына хас материалистик тенденцияләр халык алдында торган мөһим мәсьәләләргә бәя биргәндә һәм ул мәсьәләләрне чишү юлларын билгеләгәндә җитди методологик таяныч хезмәтен үти. Әйтик, җәмгыятьчелек фикере алдында торган шундый үткен мәсьәләләрнең берсе милләт язмышы, милли тел һәм әдәбият мәсьәләсе була. Бу мәсьәләләр әле XIX йөз мәгърифәтчеләре алдында ук торган, һәм алар аны мөселман дине, дөньяга дини караш салган катламнардан тазартуда сизелерлек өлеш кертәләр. Шуңа да карамастан, бу мәсьәләләр XX йөз башында да үткенлекләрен югалтмыйлар. Әйтик, тел мәсьәләсендә Г. Ибраһимов казакъларга чит, ят тел нормаларын көчләп тагарга тырышучыларга каршы чыга. «Һичбер халыкның,— дип яза ул,— авызына һичбер вакытта, аның табигый телен тартып алып, үзе теләгән яңа бер тел куяр хәл юк. Әдәби тел һичбер вакыт ясалмый. Ул халыкның үз рухындагы мәгънәне нинди тел белән әйтергә теләвеннән килеп чыга»[4]. Кайчандыр ерак үткәндә, тормышның объектив шартлары тәэсирендә төрки халыклар бердәм әдәби тел йогынтысына эләккән. Тик

[1] «Шура» журналы, 1912 ел, 10 сан, 297 бит.
[2] К. Маркс, Ф. Энгельс. Из ранних произведений. М., 1956, с. 594.
[3] Г. Тукай. Әсәрләр. 3 том. Казан, 1978 ел, 12—13 битләр.
[4] Г. Ибраһимов. Телләре башка булса да күңелләре бер. «Аң» журналы. 1916 ел, 5 сан, 87 бит.

соңыннан тарихи, географик, экономик, политик һәм мәдәни-идеологик факторлар ул халыкларның бүленүенә, аерымлануына китергән. Шундый шартларда госманлыларның, әзербәйҗаннарның, үзбәкләрнең һәм татарларның үз мөстәкыйль әдәби телләре барлыкка килгән. Бәс, шулай икән, ул халыкларны кабат бердәм тел традицияләренә буйсындырырга тырышу яки казакъларга шуларның кайсыныңбулса да телен көчләп тагарга азаплану тормышны һәм заманның агышын белмәүдән башка нәрсә түгел. Тик «хәят безнең теләвебез буенча йөрми. Аерым бер груһның фикер вә хезмәте һичбер вакыт хәят агымын туктата алмый. Хәят агымына каршы бару диңгез агымын ишкәк белән туктатырга тырышу кабиленнән бер эштер»[1]. Әлеге мәсьәләдә Җ. Вәлиди дә шундый ук позицияне яклый, бу мәсьәләгә карата булган дини-идеалистик мөнәсәбәтне кире кагып, милләт ул — буш хыял гына түгел, абстракт хисләрнең һәм фәнни доктринаның җимеше түгел, ә тормышта реаль әһәмияте булган иҗтимагый күренеш, ди. Әгәр шулай икән, төрки халыкларның бүленүе дә «реаль зарурият»[2].

*

* *

XX йөз башында яшәгән фикер ияләренең дөньяга карашларында, материалистик идеяләр белән бергә, диалектик фикерләр дә күзгә ташлана. Моның шулай икәнлеген дөньяның бердәмлеге, күренешләрнең үзара бәйләнеше, дөньяда барган процессларның характеры, сәбәпнең нәтиҗәгә күчүе турында алда китерелгән мисаллар да ачык күрсәтә.

Диалектик проблемаларның матбугат битләрендә, фәнни һәм матур әдәбият әсәрләрендә аеруча киң тикшерелгәне үсеш турындагы идея булган дисәк, әллә ни арттыру булмас кебек. Хәрәкәтне, үзгәреш белән үсешне татарның алдынгы карашлы фикер ияләре чынбарлыкның гомуми бер сыйфаты дип саныйлар. Шуның өстенә үзгәреш һәм үсешне алар гомер-гомергә булган яки барлыкка китерелгән, тудырылган элементларның гади бер күбәюе дип кенә түгел, ә яңарыш, яшәү рәвешләренең катлаулана баруы, яңа, тагын да камилрәк сыйфатларның барлыкка килүе, дип саныйлар. Органик булмаган табигатьтә, дип яза Н. Агаев, акрынлап, әмма даими төстә үсеш һәм үзгәреш процессы бара, бу процесс башта үсемлекләр, аннан хайваннар дөньясын барлыкка китерә. Җанлы табигатьтә дә даими үсеш процессы бара, шул кешелек ыруын барлыкка китерә. Үсеш-үзгәреш канунына кешелек җәмгыяте дә буйсына[3]. М. Хәнәфи антик чор философы Гераклитның диалектик фикерләренә югары бәя бирә. Аның өчен, ди ул, «барча нәрсә ага... Дөньяда хәрәкәттән башка нәрсә юк, хәрәкәт барга гына дөнья бар... Барча нәрсә ага, бер елга суында ике мәртәбә коенырга мөмкин түгел»[4].

Шунысы мөһим, татарның алдынгы карашлы фикер ияләре үсеш-үзгәрешне үткәнне кабатлау төсендә дә, өзлексез әйләнеп тору рәвешендә дә түгел, ә бәлки искенең җимерелүе, яңаның тууы төсендә аңлыйлар. «Татар шагыйрьләре» дигән хезмәтендә Г. Ибраһимов, мәсәлән, «дөньяга киләләр, яшиләр, соңра фәна кыйлә... әүвәл хәят, гыймарәт, соңра хәрәбәлек»[5], дип яза. «Мәдрәсәи Галия вакыйгасы илә» дигән икенче бер хезмәтендә ул әлеге мәсьәләгә кабат әйләнеп кайта һәм болай ди: «Адәм хыялы вә хәяте туктаусыз тәрәкъкый юлында. Тәрәкъкый димәк хәятнең иске рәвешләрен җимереп, яңа ихтыяҗларга җавап бирерлек яңа шәкелләр тудырмак димәктер... Искене җимерү белән мәйдан бушый, хәят эченнән бәреп чыгачак яңа куәтләргә юл ачылган була»[6].

Алдынгы карашлы фикер ияләренең күзаллавынча, үсеш-үзгәреш — кеше ихтыярына бәйләнмәгән объектив процесс. Аның нигезендә аллаһы тәгаләнең ихтыяры түгел, ә тышкы дөньяның зарурияте ята.

---

[1] Шунда ук.
[2] Җ. Вәлиди. Милләт вә миллият. «Вакыт» газетасы. 1914, 33—36 битләр.
[3] «Шура» журналы. 1909 ел, 3 сан, 72—74 битләр.
[4] М. Хәнәфи. Хәят вә фәлсәфә. «Аң», 1913 ел, 23 сан, 435 бит.
[5] Г. Ибраһимов. Татар шагыйрьләре. 42 бит.
[6] «Аң» журналы. 1915 ел, 20 сан, 359 бит.

Фикер иҗләре алга сөргән үсеш идеясенең кыйммәте фәнни әһәмияткә ия булуы белән генә чикләнми, ул сәяси һәм идеологик әһәмияткә дә ия була, ул — үзенең үткен очы белән татар тормышындагы бөтен иске, катып калган нәрсәләргә каршы юнәлтелгән идея, иҗтимагый үзгәрешләрнең котылгысыз һәм зарури булуын алга сөрү белән бәйләнгән идея.

XX йөз башындагы татар иҗтимагый фикерендә диалектиканың капма-каршылыкларның бердәмлеге һәм көрәше кебек мөһим законы да нык тамыр җибәрә. Г. Ибраһимов фикеренчә, «табигатьтә гүзәллек белән ямьсезлек һәрвакыт үзара янәшә яшәп килгән». Җылылык белән салкынлык, искелек белән яңалык, шатлык белән кайгы — шул капма-каршылыкның мисаллары. Капма-каршылыкларның үзенчәлекле көрәше һәм бердәмлеге тормышның нигезен тәшкил итә. «Шул көрәш туктауга, тормыш та туктый, үлем килә». «Тормышта кояш һәм кара болыт, шатлык һәм канлы күз яшьләре китергән кайгы бергә яши» дип язганда Г. Тукай да тирә-юньдәге күренешләрнең капма-каршы характерда булуыннан чыгып фикер йөртә.

Татарның алдынгы карашлы фикер иясләре иҗтимагый тормыш күренешләренә якын килгәндә һәм аларга бәя биргәндә дә капма-каршылыклар принцибына таянып эш итәләр. Бу Г. Ибраһимовның, «Аң» журналының 1915 елгы саннарында басылган, XIX йөзнең күренекле мәгърифәтчесе Ш. Мәрҗани эшчәнлеген тикшерүгә багышланган «Бөек остазымызның кайбер тәэлифләре» исемле хезмәтендә аеруча ачык күренә. Ул — Г. Ибраһимов карашынча, бик тә каршылыклы шәхес. Тышкы рәвеше, фикер әйтү алымы ягыннан ул әле мөселман галиме булып кала бирә. Тик иҗатының һәм эшчәнлегенең эчтәлеге ягыннан Мәрҗани саф мөселманлык рамкаларыннан нык ук читкә чыга. Искечә тәрбия алган руханилардан аермалы буларак, ул үткәнгә, аның традицияләренә һәм авторитетларга да ниндидер изге нәрсә итеп карамый. Аның карашы киләчәккә төбәлгән, әнә шул киләчәк хакына ул искелеккә, схоластик агуга кискен каршы чыга, кеше акылының мөстәкыйль рәвештә хакыйкать эзләргә хакы булуын яклый. Мәрҗанинең шушы капма-каршылыгы аның әсәрләрендә дә чагыла.

Шул рәвешчә, XX йөз башындагы алдынгы карашлы вәкилләр арасында үсеш-үзгәреш, үзара бәйләнеш һәм капма-каршылыклар турындагы диалектик фикерләр нык тамыр җибәрә. Дөрес, бу фикерләр стихияле төстә була һәм өйрәнә торган предмет һәм күренешләрнең диалектик чагылышы рәвешендә барлыкка киләләр. Ә диалектика үзе турыдан-туры өйрәнү предметына әйләнми. Шуңа күрә әлеге диалектик фикерләр арасында бәйләнеш булмый, алар тәзек, уйланган концепцияне тәшкил итми. Шул кадәресенә аеруча басым ясарга кирәк, үсеш идеясе белән капма-каршылыклар идеясе дә бердәм концепциягә тоташтырылмый, капма-каршылык хәрәкәтнең универсаль чыганагы итеп каралмый. Ләкин бер нәрсә бәхәссез: татар иҗтимагый фикерендә чынбарлыкны диалектик аңлау процессы урнаша һәм тирәнәя бара. Хәер, аның беренче яралгылары XIX йөздә яшәгән мәгърифәтчеләр иҗатында ук күзгә ташлана иде инде. Бу процесс дөньяга дини-идеалистик карашның характерлы бер үзенчәлеге булган метафизиканы кысрыклау юнәлешендә бара. Шуңа күрә XX йөз башының алдынгы фикер иҗләре тарафыннан якланган диалектик фикерләр татар иҗтимагый фикеренең үсешендә мөһим этап булып тора, дип әйтә алабыз.

* * *

Шулай итеп, XX йөз башында татар иҗтимагый фикерендә фәлсәфи идеяләрнең үсеше дөньяга дини-идеалистик караш хөкеменнән котылу, материалистик философия карашларын һәм фән казанышларын үзләштерү юнәлешендә яңа, кыю адым ясый. Материалистик карашлар белән рәттән, тирә-юньдә барган процессларны диалектик аңлау нык позицияләр яулый, бу исә үз чиратында моңа хәтле хакимлек иткән метафизиканы кысрыклау белән янәшә бара. Иҗтимагый аңга марксистик философиянең үтеп керүе, татар халкының алдынгы вәкилләрен Ленин идеяләренә тарту, аларны В. И. Ленинның «Материализм һәм эмпириокритицизм» кебек иҗади маркс-

измның күренекле әсәрләре белән таныштыру заманның характерлы күренешенә әйләнә.

В. И. Ленин Россиянең философик фикер тарихында бай гына материалистик традицияләр булуын әйткән иде. XX йөз башы татар иҗтимагый фикерендә дә башлангычын мәгърифәтчеләр үк салган шул традицияләр белән баю процессы бара. Татар халкы тормышындагы конкрет шартларга бәйле рәвештә, карашларында кайбер чикләнгән моментлар да булуга карамастан, татарның XX йөз башындагы алдынгы фикер ияләре дөньяны фәнни аңлау юлында җитди генә уңышларга ирешәләр, халыкның алга таба рухи үсешен билгеләрлек нәтиҗәле идеяләрне алга сөрәләр. Бу — татар халкын акрынлап заманның алдынгы идеологиясенә — марксизм-ленинизмга һәм диалектик-материалистик философиягә алып киләчәк юнәлеш иде.

# Бер сорауга — бер җавап

*СОРАУ: Бүгенге әдәбиятыбызның нинди сыйфаты аеруча көчәюен телисез?*

*МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ:*

*— Кеше рухын ачу, үзенчәлекле образ тудыру турында уйланырга иде. Ш. Камалның Газизәсе, Г. Ибраһимовның Шаһбазы, Фазыйлы, Ә. Еникинең Рәшидәсе бар бит! Ә бүгенге әдәбиятта иң актив эшләп килгән язучыларның телгә алырлык, күңелгә, тарихка кереп калырлык кемнәре бар соң? Йөзләгән язучының меңләгән әсәреннән бүген ничә образ тотып алып була? Мондый төссезлек, җансызлык борчыне дә борчымыймыни? Нигә гел макташабыз, шул турыда сөйләшмибез?*

*Мин бүгенге әдәбиятта заман рухын бирерлек, хәтердә калырлык образ тудырылуын телим. Ә бик күп язучыга, әгәр әлегә аның күңеле дөрләми, язачак темасы белән якмый-көйми икән, берничә елга каләмен куеп торырга тәкъдим итәр идем. Бу киңәшләр язучы М. Мәһдиевнең үзенә дә бик файда итәр сыман.*

# Евгений Казаков

# ЙӨЗЕК КАШЫНА НИ ЯЗЫЛГАН?

Билгеле булганча, теге яки бу халыкның килеп чыгышы, сәяси тарихы, этник составы һәм теле проблемалары язма истәлекләр белән тыгыз бәйләнештә өйрәнелә. Идел болгарларының төп өлеше читтән килгән төрле этник төркемнәрдән оешуын искә алсак, әлеге проблемаларның тагын да катлаулырак икәнлеге ачыклана.

Традиция буенча Идел Болгарстаны тарихи өч чорга — 1) әүвәлге болгар, 2) монгол яуларына кадәрге һәм 3) Алтын Урда чорларына бүлеп карала. X йөздән XV йөзнең башларына кадәрге вакытны эченә алган соңгы ике дәвер шактый җентекле өйрәнелгән. Монгол яуларына кадәрге чорга сөяк язу кораллары, берән-сәрән очраштыргалаган язмалар, мәсәлән, Әбү-Бәкернең 1147 елда йозакка гарәпчә язган язуы, Биләрдә табылган чүлмәкләрдәге тамгалар һ. б. карый. Алтын Урда чоры истәлекләреннән һ. Йосыпов, Ф. Хәкимҗанов һ. б. тарафыннан шактый яхшы өйрәнелгән күп санлы каберташ язмалары билгеле. Болгар шәһәрлекләрендә беренче мәртәбә китапларның металл тышлыклары да табылды.

Әүвәлге болгар чоры моңарчы археологик яктан иң аз өйрәнелгәне иде. Соңгы егерме ел эчендә ачылган һәм чагыштырмача яхшы өйрәнелгән каберлекләрдән (мәсәлән, Олы Тархан, Кайбель, Танкеевка, Тәтеш, Олы Тигәнәле һ. б.) һәм аерым тәбәкләрдән шушы чорның (ягъни VIII гасырның икенче яртысыннан X гасырга кадәр вакытның) үзенчәлеген билгеләргә мөмкинлек биргән бай материал тупланды. Бу, нигездә, мәҗүсилеккә һәм күчмә тормышка корылган дәүләт төзелү алды чоры, шушы вакытта Урта Идел буйларына күчеп килгән төрле кабиләләрнең үзара аралашуы нәтиҗәсендә яңа этнос — Идел болгарлары формалашкан.

Әүвәлге болгар чорын өч этапка бүлеп карарга мөмкин. Беренче этапта (VIII гасырның икенче яртысы — IX гасырның беренче яртысы) болгар-салтау (Кайбель, Олы Тархан һ. б. каберлекләр) белән кушнаренко культурасы (Олы Тигәнәле, Немчанка һ. б. каберлекләр) этник төркемнәре үзара аралаша. Аннары (IX гасырның икенче яртысы — X гасырның беренче чирегендә) алар арасына Урал-Чулман якларыннан ломоватов-стәрлетамак культурасы кабиләләренең көчле агымы килеп керә. Соңгы этапта (X гасыр тулысынча диярлек) утрак яшәү урыннары салына, дәүләт институтлары ныгытыла, ислам дине мәҗүсилекне кысрыклап чыгара һ. б.


Иң әүвәлге болгар заманындагы төрле этник төркемнәр (ә соңрак шулардан Идел болгарлары формалаша), күрәсең, төрле телләрдә, асылда борынгы төрки һәм угыр телләрендә сөйләшкәннәрдер. Аларның, бигрәк тә болгар-салтау төркемнәренең, рун (чөй) язуы белән таныш булулары бик ихтимал. Мари һәм Удмуртия АССР җирләрендә табылган рун (чөй) язуларының да болгарларга бәйле булуы мөмкин. Олы Тархан каберлегендәге салтау савытлары төбендә күренгәләгән кайбер тамгалар да рун хәрефләрен хәтерләтәләр. Урта Иделдә, Дон һәм Дунай буйларында табылган төрле тамгаларны чагыштырып тикшергәннән соң, С. А. Плетнева аларның уртак билгеләрен табып, болгарларныкы икәнлеген раслады [1].

[1] Плетнева С. А. От кочевий к городам. М., 1967, 177 бит.

Әүвәлге болгар чорының беренче этабына Олы Тархан каберлегендә табылган коелма йөзек карый. Аның турыпочмаклы кашында латинча «т» хәрефенә охшаш билге ясалган.

Илебездәге иң зур каберлекләрдән саналган Танкеевка каберлегендәге (IX—X гасырлар) билгеләр һәм язулар исә бу чорның икенче этабын характерлыйлар. X гасырга караган бер кабердәге савытның төбенә көпчәк сыман тамга сугылган, ә икенчесендә — бөтенләй бүтән төрле тамга (рәсемдә — 6). Шул ук чорга караган чүлмәккә боларга охшамаган ниндидер катлаулы билге тырналган (7).

Танкеевка каберлегендәге эзләнүләр безнең археология фәнен бик үзенчәлекле табылдык белән баетты. Танкеевкага хас йола буенча, баш очына сыерның калак сөяге, бер тоткычлы түгәрәк чүлмәк салынган, уң кул ягына бронза колак чистарткыч белән агач кынлы пычак куелган комплекс игътибарны җәлеп итте. Биредә түгәрәк кашлы көмеш йөзек, без белән түгәрәк савыт китегеннән эшләнгән орчыкбаш табылды. Баш сөягенең йөз ягында ефәккә төрелгән көмеш битлек белән маңгай буенда көмеш таңкәләр тегелгән ефәк тасма бар иде.




Чүлмәкнең борынгы заманда ук ватылган тоткычы астында хәрефкә охшаш билге барлыгы ачыкланды (8). Ә йөзек кашына өч билгедән торган язу чокып язылган иде (3). Билгеләр, аларның асылына төшенәсе бар әле, чыгышлары ягыннан бу билгеләрнең рун язмалары белән бәйләнеше булуы да бик ихтимал.

Битлегенә карап, мәрхүмәнең Урал-Чулман тирәләреннән икәнлеген билгеләргә мөмкин. Әмма чүлмәк белән колак чистарткыч болгар-салтау дөньясына хас әйберләрдән саналалар. Бу хәл мәҗүсилек вакытындагы болгарлар культурасының Урта Идел буена күченгән төрле культуралар нигезендә формалашуы турында сөйли.

Табылдыкларның характеры һәм каберлектәге урыны тикшерелгән комплексны һәм шулай ук язуларны да IX гасырның икенче яртысына карый дияргә мөмкинлек бирә.

Танкеевка каберлегеннән тагын бер кызыклы табылдык чыкты. Бу — ахак кашлы борынгы йөзек (рәсемдә — 4). Тикшеренүче Н. Гәрәева уйлавынча, йөзек кашына гарәпчә «Бисмиллаһ» («Алла исеме белән») дип язылган. Язудан тыш, анда кар таң-

кәсе сыманрак бизәк тә төшерелгән. Билгеле, асылташны исәп язу хәрефләргә дә үзенчәлекле төс биргән.

Моннан тыш, Танкеевкада тимер балта, ук очлары, дирбия детальләре, бил бавының көмеш әйберләре, түгәрәк алка һ. б. табылды. Бер тоткычлы чүлмәкләрнең берсе — болгар-салтау савыт-сабаларының соңрак варианты, ә икесе шуңа охшаш итеп эшләнгән булып чыкты. Кумү йоласының катнаш булуына карамастан, бу әйберләрнең дә Урал-Чулман якларыннан килүчеләрнеке икәнлеге бәхәссез. IX—X йөзләрдә Чулман буе кешеләре, кул белән әвәләп, салтау чүлмәкләренә охшаш савытлар ясаганнар, ә билбау детальләрендә соңрак замандагы кушнаренко истәлекләрендәге әйберләр белән бердәйлек күренә. Йөзек, билбау детальләре, кул белән әвәләп эшләнгән савытлар һәм җирләүнең каберлектәге урыны нигезендә күмелү датасын IX—X гасырлар дип кабул итәргә мөмкин. Ихтимал, ахак кашлы йөзектәге язу да шушы вакытка туры киләдер.

Шундый ук язулы йөзекнең IX—X гасырныкы дип танылган Бирка каберлегендә табылуы билгеле. Шуңа охшашлырак язу Көнбатыш Казахстанның бер каберлегендәге йөзектә дә күренә кебек, ләкин ул безне кызыксындырган вакытка карамый. Һәр очракта да язу-сызу туры сызыклар рәвешендә уелып эшләнгән булуы белән үзенчәлекле.

Әүвәлге болгардан монгол явына кадәрге чорга күчү этабына Куйбышев районы Әҗмәр авылы янындагы Әҗмәр I авыллыгында табылган язуларны кертергә була. X гасырның икенче яртысына караган кызгылт-көрән орчыкбашка биш билге сызылган. Счет төймәсе төсле божраның бер читендәге билгене һичнинди шөбһәсез рун хәрефе дип танырга була. Өч билгенең сызыклары кечкенә түгәрәкләр белән тәмамланган, дүртенчесе исә Танкеевка каберлегендәге савытта күренгән тамганы хәтерләтә (2). Язылышы ягыннан ул «к» хәрефенең Себер руникасындагы (Енисей белән Урхун өлешләренең икесендә дә) язылышына охшаган. Танкеевка каберлегендә бу билгегә тагын бер сызык кына өстәлгән.

Орчыкбаштагы язудан шундый нәтиҗә ясарга мөмкин: монгол явына кадәрге чорда, бигрәк тә аның башлангыч этапларында гарәп язуы кулланылышка кергән булса да, болгарлар рун язуын да онытмаганнар. Әҗмәр I авыллыгында табылган сөяк җәя кисәгендәге язу (рәсемдә — 5) бу фикерне раслый кебек. Яссы сөяк кисәгендәге гарәпчә текстны Мәскәү университеты профессоры Г. А. Федоров-Давыдов болай тәрҗемә итте: беренче юлда — «фатиха», икенчесендә — «шәфкатьле, мәрхәмәтле Аллах исеме белән...» Аның фикеренчә, куфи белән нәсех язулары үзенчәлекләрен берләштергән бу текст X—XI йөзләргә мөнәсәбәтле булырга тиеш.

Язу үткен тимер пычак яки кискеч очы белән уелган. Шунлыктан хәрефләр күпчелек очракта туры сызыклар ярдәмендә ясалганнар, әмма, шундый шартлылыкка да карамастан, алар җиңел укылалар. Кисүче гарәп язуының катлаулы элементларын ныклы, ышанычлы хәрәкәтләр белән, җиңел, нәфис итеп башкарган. Бу — Идел болгарлары төбәгендәге иң борынгы һәм тулы язу. Киләчәктә аның каллиграфиясенә дә, һичшиксез игътибар ителер әле.

1981 елда Әҗмәр I авыллыгында табылган алсу тестәге орчыкбаштагы тамга да шундый юл белән язылган (1). Аның Танкеевка каберлегендәге язма истәлек элементлары белән охшашлыгын да күрсәтми мөмкин түгел.

Югарыда телгә алынган археологик табылдыклар әүвәлге Болгар кешеләрендә гарәп системасы кабул ителгәнче үк язу булганлыгын күрсәтәләр, чөнки аның элементлары монгол язуларына кадәрге чорга тикле сакланганнар. Билгеле, яңа материал тагын да күбрәк туплангач кына, язулар үзләренең сер тартмаларын тулысынча ачарлар.

Мәгълүм булганча, ислам дине X гасырның беренче чирегендә Болгарга актив үтеп керә башлый. Танкеевка йөзек кашындагы язу (4) гарәп язуы һәм, ихтимал, ислам диненең дә Болгарга IX гасырның ахыры — X гасырның башларында үтеп кергән дип уйларга мөмкинлек бирә. Әмма Танкеевка белән Татеш каберлекләре материалларына караганда, мәҗүсилек, аның төп үзенчәлекләре XI гасырның башларына кадәр (бигрәк тә авыл җирендә) сакланып килгән дип билгеләргә мөмкинлек бирә.

# «ЙӨЗЕК КАШЫНА НИ ЯЗЫЛГАН?» ДИГӘН МӘКАЛӘГӘ КАРАТА

Язу проблемасы — ул, иң әүвәле, культура традицияләре проблемасы. Идел болгарларында язу системасының формалашуын, шулай ук аны куллану үзенчәлекләрен ачыкламый торып, аларның матди һәм рухи культуралары турындагы белемебез тулы дип әйтеп булмый.

Болгар дәүләтенә гарәп язуы кинәт кенә килеп кермәгән. Төрки халыклар сөйләмен якынча гына бирергә сәләтле бу язуны куллана башлау, билгеле, ислам динен кабул итү белән бәйле. Галимнәрнең тикшеренүләре күрсәткәнчә, Идел-Чулман буйларына күчкәнче, болгар кабиләләре борынгы төрки рун язуын кулланганнар. Төньяк Кавказдагы борынгы болгар язма истәлекләренең рун алфавиты нигезендә язылуы, Дон, Сыр-Дәрья буйларындагы, Надь-Сен-Миклоштагы (Венгрия), Урта Азиядәге печенегларныкы дип исәпләнгән язулар да шулай ук башкарылу моны раслый кебек.

Татарстанның төрле төбәкләрендә казу эшләре алып барганда археолог Е. Казаков тапкан язулы әйберләр бик кыйммәтле истәлекләрдән саналырга хаклы. Дөрес, савытлардагы аерым билгеләр остаһың шәхси клэймәсе яки савыт хуҗасының тамгасы булуы да мөмкин. Ләкин нәрсә генә булмасын, без аларны борынгы болгарларда кулланылган рун хәрефләре белән чагыштыра да, аларга тиңли дә алабыз. Мәсәлән, рәсемдәге 6 нчы билге төрки руникасындагы «м» авазын белдерүче билгегә охшаган, 8 нчесе Урхун язмаларындагы «з»ны хәтерләтә. Йөзектәге билгеләрне (рәсемдә — 3) ниндидер язу дип карарга тулы нигез бар, чөнки әлеге билгеләр тышкы кыяфәтләре белән төрки руннарны хәтерләтәләр, алар бер яссылыкта һәм бер сызыкта урнашканнар h. б. Әмма аларга нинди мәгънә салынган? Хәзергә әйтүе кыен. Гадәттә, йөзектә кеше исеме яисә тәкъва язу була. Биредәге хәреф-билгеләрне «н», «л» яки «ш» һәм «с»ны белдерүче рун хәрефләре белән тәңгәлләштерергә мөмкин. Шулай да, алардан сүз чыгару әлегә иртәрәк, чөнки бу йөзекнең мөһерме-түгелме икәнлеген беләсе, язуның юнәлешен ачыклыйсы бар. Хәзергә мондый язулы әйберләрне күбрәк туплау турында уйларга кирәк.

Мәгълүм ки, Идел болгарлары ислам динен рәсми рәвештә 922 нче елда кабул итәләр, әмма инде аның нигезләре һәм гарәп язуы белән алар алданрак таныш булалар. Гарәп телендәге язулы әйберләрнең әүвәлге болгар чоры катламында ук табылуы — шуны раслаучы мөһим күренешләрнең берсе. Язуларның эчтәлегеннән дә бигрәк (сүз уңаенда шуны да әйтер идем: ахак кашлы йөзектәге язуның укылышы белән генә килешеп булмый), аларның каллиграфиясе игътибарны җәлеп итә. Хәрефләрнең төз вертикаль сызыклары нык һәм төгәл басым белән уелган, куфи язуының барлык элементлары арасындагы нисбәт тә сакланган. Ул үзенең гүзәллеге һәм нәфислеге белән сокландырырлык. Көнкүреш әсбапларында да шундый осталык һәм камиллек үрнәкләре саклангач, монументаль яки декоратив әйберләрнең торышы, күрке турында фараз итәргә генә кала.

**ФӘРИД ХӘКИМҖАНОВ,**
*филология фәннәре кандидаты*

# РЕВОЛЮЦИОН КӨРӘШ СЕРЛӘРЕ

Революциягә кадәрге алдынгы иҗтимагый-политик фикернең, революцион азатлык хәрәкәтенең үсү юллары катлаулы һәм каршылыклы. А. Н. Радищевның крепостной җәмгыятькә каршы чыккан өндәмәсе елларыннан башлап Россиядә марксизмның тарала башлавына хәтле алдынгы фикерле кешеләрне барлау, мәгърифәтчелек һәм революцион демократизм, илебез халыкларының милли үзаңы формалашу үзе бер чор булып тора.

Иҗтимагый-политик фикернең үсеш мәсьәләләрен, халыкларның революцион хәрәкәтен чынбарлыктан килгән фәнни, идеяле, тәрбияви мөнәсәбәттә гомуммилли һәм региональ киңлекләрдә тикшерү зарури. Һәм әйтергә кирәк: Р. Нәфиковның бу өлкәдә бай тәҗрибәсе бар. Моңа аның «Алдынгы татар иҗтимагый-политик фикере» (1964), «XIX—XX йөз башында Идел буенда иҗтимагый-политик фикер» (1977), «Революциягә беренче адым» (1970) кебек китаплары матур мисал булып торалар. Авторның махсус белгечләр һәм киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителә торган яңа китабы[1] үзенең проблемалары буенча алдагы җыентыклары белән тыгыз бәйләнештә. Ул теоретик-методологик тирәнлеге һәм чыганаклар байлыгы белән кыйммәтле. Мәкаләләрнең күбесе фәнни куллanышка беренче тапкыр тәкъдим ителә. Аларда Идел, Урал буе, Казахстан, Кавказ халыкларының милли үзаңы ныгуның, аларның фән-культура биеклекләренә тартылуының яңа катламнары, революцион хәрәкәттә катнашу формалары һәм алымнары ачыла.

Монографиянең композициясе дә бик уңышлы төзелгән. Автор бер хезмәттә көрәшчеләрнең буыннан-буынга күчә килү мәсьәләсенең гаять әһәмиятле аспектларына һәм күренекле революционерларның, демократларның конкрет характеристикасына багышланган бүлекләрне бәйләп алып бара. Шушы бәйләнеш зур социаль яңгырашлы фактларга һәм вакыйгаларга бай тарих киңлеге фонында аларны ачыклауның конкрет мөмкинлеген тудыра.

Фәнни тикшеренүче шулай ук В. И. Ульянов-Ленин, А. И. Ульянова, А. И. Ульянова-Елизарова, Н. Е. Федосеев, А. И. Веретенникова (В. И. Ульяновның туганнан туганы), Н. Э. Бауман, Н. Нариманов һәм башкаларның биографияләрендәге шактый кызыклы һәм әһәмиятле яңалыкларны да тапкан.

Хөсәен Ямашев турында монографик тикшеренүләр булса да, РСДРП байрагы астында күпмилләтле хезмәт ияләренең интернациональ оешуы өчен көрәшкә үзенең бөтен гомерен багышлаган күренекле татар революционеры, социал-демократының күпкырлы эшчәнлеге тулысынча яктыртылып бетмәгән әле. В. И. Ленин редакциясендәге «Пролетарий» исемле большевистик газетада Х. Ямашев шәхесенә югары бәя биргән мәгълүм бер билгеләмә бар. Шуңа күрә профессор Р. И. Нәфиковның моңа кадәр билгеле булмаган материал чыганагын фәнни кулланышка тәкъдим итүе тагын да зуррак игътибарга лаек. Бу материал безне Х. Ямашевның эшчәнлеге һәм тормышы, аның укучы яшьләргә, гомумән, Идел-Урал буе, Казахстан, Кавказ интеллигенциясенә булган чиксез зур йогынтысы турындагы яңа мәгълүматлар белән баета. Монографиядә большевик Ямашевны чолгап алган мохит: Ф. Әмирхан, Г. Колахметов, Р. Маликов, И. Котлыбаев һ. б. шәхесләре мәсьәләсе аерым урын алган.

Татар демократларының Л. Н. Толстой белән элемтәдә булулары, Казан университетының китапханәсе язмышы, Габдулла Тукай һәм аның дуслары РСДРПның Казан

---

[1] Нафигов Р. И. «Тайны революционного подполья». Изд-во КГУ, 1981.

комитеты максатлары өчен акча җыешулары турындагы китап битләрен шулай ук ассызыклап билгеләп үтәргә кирәк.

Бирелә тагын фән тарафыннан җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән кызыклы бер бүлек бар. Анда прогрессив эшлеклеләрнең, демократларның магистраль көрәш юлы булган әдәбият, музыка һәм театр өлкәсендә үзләренең йогынтысын тарату эше чагылдырыла. Автор азатлык хәрәкәтенең революцион-демократик һәм пролетар этапларында халыкларны агартуда Казан университетының тоткан урыны зурлыгын да нык лы дәлилләр белән раслый. Бу бүлек тулысынча шул чор көндәлек матбугаты һәм архивларның материаллары нигезендә язылган.

Конкретлык, шул ук вакытта олы гомумиләштерүләр, аерым бүлекләр һәм бөтен хезмәт буенча ясалган ахыргы чиккәчә ачык, аңлаешлы нәтиҗәләр Р. Нәфиков монографиясенең һичшиксез зур уңышы дип санарга мөмкинлек бирә. Бу нәтиҗәләр әлеге хезмәтнең төп эчтәлеген чагылдыралар, авторның хәл-күренешләргә гомумкарашларын, фәнни тикшеренү эшендәге күп көч һәм тәҗрибә таләп иткән эзләнүләрен төптән аңларга ярдәм итәләр.

Авторның үз темасына нык бирелгәнлеге бик күп материаллар эзләүдәге төрле авырлыкларны җиңәргә булышуын да билгеләп үтәргә кирәктер. Ул, ихлас бер мавыгу белән, үз халкының һәммә проблемалары, шатлык-кайгылары уртасында кайнаган алдынгы фикерле кешеләрнең эшчәнлеге царизмның акылга сыймаслык авыр шартларында дәвам итүен ачып бирә. Шул рәвешчә, фәнни яктан бик әһәмиятле бу китапның тәрбияви роле дә зур. Ул, шушы яктан караганда, укучылар күңелендә күпмилләтле илебез тарихына кызыксыну һәм мәхәббәтне үстерү эшендә юл күрсәтүчеләрнең берсе, дияргә тулы хакыбыз бар.

Китапны укып чыкканнан соң, аны язган галим кулы аша рус, татар һ. б. телләрдәге төрледән-төрле йөзләрчә материал узуын турыдан-туры, арттырусыз-нисез әйтеп була. Аларда моңа кадәр галимнәр күзенә чалынмаган яисә күптән онытылып беткән мәгълүматлар да бар. Хәзер алар яңадан «терелеп», тәгәл эшләнгән бер системага килеп бастылар. Яңа китапның менә шушы ягы, укучыны кызыксындырып, яңа эзләнүләр һәм уйланулар дөньясына чакыра. Авторның әдәби осталыгы булмаса, мондый фикер һәм хис тирәнлегенә ирешү мөмкин түгелдер, мөгаен. Ләкин шулай да китапның тәгәл идея һәм методологик юнәлештә булуы — аның төп уңышы. Автор революцион подпольеның ничек барлыкка килүен, үсүен һәм көрәштәшләрнең — рус, татар, башкорт, казах, әзербәйҗан һ. б. халык вәкилләренең иңгә-иң торып алга баруларын, барган саен, дуслык хисенең кулларны кулга ныграк кысуын тарихның серле пәрдәсен күтәреп, ачып күрсәтә.

Яңа хезмәт югары профессиональлеге, фәнни намуслылыгы, чын мәгънәсендә марксистик-ленинчыл тирән анализы, нәтиҗә һәм гомумиләштерүләре белән яңача уйлануларга, тырыш эзләнүләргә этәрә. Болар барысы һәм тикшерелгән аспектларның киңлеге бүгенге көн белән тыгыз бәйләнешкә кереп, Коммунизм төзү бурычларына бәйле рәвештә, профессор Р. И. Нәфиков хезмәтен идеологик яктан чагыштыргысыз дәрәҗәдә файдалы һәм әһәмиятле итә.

**ГРИГОРИЙ ВУЛЬФСОН,**
тарих фәннәре докторы.
**СӘГЫЯ МИХАЙЛОВА,**
тарих фәннәре кандидаты.

# БАКЫЙ УРМАНЧЕ АЛЬБОМЫ

Альбомның тышлыгын ачкач ук Бакый Урманченың фотопортреты белән очрашабыз. Чәченең кар төсе киң маңгай аша рәссамның йөзенә җәелгән, чигәсенә орынып торган бармаклары буйлап кулына күчкән... Ак моң аның кашларын агарткан, ләкин сиксән алты елны күреп кичергән яшь күзләренә, димәк — күңеленә дә, үтеп керә алмаган. Бу күзләр, скульпторның мәшһүр «Сагыш» сынын хәтерләткән бу портрет сине сүзсез әңгәмәгә чакыралар...

Альбомның татар һәм рус телләрендә тәкъдим ителә торган кереш мәкаләсе РСФСРның һәм Татарстанның халык художнигы, Татарстанның Г. Тукай исемен-

дәге Дәүләт премиясе лауреаты, скульптор, нәкышче, график Бакый Урманченың тормыш һәм иҗат юлы белән кыскача таныштыра. Сәнгатькә һәвәс гаиләдә туып та, 1907 елдан бирле рәссам булырга хыялланып та, Бакый Урманче Бөек Октябрь революциясенә кадәр теләгенә ирешә алмый. Ун яшьлек татар малае алдында Казан сынлы сәнгать мәктәбенең ачылмаска ябылган ишекләрен революция җиле киң итеп ача, һәм 1919 елда 22 яшьлек Бакый, ниһаять, укырга керә... Бакый Урманче — татар халкының югары сәнгать белемле иң беренче рәссамнарының һәм педагогларының берсе. Ул 1924 елда «Балалар тәрбиясендә сынлы сәнгать» дигән китап яза, 1926 елда үзе укыган Казан сәнгать техникумында укыта, алтмышынчы еллар урталарында Ташкент сәнгать институтында эшли, өлкән курс студентлары өчен индивидуаль остаханә җитәкчесе була. Мәскәү, Алма-Ата, Ташкент, Балхаш, Сәмәркәнд — Бакый Урманченың төрле елларда озаклап яшәгән һәм эшләгән шәһәрләре. Алар татар совет рәссамының илһамын интернациональ рух белән баеткаччар, иҗади хезмәтенең офыкларын киңәйтешкәннәр. Кеше юлда эз калдырган кебек, юл да кеше күңелендә үзенең эзен уя. Биографиясенең географик киңлеге Бакый Урманчега татар совет сынлы сәнгатен яңа төсмерләр белән баетырга ярдәм иткән — рәссамның 1982 елда күргәзмәләр залында зур уңыш белән үткән персональ күргәзмәсе һәм кулыбыздагы альбом — моның ачык мисалы.

Казан — Бакый Урманчеда рәссам булу хыялы уяткан, аны тормышка ашырырга ярдәм иткән һәм, ниһаять, рәссамны олы рәссам итеп күтәргән төп төбәк. Казан үзенең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән татар совет сынлы сәнгатенә нигез салган аксакалның бетмәс-төкәнмәс илһам чишмәсе. Скульптор Урманче иҗатының иң биек казанышлары Казан белән, Татарстан белән бәйле.

Кереш мәкалә безне Б. Урманченың биографиясе белән таныштырганда, рәссамны кызыклы һәм зур шәхес иткән үзенчәлекләрне дә ассызыклап үтә. Талант күпчелек очракта тормышның, сәнгатьнең төрле тармакларын колачлаучан була. Пушкинны, Лермонтовны, Маяковскийны, Муса Җәлилне генә искә төшерик. Аларның һәрберсендә рәссамлык сәләте дә булган. Утыз Иманинең дә, Кандалыйның да, бөек Тукайның да талантлары әдәбият белән генә чикләнмәгәндер. Бәлки, алар да да рәссамлык я музыкаль сәләт булгандыр да ислам дине астында, тумас борын, сытылып үлгәндер. Бу, билгеле, гөман кылу гына. Рудаки, Низами, Фирдәүси, Нәсими, Хафиз, Хәйям — мөселман халыкларның күпкырлы талант ияләре, ләкин алар да, күрәсең, рәсем сәнгате белән шөгыльләнмәгәннәр... Әмма рәссамлык талантлары булмагандыр дип һич кенә дә ышанасы килми.

Бакый Урманчены кызыклы шәхес иткән үзенчәлекләрнең берсе — чит телләр белү. Мин, мәсәлән, аның француз коммунистларының «Юманите» газетасын даими укып баруын беләм. Төрек телен ул, кем әйтмешли, «су урынына эчә». Төрек теле белгече күренекле татар шагыйре Шамил Анак белән очрашкан саен, алар сәгатьләр буе төрекчә «тел чарлыйлар». Назыйм Хикмәт иҗаты турында әңгәмә коралар, аның шигырьләрен яттан сөйли-сөйли, бәхәсләшеп алалар.

Урманче — шагыйрь. Рәсем сәнгатенең өч классик жанрына сыймаган уй-тойгыларын ул шигырьгә сала. Ә шигырьгә дә сыймаганын — җырлый. Миңа берничә тапкыр аның җырлаганын ишетергә генә түгел, карап торырга да туры килде. Ул эфирда яңгырамаган борынгы татар халык җырларын башкара. «Башкара» дип мин ялгыш әйттем, ул чын мәгънәсендә җырлый — онытылып, көйгә сүз мәгънәсен эретеп куша-куша...

Ул беркайчан да утырып җырламый — бүлмә уртасына басып, таягын читкәрәк, күзгә күренмәслегрәк итеп куеп, һәм фәкать тәрәзәгә, аның аша күк киңлегенә карап җырларга ярата...

Авторлар мәкаләдә рәссамның иҗатын анализлауны максат итеп куймаганнар, ләкин бу олы, күпкырлы иҗатка керер өчен, анда буталып йөрмәс өчен тиешле ачкычларны биргәннәр һәм юнәлешләрне төгәл билгеләгәннәр. 86 яшьлек рәссамның остаханәсендә, эш вакытында төшереп алынган фоторәсемнәре кереш мәкаләгә ихласлык өстиләр, ә Урманченың үз образын тагы да кызыклырак итәләр.

Бакый Урманче 3000 нән артык графика, 300 дән артык нәкыш (живопись), 120 дән артык скульптура әсәренең авторы. Алар — илебезнең төрле музейларында, сынлы сәнгать галереяларында. Татарстан китап нәшрияты әзерләп, бастырып чыгарган бу альбомга исә барлыгы 120 әсәр тупланган, һәм алар совет сынлы сәнгатенә

зур өлеш керткән татар рәссамының иҗатын күзалларга, аның үзенчәлеген ачыкларга мөмкинлек бирәләр. Ә хәзер альбомның битләрен ачыйк һәм Бакый Урманченың берничә әсәренә аерым тукталыйк.

Альбом В. И. Ленинның мәрмәр портреты белән ачыла. Бу сын сәнгать сөючеләргә бик таныш — илебезнең, республикабызның олы бәйрәмнәренә я күренекле вакыйгаларына багышланган күргәзмәләр Б. Урманченың шушы әсәре белән башланып китәләр. Рәссам юлбашчының катгый карарга килгән мизгелен сурәтләгән. Еракларга төбәлгән күзләр, уйның аргы очын ачыграк күрергә теләп, башның тәвәккәл хәрәкәтен бер мизгелгә туктатканнар. В. И. Ленин олы дикъкатькә, якты энергия чыганагына әверелгән. Рәссам зур осталык белән В. И. Ленинның кешелеклеген һәм аның кодрәтле көчен мәрмәрдә берләштерә алган. Урманченың бу хезмәте татар совет сынлы сәнгатендәге Лениниананың иң көчле һәм мәшһүр әсәрләренең берсе.

Рәссамның татар халкының күренекле улларына багышланган скульптур портретлар галереясе аерым сүзгә лаек: Хөсәен Ямашев, Кол Гали, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Габдулла Кариев, Шәехзадә Бабич, Шамил Усманов, Гыйлем Камай, Социалистик Хезмәт Герое төзүче Рәшит Саттаров, Дәрдмәнд, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри һәм башка бик күпләр. Шулар арасында Б. Урманченың гомере буе кайтып-кайтып эшли торган образлары да бар: алар — Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил. Альбомга Муса Җәлилнең Татар дәүләт опера һәм балет театры фойесына урнаштырылган мәрмәр портреты кергән. Башы палач балтасы астында булган хәлдә дә шигырь язарга көч тапкан патриотның рухи куәте хәтта салкын мәрмәргә дә кан кайнарлыгын иңдергән кебек. Бу әсәрдә рәссамның совет кешесенең батырлыгы, ныклыгы белән соклануы, горурлануы әллә каян күренеп тора.

Менә Урал мәрмәреннән ювелирларча нәзбереклелек белән уелган Тукай. Уйчанлык һәм тәвәккәллек, моң һәм сарказм, ачу һәм үпкәле киная, хакимлек һәм самимият, үлем һәм мәңгелек — боларның барысы да Урманче иҗат иткән Тукай портретында. Әлеге сыйфатлар аерым-аерым да күренәләр һәм, рәссам тылсымы белән бер-берсен баетып, тулыландырып, ахыр чиктә кушылып, бөек шагыйрьнең гаҗәеп трагик образын тудыралар. Альбомның ахырындарак безне яшьрәк Тукай каршы ала. Башында түбәтәй, күкрәген яка астыннан сузылып төшкән бант бизи. Ул Кырлайга кайткан да үзенең мемориалы каршында биешкән Урманче ясаган имән шүрәлеләргә карап тора. Тукай — романтик, Тукай көчле, Тукай хыялына ирек биргән...

Альбомның алдагы битләре шүрәлеләргә багышланган. Менә агач тамырыннан ясалган борынлач Шүрәле, менә иренләч Шүрәле... Тукай аларны урман сарыклары дип атаган. Ә ни өчендер, бу юаш, ерткычлыктан бик ерак торган урман сарыкларын без ничә еллар инде гел явыз итеп сурәтлибез. Минемчә, Урманченың скульптур шүрәләләре, тушь белән, акварель белән сурәтләнгән гаҗәеп мәзәк, беркатлы шүрәлеләре татар фольклорына якынрак. Фәйзрахман Әминев шүрәлеләре дә!

Б. Урманче аллегорик скульптуралар остасы да. Шигырьләргә кергән «Сагыш», «Язгы моңнар», «Сөембикә», «Нәфисә» — агачтан юнылган бу әсәрләр татар совет сынлы сәнгатенең казанышлары. Күргәзмәләрдә тамашачы нәкъ менә шул әсәрләр янында озаграк тора, шулар турында тәэсирләрен тәфсилләбрәк яза.

Бакый Урманче — иҗат юлын график һәм нәкышче булып башлаган рәссам. Сынлы сәнгатьнең бу жанрлары альбомда да тиешле урын алып торалар. Менә майлы буяу белән эшләнгән «Печән базары». Культура, сәүдә һәм кыргый гадәтләр үзәге булган бу мәшһүр урынны Урманче, үзе күргәнчә сурәтләп, документ иткән. «Кичү» дигән картина, «Бикбулатов портреты», «Татар кызы», «Сепаратор янында», «Сары күлмәкле кыз», үзләренең эстетик бәһаләрен югары тоткан хәлдә, утызынчы елларның нәкышле документлары буларак та кыйммәтлеләр, чөнки алар натурадан күчерелгәннәр.

Казахстанның халык артисткасы Шара Җәндәрбәкова портреты Урманченың альбомга кергән иң якты, шатлык сирпелеп торган хезмәтедер. Берничә кат бала итәкле алтын-сары күлмәген иран келәме өстенә кояш итеп җәеп салган ак йөзле мөлаем ханым кояштан калыккан бер елмаю булып утыра. Фонны тәшкил иткән аллы-гөлле тукыма артисткаsucc хисләрен, кәефен тамашачыга җиткерергә булыша.

Рәссамның «Бүләндәж», «Сазут» кебек натюрмортлары, кайнар буяулар белән

язылган диңгез пейзажлары, Үзбәкстан оазислары, тау күренешләре, печән өсте манзаралары альбомны күңелгә тагын да якынрак итәләр.

Бакый Урманченың графикасы гаҗәеп бай һәм катлаулы. Карандаш, күмер, акварель, сангина, тушь белән ясалган күп санлы портретларда, рәсемнәрдә, китап сурәтләрендә, пейзажларда без Б. Урманчены оста рәсемче (рисовальщик), нечкә психолог, үзенчәлекле юморист, зур сатирик буларак күрәбез. Тукай, Дәрдмәнд әсәрләренә иллюстрацияләр рәвешендә эшләнгән сурәтләре рәссамның шагыйрьләрнең иҗатын, аларның эстетик идеалларын, социаль карашларын тирәнтен аңлавы хакында сөйлиләр. Альбомның дүрт бите буйлата сузылган «Кисекбаш» рәсеме кинематографлылыгы белән кызыклы. Йөзгә якын персонажның ашкынулы хәрәкәтен сурәтләгән бу сатирик рәсем — революциягә кадәрле татар костюмының үзенә күрә кечкенә бер энциклопедиясе дә.

«Бакый Урманче» — Татарстан китап нәшриятының татар рәссамына багышлап чыгарган беренче монографик альбомы. Бу башлангыч һәртөрле хуплауга һәм дәвамга лаек, чөнки ул сынлы сәнгатьнең коммунистик тәрбиядәге мөмкинлеген бермә-бер арттыра һәм аны халыкка тагы да якынайта.

**РЕНАТ ХАРИС.**

# ШИГЪРИЯТТӘ ҮЗ ЙӨЗЕ БАР

Татар балалар әдәбияты елдан-ел яңара, баеп бара. Татарстан китап нәшриятында басылган күп санлы китапларда, «Ялкын» журналында, «Яшь ленинчы» газетасында урнаштырылган төрле жанрдагы әдәби әсәрләрдә бүгенге балалар әдәбиятының тематик офыклары киңәюен, сәнгатьчә нигезенең ныгый төшүен, сабыйлар дөньясының җанлырак, кызыклырак итеп, балаларга үтемле рәвештә тасвирлануын, заман сулышының да ныграк чагылуын күрергә мөмкин. Яңа исемнәр, яңа әсәрләр... Алар белән без даими очрашып торабыз. Яңа исемнәрнең язмышлары исә төрлечә. Күпчелеге, балалар өчен бер-ике китап чыгару белән, бу өлкәдә иҗат итүдән туктап кала: алар өчен балалар әдәбияты зурлар әдәбиятына күчәр алдыннан бер тәҗрибә мәктәбе ролен генә үти. Бик сирәкләре генә үзләренең иҗатларын һәм язмышларын балалар әдәбияты белән ныклап, гомерлек итеп бәйлиләр. Роберт Миңнуллинны мин менә шундый шагыйрьләрнең берсе — балалар дөньясын үз иткән, аларга үз күңеленең бөтен байлыгын, җылысын биргән, нәниләр өчен иҗат итүне бик тә җаваплы эш итеп хисаплап, шушы өлкәдә дәвамлы һәм нәтиҗәле эшләп килүче дип саныйм.

Соңгы елларда Роберт Миңнуллинның исеме балалар дөньясында популяр булып китте. Аны белмәгән, әсәрләрен ишетмәгән укучы сирәктер. Моңа бигрәк тә телевидениедә балалар өчен «Шигъри тәлгәшләр» дигән тапшыру алып баруы ярдәм итте булса кирәк. 1976 елдан башлап бүгенгәчә даими рәвештә ул нәни укучылары белән телевидение аша очрашып тора, алар белән җанлы әңгәмә алып бара.

Р. Миңнуллин балалар поэзиясе өлкәсендә җитмешенче елларның икенче яртысыннан башлап эшли. Шул вакыт эчендә ул кече яшьтәге балалар өчен күп шигырьләр язарга, өч җыентык чыгарырга өлгерде: «Акбай цирк карый» — 1978, «Җиде абый тай җигә» — 1980, «Айга очтык!»[1]. Ә бу китапларга хәтле аның зурлар өчен язылган шигырьләре, җырлары бар иде. «Әнкәй», «Килен төшә» кебек җырлары халык арасында киң яңгыраш алды — ул җырларны һәркайда яратып җырлыйлар. «Бәхетле булыгыз» (1976), «Сөенсеннәр әле каеннар» (1979) исемле җыентыклары тормыш турында җитди уйланучы, үзенчәлекле шигъри моңга, аһәңгә ия булган шагыйрь тууы турында сөйлиделәр. Шулай — зурлар поэзиясендә үзен танытканнан, шигъриятә билгеле бер тәҗрибә туплаганнан соң балалар поэзиясенә килүе шагыйрьнең шушы өлкәдә тиз үсүенә, сәләте тиз ачылуына һәм нәниләр өчен яңа сүз әйтүенә сәбәпче ныклы нигез булды. Дөрес, әүвәлгерәк шигырьләрендә аның балалар әдәбиятында үзенә остаз итеп ал-

[1] Миңнуллин Роберт. Айга очтык! Шигырьләр. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1982.

ган Б. Рәхмәт, Ә. Фәйзи, Ш. Галиев кебек шагыйрьләрнең тәэсире турыдан-турырак та чагылгалады. Әмма һәр шагыйрь өчен табигый булган өйрәнү чорын ул чагыштырмача тиз үтте, балалар шигърияте́ндә үз сукмагын тиз тапты, үз тавышы, аһәңен тиз иштерде. Хәзер инде аның үз йөзе, үз стиле бар һәм ул стиль аерымланганнан-аерымлана, үзенчәлекле төсмерләре ачыкланганнан-ачыклана бара. Бу стильнең төп хасиятләре итеп: җитдилек белән уенның — акыятнең — хыялның, зурлар дөньясына омтылу белән баланың үз дөньясында яшәү стихиясенең Р. Миңнуллинча үзгә рәвештә бер-бере белән тоташуын, кушылуын, «каршылыклар бердәмлеге» тәзүен санарга мөмкин. Бу «кушылулар», әлбәттә, төрле шигырьдә төрлечә: кайсысында җитдилек һәм чынлык алгы планга чыга, кайсысында шуклык-мәзәклек, наян көлү өскә күтәрелә, кайсында хыял уены җиңә... Шушындый «каршылыклар бердәмлеген» ачуга нигезләнгән сурәтле фикерләү рәвеше шагыйрьгә балалар поэзиясенең яңа шигърият чирәмнәрен күтәрергә, үтемсез коры вәгазьдән һәм образсыз информациядән котылырга ярдәм итә, балалар шигърияте поэтикасын төрләндерергә һәм баетырга киң мөмкинлекләр ача.

Хәзер инде татар балалар поэзиясен Р. Миңнуллин шигырьләреннән башка күз алдына китерүе кыен. Р. Миңнуллинның нәни геройлары да шагыйрь шигырьләрендәге сүзләр кебек — терелләр, хәрәкәтчәннәр... Шагыйрь балаларның дөньяга һәм кешеләргә сокланып һәм гаҗәпләнеп карау тойгысын матур итеп, ышандырырлык итеп сурәтли. Шигырьләрдәге балалар— Алмаз, Әнвәр, Фәһим, Гөлнар, Санияләр табигатьнең һәм хайваннар дөньясының һәр төрле күренешләренә — мөгезле болытларга да, җәяүле бураннарга да, диңгездәге дельфин һәм акулаларга да, цирктагы филләргә дә, йорттагы тавык һәм кәҗәләргә дә, Акбай, Актүш, Актырнак исемле этләргә дә күзләрен зур ачып, гаҗәпләнеп карыйлар. Алар әтиәниләренең, әби-бабайларының, апаабыйларының, дусларының, үзләренең тормышларын, кыланышларын игътибар белән күзәтәләр һәм гыйбрәт алырлык нәрсәләр эзлиләр, табалар...

Геройлар арасыннан Алмаз исемлесе үзенең активлыгы һәм үткенлеге белән аерылып тора. Ул — китаптагы күп шигырьләрнең уртак герое, ул Ш. Галиевнең Шәвәлие кебек бер шигырьдән икенчесенә күчә. Без аны балалар бакчасында да, беренче-икенче классларда укып йөрүен дә күрәбез. Ул да кызыксынучан һәм күзәтүчән, бераз гына хәйләкәр, бераз гына наян, һәртөрле шуклыклар да уйлап чыгара. Кыскасы, исеме белән генә түгел, үзенчәлекле кыланышлары белән дә истә кала. Ул үзүзенә дә, кайвакытта олыларга да тәнкыйть күзе белән карап куя. Дус-ишләре дә күп, әмма аны әти-әнисенә үзенең бер генә бала булуы нык борчый:

**Бергәләшеп уйнарга**
**Бер иптәш кирәк миңа,**
**Берәү генә булса да,**
**Ямьсез генә булса да,**
**Елак кына булса да**
**Энекәш кирәк миңа!**

Баланың әнә шундый борчуы аша шагыйрь олылар күңелен дә, зурлар дөньясын да гел борчып торган мәсьәлә күтәрә, бүгенге тормыштагы социаль проблемага игътибар итә. «Нәни поши» шигырендә дә олы тормышның драматик бер күренеше чагыла:

**Ул поши баласын әти**
**Карурманнан тапкан бит.**
**Әнисен... усал абыйлар —**
**Браконьерлар аткан бит.**

Р. Миңнуллин матурлыкка, әхлаклылыкка өйрәтүне зурлар тормышындагы уңай мисаллар аша алып бара. Бу, гомумән, балалар әдәбиятында кабул ителгән, ныклы традициясе булган юнәлеш. Әмма шушы язылмаган кагыйдә еш кына әдәбиятта әдәби канун рәвешен алып куя, шуның нәтиҗәсендә, бала күңелен тормыштагы ямьсез күренешләр белән рәнҗетмәскә теләү балалар әдәбиятын чикләүгә китерә. Р. Миңнуллин исә «Энекәш кирәк миңа!», «Нәни поши», «Дөнья балаларының кешелеккә әйтер сүзе» кебек шигырьләрендә яшәешнең гомуми мәсьәләләрен күтәреп, әлеге чикләнгәнлектән сикереп чыгу юлында уңышлы тәҗрибә ясады. Шагыйрьнең кешелекне борчыган ноктаparams алып чыккан шигырьләре хәзергә аз булса да, алар гаять тә тәэсирле, шигърияткә һәм актуаль яңгырыйлар.

**Ләкин әле җиребездән**
**Кан һәм яшь исе килә.**

**Юк, үләргә теләмибез —**
**Безнең яшисе килә!**
**Я-ши-се ки-лә!!!**

Дөнья балалары җирнең язмышы өчен әнә шундый борчу белән яшиләр. Татар шагыйре Р. Миңнуллин нәниләрдән ишеткән әлеге борчулы сүзне татарча әйтсә дә, ул борчылу кешелек өчен уртак.

Балалар язучысы булу өчен дөньяга балалар күзе белән карый белү, балаларча уйлый, хыяллана алу зарури. Бала ясалмалылыкны, сабый булып кыланырга тырышуны тиз сизеп ала — фальшьны ул яратмый, кабул итми. Р. Миңнуллин шигырьләренең балаларга бик тә якын булулары авторның дөньяны бала булып кабул итү хасиятен саклый алуы белән бәйле. Шагыйрь сабыйларның үзләренчә уйлап һәм уйнап яшәүләрен, шул уеннары белән чынбарлыкны үзләренчә танып-белүләрен табигый итеп сурәтли, шигърияте юлларда ача.

Бала өчен хыял белән чынбарлык арасы бик тә якын. Р. Миңнуллин да шигырьләрендә шушы чикне җиңел генә үтә ала, уеннан чынга, чыннан уенга тиз күчә ала. Бу хасиятләр «Айга очтык», «Йолдыз буласым килә», «Ми-8А» шигырьләрендә бигрәк тә ачык күзгә ташлана.

Р. Миңнуллин шигырьләрендә балалар уйнарга яраталар. Әмма шагыйрьнең осталыгы бала уенын тасвирлауда гына түгел, ә аның яшәешен, дөньяны кабул итүен уенга бәйләп ачуында, бала уенын дөньяны танып-белү чарасы буларак күрсәтүендә. Шагыйрь нәниләрнең шушы хасиятләрен — уен аша тормыш тәҗрибәсе туплауларын гаять нечкә тотып ала. Шушы нигездә шигырьдә сәер әверелешләр, гаҗәеп хәлләр туа, сурәтле фикерләү үзенчәлекле рәвеш ала. Бервдә гади генә әйберләр дә тылсымлыга әверелә, җансыз предметлар җанлана, җанлылары — җансыз кала. «ДТ-75» тракторының улына җырлаган бишек җырында трактор телгә килеп, улына болай дип көйли:

**Йокла, улым, матурым,**
**Ят, ял итсен моторың,**
**Бәләкәч тракторым!**
**Тыр-тыр-пытыр-тыр-тырым,**
**Пытыр-пытыр-тыр-тырым,**
**Йокла инде, күз нурым!**
**Тыр-р-р-р-р-р-р-р-р...**
**Тыр-р-р-р-р-р-р-р...**

Бу өзектә шагыйрьнең сүз һәм аваздашлар яңгырашына, телгә нык игътибар итүе дә ачык күренә. Аның теле төзек, аһәңле, һәртөрле чагыштыру-сурәтләргә бай.

Әйе, Роберт Миңнуллин иҗаты хәзерге балалар поэзиясен үстерүдә, баетуда актив катнашса, телевидениедәге «Шигъри тәлгәшләр» тапшыру аша балалар әдәбиятын, сәнгатен пропагандалау буенча зур эш алып бара. Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясе лауреаты булуы исә аның шушы өлкәдәге тырыш эшчәнлеген лаеклы бәяләү буларак кабул ителде. Бу факт шул ук вакытта республикабыз җәмәгатьчелегенең балалар әдәбиятына булган җитди игътибары һәм кайгыртучанлыгы турында да сөйли.

**НИЛ ЮЗИЕВ.**

# ТОРМЫШТАН ҺӘМ ТОРМЫШЧАН

Кайвакытта бер әсәр буенча шагыйрьнең бөтен тормышын, күңел байлыгын, иҗат юнәлешен абайларга мөмкин.

**Хәтеремдә сугыш шулайрак калган:**
**Әтине озата киткән абый кайтты**
**һәм кычкырды шашып:**
**— Әни, атыбыз,**
**Болан сазлыгында атыбыз батты!**

Бер карaганда, гади генә булып тоелган күренештә шагыйрь иҗатының җирлеге, аны олы идеаллар белән тоташтырып торучы тамырлар ачыла. Баткан атны ил белән коткарганда сабый күңеле сугыш ачысын сиземләгәндәй була, ул аны атның сагышлы күзләреннән күрә. Шагыйрь шушы халәтне табигый һәм катлаулы сурәт аркылы ача, шигъри гомумиләштерүләргә ирешә.

Әлеге шигырь — Шамил Маннаповның «Кайту» исемле яңа җыентыгыннан[1]. Бу шагыйрьнең иҗаты турындагы фикерләремне инде күптән укучы белән уртаклашырга уйлап йөри идем. Ниятем шагыйрьнең яңа шигъри җыентыкларын укыганда тула-тулыша килде һәм, ниһаять, аның бу китабын укып чыккач, кулга каләм алдым. Югыйсә, чыннан да, без чордашларыбыз хакында әйтер сүзләребезне әйтергә базмыйча, тартынып, тарсынып — шиктый гына уйланып йөрибез. Ә кайвакытларда, шулай уйланып йөри-йөри кичерелмәслек дәрәҗәдә соңга да калабыз.

Без кулга алган китапның җирлеге бүгенге көнгә тоташкан. Ул узганнарга, аерып әйткәндә, олы шагыйрьләребезне «язмыш гүя үзе саклап барган», утлы дугалардан исән-сау алып чыккан вакытларга сак кына кагылганда да, укучы күңелен кабат бүгенге көнгә кайтара.

Җыентыкта тормыш һәм шигърият бердәмлеге нык сизелә. Аны раслау өчен «Гомәр» дигән әсәрне искә алу да җитә. Ул тыныч тормышта батырларча һәлак булган яшь егеткә багышланган.

**Кемдер әйтә:**
**— Тракторын**
**Җәлләгәндер, җүләр.**
**Якын дуслары өзелә:**
**— Гомәр, Гомәр, Гомәр!**

Шигырьнең бер строфасын уку белән колагыбызда һаман шул ук, бер үк исем — «гомер» сүзенә аһәңдәш исем — безнең күп, бик күп каһарманнарыбызның үлмәс батырлыгын дәвам иткән гомер кебек, моңлы бер җыр булып яңгырап тора. Фикер һәм кичерешләр берлегенә нигезләнгән шигырь әле көй язылганга кадәр үк тормыштан килгән бер җыр булып агыла сыман.

Автор шигырь сөючеләргә үзен әллә кайдан түгел, ә бәлки шигырьләреннән эзләргә куша:

**«Сезнең заман нинди иде!» — диеп**
**Киләчәктә берәү әгәр дә**
**Сорый калса,**
**Замандашым сөйләр:**
**— Ул зур иде, башы — галәмдә...**

Һәрбер әдәби әсәр, димәк, язучы күңеле дә, килер көннәр белән тирән бәйләнештә була, бәйләнгән була. Әнә шуны аңлап иҗат ителгән әсәрләр вакыт чикләрен узып, укучы тормышына кабат кайталар. Гомумән, бер карасаң, иҗат — ул кешеләр йөрәгенә кабат-кабат кайту, узган көннәр, бүгенге чор һәм киләчәк турында уйлану, шулар хакында сөйләшү кебек бит.

**Мин кайтырга чыктым**
**Шигыремдә**
**һәм шигырьләр белән,—**

ди шагыйрь.

Аның һәр китабы якташлары һәм тулаем алганда, барлык әдәбият сөючеләр янына кайту сыман. Әйе, ул бит шул ук укучылары арасында туган, шунда үскән... Шагыйрь буларак та шунда һәм шулардан: алар җырлаган җырулардан, алар сөйләгән гыйбрәтле вакыйгалардан, алар әйткән хикмәтле сүзләрдән, гыйбарәләрдән илһам җыеп барлыкка килгән. Халыкчанлыкның үзе дә борынгы җырлардан яки әкиятләрдән, йолалардан, ырым-ышанулардан аерым-аерым гына килмидер ул. Аларның һәммәсе бу иҗатта тулы оркестр сыман бергә кушылган. Әнә шул аһәңнәр күп вакытта каләм иясе күңелендә, аңында шигырь юлларына әверелеп, аннары кәгазьгә күчеп, кат-кат эшкәртеләдер.

Соңгы елларда безнең тәнкыйтьтә «тыныч лирика» дигән төшенчә еш кулланыла башлады. Чыннан да, кайбер шагыйрьләребезнең язганнары артык сабыр кебек. Аларның лирик герое зур шатлык яки кайгы килгәндә дә тыныч-сабыр кала ала. Бәлки бу тышкы сабырлык кынадыр? Кеше эчтән яна-көядер? Шулай да, бу сабырлык тора-бара битарафлыкка әйләнмәсен иде, дип уйлап та куйгалыйсың. Һәм сиздерми генә килеп, шул артык «сабыр»ны чеметеп аласы иде, дисең. Яисә әкияттәгечә әфсен укып, тау елгасына әверелдерәсе... Аксын иде таштан ташка сикереп, ярсып-шашып!.. Ш. Маннапов шигырьләрендә дә сабырлык бар. Ләкин аның югарыда әйтелгәне түгел, ә ир-егетләрчә сабырлык, җил-яңгырга, бураннарга көрәшүчеләрчә түзә белгән сабырлык. Бу шигырьләрдән караңгылыкны җиңәргә омтылган эчке нур, җылылык бөркелеп тора. Бу сабырлыкның зур эчке җегәре бар.

Ш. Маннапов шигырьләренә язылган «Солдатта булган диләр...», «Керфегеңә тамармын мин...», «И Казаным, кердең йөрәгемә» шикелле җырлар бар. Яңа китаптагы «Кичермәсләр» җыры да үзенчәлекле булуы белән, хисе белән җәлеп итә.

[1] Маннапов Шамил. Кайту. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1981 ел.

Монда чәчәк-гөлләр дә, айлы кичләр дә, сөю-хисләр дә җанлы сурәт булып гәүдәләнәләр. Күңелдә алар белән серләшәсе, шатлык-кайгыларны уртаклашасы килү тойгысы уяна.

Иҗат иткәндә шагыйрь үз күңеленең байлыгына, аның рухи халәтләре башкаларга да кызыклы һәм файдалы булуына ышанырга тиештер. Мөгаен, шул чакта гына ул шәхси кичерешләрен, уйлануларын кешеләргә тулысынча ышанып, бөтен килеш тапшыра аладыр. Әнә шул хакыйкатькә ышанып җитмәгәндә, шагыйрь иҗатына «чит дулкыннардан» тотып алынган юллар керә башлый. Шамил Маннапов иҗатын күзәтеп барган укучылар белә: шагыйрь үзенең үсеш юлында андый кимчелекләрдән арына бара. Шул ук вакытта ул җиргә якыная, үзенең асылына кайта бара. «Кайту» китабыннан күренгәнчә, ул чын ир-егетләрчә үзенә, күңел байлыгына, замандашларына ышана. Шагыйрь шигъри осталыгын һаман арттыра баруы белән үз иҗатына карата да ышаныч, яңадан-яңа өметләр уята. Бу китабы аның шигъриятә туктаусыз эзләнүен, табу һәм кайбер югалтуларын, үз иҗатында янә бер баскычка күтәрелүен ачык күрсәтә.

**ФӘННУР САФИН.**

# ИЗГЕ НИЯТ

Алдымда яңа китап ята. «Энҗеләр балкышы». Авторы — яшь язучы Нурислам Хәсәнов [1].

Н. Хәсәнов совет кешесенең фидакарь хезмәтен һәм советча яшәү рәвешен күрсәтүне, әнә шул якты мисаллар аша яшьләрне тәрбияләүгә өлеш кертүне үз алдына изге бурыч итеп алган. Зур бер заводта металл коючы булып эшләүче Мөстәкыйм Җаббаров образы җыентыкны бизәп тора дип әйтергә мөмкин. Чын эшче кеше үз хезмәтенең нәтиҗәсе белән горурлана, осталыкта ирешелгән дәрәҗәсеннән чигенүне мөмкин булмаган эш дип карый. Мөстәкыйм дә үз эшен биш бармагы кебек белә һәм бик нык ярата. Ул тормышта нинди дә булса карьера эзләми. Осталыгын камилләштерү, эшенең бик нечкә серләренә төшенү аның өчен хезмәт баскычыннан күтәрелүгә бәрабәр. Завод капкасыннан чыгу белән генә ул үзенең эшче икәнен онытмый, эш процессы аның уйларында дәвам итә. Металл эретү технологиясенең хикмәтле закончалыклары аның баш миенә язылган, шул белемгә ул үз практикасында булган төрле очракларны китереп ялгый. Уйланып йөри-йөри, бер көнне, йокларга яткан җирдән, ул көндез эштә булган җитешсезлекнең сәбәбен ача.

Иҗат белән яшәүчеләр гадәттә кайберәүләр өчен сәеррәк тоела. Мөстәкыймне дә хатыны «лунатик» дип атый. Нихәл итәсең, игенче өчен яңа гына борын төрткән зәгыйфь шытым яки каерылып уңган бодай кырлары якын булган кебек, Мөстәкыйм өчен дә эрегән металларның энҗедәй балкышын күрү гаять сөенечле. Шул рәвешле, автор бүгенге эшчеләрнең рухи дөньясына үтеп керүгә омтылыш ясый.

«Биеклек» хикәясендә исә коллектив һәм җитәкче мәсьәләсе күтәрелә. Элекке мастер Александр Артомонов белән бу эшкә яңа гына билгеләнгән Шәрипнең эш стиле әсәрдә контраст итеп куела. Язучы Александрны акыллы, эшлекле, эшчеләр белән аралашканда итагатьле итеп бирсә, Шәрипне исә дорфалыкта гаепли. Ә эшче Мансур бу ике җитәкчегә бәя бирүче сыйфатында гәүдәләнә. Биредә Н. Хәсәнов, үзе дә сизмәстән, кешеләр мөнәсәбәтендә четерекле психологик моментка кагыла. Еш кына шулай була бит: көннәрдән бер көнне эшчеләр арасыннан берсен җитәкче итеп күтәрәләр. Бу кеше хәзер вазифасы буенча элеккеге хезмәттәшләренә баш булырга тиешле. Әмма кайберәүләр шушы психологик киртәне атлап чыга алмыйлар, яңа җитәкчене санга сукмау юлына басалар. Әлеге хикәядә дә мастер белән эшче арасындагы конфликт шул нигездә килеп чыга. Мансур яңа мастер Шәрипнең үтенечен кырыс итеп кире кага һәм үзе дә аңардан төртмәле җавап алырга мәҗбүр була. Биредә авторның да яңа мастерга өстәнрәк каравы сизелми калмый. Эшчене хөрмәт белән әтисе исемендә кушып атасалар, мастерны исә тулы исеме белән дә әйтүче юк. Әсәрдә аңа сөйкемсез сәяк итеп карау әллә каян күренеп тора. Ә шул ук Мансур үз күз алдында яшь эшче Шамилнең техника хәвефсезлеге кагыйдәлә-

[1] Хәсәнов Нурислам. Энҗеләр балкышы. Хикәяләр. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1982.

рен бозуга юл куя. Кыскасы, автор бу хикәядә нәрсәне яклавын, нәрсәне тәнкыйть итүен үзе дә төгәл ачыклап бетерә алмаган. Нәтиҗәдә, характер бөтенлегенә зыян килә. Һәм очы очка ялганмау хасыйл була. Әйе, эшчеләр турында әсәр язу өчен производствоны яхшы белү генә җитми. Аның өчен эшче кешенең күңел дөньясын тирән ачу да, эш-хәрәкәтләрне бәяләүдә төгәл ачыкланган кредоң булу да, әйтергә теләгән сүзеңнең анык булуы да мәһим. Производство темасына язучы авторлар завод-фабрикларда һәм төзелешләрдә эшләүчеләр хезмәтенең шигъриятен ачып бирү, хезмәт процессын сәнгать дәрәҗәсенә күтәреп сурәтләү осталыгына ия булырга тиешләр. Шуннан башка схематик образлар һәм коры вакыйгалар гына барлыкка килә, әсәрнең теле авырлаша.

Эчтәлекне үзенә генә хас формада бирүгә дә игътибар йомшармаска тиеш. Яшь язучының «Кыңгыраулы сәгать» хикәясен генә алыйк. Аның нигезендә юмористик ситуация ята. Бишенче разрядлы фрезерчы Гата әрлән кебек заводтан нәрсә генә ташымаган! Фотокарточка рамнарына кадәр шуннан ясап алып кайткан ул. Бер көнне цех начальнигы өстәленнән будильник чәлдерә бу! Моңа кадәр ташыган әйберләре проходнойдан үткәндә кесәдә тын гына ята торган иде, ә бу юлы (кирәк бит!) нәкъ вахтер кыз янынннан үткәндә генә будильник шалтырый башламасынмы? Карак Гата, шул рәвешле, тотыла һәм тиешле җәзасын ала. Күрәбез, вакыйга Гата өчен драматик, ә укучы өчен көлкеле. Әмма автор шушы көлкегә ачкыч ярата белмәгән, аны авыр, салмак итеп сурәтләп бирү юлыннан киткән. Ләкин Н. Хәсәнов Гатаның ачкүзлелеген, туймас табигатен үтемле буяулар белән шактый ачып бирә алган. Бусы инде автор файдасына сөйли.

Шулай да шәхси-интим тормыш гәүдәләнгән хикәяләрдә яшь язучының каләме ышанычлырак эш итә. Биредә сүзләр дә урынлы кулланыла, персонажлар да табигыйрәк хәрәкәт итә. Бу — авторның геройлар «кабыгына» керә белүе, теге яки бу ситуациядә кешенең үзен ничек тотуын, ничек сөйләшүен ялгышмыйча тоя белүе нәтиҗәсе. Менә «Кичеккән күке моңы» хикәясендәге Илгизәр. Ул гомер буе әтисенә үпкәләп яшәгән. Сәбәбе: өч бала белән тол калган әтисенең икенче бер хатынга өйләнүе. Илгизәр «миңа бүтән әни кирәкми» дип авылдан ук чыгып китә. Бик күп еллардан соң, Казанга кайткач, ул әтисен күреп чыгарга тели. Әле бу юлы да туп-туры әтисе йортына юнәлми, башта кунакханәгә урнаша. Шуннан соң гына әтисен эзләп китә. Ләкин ата инде үлгән. Илгизәр күңелендә соңарып булса да әтисенә, үги әнисенә карата миһербанлык уяна... Әйе, бик кирәкле теманы кузгаткан, күпләрне уйланырга мәҗбүр итә торган тормыш материалы бу. Язучы аны кеше күңелен дулкынландырырлык итеп сурәтләп тә бирә алган.

Бу яктан «Фаҗигадан соң» хикәясе дә авторның уңышы дип санала ала. Яшь эшчеләр Камил, Чыңгыз, Дилбәр образлары үзләренең чын, табигый халәтләре белән бирелгәннәр. Камилнең фаҗигасен үз максатында файдаланырга теләүче Мирзаның чирканыч образы да күңелгә тәэсир итә. «Танышу» хикәясе исә геройның күңел монологы буларак үзенчәлекле. Оригиналь вакыйгасы һәм сурәтләү формасы белән ул игътибарны тарта. Хикәя бүгенге яшьләрнең матур күңел дөньясын ачып бирүе белән дә якты тәэсир калдыра.

Язучының нәсерләре дә күңелдә сафлык, оптимизм уяталар. Туган якның табигатенә, сайрар кошларына, гаять игелекле кешеләренә гашыйк ул. Бу илаһилык укучы күңеленә дә күчә. Игенченең, эшченең дөньяны матурлавы, илгә бәрәкәт бирүе шагыйранә итеп әйтеп бирелгән. «Сайра син, сайра, илһам кошем. Син килеп сайраган тәрәзәләр аша мин бу тыныч дөньяны, заводымны тагын да яктырак күрәм. Яшисе килә. Көрәшеп, җиңеп яшисем килә»,— ди автор. Күрәбез, илһамланып яшәү завод тормышында да шигърият күрергә ярдәм итә. Яшәү мәгънәлерәк булып әверелә.

Китапка кергән хикәяләрнең берсендә болай ди: «... тезелә барган уйларымны, сабыр эшче намусы, эшче фидакарьлеге турындагы фикерләремне үземчә әйтеп бирәсе килә минем».

Әйдәгез, язгыз, яшь язучы иптәш! Ниятегез изге!

**ФОАТ ГАЛИМУЛЛИН.**

# ИСКЕРГӘН АКЧАЛАР ТАРИХЫ

Әйе, яшь язучы Камил Кәримов иҗат иткән һәм «Казан утлары» журналының быелгы 3 нче санында басылып чыккан «Алдавыч көз» повесте искергән акчаларга бәйле бер гыйбрәтле хәл турында. Ләкин биредә, бу әсәрдә, искергән акчалар үзләренең туры мәгънәсендә генә түгел, ә сәнгать ягыннан тагын да мөһимрәк булган икенче мәгънәсендә дә аңлашыла. Шуңа күрә, әлеге кечкенә повестьның мәгънә төсмерләрен һәм яшь прозаикның иҗади уңышының серен ныграк аңлау өчен, башта әсәрдәге төп вакыйганы кыскача искә төшереп алыйк.

Илленче еллар. Бер авылда сатучы булып эшләүче Әгъдия исемле хатын кеше алдап җыйган бөтен акчасын пыяла банкага тутырып, алмагач төбенә күмә. Әмма бераздан үзе каты авырып китә һәм дөнья куя. Аның күмгән акчалары беркемгә беленмичә җир астында кала.

Озак еллардан соң гына, кышкы салкыннан өшеп корыган алмагачлар урынына яңаларын утыртырга дип чокыр казыганда, пыяла банкадагы теге акчалар килеп чыга. Ләкин, кәгазе бозылмаган булса да, хәзер инде алар — иске акчалар!

Менә шушы мәгънә яшь язучы повестеның бөтен эчтәлеген берләштерә кебек.

Әйе, Әгъдиянең җыйган акчалары искергән — хәзер аларның беркемгә дә кирәге юк! Бу — аның тормышта йөз тоткан юнәлеше искергән дигән сүз. Бу — Әгъдия кебек яшәү, көн күрү искергән дигән сүз. Һәм, тагын да гомумиләштеребрәк карaганда, акчага табынып яшәү үзе — безнең матур җәмгыятебез өчен искергән күренеш дигән сүз!

Искергән акчалар бу повестьта әнә шундый тирән мәгънәгә ия.

Яшь язучы повестена шундый эчтәлек сала һәм аны укучы күңеленә тәэсирле итеп җиткерә. Юк, алынган гыйбрәтле вакыйгасын тәфсилле рәвештә сөйләп кенә чыкмый автор. Ул повестьның бөтен агышын да мавыктыргыч, кызыклы итеп төзи, үзенең шактый осталыкка һәм тәҗрибәгә ия икәнен күрсәтә.

Менә «Алдавыч көз» әсәренең ничек башланып китүен генә карыйк. Автор башта укучының игътибарын җәлеп итәрлек күренеш биреп ала: Нәгыймә карчыкның алма бакчасыннан иске акчалар табылуын сурәтли, малайлар акча белән уйный башлыйлар.

Малайлар берни белмичә уйный бирәләр, ә укучыда зур кызыксыну уяна — «Нинди акчалар болар? Нишләп җир астына күмелгәннәр алар?»

Шуннан соң инде — укучы күңелендә түземсезлек тудырганнан соң — автор тыныч кына тонда үткән еллар тормышын сөйли башлый. Әкрен-әкрен сатучы Әгъдия язмышы күз алдына килеп баса.

Әмма шунысына игътибар итәргә кирәк: Әгъдия язмышын безнең күз алдында яңадан яшәткәндә автор бер генә җирдә дә үз мөнәсәбәтен турыдан-туры белдерми, аның акча туплавын ачыктан-ачык гаепләп чыкмый. Яшь язучы сурәтләгән вакыйгалар барышында күңелдә үзеннән-үзе диярлек антипатия, эчке нәфрәт туа.

Ә инде ахырда, кешене алдый-алдый акча җыйган Әгъдиянең үзенең авырып китүе һәм дөнья куюы, ә акчаларның җир астында калуы, беркемгә кирәкмәгән буш кәгазьгә әверелүе — бөтен сүзләрдән мәгънәлерәк булып чыга. Алдагы вакыйгалардан соң, алар яктылыгында бу күренеш зур әхлакый яңгыраш ала. Ул Әгъдия язмышының тулы һәлакәтен күз алдына бастыра.

Камил Кәримовның хикәяләү рәвеше дә үзенчәлекле. Ул юмор беләнрәк яза, халык тәгъбирләрен һәм тел бизәкләрен матур куллана. Анда күренекле сүз остасы Фатих Хөсни стилен хәтерләткән, әйбәт мәгънәдәге аваздашлык та чалымланып китә. Мондый алым авторга хикәяләүне табигый һәм кызыклы итәргә булыша.

Ләкин, шул ук вакытта теләк төсендә әйтик: бу әйбәт сыйфатның икенче төрлерәк чагылышыннан сакланырга да кирәк яшь авторга. Анысы — кәлкелә кебек тоелган сүзләр һәм күренешләр белән вакыт-вакыт артыграк мавыгып китү. Әнә шундый артык мавыгу булган җирдә еш кына мәгънәви һәм психологик тирәнлек кими.

Журналда басылган яңа повесте яшь прозаикның үсә баруын күрсәтә, үз иҗатына булган өметләрне тулырак аклый баруын раслый.

**МАНСУР ВӘЛИЕВ.**

Резеда Ганиева

# КАРШЫЛЫКЛЫ ЕЛЛАР АВАЗЫ

Беренче рус революциясе белән рухланып әдәбиятка килгән шагыйрьләр арасында Нәҗип Думави исеме күренекле урын биләп тора. Габдрахман Сәгъди сүзләре белән әйтсәк, ул «Тукай, Дәрдмәнд, Сагыйть Рәмиевләрдән кала, бу дәвернең көчле шагыйрьләренең берсе»[1] була. Әдәбиятның төрле жанрларында эшләп, Думави бай иҗат мирасы калдыра. Ул шулай ук иҗтимагый-политик темаларга, укыту-тәрбия мәсьәләләренә караган күп санлы мәкаләләр яза, тәрҗемә итү белән дә шөгыльләнә.

Нәҗип Думави (Нәҗип Сибгатулла улы Тахтамышев) 1883 елның 19 маенда Чистай өязе (хәзерге Аксубай районы) Яңа Дума авылында дөньяга килә. Дүрт ел дәвамында әтисе мәктәбендә башлангыч белем алгач, аннары бер кышны Кизләү мәдрәсәсендә уздыргач, Нәҗип Казанга килә һәм Печән базарында яңа ачылган Габдулла Апанаевлар мәдрәсәсендә 19 яшенә кадәр укый. Җиткән егет хәлендә ул татар балалары өчен ачылган рус мәктәбенә йөри, бик кыска гына вакыт эчендә русча укырга-язарга өйрәнә.

Казанда яшәгән елларда Думави күп укый. Аеруча философия буенча язылган хезмәтләр белән кызыксына. Ул үзенең фикри үсешенә мәгърифәтче Шәмсетдин Көлтәси әсәрләренең тәэсире зур булганлыгын ассызыклый[2]. Белемгә сусаган шәкерт көнчыгыш телләрендәге газеталарны алып укый, Галиәсгар Камалның яңа ачылган китап магазинындагы китаплар белән танышып бара. Укыту, тәрбия һәм методика буенча язылган хезмәтләр аның күңеленә бик тә хуш килә.

1902 елда мәдрәсәне тәмамлагач та, Думави Учительская школага кереп уку турында хыяллана. Ләкин матди хәле авыр булу сәбәпле, бу уен тормышка ашыра алмый. Бераз акча эшләп кайту максаты белән ул Астрахань һәм Гурьевкадагы балык промыселларына китә, аннан казах далаларына юнәлә һәм ике ел буе шунда балалар укытып кала.

Әйтергә кирәк, Думави гомеренең байтак өлешен (30 елга якын) педагогик хезмәткә багышлый: туган авылында, Буби мәдрәсәсендә, Уралдагы күмер шахталарында (Кизелдә), Рязань губернасындагы Вәрәки авылында, Чистайда, Үзбәкстанда укытучы булып эшли.

Демократия һәм прогресс тарафдары буларак, Думави патша самодержавиесе тарафыннан эзәрлекләнә, Буби мәдрәсәсе вакыйгалары уңае белән 9 ай ярым төрмәдә утырып чыга. Рус-япон сугышы һәм беренче империалистик сугыш кебек афәтләрнең җәфаларын да үз җилкәсендә татый. Шактый катлаулы һәм каршылыклы иҗат юлы үтеп, социалистик революциягә хезмәт итү бәхетенә ирешә.

Нәҗип Думави поэзиягә Беренче рус революциясе алдыннан килә. Казах далаларында укытучы булып эшләгән елларда ул иҗат эше белән танышу, күренекле

[1] Габдрахман Сәгъди. Татар әдәбияты тарихы. Казан, Татарстан дәүләт нәшрияты, 1926, 238 бит.
[2] Тәрҗемәи хәл урынында. Кулъязма (СССР Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият-тарих институты фәнни архивында саклана). 8 бит.

акыннар белән аралашу Думавида иҗат дәрте уята. Аның беренче адымнарыннан ук мәгърифәтче шагыйрь Акмулла йогынтысын тоярга мөмкин.

Думавиның башлангыч чор иҗатындагы әдәби тәэсирләрнең икенче зур чыганагы — рус әдәбияты. Шагыйрь рус телен һәм әдәбиятын яхшы белгән. «Тәрҗемәи хәл»ендә ул «рус классикларын укып чыктым» дип, искәртеп үтә (10 бит). Аны рус мәгърифәтчелек реализмының танылган вәкиле И. А. Крылов аеруча җәлеп итә. Думави еш кына Крылов мәсәлләренең сурәтләр дөньясына, художество принципларына мөраҗәгать итә.

Беренче рус революциясен Думави шатланып каршы ала. «Хөррият кояшы туды,— дип яза ул «Безләр нишлибез?» исемле мәкаләсендә.— Русия эче әүвәлге хәлен бөтенләй үзгәртеп, боз диңгезе кебек туңып, бөрешеп яткан халык менә кузгала, менә тавышлана башлады»[1]. Илдә барган революцион үзгәрешләр белән рухланган Думави җаны-тәне белән иҗат эшенә бирелә. 1906 елда ул аеруча күп яза. «Азат», «Әл-гасрел-җәдид», «Казан мөхбире», «Фикер», «Йолдыз», «Өлфәт» һ. б. газеталарда ул бер-бер артлы үзенең күп санлы шигырь һәм публицистик мәкаләләрен бастыра.

Шагыйрьнең башлангыч чор иҗаты мәгърифәтчелек идеяләре белән өртелгән. Думави революциянең халыкка гаделлек, ирек һәм бәхет алып киләчәгенә нык ышаныч белдерә, мең ел дәвамында татарларны тәдәнни (регресс) арбасына җиккән иске дөньяны, феодаль торгынлыкны кире кага. («Эш вакытына карап», «Китәчәк иске дөньяга яңа дөньяның сүзләре»).

Думавиның идеалы — «калыккан Чулпан» — революция ярдәмендә татар тормышын яңарту, Европа цивилизациясе дәрәҗәсенә күтәрү. Башка татар язучылары кебек, ул да «чиләк-чиләк кан түгеп яуланган» революция милли һәм социаль азатлык, прогресс идеяләренең чәчәк атуына китерер, изелгән милләтләр үз хакларын алыр, илнең иҗтимагый-политик һавасында «салкын җил исүдән туктар» дигән өмет белән яши («Буш вакыт», «Картлар агызыннан яшьләргә хитаб»).

Күрәбез, Думавиның башлангыч чор иҗатында (1905—1906) мәгърифәтчелек реализмы принциплары өстенлек итә. Шул сәбәпле шагыйрь иҗатында озак гасырлар дәвамында татарларда хөкем сөргән феодаль торгынлыкны, милли-колониаль изүне тәнкыйтьләүгә зур урын бирелә. Үз чоры җәмгыятен ул Крылов мәсәлендәге кысла, аккош, балык кебек төрлесе төрле якка тарткан, ләкин һич тә кузгала алмаган тәдәнни арбасы белән чагыштыра («Рак, аккош, балык», «Бер күренеш», «Вәхшәт-мәдәнияте», «Көтүчеләр», «Татар»). Әмма шул ук вакытта Думави әсәрләрендә мәгърифәтчелек эстетикасына хас үгет-нәсихәт, дидактизм да байтак әле.

Думави иҗатындагы мәгърифәтчелек инде XIX йөз татар мәгърифәтче язучыларын кабатлау түгел. Аның шигырьләрендә Беренче рус революциясе тәэсире, яңа заманның революцион рухы ярылып ята, халык тормышы белән бәйләнеш үзәккә куела. Революцион-демократик тенденцияләр белән үрелгән мәгърифәтчелек карашларын «Безләр нишлибез?» (1906) исемле публицистик мәкаләдә дә сизеләргә мөмкин. Ул анда иске тәртипләрне юк итү, гаделлек урнаштыру өчен «сугыш», «тартыш» кирәклеге турында сөйли. «Байлар җире» (1906) исемле шигырьдә дә Думави:

**Җир кирәк безнең өчен сулу саен,**
**Түгел бернчә елга яки аен;**
**Эчмәсен бояр гына аның маен,**
**Тырышып, кулга алыйк җирне, дуслар!**[2]

— дип өнди. Ләкин әлеге көрәш идеясе гакыл белән уйлап эш итүгә («уйлаек, гакыл бар бит башыбызда»), ягъни мәгърифәтчелек концепциясенә корылган.

Мәгърифәтчелек әдәбияты традицияләре Думавиның реакция һәм уныкчы елларда язылган әсәрләрендә дә юкка чыкмый. Реализм һәм романтизм эстетикасының каршылыклы мөнәсәбәтен гәүдәләндергән әсәрләрдә мәгърифәтчелек идеоло-

[1] Әл-гасрел-җәдид. 1906. № 12. 596 бит.
[2] Думави Н. Шигырьләр һәм поэмалар. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1960. 12 бит. (Мисаллар шул басма буенча китерелә)

гиясе әле шактый көчле һәм ул күбрәк җәмгыятьтәге әхлакый бозыклыкларны тәнкыйтьләүгә хезмәт итә (мәсәлән, «Кем гаепле» повесте, 1912).

Шул ук вакытта Думави капитализм шартларында мәгърифәтчелек чаралары ярдәмендә җәмгыятьне һәм кеше табигатен яхшы якка үзгәртү мөмкин түгеллегенә дә ышана башлый. Мәсәлән, «Яңадан тугдырыңыз!» һәм «Карт мөгаллимнәр» (1914) хикәяләрендә язучы татар әдәбиятында шактый таралган мәгърифәтле кызлар, аналар һәм мөгаллимнәр концепциясе белән бәхәскә керә. Әле күптән түгел генә укымышлы «бер мөгаллим нич᠎ә мең кешегә каршы тора ала», татар тормышының якты киләчәге безнең кулда дип уйлаган милләт каһарманнары үзләрен «һавасыз бушлыкта очучы канатсыз кошлар» икәнлекләрен аңлыйлар һәм мөгаллимлекләрен ташлап, кайсы — шәлче, кайсы — лимон-апельсин сатучы, кайсы иске-москы җыйнап көн күрүче-чүпрәкче булып китәләр.

Беренче рус революциясе елларындагы кебек, мәгърифәтчелек романтикасы белән мавыгуның яңа тарихи ситуациядә чикләнгән булуын Думави «Ашыкмаска кирәк» (1914) исемле публицистик мәкаләсендә дә искәртеп үтә.

Мәгърифәтчелек идеалларыннан күңеле кайту Думавиның прогресс турындагы өметләрен кисә, капитал дөньясының «салкын акылына», фәненә, әдәбиятына, фәлсәфәсенә һәм башка якларына тәнкыйди карашын тирәнәйтә. Үз нәүбәтендә бу хәл аның иҗатында критик реализм принципларының тамыр җәюе, ныгуы өчен уңайлы җирлек була.

1906 елда ук язган «Эч поша, күңел болгана», «Җәй үтеп кышның башы җиткән иде», «Үтте, үтә» кебек шигырьләрендә XX йөз башы татар тормышы өчен бик тә әһәмиятле булган социаль мәсьәләләр яктыртыла. Алар шигъри ассоциация чылбырының тыгыз бирелүе, сурәтләр һәм дөньяга карашның үтә субъектив асылы белән бик үзенчәлекле.

Менә, мәсәлән, «Революция заманы» (1906) исемле шигырь. Шагыйрь давыллы океан, ачы җилләр, һәлакәт алдында торган кораб сурәтләре ярдәмендә иҗтимагый тетрәүләр кичергән Россия чынбарлыгын гәүдәләндерә.

Бәхетсез язмышка юлыккан шәхеснең рухи фаҗигасен гәүдәләндерүче традицион кораб образы Көнбатыш һәм Көнчыгыш әдәбиятларында бик борынгыдан кулланылып килә. XX йөз башы татар әдипләре иҗатында да бу образ еш күзгә чалына. Кораб-көймә сурәтенә мөрәҗәгать итеп, уңышлы әсәр тудыручыларның күренеклесе — Дәрдмәнд. Аның «Кораб»ы (1908) — революцион тетрәүләр чорындагы ил, халык, милләт һәм тарихи барыш, иҗтимагый үзгәрешләр турындагы фәлсәфи уйларны белдерүче күп мәгънәле романтик символ. Думави корабы исә — реалистик эчтәлекле образ, һәм ул бер анык мәгънәгә ия. Аның океанда чайкалучы мәмләкәт корабы — революция тәэсирендә тарих сәхнәсеннән китү мәҗбүрияте алдына куелган самодержавие символы. Шул ук вакытта бу реалистик символ экспрессионистик образлылык белән дә үрелгән. Мәсәлән, корабның хәвефле һәм киеренке хәрәкәте, ул кеткән фаҗига күп санлы экспрессионистик детальләр, ассоциацияләр ярдәмендә ассызыклана. Нәтиҗәдә, шагыйрьнең кораб образы — иске дәүләт машинасы символы тагы да реальләшә төшә: аның яга торган мазуты беткән, компасы бозылган, ямаулы җилкәннәре тетелгән, шнурларын көя ашаган, арканнары өзелгән, пар казаны да кителгән. Корабка утырган пассажирлар төрлесе төрле якка йөз тотканнар, командир һәм боцманнар, кесәләре алтын белән тулган байлар абына-сөртенә рульгә таба йөгерәләр, тиргә батып, корабны афәттән коткарырга маташалар, әмма аларның тырышулары юкка гына. Чөнки революция дулкыннары корбаны «төбеннән ук куптармыйча, аны батырмыйча» туктамаячак.

Думави шигырьләренең эстетик идеал структурасында социаль момент гаять зур урын алып тора. Ләкин, экспрессионистик язучыларга хас булганча, ул әле бу социаль каршылыкларның асыл мәгънәсен, алардан котылу ысулын таба алмый, бу турыда язсаң да, сөйләсәң дә файда юк дип саный:

Язарсың да, сөйләрсең дә,—
һәнүз бер мәнфәгать чыкмас,

**Булып торгач бу дөньяның**
**Капитал — мөхтәрәм ханы!..**

Еш кына экспрессионистлар, романтиклар кебек, капитал хакимлеген ахыр заман, котылгысыз афәт белән чагыштыралар. Сыйнфый гаделсезлекләрне кешеләр ихтыярына бәйсез шайтан коткысы, кыямәт алдыннан дөньяны бутаган алдакчы Дәҗҗал эше дип бәяләү Думавида да бар.

«Эч поша, күңел болгана» шигырендә шәхесне физик һәм рухи изгән буржуаз җәмгыять сыкраулы, сызланулы пафос белән кире кагыла, гадәттән тыш киеренке кичерешләр фонында бирелә. Моннан соң язылган әсәрләрдә экспрессионистик сурәтлелек тагы да арта төшә, үзенең башка төсмерләре, башка хасиятләре белән калкып чыга. Капитал дөньясын экспрессионистларча тәнкыйтьләү — Думави критик реализмындагы гуманистик яңгырашка ия булган үзәк мотивларның берсе. Һәр чак диярлек бу мотив куе, караңгы төстәге күп санлы гиперболик сурәтләр ярдәмендә ассызыклана, күңелсез һәм куркыныч кичерешләр белән сугарыла, укучы күз алдына кино тасмасындагы кебек тиз алмашынып торган, эре план белән бирелгән социаль изү картиналары килеп баса.

Думави критик реализмының мондый экспрессиониситк яңгырашка ия булуы социаль җирлек белән дә бәйләнгән. Мәгълүм булганча, XX гасыр башында капитализм үзенең югары үсеш баскычына, тагын да ерткычрак һәм рәхимсезрәк этабына — империализмга аяк баса. Капитализм дәверендә хезмәт ияләрен изү, газаплау, җәзалау иге-чиге булмаган фаҗигале яшәешне хәтерләтсә, кискен сикерешләр, катастрофалар, конфликтларга мул империализм чорында исә, бу социаль изү котылгысыз фаҗига белән очланучы көрәнеш төсен ала.

Буржуаз җәмгыятьнең халык бәхетенә дошманлыгын, хезмәт белән капитал арасындагы үтеп чыга алмаслык каршылыкларны гәүдәләндергән «Җир күмере казучылар» (1907) исемле шигыре — шагыйрь иҗатындагы социаль лириканың матур үрнәкләреннән берсе. Думави поэзиясенең халык тормышы белән «нык тоташканлыгына», образ-сурәтләр дөньясының байлыгына басым ясап, шагыйрь Сибгат Хәким: «...Нәҗип Думавиның һәр сүзе ташкүмер шикелле тыгыз, салмак,— дип язды.— «Җир күмере казучылары»на гына күз салсагыз да, шуны күрерсез. Кайда ул бакчалар, гөлләр, былбыллар белән мавыгу... Ул вакытларда нык таралган шартлы-риторик көнчыгыш поэзиясенең трафарет образлары... Нәҗип Думавины чынбарлыктан, ачы хакыйкатьтән читкә генә алып китәләр» [1].

Караңгы реакция елларында да Думави үзенең демократик идеалларына тугрылыклы булып кала. Ул чын мәгънәсендә «халык кайгысын җырлаучы» [2] шагыйрь булып танала. Думави авылда крестьяннарның җирсезлек, фәкыйрьлек, ачлыктан интегүләрен күрә, тормышның материаль кысынкылыкларын, рухи изүен үз җилкәсендә татый. Укыта торган мәкаләсендә «туенып торырлык доход булмау» [3] сәбәпле һәм өстәвенә кадимче муллаларның «мәсҗедтә митинг ясый» [4] дип, бертуктаусыз донос язуларыннан туеп, ул туган авылыннан Уралга күчеп китә һәм Кизел заводы каршындагы мәктәптә мөгаллимлек итә. Думави Кизелгә әле 1906 елда ук килеп, «меңләгән татар эшчеләренең заводның иң пычрак вә кара эшләрен башкаруын» үз күзләре белән күреп киткән була. Ул чакта ук «зверьдән дә катырак завод мулласы» Думави турында «муллаларының бөтен ризыкларын һәм абруйларын йотачак аждаһа» [5] дигән коткы таратып, аны мәктәпкә кабул иттерми. Кизелгә икенче мәртәбә килүендә дә, шагыйрь кадимче муллалар белән конфликтка керә, уку елын тәмамламас борын мөгаллимлектән китәргә мәҗбүр була. Беркадәр вакыт ул шахтерлар белән күмер чаба, эшчеләрнең авыр хезмәте, начар яшәү шартлары белән якыннан таныша, аларның рәхимсез эксплуатацияләнүләрен күрә.

Буби мәдрәсәсендә укыткан елларда да Думави царизм ялчылары, реакция

[1] Сибгат Хәким. Үз тавышың белән. Казан, 1969, 58 бит.
[2] Вакыт, 1909, 3. I., № 414.
[3] Әхбәр, 1908, 6. II., № 23.
[4] Әхбәр, 1908, 4. IV., № 48.
[5] Әл-гасрел-җәдид, 1906, № 11, 586 бит.

тарафдарлары эзәрлекләвеннән котыла алмый. Сарапул төрмәсенең политик тоткыннар камерасында ятып чыга. Төрмәдә утырганда Думави марксизм нигезләре белән таныша, «зур даһи... Маркcның икътисади (экономик) зарурияtләрен», Плеханов хезмәтләрен өйрәнә. Шул вакыттан башлап ул полиция күзәтүе астында тора. «Кайда барсам да,— дип яза Думави тәрҗемәи хәлендә,—обыскалар кыйла иделәр. Артымнан полиция күзәтеп йөри иде».

Иҗтимагый-политик каршылыклар, социаль сугышлар белән тулы Россия чынбарлыгы, ачы тормыш тәҗрибәсе шагыйрьнең иҗатына да тәэсир ясамый калмый, билгеле. Зур бер төркем булып, аның поэзиясенә реакция символлары — золмәт, төн, җан кыеп йөрүче ябалаклар, кан коючы вәхши палачлар, төрмә сакчысы, казаклар, елан-чаянлы дөнья, юлсыз-маяксыз хәят образлары килеп керә.

XX йөз башы татар поэзиясендә мәхбүс (тоткын) темасы күбрәк романтик эчтәлектә яктыртыла. Демократик язучыларның байтагында ул ирек, азатлык турындагы якты өметләр, көрәш идеяләре белән бергә үреп бирелә (Г. Тукай, С. Рәмиев, С. Сүнчәләй). Аерым язучылар иҗатында мәхбүс темасын реалистик җирлеккә күчерү очраклары да бар (Г. Камал). Әмма замандашларыннан аермалы буларак, Думави «хәбес — мәхбүс» («төрмә — тоткын») мотивын экспрессионистик стиль чаралары ярдәмендә һәм реалистик, һәм романтик ысул белән эшкәртә, «бәхетсезләр абзары» булган төрмә тормышының коточкыч шыксызлыгына һәм авырлыгына басым ясый. Думави мәхбүсләре тоткынлыктан котылу юлын бары тик язмыш җибәргән әҗәлдә генә күрәләр, агу эчеп булса да, аны якынайту турында уйлыйлар, элекке ирекле тормышны, туган җир, туган табигатьне сагынып сулкылдап елыйлар, канлы күз яшьләре түгәләр («Мәхбүс», «Мәңгелек мәхбүс», «Яз үтеп, җәйнең башы житкән иде...», «Себер төрмәсендә тәрәзә рәшәткәсенә кунган кошны күреп, бер карт әйтә», «Мәхбүс дустыма»). Күренә ки, Думави шигырьләренең байтагында традицион романтик шартлылык һәм контрастлар системасы әле саклана.

Ә менә «Себер» (1907) шигырендә тоткын темасы реалистик эчтәлек алган. Ул 1907 елның 3 июнь переворотыннан соң илдә карагруһчылар оештырган террорга турыдан-туры ризасызлык белдерү рәвешендә язылган. Думави сурәтләгән мәхбүсләр дөньясы — ул «револьверлы кагаулар» (тилгәннәр) белән тулган Себер. Монда һәр хөр фикер иясенә бәхетсезлек тажы кидерелгән. Шагыйрь илдәге хәрби-политик режим, реакция изүе турында критик реалистларча җанлы картина тудыра:

**Давыл, кар, боз, суык-салкын һавасы,**
**Ябык, хур, кайгылы һәрбер баласы.**
**Хәбес, төрмә, богаулар һәм богаулар,**
**Кылыч, мылтык, револьверлы кагаулар.**
**Караңгы, һәр кеше монда бәхетсез,**
**Бәхетсез малик [1] монда тәхетсез!**

Экспрессионистларча тыгыз сурәтлелеккә корылган бу өзектә патша самодержавиесенең мәрхәмәтсезлеген күрсәтү, аны фаш итү ярылып ята. Думавиның царизм чынбарлыгын төрмә белән чагыштырган шигырьләре шул чор иҗтимагый көрәшендә әһәмиятле роль уйный һәм татар демократик әдәбиятының казанышы була.

Капитал дөньясының котылгысыз юлдашы — сугыш турында язганда да, шагыйрь социаль контрастларга басым ясый, критик реалистларча эш итә. Мисалга «Сугыш» (1908) шигырен алыйк: далада канга батып, тилмереп, ир-егетләр үләләр; икенче якта өстен сыйныфлар җырын җырлаучы поп белән мулла, «Безнеке җиңсен!», «Илаһи, ярдәм!» дип, сугышка үзләренең фатихаларын бирәләр, генераллар алачак медальләр өчен сөенәләр. Бу шигырьдә дә шагыйрь реализмы экспрессионистик алымнар белән аралаша. Сугыш фаҗигасе, канлы буяулар, шомлы сурәтләр натуралистик төгәллек белән күз алдына китерелә. Думави гомумдемократик һәм пацифистик эчтәлекле шигыре белән, халыклар, дәүләтләр арасындагы мәгънәсез суешлар һәм корбан бирүләрнең кешелеккә дошман икәнлеген раслый. «Сугыш» шигыренә Габдулла Тукай да уңай бәя бирә. Сәгыйть Сүнчәләйгә язган хатларның

[1] Малик — хуҗа.

берсендә ул бу әсәрне «мәгънәви ягы яхшы булганга күрә», «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» исемле җыентыкка кертүе турында искәртеп үтә [1]. «Сугыш» шигыренең үткен социаль эчтәлеге заманында патша цензорларының да эчен пошыра. 1914 елның 29 августында граф Татищев язган хатта бу әсәрнең тенденциоз булуына игътибар ителә [2].

Беренче империалистик сугыш елларында язылган «Ватан каһарманы, яки агач аяк» (1916), «Сугыш тәэсираты» (1916), «Головка» (1917) кебек хикәя һәм шигырьләрнең дә төп темасы — хезмәт ияләренә сугыш алып килгән бәла-казалар.

«Сугыш тәэсираты» (1916) шигырендә Думави буржуаз җәмгыятьнең кешелексезлеген, ерткычлыгын, андагы әхлакый принципларның череклеген фаш итә. Ләкин, сугыш темасына язылган башка әсәрләрдән аермалы буларак, биредә капитал дөньясына карата әйтелгән гаепләү сүзләре һәм романтик, һәм экспрессионистик сәнгать чаралары ярдәмендә тормышка ашырыла. Шигырьнең беренче өлешендә шомлы тынлыкка күмелгән далада канга батып яткан, рухы сынган егет һәм аның канын эчәргә, канлы калҗасын чукырга килгән вәхши карга образы сурәтләнә. Мондый романтик ситуация дөнья әдәбиятының бик күп әсәрләрендә очрый. Әсәрнең икенче өлешендә сугыш корбаны булган егеткә ананың кинаяле киңәше тәкъдим ителә. Кол булып яшәргә теләмәсәң, ди ул, хаклык-вөҗдан булмаган бу хәяттә башкалар кебек «көчле булырга» — залимнәрчә юл кисәргә, урларга, таларга, башкаларга кызганмыйча штык кадарга кирәк. Бары тик шул чакта гына заман халкы «сиңа егет дияр»...

Уңай фикер рәвешендә әйтелгән һәм буржуаз җәмгыятьнең ялган морален тәнкыйтьләгән Думави ирониясе татар әдәби тәнкыйтендә каршылыклы фикерләр тудырды. Берәүләр әлеге әсәрне сугышка өндәгән, кыргыйлыкны мактаган шигырь дип кабул иттеләр (Гали Халит) [3], икенче берәүләр Думави «туры мәгънәсе дә, ирониясе дә игелекле булган юллар язды», диделәр (Хатип Госман) [4], өченче берәүләр шигырьдә декадентлык әдәбиятына барып тоташкан «үтә зур кеше» культы булу ихтималын әйттеләр (Ибраһим Нуруллин) [5]. Шигырьдәге иронияенең сугышка каршы юнәлдерелгән булуын раслаган караш та мәгълүм (Мөхәммәт Гайнуллин) [6].

Думавиның «Сугыш тәэсираты» шигыре турында фикер төрлелеге, беренчедән, романтик иронияенең катлаулы эстетик табигате, аның күп мәгънәлелеккә юл куюы белән аңлатыла. Икенчедән,— бусы иң әһәмиятлесе — экспрессионизм белән мөнәсәбәткә керү, немец идеалистик философиясенең көчле йогынтысын кичерү (Шопенгауэр, Ницше), М. А. Бакунинның анархистик өйрәтмәләре белән таныш булу Думавиның дөньяга карашларын чикли, аның ирониясенә чамадан тыш күпертелгән нигилистик эчтәлек сала. Шул сәбәпле шигырь залим заманадан бизгән, буржуаз тәртипләрдән гайрәте чиккән шәхеснең көчле индивидуаль бунты рәвешендә яңгырый.

Думавиның унынчы еллардагы иҗат эволюциясе сикәлтәле авыр юлны хәтерләтә. Бу елларда да ул дөньяга карашларда да, сәнгатьчә фикерләүдә дә үтә кискен контрастлар белән эш итә, бер чиктән икенче чиккә ташлангалый. 1916 ел дәвамында гына да Думави анархистларча кискен рәвештә буржуаз эгоизмны тәнкыйтьләгән «Сугыш тәэсираты» шигыре белән беррәттән, мистик элементларга өлеш чыгарган «Тәңре» шигырен яза, кешенең дөнья көтүен Дәрдмәнднең «Хәят» шигырендәгечә курчак уены белән тиңләштерә, язмыш фәлсәфәсен алга этәрә. «Син — кеше!» шигырендә исә Думави шәхесне бөек зат дип исәпли, хәтта аны Көнчыгыш пантеист шагыйрьләречә алла белән янәшә куя, җир улларының куәте кара көчләргә каршы юнәлдерелергә тиешлеген раслый:

Бирмә серне, бул гали! Типсен йөрәк зурлык белән...
Син беләмсең, синдә күпме көч барын, куәт барын!

---

[1] Габдулла Тукай. Әсәрләр, 4 том. Казан, Татарстан китап нәшрияты. 1977, 312 бит.
[2] ЦГИАЛ, 776 фонд, 21 тасв. 415 саклау берәмлеге, 1—2 битләр.
[3] XX йөз башы татар әдәбияты. Очерклар. Таткнигоиздат, Казан, 1954, 102 бит.
[4] Усманов Хатип. Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында татар поэзиясе. Казан университеты нәшрияты, 1964. 102 бит.
[5] Нуруллин Ибраһим. XX йөз башы татар әдәбияты. Казан университеты нәшрияты, 1966. 360 бит.
[6] Гайнуллин М. Татарская литература и публицистика начала XX века. Казань, 1966. 264—265 битләр.

**Тип, очыр бу дөньяның барлык кара куәтләрен!**
**Син — бөек!— Салган синә ходай күктән үз орлыгын!..** [1]

Бу рәвешчә кешегә дан җырлау, аны кайгы-хәсрәтле, хурлыклы яшәештән котылу өчен рухи бөеклеккә, кара көчләргә буйсынмаска өндәү — Думави иҗатының көчле ягы. Әмма бу очракта да әле аның көчле, азат һәм батыр рухлы кеше турындагы идеалы «үтә зур кеше» культы тәэсиреннән, волюнтаристик төсмерләрдән азат түгел («Тип, очыр бу дөньяның барлык кара куәтләрен»).

Кеше темасы Думави иҗатында тулы бер эволюция кичерә. Әдәби эшчәнлегенең мәгърифәтчелек белән сугарылган беренче адымнарында ул мәдәниятле инсан образын иҗат итә, кайчандыр вәхшәт колы, табигать баласы булган кешенең авыллар, шәһәрләр, пайтәхетләр салучы, машиналар ясаучы, диңгездә йөзүче цивилизацияле кеше итеп тәрбияләүдә төп көч кыл, гыйлем дип чыга («Инсан», 1906) [2].

Социалистик революциядән соң да кеше темасы Думавиның игътибарын били. А. М. Горькийга ияреп язган «Кеше» (1923) нәсерендә юлдагы киртәләрне аударып, алга, киләчәккә, ирекка, бәхеткә ыргылучы гайрәтле, куәтле, горур герой образы белән очрашабыз [3]. Бөек пролетар язучысының лирик-философик поэмасында төп образ — кешелек тарихын алга әйдәүче кеше акылы, аның фикер кояшы. Әмма Думави кеше темасын Дәрдмәнд романтизмы рухындарак эшкәртә, «тәкәббер, даһи улы» кешене Көнчыгыш фәлсәфәсендәгечә «тарихи мөсафир» рәвешендәрәк укучыга тәкъдим итә.

Реакция һәм унынчы еллардагы Нәҗип Думави эшчәнлеге гаять киң һәм күпкырлы. Ул поэзия, проза, публицистика, тәрҗемә һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендә зур активлык күрсәтә, «сәнгать һәм нәфасәтнең бик сирәк табыла торган» [4] төре — сатирада тырышып эшли. Аның сатирик әсәрләренең күпчелеге төрле псевдонимнар белән («Өй анасы», «Астыртын», «Әрлән», «Озынколаков», «Философ» һ. б.) «Ялт-йолт» журналында басылганнар. Әдип бу журналда аеруча 1914 елда актив язышкан: Думави сатирик әсәрләренең барысы да диярлек реалистик яңгырашлы. Аларның байтагында Тукай сатирасы традицияләре белән аваздашлык та ачык сизелә. Төрле сатирик жанрларга һәм алымнарга (хикәя, мәкалә, фельетон, матбугат күзәтү, сүзлек, сорау-җавап, русчадан үзгәртү һәм тәрҗемәләр) мөрәҗәгать итеп, ул һәртөрле искелек тарафдарларын, хатын-кыз азатлыгына каршы чыгучы кадимчеләрне, «изге» суфыйларны, мулла-мәзиннәрнең мәгънәсез низагларын, схоластик мәдрәсәләрне, үз мәнфәгатьләрен генә күзәтүче милләтчеләрне, сафсатачы клерикаль һәм буржуаз матбугат вәкилләрен, төрле юнәлештәге газета-журналлар арасындагы мәгънәсез талашларны камчылый.

Унынчы елларда Думави балалар әдәбияты өлкәсендәге эшчәнлеген тагын да җанландырып җибәрә, балалар өчен шактый күп хикәяләр язып ташлый, педагогик һәм методик темаларга чыгышлар ясый, тел һәм имля (орфография) мәсьәләләре белән аеруча кызыксына, мәктәпләр өчен дәреслекләр төзи.

Думавиның 1907—1917 еллардагы матур әдәбият өлкәсендәге эшчәнлегенә килсәк, анда бер-берсенә капма-каршы булган идеологик күренешләр, эстетик фикерләр һәм әдәби тәэсирләр, өмет һәм өметсезлек мотивлары бергә килеп очраша, бер-берсе белән тыгыз мөнәсәбәткә, я булмаса бәрелешкә керә. Буржуаз җәмгыятьнең газаплы тормышы, реакция еллары, беренче бөтендөнья сугышы шагыйрьне тирән рухи газаплар, төрле шикләнү, аңламау һәм фикри эзләнүләр дәрьясына ташлый, яшәешкә, кеше һәм аның акылына ышанмаучылыкны, скепсисны арттыра («Аңламак мөмкин түгел бу дөньяда һич нәрсәне»). Шунлыктан Думавиның дөньяга бик садә һәм пакь булып туган, «хәр фикер әлифбасы» узган геройлары золмәт һәм хәшәрәт белән тулган реакция елларын каргыйлар, кеше табигатенең бозыклыгыннан зарланалар, адаштырган, саташтырган, катлы-катлы шөбһә белән тулган алдакчы дөньяны яратмыйлар («Төн» — 1907, «Дөнья» — 1908, «Бу да бер киңәш» — 1912), ямьсез хәятне яңарту өчен «һәр адәм башлап үзен ислях итәргә тиеш» дигән толстойчылык карашларына да ышанып куялар («Дөнья кайчан ислях

[1] Аң, 1916, 11—12 саннар, 183 бит.
[2] Казан мөхбире, 1906, 24 апрель.
[3] Кеше (Горькийга ияреп).— Безнең юл, 1923, 12 сан, 21—23 битләр.
[4] Тәраккый иттек.— Ялт-йолт, 1974, 72 сан, 3 бит.

улынырі» — 1912), вакыты-вакыты белән илаһияткә дә сыгыналар («Мәэюскә», «Коръән», «Үзгәртү» — 1912, «Сәҗдә» — 1914). Җанны борчыган сорауларга җавап табарга тырышып, Думави Көнбатыш һәм Көнчыгыш фәлсәфәсен өйрәнә, культуратарих мәктәбе, руссоизм, романтизм, экспрессионизм кебек әдәби-эстетик юнәлешләрнең, позитивистик философиянең уңай һәм тискәре тәэсирен кабул итә.

Реакция елларында Думави поэзиясенә үтеп кергән формализм күренешләре, шигърият өлкәсендәге кайбер зәгыйфьлекләр, чатаклыклар Габдулла Тукай һәм Галимҗан Ибраһимов кебек демократик язучылар тарафыннан тәнкыйть ителә. Әдипнең унынчы елларда язылган кайбер әсәрләрендә азмы-күпме декадентлык чире билгеләре дә күренгәли, татар әдәбияты җирлегендә модернистик әдәбият адымнарын сынап карау очраклары да була. Әмма ничек кенә булмасын, Думавиның бу чорда язылган әсәрләренең күбесе — экспрессионистик үткенлек белән буржуаз җәмгыятьнең эксплуататор асылын, черек моралең тәнкыйтьләгән әсәрләр.

Унынчы еллар Думави иҗатында күзгә ташланган җитди үзгәрешләрнең берсе — ул романтизмга таба юл тоту, романтик әдәбият һәм эстетика кануннарын актив үзләштерү. Бер-бер артлы әдипнең романтик эчтәлекле шигырь, поэма, хикәя һәм повестьлары дөнья күрә («Болгар кызы Тойгы туташ» — 1911, «Юкка үлде» — 1912, «Алла тигезли» — 1912, «Гыйшык трагедиясе» — 1916, «Шәрык даһие» — 1915).

Бу чорда дөнья күргән бер төркем әсәрләрдә бәхет — хыялый өмет кенә, тормышта җәфалану, интегү котылгысыз дигән универсаль иҗтимагый пессимизм өстенлек ала. Мәсәлән, «Алла тигезли» (1912) хикәясенең исеме үк яшәештәге бәхетсезлек һәм явызлыкның чыганагын иррациональ көчләргә, язмыш фәлсәфәсенә таянып аңлау турында сөйли. Мәзкүрә ханым ире тарафыннан никадәр генә рәнҗетелмәсен — «тормыш шулайдыр» дип, барысына да түзә, каршы сүз әйтми. Аның сукыр ихтыяр колы икәнлеге: «Ах фәләк, кешеләрнең башына ниләр китерми» — дигән автор сүзләре белән дә раслана.

Идея-эстетик яңгырашы белән бу хикәя Морис Метерлингның «үлем театры» принципларын искә төшерә. Бельгия драматургының бер пьесасын татарчага тәрҗемә итүе («Чакырылмаган кунак», 1916) Думави Метерлингның башка әсәрләре белән дә таныш булган дип уйларга урын калдыра. Татар әдибе дә, Метерлинг кебек, яшәеш, үлем, дөньяны танып белү, гаделлек, хакыйкать кебек сорауларга җавап эзли. Ялгызлыктан гаҗиз, үлем, язмыш каршында көчсез, явызлыкка каршы көрәшкә сәләтсез «мескинә» хатын образы мистик иррациональ фикер йөртүче Метерлинг геройлары белән күпмедер дәрәҗәдә аваздаш.

Ә менә «Алла тигезли» белән бер үк елны язылган «Юкка үлде» хикәясендә Думави язмыш, үлем концепциясен кире кага, үлемне идеаллаштыручы консерватив романтиклар, модернист һәм декадент язучылар белән бәхәскә керә. Хикәядә яшь бер философ, дөньядан туеп, табигать шау чәчәккә күмелгән язгы бәйрәмнәрнең берсендә сазлыкка батып үләргә дип юл тота. Бөтен табигать — чәчәкләр, карлыган, чияләр, чыпчык, тургай, күкеләр һәм якты кояш аның үлеменә каршы. Әмма философның бу матур табигатькә һич тә исе китми, чөнки ул һичкайда хакыйкать тапмаган. Җәмгыять белән конфликтка кергән бу философның үлеме Ницше фәлсәфәсе рухында сурәтләнә. Рухы белән горур һәм көчле герой үзенә «ирекле үлем» сайлавы белән бик тә бәхетле. Әмма аның дөнья белән бу рәвешчә алыш-бирешне өзүен, тормыш матурлыгын, «олуг нигъмәтләрен» күрергә теләмәвен автор кабул итми, «Юкка үлде» дигән нәтиҗә ясый.

Шуны әйтергә кирәк, унынчы еллар Думави иҗатында романтик һәм руссоистик эчтәлекле табигать һәм мәхәббәт культына шактый гына зур урын бирелә. Мәсәлән, өч бүлекчәдән торган «Сихерле тамчылар» хикәясендә руссоистларча бер-бер артлы дөньяви фәннәр, философия һәм матур әдәбият инкяр ителә, мәдәният кеше бәхетенә дошман, бары тик шәхеснең табигый хисләре — мәхәббәт кенә яшәешкә мәгънә бирә дигән романтик нәтиҗә ясала.

Француз язучысы, Жан Жак Руссо тарафдары Бернарден де Сен-Пьерның «Индийская хижина» сатирик-философик повестена адаптация рәвешендә язылган «Хакыйкать артыннан» хикәясе дә шундый ук руссоистик һәм романтик концепциягә корылган.

Хикәядә төрле мәнфәгатьләр белән пычратылган цивилизация дөньясы кеше-

ләр арасындагы чын табигый мөнәсәбәтләргә каршы куела. Ул чын рухани, мәгънәви һәм бәхетле тормыш бары тик табигатьтә генә, үзенең гадел хезмәте, саф мәхәббәте белән табигать кочагында көн күрүче гади кешедә генә диган фикерне куәтли. Әйтергә кирәк, менә шундый караш Думави эстетик эзләнүләренең үзәгендә ята. Бу караш татар демократик әдәбиятының күпчелек вәкилләренә хас. Кеше хәсрәт чиксә генә бәхеткә ирешә ала диган концепция, гомумән, татар әдәбиятында борынгыдан ук яшәп килә (мәсәлән, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастаны). Рус әдәбиятында мондый руссоистик караш аеруча Ф. Достоевскийга хас. «Инсаннарны фәлякәт иршад итәр», ягъни бәла-каза туры юлга күндерер кебек руссоистик мотив Бернарден де Сен-Пьер повесте аша Думави иҗатына да үтеп керә.

Шул рәвешчә, Думави иҗатындагы һәм эстетикасындагы руссоистик тенденцияләр төрле эчтәлектә бирелә. Акылны хискә, җәмгыятьне табигатькә, социаль мөнәсәбәтләрне табигый мөнәсәбәтләргә каршы кую, фән, философия һәм матур әдәбиятның иҗтимагый тормыштагы ролен танымау, табигать белән мәхәббәтне генә хакыйкать һәм матурлык чыганагы дип игълан итү — болар асылда буржуаз җәмгыятьтәге тәртипләрне кире кагу юлын эзләгәндә туган идеологик күренеш һәм романтик эстетиканың каршылыклы гәүдәләнеше.

Унынчы елларда Думави әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеген җанландырып җибәрә һәм ул нигездә ике юнәлештә бара. Мәкаләләрнең бер төркемендә ул романтик эстетика принципларын алга этәрә, ә икенче берләрендә реалистик эстетика тарафдары буларак чыгыш ясый. Бу соңгысына мисал итеп 1911 елда, А. М. Горький редакцияләгән «Современник» журналында басылган «Пробуждение русских татар и их литература» исемле мәкаләсен атарга мөмкин. Бу мәкалә әдәби хәрәкәтне Россия һәм татар тормышындагы иҗтимагый-политик, социаль-экономик һәм идеологик күренешләр белән тыгыз мөнәсәбәттә яктыртуы, объектив эчтәлекле булуы белән игътибарны җәлеп итә. Думави татар әдәбиятының чишмә башын Болгар җирлеге, болгар чоры белән бәйли, аның үсеш этаплары — урта гасырлар, XIX йөз, XX гасыр башы турында фикер йөртә, феодализм һәм капитализм чорындагы әдәби багланышларның чыганаклары һәм үзенчәлекләренә күз сала, мәгърифәтчелек чоры иҗтимагый фикеренә, әдәби процесска анализ ясый, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, З. Бигиев, Р. Фәхретдинов, Ф. Кәрими кебек мәгърифәтче галим, публицист һәм язучылар эшчәнлегенә бәя бирә. Әлеге мәкаләдә Думави Беренче рус революциясе чорындагы иҗтимагый политик агымнар, идеологик көрәш белән таныштыра, революциянең татарларны рус культурасы белән якынлаштыруда искиткеч роль уйнавы турында әйтә, Тукайның халык шагыйре икәнлеген ассызыклый, аның халык рухы белән сугарылган шигырь, поэма, әкиятләр язуы, күп санлы Пушкин һәм Лермонтов әсәрләрен татарчага тәрҗемә итүе турында сөйли. Шул чор әдәби тәнкыйтендәге бәхәсләр тәэсирендә булса кирәк, Думави «Сәгыйть Рәмиев поэзиясен Тукай белән чагыштырганда тирәнрәк», аның «теле нәфис һәм баерак» диган ялгыш нәтиҗә дә ясый. Беркадәр соңрак Тукай турындагы мондый караштан ул баш тарта, аны «татарларның бердәнбер бөек шагыйре» итеп таный («Яңа стильдә тәнбиһ!» [1] — «Ялт-йолт», 1914, 81 сан).

Думавиның Октябрь революциясеннән соң язылган «Шәрык даһиларыннан Рабиндранат Тагор» исемле мәкаләсен дә («Кызыл Шәрык», 1920, 2 сан) реалистик әдәбият белеме казанышы дип әйтергә мөмкин. Шагыйрь Тагор иҗатын һинд халкының инглизләргә каршы милли азатлык хәрәкәте белән бәйләп карый, аны социаль изүгә каршы көрәшкә өндәүче, халык хәсрәтен җырлаучы каһарман шагыйрь дип бәяли.

Унынчы еллар Думави эстетикасындагы чуарлык, капма-каршылык өлешчә аның төрле философик тәгълиматларга мөрәҗәгать итүе белән дә аңлатыла. Мәсәлән, «Сихерле тамчылар» исемле хикәясендә ул Платон, Аристотель, Сократ, Бэкон, Локк, Декарт, Дарвин, Руссо, Кант, Шопенгауэр кебек борынгы һәм яңа заман философлары хезмәтләрен һәм «пессимистлык, оптимистлык, индивидуалистлыктан гый-

---

[1] Тәнбиһ — кисәтү, искәртү.

барәт булып кала торган бу фәлсәфәләр»нең анық аңында фикер сугышы кузгатуы турында әйтеп үтә. Моннан тыш Думави Европа рус һәм төрек әдәбият белеме, андагы төрле мәктәпләр, юнәлешләр, идея көрәшләре белән яхшы таныш була. XIX гасыр һәм XX йөз башы Европа, рус һәм төрек әдәбияты белемендә киң таралган культура-тарих мәктәбе принциплары Нәҗип Думавиның романтик эстетикасына аеруча зур тәэсир ясый.

Күреп үтелгәнчә, Нәҗип Думавиның тормыш юлы һәм иҗаты бик катлаулы. Ул яшәгән чор — иҗтимагый формацияләр алмашынган, татар җәмгыятендә сыйнфый каршылыклар кискенләшкән, милли азатлык һәм халык революцион хәрәкәтләре тирәнәйгән бер чор. Бу вакыйгалардан, заманнан, халык тормышыннан Думави да читтә калмый. Әмма ул иҗтимагый тетрәүләр зарурияттен томанлы күзаллый, тарихи дөреслекне аңлауга икеләнүләр, ялгышулар аша килә. Бу исә аның әдәби-эстетик карашларын да каршылыклы итә, гуманистик эчтәлекле, демократик юнәлештәге иҗатында вакыты-вакыты белән консерватив тенденцияләргә дә урын бирелә.

1917—21 елларда Думави Чистайда яши, андагы мәктәпләрдә, укытучылар хәзерләү курсларында укытучы һәм өяз мәгариф бүлегендә инспектор булып эшли, «Берлек» газетасында үзенең әсәрләрен бастыра. Идел буендагы каты ачлык елларында ачларга ярдәм комитетлары оештыру, тукландыру пунктларын ачу буенча зур тырышлык күрсәтә, Фәтхи Бурнаш тарафыннан төзелгән «Әдәби ярдәм мәҗмугасе»ндә (1922) катнашып, аның гонорарын тулысы белән ачларга ярдәм фондына тапшыра. Думавиның ачлык фаҗигасе турындагы шигырьләре «Берлек», «Татарстан хәбәрләре» газеталарында да дөнья күрә.

1921—25 елларда туган авылында мулла булып исәпләнсә дә, Думави күбрәк җәмәгать һәм иҗат эшләре белән мәшгуль була, еш кына Чистайга, Казанга бара, авылда ликбезлар, төрле курслар оештыра, аларның укыту эшләрен җайга сала, үзе дә төрле фәннәрдән дәрес бирә, сәләтле яшьләрне рабфакларга һәм партия мәктәпләренә укырга әзерли.

Гомер буе дини фанатиклар белән конфликтта яшәгән, ә иҗатында алардан көлгән Думави 1925 елда рәсми рәвештә руханилык вазифасыннан баш тарта. Озак та үтми ул Дагстан педагогия техникумына укытучы булып китә. Ә аннан Сәмәркандка күчеп килә, Педагогия институтында лекцияләр укый, тәрҗемәче булып эшли.

1927—1933 елларда Думави Үзбәкстандагы культура-агарту оешмаларында хезмәт иясләрен материалистик рухта тәрбияләү буенча зур эш башкара, фәнни-популяр темаларга күп санлы чыгышлар ясый.

Сугыш утларын кичкән, зур рухи сынаулар аша үткән, ару-талуны белми халыкка хезмәт итәргә омтылган шагыйрьнең сәламәтлеге шәптән булмый. Үпкә авыруы һәм ревматизмнан җәфа чиккән Думави 1933 елның 5 маенда Сәмәркандтан ерак түгел Булунгур шифаханәсендә дөнья куя.

# ҖИРНЕ ҖЫР БИЗИ



РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисты Эмиль Җәләлетдиновның җырлавын, аның исемен республикабызда ишетмәгән кеше юктыр. Ул сәхнәдә 20 ел буе чыгышлар ясаган чор музыка җәмәгатьчелеге өчен гаять әһәмиятле вакыйгалар белән бәйле. Җырчының осталыгына илебезнең ерак төбәкләрендә, чит илләрнең күп кенә шәһәрләрендә яшәүче тамашачылар да сокланалар. Ә менә аның тормыш һәм иҗат юлына алып килгән сукмак кайдан башлана соң?

Э. Җәләлетдинов 1933 елның 2 июлендә Сәмәрканд шәһәрендә туа. Тормышында аның җырчы юлын сайлавында нинди дә булса очраклылык хәлиткеч урын тотмый. Музыкант булу күптән билгеләнгән, һәм аңа шушы олы максаттан читкә тайпылмаска гына кирәк була. Әйе, кечкенә малайдагы музыкаль сәләт бик иртә беленә. Хәзер дә җырчы бала чагын музыкадан, көй-моңнан башка күз алдына китерә алмый. Аларның гаиләсендә еш кына татар һәм рус җырларын җырлыйлар, абыйсы көн саен диярлек скрипкада уйный. Әтисенең бертуган Галия апасы Э. Җәләлетдиновның хәтерендә аеруча җылы бер истәлек булып калган. Чөнки ул татарча җырларны бик яратып җырлаган. Гаилә вәкилләре фәкать рус телендә генә сөйләшкәнлектән, бары шушы җырлар гына Эмильгә туган теленең искиткеч байлыгын һәм шигърилеген күңеле белән тоярга, аңларга ярдәм иткәндер, шәт. «Кара урман», «Әллүки», «Иртә дә кил, кич тә кил» кебек җырлар булачак җырчының иң яраткан көйләре булып китәләр. Өйдә уйнаган, шаярган вакытларында балалар һәрбер уенны җыр белән башлап җибәрәләр. Эмиль апасы Рина белән кич саен җырлый торган булалар. Аннары, кетмәгәндә күреп алган бер патефон малайның бөтен игътибарын җәлеп итеп ала. һәм күпкә-озакка үзенең патефонын булдыру турындагы хыял аның барлык башка уй-теләкләрен каплап тора. Бу хыял тормышка ашканнан соң, өйдә репродуктор да барлыкка килгәч, болай да Эмильнең күңелен алгысытып торган музыканың йогынтысы тагын да артып китә. Шул вакыттагы Энрико Карузо, Сергей Лемешев, Оксана Петрусенко шикелле беренче кумирларның Э. Җәләлетдинов иҗат юлына матур бер тәэсире булмый калмагандыр, мөгаен. Тора-бара музыка белән кызыксыну аны күрше йортта яшәүче кешеләр белән дуслаштыра. Аларның берсендә радио белгече яши, димәк, аның радиоалгычы буенча төрле көйләрне теләгән хәтле тыңлап була. Әмма Эмильне иң нык таң калдырганы: икенче бер күршеләрдә хәтта пианино, чып-чын пианино булу! Менә шушыларның һәммәсе

белән бергә ундүрт яшь тулганда мәктәпләрнең сәхнәсендә беренче мәртәбә чыгыш ясау яшүсмер чак хатирәләрен аерата яктыртып тора.

Җиденче классны тәмамлаганнан соң, Эмиль Сәмарканд музыка училищесына килә. Ләкин үзенең яшь тавышы әле ныгып-ачылып җитмәгәнлектән, күптәнге теләгенә ирешүне, чынлап торып моң серләренә өйрәнүне соңгарак калдырып торырга мәҗбүр була. Музыкага булган мәхәббәт егетне һаман-һаман музыкаль белем тирәнлегенә чакырып тора. 1950 елда ул бала чагыннан бирле күңелен җилкеткән хыялын тормышка ашыра, әлеге музыка училищесының вокаль һәм хор белән дирижерлык итү бүлекләрендә укый башлый. Әкрен-әкрен ноталарны укырга, җырлау культурасына һәм хор белән дирижерлык итү осталыгына өйрәнгән саен, Э. Җәләлетдинов үзенең дөрес иҗат юлын сайлавына тагын да ныграк ышана бара.

Училищедан соң Совет Армиясе сафларында хезмәт иткәндә ул полк һәвәскәрләре җитәкчесе була, солдатларга җырлар өйрәтә, үзе дә җырлый, алар белән бергәләп зур бәйрәм концертларында, конкурсларда катнаша.

Армия хезмәтеннән соң Э. Җәләлетдинов Ташкент дәүләт консерваториясенә укырга керә һәм, озак та үтми, инде күптән күңелендә йөргән Казанга күчеп килә. Казан дәүләт консерваториясендәге В. А. Воронов классында укый башлый. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе В. А. Воронов, җырчының ул вакытта артык зур булмаган тавышында Н. Җиһановның киләчәк мөмкинлекләрне күрүе һәм яшь студентның үз классына тәкъдим ителүе турында сөйли.

Консерваториядә уку җырчыга опера спектакльләре эше белән дә якыннан танышырга мөмкинлек бирә. Дөнья классикасына кергән опералардагы арияләр белән беррәттән Э. Җәләлетдинов татар, үзбәк операларында да җырлый. Ул, әйтик, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында Җ. Фәйзинең «Тапшырылмаган хатлар»ында — студент, С. Сәйдәшев белән А. Ключаревның «Наемщик» операсында Батырҗан партияләрен башкара. Бу эш аның репертуарын тагын да баета, иҗади үсешенә булыша. Мондый спектакльләрдә катнашу һәрвакытта зур профессиональ осталык мәктәбе була, әсәрдәге характерларны төгәл һәм образлы итеп тамашачыга җиткерергә омтылу, һәр сүзнең, хәрәкәтнең тәэсир итү көчен тирәнтен тою кебек җырчы өчен зарури булган сыйфатларны тәрбияли.

Музыкаль спектакльләрдә эшләү белән бергә, Э. Җәләлетдинов концертларда бик еш чыгыш ясый. Мөстәкыйль иҗат эшчәнлеген дә ул 1962 елда Г. Тукай исемендәге Татарстан дәүләт филармониясе солисты буларак башлап җибәрде. Аңа баштан ук әзләнү хас иде: үз репертуарын эзләү, аны һаман яңартып тору, яңа җырны башкару алымын эзләү... Ул соңгы елларда, тирән кичерешләргә бай романсларга йөз тотып, игътибарын күбрәк камера вокаль лирикасына таба юнәлтте. Инде артист татар музыкасында туган әсәрләрнең байтагын халыкка җиткерүче, бик күп яңа романсларны, җырларны иң беренче башкаручы булып танылды.

Җырчының композиторлар белән дуслыгы аның иҗат юлын аерата бизәп тора. Бу дуслык студент елларында ук башлана. Ул чакта язмышның бәхетле бер мизгеле аны Н. Җиһанов, М. Мозаффаров, А. Ключарев, Җ. Фәйзи кебек күренекле композиторларыбыз белән таныштыра. Э. Җәләлетдинов аларның иҗатына тугры калды, җырларын һәрвакыт яратып башкара. Аның концертлары программаларында вокаль музыка язган һәм язучы барлык композиторларыбызның да әсәрләре урын алган. Шулар өстенә ул — СССР, РСФСР, ТАССР Композиторлар союзлары оештырган чараларда иң актив катнашучыларның берсе. Чынлап та, съезд яки пленумнарда, юбилей янсә зур иҗат кичәләрендә ул ихлас күңелдән теләп чыгышлар ясый. 1978 елда аның исеменә СССР Композиторлар союзыннан хат килүе дә очраклы хәл түгел. Анда СССР Композиторлар союзының беренче секретаре, СССР халык артисты Т. Н. Хренников композиторларның VI Бөтенсоюз съезды концертында катнашуы өчен секретариат исеменнән җырчыга рәхмәт белдерә һәм аның бирудә чыгыш ясавы съезд делегатларына, күп санлы кунакларга, андагы барлык совет музыкасын сөючеләргә нык ошавын билгеләп үтә. Төркмәнстанда, Казахстанда, Каракалпакстанда, Украинада, илебезнең башка бик күп төбәкләрендә, шәһәрләрендә уздырылган һәм гомерлеккә хәтердә кала торган шундый кичәләрдәге чыгышларын Э. Җәләлетдинов илһамланып искә төшерә.

Соңгы елларда җырчының композитор Рөстәм Яхин белән иҗади дуслыгы ныгыганнан-ныгый бара. Танылган композиторның әсәрләре Э. Җәләлетдинов репертуарында аерым әһәмияткә ия. Җырчы РСФСРның халык артисты Р. Яхинның күп кенә әсәрләрен беренче булып яңгыратты, һәм ул җырлар музыка сөючеләр күңеленә нәкъ ул башкарганча сеңеп калды. Бу сүзләрне раслау өчен «Син кал, иркәм, бездә», «Күңел йолдызы», «Уникe батыр турында баллада», «Бик курәсем килә», «Яшә, Сәмарканд!» һәм башка җырларны искә төшерү дә җитә. «Рөстәм Хаҗиевич белән, гаҗәеп сәләтле, эшчән һәм таләпчән кеше белән, бергәләп эшләгән кызыклы сәгатьләр һичберкайчан онытылмас,— ди Э. Җәләлетдинов.— Аның көйләрендәге иң әүвәл моң байлыгы белән аерылмаслык булып үрелгән классик җитдилек, фразаларның гаҗәп дәрәҗәдә эшкәртелгәнлеге һәм эчке киң күңеллелеге сине һәрвакыт бик тиз биләп ала».

Тамашачыларның хәтерендәдер: 1975 елда Татарстан композиторлар союзының XIV Пленумы концертында Э. Җәләлетдинов башкаруында «Тукай ритмнарында» дип исемләнгән яңа вокаль-симфоник поэма яңгырады. Композитор А. Монасыйпов иҗат иткән әлеге әсәр буенча эшләү җырчының иҗат юлында үзе бер этап рәвешен алды. Бу яңа хезмәт татар музыкасы өчен һич тә гадәти түгел, бөтенләй яңа күренеш иде. Менә шушы кыю, бирелеше буенча искиткеч яңа һәм бүгенге поэмага бер дә көтмәгәндә-уйламаганда борынгы заман сулышы килеп керә. Җырчы, вокаль-симфоник поэманы җырларга әзерләнгәндә, композитор белән бик күп көч сарыф итәргә туры килүен әйтә. «Башта әле чиста техник яктан байтак көч түктек. Баштарак авыр һәм күп нәрсә аңлашылмый иде,— ди Э. Җәләлетдинов ачыктан-ачык.— Рөстәм Яхинның җыр лирикасындагы моң һәм матурлык сурәте эчке дөньяңны шунда ук үзенеке итә дә куя. Алмаз Монасыйпов әсәрләре исә озаклап, тырышып эшләгәнне таләп итә, һәм бары тик шуннан соң гына, бер чама образга күнеккәч кенә, әлеге әсәрләрне бәяләү мизгеле якынлаша башлый...»

Э. Җәләлетдинов кешеләр белән ифрат та дусларча мөгамәләдә, оптимистик рухлы, киң күңелле әңгәмәдәш. Ул безнең кайбер сорауларыбызга җавап бирергә рәхәтләнеп риза булды.

— Сезне җыр, сәхнә һәм гомумән актерлык сәнгате аерата кайсы ягы белән үзенә тарта?

— Актер, аерым алганда җырчы тормышы — бик тә тынгысыз тормыш. Бу тынгысызлык һәр даим бер шәһәрдән икенче шәһәргә, авылдан авылга күченеп йөрүдән генә гыйбарәт түгел әле. Артист профессиясе һәрвакыт эш халәтендә, формада булуны, үзеңне иҗади киеренкелектә тотуны, ару-талуны белмичә эшләүне таләп итә. Иҗат кешесе әнә шулай эшләгәндә генә тамашачы күңеленә рухи ләззәт китерә һәм чын-чынлап бәхетле була ала. Сәнгать дөньясы ул бөек максат-хыяллар, игелекле ашкынулар дөньясы. Чиксез ерак тоелган иң гүзәл хыял белән нәкъ менә сәхнә очраштыра. Әгәр дә талантыңның, сәләтеңнең җегәре җитеп шушы хыялый дөньяга тыңлаучыларыңны да ияртеп керә алсаң, бу инде артистның профессиональ уңышы, профессиональ бәхете дип атала.

— Яшь җырчыларга нинди киңәшләр бирер идегез?

— Иң әүвәл үз эшеңне яратырга, армый-талмый өйрәнергә һәм өйрәнергә кирәк. Профессионал җырчы, һичшиксез, халык моңнарының, дөнья классикасы көйләренең иң камил үрнәкләрен белергә тиеш, дип уйлыйм. һәм үзең җырлау гына түгел, җыр сәнгатендә танылган осталарның язмаларын даими тыңлауны да үзеңә кагыйдә итеп алу зарури. Аннары, үз заманыңны тоя белергә, шул хисне югалтмыйча сакларга, бүгенге музыкаль әсәрләрнең иң әйбәт дигәннәрен сайлап алырга күнегергә дә кирәк. Үзеңдә музыкаль зәвык тәрбияләү, һәр даим музыкаль белемеңне үстереп торуы да бик мөһим. Болар һәммәсе дә — җырларга өйрәнү эшендә зур ярдәмчеләр.

— Яңа җыр өйрәнгәндә Сез үзегез, гадәттә, нинди эштән башлыйсыз?

— Бу эшне күп вакытта көй язылган шигырь белән танышудан башлыйм. Башта сүзләр, аннары көй аркылы әсәрнең төп мәгънәсен, фикерен аңларга тырышам. Бу фикернең минем дөньяга булган карашыма тәңгәл килүе дә бик әһәмиятле, билгеле. Әгәр дә җырның авторлары миңа якыннан таныш булмасалар, мин аларның иҗатын, образлар һәм хис-кичерешләр дөньясын өйрәнәм. Әнә шул рәвешчә җыр, әйтерсең лә, күңелдә яңабаштан туа. Чыннан да, әсәрне халык алдында беренче мәртәбә

башкаручыны жырның өченче авторы дип юкка гына әйтмиләрдер шул... Вакыт узган саен, жыр камилләшә бара. Жырны өйрәнгәндә, аның авторлары белән аралашу, киңәшү һәм бергәләшеп фикер йөртүнең дә ярдәме зур.

— Алдагы бер әңгәмәбездә Сез тавыш гигиенасына, ашау-эчү режимына бик игътибарлы булуыгыз, һәркөн иртән физзарядка ясавыгыз турында әйткән идегез. Болар, минемчә, хезмәтегез буенча да зарур күренешләр. Ә менә башка буш вакытларыгызны Сез ничек уздырасыз?

— Буш вакытым булмый диярлек. Ләкин шулай да кайвакытта фотография белән шөгыльләнәм, велосипедта йөрим. Йорт эшләрен яратып башкарам. Сүз уңаеннан шуны да әйтеп узыйм: тәмле итеп пылау да пешерә беләм!.. Аннары, ТАССР художниклар союзындагы һәм Татарстан сынлы сәнгать музеендагы күргәзмәләрнең берсен дә калдырмыйча карап барырга тырышам.

— Иҗат планнарыгыз белән уртаклашсагыз иде.

— Татар композиторларының әсәрләреннән ике концертлык цикл әзерләргә хыялланам. Аларның берсендә — арияләр, романслар, халкыбызның борынгы жырлары, икенчесендә Н. Жиһанов, Л. Любовский, А. Монасыйпов, Б. Мулюков, Р. Яхинның вокаль цикллары урын алачак. Мин хәзер шушы концертларның программалары буенча эш алып барам. Шулай ук көнбатыш романтикларының әсәрләреннән төзелгән аерым концерт белән чыгыш ясыйсым килә. Аннары тулы бер кичәне рус классик романсына багышларга уйлыйм. Планнар зур, эшләгән саен эшлисе килә. Чөнки жыр тамашачы күңелен яктырта, рухи яктан баета һәм, гомумән, бөтен жир йөзен бизи...

Э. Жәләлетдинов репертуарында хәзер совет һәм шулай ук чит ил композиторларының төрле чорларда иҗат ителгән 750 гә якын ария, романс һәм жырлары бар. Ул халкыбыз жырларын да яратып башкара. «Халык жыры күңелле-шаянмы, әллә сагышмы, ул барыбер акыллы һәм тирән хисләрне белдерә,— ди жырчы.— Аның һәрвакыт яңа, моңа кадәр ачылмаган якларын табасың».

Жырчы үзенең тавышын теге яки бу жанр таләпләренә шактый жиңел буйсындыра. Аның тавышын үзенә бертөрле бәрхет сыман йомшак тембрыннан бик тиз танып була. Артистның югары профессиональлеге һәм жырлау культурасы эчкерсез күңел жылылыгына туры килеп тора. Аның зур мөмкинлекләрен, талантын бала чактан бер максатка юнәлдерелгән хезмәте, эш сөючәнлеге ныгыта. Боларның барысын да сәнгатькә бирелгәнлек, олы мәхәббәт бизи.

НУРИЯ ХӘЙРУЛЛИНА

## *Каләмдәшләребез — СССР Язучылар союзының яңа әгъзалары*



## Фәрит Хатипов

1930 елда Актаныш районының Пучы авылында туган.

Казан дәүләт педагогия институтының татар әдәбияты кафедрасы мөдире Фәрит Хатипов илленче елларның урталарыннан алып, бүгенге көнгәчә әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә актив эшләп килде. Ф. Хатипов бигрәк тә прозаны яратып өйрәнә, аның үсешенә бәйле җитди теоретик мәсьәләләр күтәрә.

Тәнкыйтьченең «Мирсәй Әмир» исемле монографиясе (1964), «Эпик жанрлар» (1973), рус телендә басылган «Геройның рухи дөньясы» (1981) кебек китаплары дөнья күрде.



## Рахмай Хисмәтуллин

1934 елда Актаныш районы Әнәк авылында туган. Казан дәүләт университетының физика-математика бүлеген тәмамлагач, инженер, район газеталарында әдәби хезмәткәр, «Социалистик Татарстан» газетасының Түбән Кама постында үз хәбәрчесе булып эшли. Күп еллар дәвамында шул ук шәһәрдәге «Кама таңнары» әдәби берләшмәсен җитәкли.

Р. Хисмәтуллинның «Салават күпере» (1964), «Күкрәү авазлары» (1967), «Үземне таптым» (1980) исемле хикәя һәм очерк китаплары дөнья күрде.



## Фоат Садриев

1941 елда Мөслим районында туган. Озак еллар буе Ф. Садриев Мөслим район газетасы редакторы булып эшли. Беренче драма әсәре — «Оҗмах ишеге төбендә» комедиясе 1969 елда «Идел» альманахында дөнья күрә. Аннары ул «Их сез, егетләр», «Ач тәрәзәң», «Кондырлы кодача» исемле комедияләрен язды — алар Әлмәт драма театры сәхнәсендә куелдылар.



## Зиннур Мансуров

1949 елда Мамадыш районының Түбән Ушмы авылында туган. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлагач, берничә ел Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. Бүгенге көндә ул — «Социалистик Татарстан» газетасының әдәбият һәм сәнгать бүлеге корреспонденты. Яшь шагыйрьнең «Кул бирәм» (1979), рус телендә Мәскәүдә «Меңъяфрак» (1983) исемле китаплары дөнья күрде.

### ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Татарстан Язучылар союзы идарәсе һәм партия оешмасы яшь талантлар белән эшләүгә даими игътибар бирәләр һәм нәтиҗәле эш алып баралар. 29 мартта булып узган ачык партия җыелышында ике яшь язучы — Н. Гыйматдинова һәм К. Кәримов иҗатларын тикшерү мәсьәләсе куелу да моның бер күркәм чагылышы булды. Җыелышта чыгыш ясаган язучылар А. Расих, Т. Миңнуллин, Р. Харис, Ф. Миңнуллин, Ә. Баянов, Р. Мостафин, партия бюросы секретаре Р. Мөхәммәдиев һ. б.лар яшь авторлар иҗатының уңышлы һәм кимчелекле якларына туктадылар, аларга армый-талмый иҗат итәргә һәм кыенлыклар алдында каушап калмаска киңәш бирделәр.

### ИҖАТ ИНТЕЛЛИГЕНЦИЯСЕ УКУЫ

15 апрельдә КПСС өлкә комитетының Политик мәгариф йортында иҗат интеллигенциясе өчен даими эшләүче семинарның чираттагы занятиесе булды. Анда катнашучылар алдында КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев «Культура үсешенең, эчке һәм халыкара хәлнең кайбер мәсьәләләре» дигән темага чыгыш ясады. СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының археология һәм этнография секторы мөдире, тарих фәннәре докторы А. Х. Халиков Татарстан тарихын өйрәнү буенча яңа археологик һәм этнографик материаллар белән таныштырды.

Политик поэзия сәгатендә шагыйрьләр Н. Арсланов, И. Юзеев, Р. Харис, Р. Гатауллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Зөлфәт һәм Ф. Сафин чыгыш ясады.

### ДУСЛЫК КИЧӘСЕ

Мәскәүдә язучыларның А. А. Фадеев исемендәге Үзәк йортында күренекле татар совет шагыйре Әхмәт Ерикәйнең 80 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль кичә уздырылды. Аны СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов ачты. Ул Ә. Ерикәйнең биографиясе һәм иҗат эшчәнлеге белән кыскача таныштырды. РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре шагыйрь Николай Доризо, шагыйрь Вадим Кузнецов, әдипне яхшы белгән, аның белән бергә эшләгән шагыйрьләр Михаил Львов, Павел Железнов, Рувим Моран кызыклы истәлекләре һәм фикерләре белән уртаклаштылар.

Татарстаннан килгән кунак, «Казан утлары» журналының баш редакторы шагыйрь Ренат Харис һәм шагыйрь Гәрәй Рәхим чыгышларын тамашачы бик җылы каршы алды.

Кичәнең икенче өлешендә Татарстан сәнгать осталары башкаруында Ә. Ерикәй шигырьләренә язылган җырлар яңгырады.

«Бу кичә башкала тамашачысының күңелендә онытылмас гүзәл хатирә булып сакланыр»,— дип яза безгә Мәскәүдән Диләфрүз Яруллина.

### ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

8 апрельдә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында «Казан утлары» журналы җитәкчелеге белән институт җитәкчелегенең очрашуы булды. Очрашуда «Казан утлары»ның эш перспективалары турында журналның баш редакторы Р. Харис, галимнәрнең соңгы еллардагы эшчәнлеге хакында институт директоры, философия фәннәре докторы профессор Я. Абдуллин чыгыш ясады.

Журнал редакциясе белән Тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни хезмәтләрне популярлаштыру буенча хезмәттәшлеге турында эшлекле сөйләшүдә сектор мөдирләре, күренекле галимнәр катнашты.

### «КАЗАН ЯЗЫ»

Республикабыз башкаласында «Казан язы» исемле әдәби бәйрәмнәр үткәрү традициягә әверелде. Быел алар март ахырында ук Сәүдә хезмәткәрләре культура йортында һәм Сәетгалиев исемендәге культура сараенда башланып китте. Бу әдәби-музыкаль кичәләрдә язучылардан Г. Ахунов, В. Нуруллин, М. Мәһдиев, М. Хөсәен, Р. Фәйзуллин, Р. Мингалим, Р. Миңнуллин, сәнгать осталарыннан З. Нурмөхәммәтов, Ш. Әхмәтҗанов, Р. Ибраһимова һәм башкалар катнашты.

* * *

18 мартта Лаеш районы Культура йортында СССР Верховный Советы депутаты, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов белән очрашу булды. Әдип татар совет әдәбиятының соңгы еллардагы казанышлары турында сөйләде, үзенең иҗат планнары белән уртаклашты, әдәбият сөючеләрнең күп санлы сорауларына җавап бирде.

## БАЛАЛАР КИТАБЫ АТНАЛЫГЫ

Һәр елны укучыларның язгы каникуллар вакытында Язучылар союзы һәм Республика китап сөючеләр җәмгыяте «Балалар китабы атналыгы» үткәрәләр. Быел да март ахырында Казанның А. Алиш исемендәге Пионерлар сараенда, 35 нче, 15 нче, 81 нче, 66 нчы, 67 нче мәктәпләрдә, 10 нчы интернат-мәктәптә яшь әдәбият сөючеләр яраткан язучылары Ш. Галиев, Ш. Рәкыйпов, В. Нуруллин, М. Скороходов, Г. Паушкин, Җ. Тәрҗеманов, М. Елизарова, Р. Миңнуллин һ. б. белән очраштылар. Зеленодольск шәһәренең 4 нче, 10 нчы мәктәпләрендә дә шундый кызыклы очрашулар оештырылды. Анда шагыйрьләр Р. Мингалим, Роберт Әхмәтҗанов, Ф. Сафин, Җ. Дәрзаманов һәм башкалар катнашты.

* *

Әлмәт шәһәрендә яшь әдәбият сөючеләр белән очрашуларны җирле язучылар оешмасы һәм шәһәрнең китап сөючеләр җәмгыяте оештырды.

22 мартта нефтьчеләрнең Культура һәм техника сараендагы «Яшь нефтьчеләр клубы»на йөрүче өлкән класс укучылары алдында чыгыш ясап, Әлмәт язучылар оешмасының җаваплы секретаре Ә. Гаффар татар әдәбиятының традицияләре һәм бүгенге торышы, нефть ягы язучыларының иҗади эшчәнлеге турында сөйләде. Кичәдә яшь шагыйрьләр Р. Рәкыйпов һәм О. Кәримова үзләренең яңа шигырьләрен укыдылар.

25 мартта шагыйрь Г. Афзалны Әлмәттәге 5 нче мәктәп пионерлары үзләренә кунакка чакырдылар. Шагыйрь укучыларны үз тормышы һәм иҗат юлы белән таныштырды, яңа әсәрләрен укыды.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Әдәби тәнкыйть секциясенең 10 марттагы утырышында «Татар поэзиясендә традицияләр һәм новаторлык проблемасы» дигән көн тәртибе тикшерелде. Бу мәсьәлә буенча филология фәннәре кандидаты, яшь тәнкыйтьче Ә. Мәхмүдов чыгыш ясады. Фикер алышуларда катнашкан тәнкыйтьчеләр Н. Юзиев, Р. Мостафин, Ф. Мусин, Х. Хәйри, Н. Хисамов, М. Гайнетдинов, З. Мәҗитов, шагыйрьләр М. Шабаев, Ә. Рәшитов поэзиябез үсешенең актуаль проблемаларына тукталдылар.

*
* *

Шагыйрьләр секциясенең 4 мартта узган утырышында «Казан утлары» журналының баш редакторы шагыйрь Ренат Харис белән очрашу булды. Поэзиянең иң актуаль жанрларына һәм соңгы еллар татар шигъриятенә багышланган бу әңгәмәдә Р. Харис үзенең кызыклы күзәтүләре белән уртаклашты, күп санлы сорауларга җаваплар биреп, иҗат планнары белән уртаклашты.

*
* *

Секциянең 14 апрелендә уздырылган утырышында филология фәннәре докторы профессор И. Г. Нигъмәтуллина соңгы елларда басылган поэмаларның үзенчәлеге турында сөйләде.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

9 нчы февральдә Әлмәт язучылар оешмасы җыелышында башлап язучы шагыйрьләр Иван Винокуров, Дмитрий Матвеев, Сарманда яшәп иҗат итүче Дамир Гарифуллин һәм очеркист Изаил Зарипов иҗаты турында сөйләшү булды. Фикер алышуларда Г. Афзал, Ә. Маликов, Ә. Гаффар, А. Хәсәнов, Р. Рәкыйпов, К. Булатова һ. б. иптәшләр катнашты.

*
* *

Әлмәт язучылар оешмасында яшь һәм башлап язучылар иҗатына зур игътибар бирелә. Әдәби алмаш белән эшләү, аларның беренче адымнарына кайгыртучан һәм таләпчән караш Г. Афзал, Р. Төхфәтуллин, Ә. Маликов, К. Булатова, Э. Мөэминова, Ш. Бикчурин кебек танылган әдипләрнең көндәлек эшләрендә чагыла.

Оешманың 6 апрельдә уздырылган гомуми утырышы яшь һәм башлап язучыларның иҗатын, беренче кулъязма китапларын тикшерүгә багышланды. В. Ларин повестьлары һәм хикәяләре, М. Нәгыймованың «Язмыш сынавы» дигән романы, В. Туктарова һәм Т. Чудинова шигырьләренә һәрьяклы бәя бирелде, әлеге кулъязмалар Татарстан китап нәшриятына тәкъдим ителде.

## РЕДАКЦИЯ КУНАГЫ

«Казан утлары» журналы редакциясендә кызыклы һәм файдалы очрашу булды: безгә кунак булып журналның авторы һәм дусты Арча районының «Искра» колхозы председателе, СССР Верховный Советы депутаты Фәйзи Галиев килде. Редакция хезмәткәрләре белән колхоз председателе арасында булган җанлы сөйләшү татар әдәбиятының һәм бүгенге колхоз авылының тормышына, уртак проблемаларына багышланды.

Очрашуда ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе, СССР Верховный Советы депутаты Г. Ахунов, Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары И. Юзеев катнашты.

## ЯЗУЧЫНЫҢ ТУГАН АВЫЛЫНДА

Февраль аенда Арча районының Яңа Сала авылында СССР Дәүләт премиясе лауреаты язучы Гомәр Бәшировның туган нигезендә яңа китапханә ачылды. Бу бәй-

рәмдә язучылар Гомәр Бәширов, Мөхәммәт Мәһдиев, шагыйрь Илдар Юзеев һәм КПССның Арча райкомы секретаре М. Л. Гыйнетдинов катнашып, әдәбият сөючеләр алдында чыгыш ясадылар.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

* * *

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен КПССның Татарстан өлкә комитетының культура бүлеге мөдире **Мөдәррис Мусинович Мусинга**, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 10 февраль Указы белән, **«РСФСРның атказанган культура работнигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы **Мөхәммәт Мәһдиевкә**, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 12 январь Указы белән, **«РСФСРның атказанган культура работнигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы һәм драматург **Илдар Юзеевка**, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 11 март Указы белән, **«РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

Совет матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен «Ялкын» журналының баш редакторы **Роза Хафизовага**, РСФСР Верховный Советы Президиумы Указы белән, **«РСФСРның атказанган культура работнигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе артисткасы **Флюра Сөләймановага**, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы белән, **«Татарстан АССРның атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты **Әнвәр Гобәйдуллинга**, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы белән, **«Татарстан АССРның халык артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет театр белгечлеге һәм театр тәнкыйте өлкәсендәге хезмәтләре өчен СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән гыйльми хезмәткәре **Ильтани Иляловага**, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 31 январь Указы белән, **«Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм 70 яшь тулу уңаеннан язучы **Әминә Бикчәнтәева** КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Почет грамотасы белән бүләкләнде.

# БАЛА БӘХЕТЕ САГЫНДА

Мәгълүм ки, зур рәссамнар бер-берсенә охшамаганнар, әмма аларны күпкырлы талантлары берләштерә. РСФСРның һәм ТАССРның халык художнигы, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Бакый Урманче таланты да, һичшиксез, әнә шулай күпкырлы. Аның бай тормыш тәҗрибәсе һәм эрудициясе бигрәк тә скульптура портретында тирән чагылыш таба. Чыннан да, бу жанр аерым образны җәмәгатьчелек биеклегенә күтәрә, аның олы кешелеклелеген, кабатланмас мәгънәгә ия булуын аңлата ала. Г. Ибраһимов, Г. Тукай, М. Җәлил портретлары һәм «Сагыш», «Язгы моңнар» кебек лирик-фәлсәфи хезмәтләр нәкъ менә шул биеклектә.

Художникның һәрбер хезмәтендә, хәтта ул зур дөньяның бәләкәй генә бер почмагы булса да, анда иҗат кешесе үзе дә шуның бер өлеше булган бөтен галәм гәүдәләнә шикелле. Беренче карашка очраклы гына булып күренгән кечкенә генә натюрморт та — бу дөньяның бер кисәге, портрет — йөзләрчә кешеләрнең йөз сызыклары, гади генә, тыныч кына пейзаж исә — күз алдына китерүе дә кыен булган киңлек, иркенлек...

Бакый Урманченың «Сара ханым белән Илдар» исемле хезмәтендә тормыш шатлыгын, аның бербөтен һәм камил булуын тоясың. Рәссам, әйтерсең лә, әкрен һәм сиздермичә, мәһабәт тынлыкны бозмыйча гына ана белән баланың серле бердәмлек дөньясына уза.

Ана түшәктә яткан сабыена таба иелгән. Аның кыяфәте бик тәэсирле: анда сакчыл игътибар да, ягымлылык та, ана кешенең иксез-чиксез тугрылыгы да бар. Ул сабые белән яңадан кушылган сыман. Шушы кушылу ана каршында нәни затның тормышы турындагы борчылулар чоңгылын, аның киләчәге турында уйлануларын, Мәңгелекнең бер кисәкчеге өчен җаваплылыгын һәм үзенең көчен кабат барлау кебек халәтләрне ачып сала.

Картинаның композицион чишелеше әйләнә-тирәнең тынлыгына ишарәли. Композиция образларның талгын ритмына корылган. Йомшак итеп тасвирланган силуэтлар, җемелдәп торган буяулар, алтынсу тон — болар барысы да үзгә бер музыка сыман лирик йогынты ясыйлар. Әнә шул рәвешчә тамашачы һич көтелмәгән салмак ритмнар һәм хисләр дөньясына барып керә.

Картинаның берникадәр эскизлылыгы, киң һәм кискен буяулар рәссамга ана серләренең сафлыгын сакларга ярдәм итәләр. Художник гадәти тормышыбыздагы гармониялелекне күреп алган һәм безгә дөньяның кешелекле рухи башлангычын ачып биргән.

**Д. САДЫЙКОВА,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның фәнни хезмәткәре.


●

Тышлыкның дүртенче битендә: рәссам Бакый ага Урманче үзенең «Язгы моңнар» дигән әсәре янында.

Р. Мансуров слайдлары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)